(Баш)
Г 27

МӘҖИТ ГАФУРИ ӘСӘРЛӘРЕ

ТАТГОСИЗДАТ
1941

Г14 | 37248

М. Гафури
әсәрләре

16/I.42	[illegible]		6-15
20/X	317	27/I 50	48
28/7	317	3/II [illegible]	7 [illegible]
[illegible]	414.	14/X 50	147.
[illegible]	[illegible]98	22/X 57	805
			803.

С(Баш
F27
Г14

МӘКТӘП СЕРИЯСЕ

МӘҖИТ ГАФУРИ

ӘСӘРЛӘРЕ

372418

56-09-6

ТАТГОСИЗДАТ
МАТУР ӘДӘБИЯТ СЕКТОРЫ
КАЗАН 1941

М. ГАФУРИ ӘСӘРЛӘРЕ

Халык шагыйре Мәҗит Гафури татар әдәбияты тарихында иң күренекле язучыларның берсе.

Ул Октябрь революциясенә кадәр Г. Тукай, Г. Камаллар белән чордаш һәм фикердәш булып иҗат иткән шагыйрь. Мәҗит Гафури 32 еллык иҗат гомерендә катлаулы юлны үтте. Аның иҗаты совет тормышы шартларында аеруча киң җәелеп үсте. Ул социалистик реализм әдәбиятын үстерүчеләр сафында актив иҗат итүче шагыйрь һәм язучы иде.

М. Гафури, иҗатының беренче чорында вак буржуа карашларының йогынтысы астында булды. Ул бу чордагы әсәрләрендә социаль мәсьәләләрне ачык итеп куймый, күбесенчә гомумән милләтне агарту, белемгә өндәү һәм кешеләрнең барсына да тигез карарга кирәклек турында яза, кайбер әсәрләрендә дини мотивлар да очраштыргалый. 1905 нче елдагы буржуаз-демократик революциядән соң инде М. Гафури иҗатында социаль-политик мотивлар ачыграк яңгырый башлыйлар. 1905 нче ел революциясе шагыйрьне рухландырып җибәрде, ул аңа тәбрикләү ерларын багышлады. Революция вакытлыча җиңелгәч, Россияне каплап алган кара реакция елларында М. Гафури тирән уйга талды һәм, реакция кара көчләренең басымына бирелеп китмичә, изелгән һәм кимсетелгән хезмәт ияләренең интересларын яклаган хәлдә, капитализм эксплоатациясенең рәхимсезлеген, «кан эчүче бүреләрнең»—алпавыт һәм капиталистларның Дәүләт Думасы ачкан булып, халыкның күзен буяуларын, алдауларын фаш итеп ерлады. Моны без «1906 нчы елдан 1907 нче елга васият», «Җиденче елның җавабы», «Бай кеше», «Бай һәм хезмәтче», «Кызганам» һ. б. күп кенә шигырьләреннән бик ачык күрәбез.

Шагыйрь патшаларга, байларга һәм аларның бөтен

иярчен этләренә каршы килешмәүчән ачу, каты нәфрәт белән чыга. Шагыйрь үзенең нәфрәтен, дошманлык хисен каты, кыю сүзләр белән әйтә.

Чәйнәп ташлар идем патшаларын,
Буып алыр идем җаннарын,
Ач этләргә өләшеп бирер идем
Итләрен һәм кызыл каннарын! —ди ул.

1914 нче елда башланган империалистик сугышка каршы М. Гафури протестын белдереп, «Фитрат заманы», «Юктырсың ла алла» һ. б. шуның кебек шигырьләрен язды. Империалистларның бу канлы сугышлары хезмәт иясе халкына зур авырлыклар, газаплар, бәхетсезлекләр китерүен шагыйрь ачык итеп әйтте.

Мәҗит Гафури Октябрь революциясенә кадәр язылган шигырьләрендә һәм хикәяләрендә хезмәт иясе халыкның моң-зарын, омтылышын, теләкләрен һәм капитализмның төрле төстәге изүләренә каршы протестларын чагылдырды. Ул демократик идеяләрне яклады һәм иң авыр моментларда да шул идеяләренә хыянәт итмәде.

Шагыйрь үзе дә моны әйтә:

Утыз ел сакладым веждан,
Утыз ел сатмадым веждан,
Шуны саклар өчен бик күп
Авырлыклар күтәрде җан.

М. Гафури өч революцияне—1905 нче елгы буржуаз-демократик революцияне, Февраль буржуаз-демократик революцияне һәм Октябрь Социалистик революцияне башыннан кичергән шагыйрь. Аның иҗаты, дөньяга карашы үскәннән үсә һәм киңәя барды.

Аның иҗат юлында каршылыклар, киртәләр дә булды. Аңа бик күп авырлыклар күтәрергә туры килде һәм ул халык алдында шагыйрьлек, гражданлык вежданын саф килеш саклап, авырлыкларны җиңеп чыкты.

М. Гафуриның 32 еллык әдәби хезмәтенең күбрәк өлеше Октябрь революциясеннән соңгы чорга, илебездә социалистик тормыш төзү чорына туры килә. Ул бөек революциянең беренче көннәреннән үк совет хөкүмәте яклы булып, бөтен иҗат көчен совет хөкүмәтен ныгытуга, илебездә шатлыклы яңа тормыш төзүгә, формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураны үстерүгә бирде. М. Гафури татар һәм башкырт совет поэзиясенең иң алдынгы вәкилләреннән берсе иде. Ул иң актуаль мәсьә-

ләләрне вактында тотып алып массага җитәрлек итеп гади, аңлаешлы итеп язды. Аның төрле газета һәм журналларда басылган, шулай ук язылып та, басылмыйча, авторның үз архивында калган шигырьләре, хикәя һәм очерклары моны бик ачык раслыйлар. Моны шушы җыентыкка кергән әсәрләреннән дә күрергә мөмкин.

«Ленинизм минем маягым!» дигән кыска гына шигырендә М. Гафури үзенең иҗатына бик дөрес бәя биреп, болай ди:

Совет яклы булдым, аңа каршы
Торган чакларда да күп халык,
Батырларча советны якларга
Кулыма каләм атлы ук алып.
Дөрес, кай чак тормыш баткагында
Тайгалады минем аягым,
Ләкин бик тиз табып алдым
Сүнмәс Ленинизм маягын!

М. Гафури безгә бай әдәби мирасын калдырды. Аның иҗаты тематик яктан да һәм жанр ягыннан да шактый киң. Ул шигырьләр язу белән бергә, хикәя һәм повестьләр, очерк һәм фельетоннар да, пьесалар да язды. Аның әнә шул бай әдәби мирасы тулысынча тупланып, киң күләмдә өйрәнелмәгән, тикшерелмәгән әле. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, гомумән бездә язучыларның әсәрләрен, кулъязмаларын җыю, туплау, архивларын булдыру һәм моңарчы басылып чыкмаган әсәрләрен бастыру, шуларны өйрәнү эше гафу ителмәслек дәрәҗәдә начар тора. Бу җитешсезлекне бетерү Татарстан Совет Язучылары Союзының һәм тел-әдәбият институтының иң якындагы бурычы. Һич шиксез, бу эшкә барлык совет җәмагатчелегенең ярдәме булырга тиеш.

М. Гафуриның бу җыентыгына әнә шул җитешсезлекне бетерүдә беренче уңышлы адым итеп карарга кирәк.

Укучылар игтибарына тәкдим ителә торган бу җыентык шагыйрьнең улы Әнвәр Гафури тарафыннан тупланган материаллар буенча төзелде. Монда кергән әсәрләрнең күпчелек өлеше бер кайда да басылмаган, М. Гафуриның кулъязмалары архивыннан табылган кайбер әсәрләре үз вактында теге я бу газета-журналларда басылып та, соңыннан шагыйрьнең җыентыкларына кермәгәннәр. Шагыйрьнең кулъязмалары әле тикшерелмәгәнлектән, җыентыктагы кайбер әсәрләрнең язылу елларын билгеләп булмады (билгеле булганнарының еллары күрсәтелделәр).

Бу җыентык М. Гафуриның моңарчы басылып чыкмаган әсәрләренең барсын да үзенең эченә ала, дип әйтеп булмый, әлбәттә. Язучының тулы архивын булдыру, барлык әсәрләрен туплау өстендә эшләү дәвам иттерелергә тиеш. Билгеле, моңа карап тулы булмаган бу җыентыкның әһәмияте кимеми. Җыентыкта оста, зур художник каләме белән язылган әсәрләр саны байтак. Алар киң укучылар массасына җиткерелергә лаеклы әсәрләр.

Бу җыентык, М. Гафури иҗатының ачылып бетмәгән якларын ачыклауда әдәбиятчыларга, аның иҗатын өйрәнүчеләргә зур ярдәм итәчәк. «Тәрҗемәи хәлем», «Исемдә калганнар», «Тукай Уфада», «1905 нче ел революциясе хакында истә калганнар» кебек истәлекләре М. Гафуриның биографиясен өйрәнергә һәм карашларын ачыграк аңларга да ярдәм итәләр. Аның биографиясен язучы иптәшләр арасында ялгыш белешмәләр бирүне хәзер дә очратырга туры килә. Хәтта М. Гафуриның туган елын 1880 нче ел урнына 1881 нче ел дип йөрүчеләр дә булгалады.

Җыентыкка кергән әсәрләрнең әдәби кыйммәте, художество эшләнеше бер дәрәҗәдә түгел. Шулай да аларның күпчелеге киң укучы массасының игтибарын үзләренә тартырлык итеп оста каләм белән язылганнар. «Юл», «Сулган чәчкә», «Адашкан», «Нигә кирәк иде», «Тарихи ун ел», «Чәчү беткәч», «Ленинизм минем маягым» һ. б. шигырьләре, «Бал корты һәм кигәвен», «Энә белән епь» кебек мәсәлләре, «Серле бер мәхәббәтнең тарихы» дигән язылып бетмәгән хикәясе һәм истәлекләре аеруча уңышлы әсәрләр. Аларда М. Гафуриның осталыгы, тирән хисле, сизгер йөрәкле шагыйрь булуы күренә.

М. Гафуриның зур поэмаларга сирәк тотынганлыгы безгә билгеле. Аның «Эшче» поэмасыннан тыш зуррак поэмасын күрсәтә алмыйбыз. Шуңа күрә булса кирәк, М. Гафури поэма язу белән кызыксынмаган, аңа игтибар бирмәгән шагыйрь, дигән карашны очратырга туры килә иде. Бу караш дөрес түгел, әлбәттә.

М. Гафуриның зур поэма тудыру өстендә җидди эшләгәнлеген аның архивындагы материаллар, шушы җыентыкка кергән «Җәннәт көткәндә» поэмасы бик ачык аңлата.

«Җәннәт көткәндә»—язылып бетмәгән поэма. Аның язылу елы хәзергә безгә билгеле түгел. Шагыйрь аны сатирик поэма итеп язарга уйлаган. Поэманың характерыннан, эчтәлегеннән шул сизелә. Язылып бетмәгән булуына карамастан, ул игтибарга алынырга хаклы әсәр.

М. Гафури бу поэмасында татар буржуазиясенең идиотлыгын, магнәсез хыялын, кабәхәтлекләрен ачып сала. «Миллион белән эш күргән», «ни теләсә шуны эшли алган», үзләрен «җәннәт кешеләре» итеп санаган Сафа, Мәхмүт байлар җәмгыятенең, «җәннәтенең» бозыклыкларын, паразитлыгын шагыйрь зур осталык белән фаш итә.

Шигырьләрнең күпчелеге теге я бу вакыйга, истәлек, тәэссөрат уңае белән язылган лирик шигырьләр, хәтта анда М. Гафуриның безгә әле моңарчы билгеле булмаган, интимный лирикасын да очратабыз. Шагыйрь аларны «үзе өчен» дип блокнотына язып барган һәм, үзе исән чакта дөньяга чыгарырга кирәкле тапмаганлыктан, күрәсең, һичбер кайда бастырмаган. Ул шигырьләре көчле хиссиятле, тирән эчтәлекле шигырьләр. Алардан без шагыйрьнең күп уйлануларын, эчке дулкынлануларын ачык сизәбез. Моны лирик шигырьләре генә түгел, «Серле бер мәхәббәтнең тарихы» хикәясендә дә күрергә мөмкин.

Җыентыкка төрле елларда язылган әсәрләр кергән. Алар шагыйрь иҗатының төрле чорын характерлыйлар. Шуңа күрә, анда шагыйрьнең карашында булып узган каршылыклар да сизелеп тора.

М. Гафури кайбер шигырьләрендә («Кайчан мин дөньяга килгәч...» һ. б.) һәм «Серле бер мәхәббәтнең тарихы» нда шәхес иреклеге, бәйсезлеге мәсьәләсе турында фикер йөртеп, моңа ачык бер җавап бирә алмыйча кала. Абстракт рәвештә власть, закон турында әйтеп, төп сәбәпне шуннан табарга уйлый, һәм, бик табигый, җавабын аннан таба алмый. Чөнки бу әсәрләрдә ул, җәмгыяттәге каршылыкларны сыйнфи көрәш күзлегеннән, социаль-политик сәбәпләр күзлегеннән карап аңлау дәрәҗәсенә күтәрелмәгән әле.

Шагыйрь мәхәббәт, дуслык, бер-береңә ярдәмләшү, хезмәтне сөю кебек кешелекнең иң яхшы сыйфатларын аеруча елылык белән ерлый. Ул, мәхәббәтнең иҗатка илһам, дәрт бирүен, шагыйрьне канатландыруын кат-кат әйтә. Ул хәтта:

> Ул канатланган фирештә, ул миңа илһам бирә,
> Мин сулып беткән булыр идем фәкат ул җан бирә

ди. Билгеле, шагыйрьнең шулай әйтергә хакы бар. Ләкин ул үзенең мәхәббәт турындагы мактау ерларында субъектив якны гына ала; абстракт, билгесез «фәрештә» кебек нәрсәләр белән чагыштырулар ясый, кайбер урыннарда,

тормыштагы конкрет җанлы образ чагыштыруыннан читләшкәләп тә куя. «Серле бер мәхәббәт тарихы» нда бирелгән мәхәббәт тә артык кабарынкы, әйтергә мөмкин булса, «серле» романтика белән сугарылган. Шулай да М. Гафуриның айнык, таза реализмы монда да өстенлек ала. Ул чын реалист язучы һәм шагыйрь. Ихтимал, шуңа күрә дә кабарынкы романтик стильдә башланган повестьләрен ахрынача язып бетермәгәндер; җыентыкка кергән язылып бетмәгән повестьләр аның реалистик каләменең бер яклы романтик стиленә капма-каршы төшүе сизелә. (Бигрәк тә матур башланган, кызганычка каршы язылып бетмәгән, тирән хисле «Серле бер мәхәббәт» не укып карагыз.)

«Хокуксызлар», «Гармон тавышы», «Йөзгә-йөз каршы килгәндә», «Денщик Мәхмүт» хикәяләре реалистик әсәрләр; алар реалистик буяуларга, образларга шактый бай әсәрләр.

М. Гафури гүзәллек, матурлык каршында баш ия. Ул рухи бөтенлекне, эчке һәм тышкы гүзәллекне яклый. Революциягә кадәр язган шигырьләрендә бу мотивлар бик үк төгәл, ачык яңгырамаган булсалар, революциядән соңгы әсәрләрендә ул тулырак, ачыграк янгырый. Шагыйрь инде бәхетнең, мәхәббәтнең, чын рәхәтнең тормышта конкрет көрәш, хәрәкәт, социаль көчләр белән аерылгысыз бәйле булуын аңлый.

Чын бәхетләр эзләп йөрүчегә
Тыныч җәннәт бәхте кечкенә.
Җанга азык биргән иң зур бәхет,
Иң зур рәхәт мәгәр эш кенә.

Ни кызык бар коры матурлыкта
Төрле-төрле эшләр булмагач,
Завод, фабриклары кычкырышып,
Эшчеләре кайнап тормагач,—

ди шагыйрь.

Социалистик илебезнең гигант төзелешләре, заводларның һәм колхозларның уңышлары, социалистик милли республикаларның хуҗалык һәм культуралары чәчәк атуы—барсы да М. Гафурине рухландыралар һәм ул, барлык иҗат көчен биреп, гомеренең соңгы көненә кадәр иҗат итә. Ул «иске кием кебек, ызан белән ямау салмаган» киң басуларны, совхоз һәм колхоз басуларын күреп шатлык белән ерлый. Аерым хуҗалыклы крестьяннарне кумәкләшергә, колхозга берләшергә өнди. Ялгыз, маяк-

сыз, перспективасыз тормышның авырлыгын әйтеп, «Адашкан» кебек матур шигырьләрен яза.

Буран һаман уйный, һаман гөжли,
Чокыр-чакырларны тигезли...

Ялгыз юлчы буран дулкыннары
Уртасында карга күмелде...
Ялгыз юлчы шулай адаша...
Маяксыз юл белән киткән кеше
Һәләк була... үзен кар баса.

Нинди матур, мәгнәле, үткен чагыштыру ясалган юллар! Аларны М. Гафури шигырьләреннән бик күп табарга мөмкин.

Югарыда күргәнебезчә, М. Гафури шагыйрь дә, прозаик та. Аның «Фәкыйрлек белән үткән тереклек» хикәясе, «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Тормыш баскычлары» һәм шушы җыентыкка кергән прозаик әсәрләре М. Гафуриның прозага да нинди зур әһәмият биреп иҗат иткәнен, аның талантының киңлеген бик ачык күрсәтәләр. Моңарчы әле безнең әдәбиятчыларыбыз аны шагыйрь булу ягыннан күбрәк өйрәнәләр, аның прозасы икенче планга рак куелып каралып килә иде. Бу, билгеле, М. Гафури прозасына җитәрлек әһәмият бирмәүдән, аның үзенчәлекле прозаик булуын күрә белмәүдән килеп чыккан хәл. М. Гафуриның прозасы киңрәк өйрәнелергә тиеш. Моңа шушы җыентыкта тупланган прозаик әсәрләре дә ярдәм итәрләр, дип уйлыйбыз.

Кыска гына бу мәкаләдә М. Гафуриның бөтен иҗатына яки җыентыкка кергән барлык әсәрләренә анализ бирү максаты куелмады. Безнең бурыч—шагыйрьнең иҗат мирасын тулырак туплау эшенең әһәмиятен әйтеп, җыентыкның укучы массасы өчен кыйммәтен, кирәклеген билгеләү булды.

Хәсән Хәйри.

ШИГЫРЬЛӘР

I

1909

...ГӘ БАГЫШЛАП

Кәндеңә[1] кәндем әсир һәм гыйшкыңа калбем мәдар[2],
Ошбу көн кәндем мәет сандым, дәхи булмәм мәзар.
Аһ-зарым, йөздә сарым дагвамә кафи[3] бәнем,
Гыйшка янып гөл кебек сулган бу көндә ак тәнем.
Дахил итте[4] бу гыйшык мине әсарәт тәхтенә[5],
Корбан булсам ни зарар бар син мәләкнең[6] бәхтенә...
Син яшә мәсгут булып, артык хәятны эстәмәм,
Дөньядан аерыр мине шиксез-хисапсыз хәзне-гам[7].
Дәрдемә дәрман висален[8], әмма бу бер юк хыял,
Безләрн җыймас фәләк[9], чөнки бу әмри мөхаль.
Шөбһә юктыр, бу җанымның аслы синнән бер кисәк,
Мин ничек синсез торырмын, без асылда бер исәк!..

БАКЧАДА

Бүген әллә нигә мәхзүн[10] күңелләр,
Минем күңлемне ачмыйлар бу гөлләр.
Матур хур кызлары алдында торса
Мине мәсгут итәр төсле түгелләр.

Нигә күп сайрашасыз сандугачлар?..
Сезне шатландырамы бу агачлар?

---

[1] Кәндеңә — үзеңә.
[2] Калбем мәдар — күңлем бәйле.
[3] Дагвамә кафи — дагвамне раслау өчен шул гына да җитә.
[4] Дахил итте — кертте.
[5] Әсарәт тәхтенә — коллык астына, тоткынлыкка.
[6] Мәләк — фәрештә.
[7] Хәзне-гам — кайгы-хәсрәт.
[8] Висалең — юлыгуың, ирешүең.
[9] Фәләк — язмыш.
[10] Мәхзүн — күңелсез.

Сезне дә юкса мәфтүн[1] итәләрме?
Зифа буйлы матурлар, кара чәчләр?..

Алай түгел, мәхәббәт башка-башка,
Алар гашыйк чәчәк берлән агачка,
Мине мәфтүн итеп торган матурның
Чәчәк тик кадере юктыр сандугачка.

Яратмак бер вә ләкин юллары күп,
Берәүнең дошманы башкага мәхбүб[2].
Кеше шелтәсе кар итмәс кешегә,
Әгәр булса гашыйк чын гыйшка мәнсүп[3].

Кешенең үзенә үз хәсрәте зур,
Димә аны хәкыйр[4], бичара һәм хур,
Мәхәббәт—мәҗбүри булган бер эш ул,
Мәхәббәт әһле мәхзүн һәм дә магрур.

ВАФАСЫЗ ГАШЫЙК

Ни вакыт күрсәң дә ул башын түбән бөккән була,
Сызлана аһ-ваһ итә, күздән яшен түккән була.
Ни сәбәптәндер, бичара... дөньядан кул селтәгән,
Өмедени өзгәндер инде файда юк, дип шелтәдән,
Дөньяда һәр нәрсәгә нәфрәт күзе берлән бага,
Илтиҗа[5] кылган кебек ул инде ялгыз аллага.
Вакты берлән ул матур сөйгән, сөелгән иде,
Һәммә эштән ләззәт алган, уйнаган, көлгән иде.
Тик бу көндә калган ул сөйгән ярыннан айрылып,
Аһ, вафасыз!.. ди, минут саен гыйшык берлән янып.
Магшукы чыннан югалган, инде тик төштә күрә,
Тик хыял, өмид берлән янган йөрәген сүндерә.
Ул һаман сөя аны, ләкин ачу катыш сөя,
Шул мәхәббәт алдына барып һаман да баш ия.
Кайда ул үткән матурлык, йөзләре сулган аның,
Капкара матур күзенә яшьләре тулган аның.
Инде белдек бу гашыйкның ни өчен яшь түккәнең,
Кайгыда көн иткәнен, һич күрмичә ләззәт тәмен...

---

[1] Мәфтүн — үз йогынтысына алу, буйсындыру.
[2] Мәхбүб — сөелүче.
[3] Чын гыйшка мәнсүп — чын күңленнән сөюче булса.
[4] Хәкыйр — кимсетелгән.
[5] Илтиҗа — сыену.

1913

КӨЗНЕҢ СОҢЫ

Кырау төшеп бөтен җирне агартыр,
Күңелсезлек бөтен мәхлуктә артыр.
Җитә дип ошбу җирдә карлы кышлар,
Елы якка очалар барча кошлар.
Коеп яфракларын җөмлә агачлар,
Китәр ташлап боларны сандугачлар;
Бу мескеннәр калырлар һеп ялангач,
Бетеп яфрак коры агачка калгач.
Фәкыйр, бер нәрсәсез калыр басулар,
Туңа башлар бу көндә барча сулар.

* * *

Авырлык, ярлылык кай җирдә булса, мин дә шул якта,
Булырмын вөҗданымның зур теләгеп биргән шул чакта.

УФА САХРАЛАРЫ

Кайда китте, дускайларым, күңел хушлар,
Сахрага чыга идек барча дуслар.
Бер сәбәпле хатеремез мәхзун булса,
Күңелне ачар иде төрле кошлар.
Бөйлә матур төрле чәчәк үскән ничек,
Төрле тараф башын бора җилләр исеп;
Күз салсаң, ал-кызыллы мәнзарасы[1]
Хыянәтсез саф күңелне китә кичеп.
Төрлесеннән чыгып тора төрле исләр,
Багзесенә асылынган ал җимешләр,
Сират кичеп фирдәвестә утыргандай,
Шат уларак утырамыз без дус-ишләр.
Уфа, Кырым сахралары фирдәвестәй,
Монда йөрсәң бар кайгылар искә төшмәй;
Һавасы саф; сырхауларга шифа була,
Сулары агып ята саф көмештәй.
Болыт юк, һавалар саф, көннәр тымык,
Яфрак илә өретелгән яшел чыбык;
Төрле-төрле яшел, кызыл үләннәргә.
Рух кертә, нурлы кояш балкып чыгып.

[1] Мәнзарә — күренеш.

Идел буе һәр төрле агачлар бар,
Җәннәт кебек, агач асты аккан әнһар[1].
Чык төшкән чәчәкләргә кояш чыгып,
Җир өстендә пәйда була төрле нурлар.
Каек берлә суда йөрсәң ишкәк ишеп,
Шатлыклары җаннарыңнан китә кичеп;
Яз булса, кәсбе һава кыйлып ята,
Мәскәү, Казан таләбәсе, кымыз эчеп.
Идел буе, биек ярның башларында,
Утырамыз көндез агач асларында;
Арлы-бирле төрле балык йөзеп тора,
Кызлар кебек, унҗиде яшьләрендә.
Кич булса, бу урынга төшә чыклар,
Сирәк-сирәк селкенәдер яшь чыбыклар;
Бу сыйфатлы җөзьи җәннәт[2] урыннарда,
Җанлы бәндә, гафил ятып, ничек йоклар?
Яфракның арасында сандугачлар,
Берсеннән соң сайрарга берсе башлар.
Сандугачның тавышлары тәэсир итеп,
Җилсез вакыт селкенәдер яшь агачлар.

1917

ЮЛ

Тапмадым мин дөньяда икнаг[3] итәрлек бер ысул,
Һәммә суллар миннән ундыр, чөнки мин сулдан да сул.
Мин шуңар мәнсүп түгел һичбер сәяси фиркагә,
Әллә нинди мәсьүлият йөкләмим дип җилкәгә.
Мин бара алмыйм бәндәләр салган вә сызган юл белән,
Чикләнә алмыйм һич вакыт тәртип, низам, канун белән.
Һич тә тәхдирсез[4] вә чиксез хөрриятне мин сөям,
Шундый голвиятне[5] эзлим һәм шуңарга җилкенәм.

---

[1] Әнһар — агым сулар, дәрьялар.
[2] Җөзьи җәннәт — оҗмахның бер почмагы шикелле.
[3] Икнаг итәрлек — канәгатьләндерерлек.
[4] Тәхдирсез — буйсынусыз, баш идерүсез.
[5] Голвият — бөеклек.

* * *

Кешеләр берсе-берсен яманлаша,
Иптәше иптәшенең гаебен ача,
Хәкыйкат эш күрә алмый бу дөньяда,
Эш күрә: кода-кодагый һәм кодача.
Ничә әйтсәң дә бу халыкның холкы бик тар,
Голвият юк һичберсендә, тик ваклык бар,
Сайлап-сайлап тугрылыкны таба алмыйм,
Аһ, туганнар, эшләр начар, эшләр начар!..
Нигә болай, әллә, дуслар, мин ахмакмы?..
Әлә чынлап та бу кешеләр бик вакмы?..
Күп эзлимен инсаният дөньясыннан —
Ләкин һичбер таба алмыймын хәкыйкатне.

* * *

Гомернең чәчкәсе сулды,
Йөреп вак тормыш артыннан.
Бөтен кечләр тәләф[1] булды,
Йөреп юк-бар эш артыннан.
Торып пычрак мөхиттә
Керләнеп һәм пычранып беттем,
Җитәм дип изге максатка
Йөри торгач, арып беттем.

САЗ

Уйнама сазың, рәнҗетмә җаным,
Күрмәсен дөнья аһ вә әфганем[2].
Сазыңны уйнап яндырма, туган,
Аннан башка да янадыр бу җан.
Искә төшермә үткән гомерне,
Сазыңны сызма, көйләрне сузма,
Моң-зар эчендә торам ансыз да.
Уйна сазыңны әнә син анда,
Моңлан вә сызлан мин юк урында.

---

[1] Тәләф булу — һәлак булу, бетү.
[2] Әфган — зар, сагыш.

1919

КӨТМӘГӘНДӘ!..

Көтмәгән чакта килеп кергәч җаным
Аптырап киттем, ниһаят каушадым...
Шатлыгымнан әллә нишләп калтырыйм,
Сүз табалмыйм, гел генә юк-бар сорыйм:
— «Кайда бардың? Тышта бик салкынмы?» дим.
«Балдагың бигрәк матур!.. Алтынмы? дим.
«Син йөрергә аш ашап чыктыңмы?» дим,
«Беркөн алган алтын алкаң шулмы?» дим.
Магнәсез һәм дә җилемсез сүзләрем,
Чөнки анда уй, фикер һәм күзләрем.
Сокланып кат-кат карыйм аппак битен,
Каушавымнан онытамын сүз тәртибен.
Сөйгәнемне аңлатам тик сүз белә,
Ул шуны аңлап матур, кызарып көлә.
Ул шулай көлсә хуш исләр бөркелә,
Күзләреннән серле нурлар сирпелә.
Шул ике нәрсә белән исрек булам,
Зур гаепле бәндә төсле тотлыгам.
Ул чыгып киткәч алам иркен солу,
Эчтән уйлыйм: «Эх, матур соң! Эх, сылу!..»
Күргәнемне уйлыймын да шатланам,
Киткәнен уйлап кызу утта янам.
Күңлемә ул нурлы шәм кабызып китә,
Төн буе балкып янарга шул җитә...

ИМЛА

(...гә)

Ни генә язсам мәхәббәт тугрисында ер белән,
Һәммәсен яздым аларның синнән алган нур белән.
Мин сине күргән вакытта күзләрең явдырды нур,
Ошбу нурлардан тезелде бер рәткә ошбу ер.
Әйтмәдең син ошбу ерларның берен дә сүз белән,
Имла иттердең аларны шул ике зур күз белән.
Сүз дә юктыр, ошбу ерлар бик матур һәм бик дөрес,
Чөнки бу эшләр синең әмрең белән эшләнгән эш...

КӨЛДЕ

Күрәм: җаным бүген нинди күңелле!..
Матурланган яңаклар аллы-гөлле.
Матурлык өстенә артты матурлык,
Качан ки шатланып елмайды көлде:
Кызыл гөл төсле ирне уртасыннан
Тезелгән энҗедәй тешләр күренде.
Матурлык нурларын чәчте битеннән,
Гүяки ул шушы нурга күмелде.
Гыйшык берлән авырган назлы җаным,
Аның шул көлгәнен күргәч терелде...

БАРЧАСЫННАН СИН МАТУР

Күккә бактым: ай, кояш һәм төнге йолдызлар матур,
Җиргә бактым: монда йөргән хур кебек кызлар матур.
Ул болыннарда чәчәкләр берсе-берсеннән матур,
Бу саналган нәрсәләрнең һәммәсеннән син матур.
Син зоһур[1] итсәң әгәр дә бер вакытта каршыма,
Ай, кояш, йолдыз вә кызлар онтылалар барсы да!..

ЯҢА ТАНЫШЫМ

Мин, кояштан качкан ярканаттай,
Качтым, бер вакытта, сөюдән,
Гаһед[2] иттем һичкемне сөймәскә,
Сакландым мин янып, көюдән.
Гыйшык керсә күңлем ишегеннән
Тәрәзәсеннән куып чыгардым,
Шушы кылган гаһедем, тоткан юлым
Белән ничә еллар мин бардым.
Былбыл кебек моңлы янган йөрәк
Назлы чәчкәләргә кунмады,
Әллә кемне көтте, сайрый-сайрый,
Ләкин көткән өмет булмады.
Шулай йөрдем ничә еллар буе,
Ялгыз булдым, ялгыз ерладым,

---

[1] Зоһур итсәң — килеп чыксаң.
[2] Гаһед — Ант, вагдә

Әкрен-әкрен сүнгәнсымак булды
Балкып янган күңел нурларым...
Бер вакытта күреп бер матурны,
Кыйлдым ак йөзләрен тамаша,
Бите ал-кызыллы чәчкә кебек,
Күргән вакыт күзләр камаша.
«Аны» күрү белән, моңлы былбыл,
Шатлыгыннан сызып сайрады,
Балкып торган гөлләр арасыннан
Шушы матур гөлне сайлады.
Шунда минем сүнәр-сүнмәс нурым
Балкып китте, кире кабынды,
Моңлы былбыл, төшеп үз тәхтеннән,
Шул матурга барып табынды.
Рухландым шунда, күңелем нуры
Гареш агләләргә сузылды,
Шул минуттан башлап «һич кешене
Сөймәм» дигән гаһедем бозылды...

37248

ГАҖӘП ЭШ

Бик гаҗәп эш!.. Мин кичә кичкә таба кайтып килэм.
Шунда алдымда янып, балкып торучы нур күрәм.
Ошбу нур — кояш нуры дисәм, кояш баткан вакыт,
Ай дип әйтсәң, бу түгелдер тулган ай калыккан вакыт.
Соңра белдем ошбу нурның ник вә кайдан килгәнен:
Нак шушы чакта урамга чыккан икән сөйгәнем.

МИҢ

Синең аппак йөзең өстендәге шул кечкенә миңне
Күрәм дә, тулган айның бер эшен уйлап көләм инде.
Менә ул эш ничек булган: сиңа айның күзе төшкән,
Синең матурлыгың күргәч, эче янган вә көнләшкән.
Күрә ул шунда—син айның үзеннән күп өлеш нурлы,
Битендәге шушы миңгә сагәтләрчә карап торды.
Бераз торгач та магрур ай: «Бу йөздән киммени мин...» ди,
«Фәкать үз йөземә сөртим шуның төсле матур миңне»—
Диде дә ак нуры өстенә аз-азлап кара сөртте,
Гүяки ул синең төсле булам дип, битенә миң төртте.
Менә нак шул вакыттан бирле калды ай йөзендә тап,
Аның йөзендәге таплар минем сүзне кыла исбат.

Кытапханәсе

Хәзер ул ай сине күрсә, оялып битенә болыт каплый.
Болытлар булмаса, төннәр буе җир өстенә калыкмый...

ШӘҮЛӘСЕ

Биш көн инде күргәнем юк сөйгәнемнең гәүдәсен,
Тик хыял берлән күрәм нурдан гыйбарәт шәүләсен.
Шәүләсе алдымда баскан нак илаһи бер санәм[1],
Шул сурәт алдында табынып шатланам, ләззәт алам.
Мин шулай тагзим итәм[2] бит сөйгәнемнең шәүләсен,
Нәрсә эшләрмен әгәр күрсәм аның чын гәүдәсен?..

«УЛ»

Ай кебек йөз, кап-кара күз, ал-кызыл йомшак яңак,
Энҗедәй теш, ул матур түш, ул муеннар—сөттән ак.
Гөл кебек, бигрәк килешле, кып-кызыл йомшак ирен,
Җан керер җансыз кешегә бер тигезсә төкреген.
Кап-кара һәм сап-сары түгел чәче, тик уртача,
Магнәви бер җанлы төсле, күрдисәң күңлең ача.
Бар матурлыклар җыелган ошбу биттә, шөбһәсез,
«Берәү бар, һич охшашы юктыр... »дип әйтсәң бетте сүз.

БЕР ГАШЫЙКНЫҢ СҮЗЛӘРЕ

Мин аның алдында чакта бер минут итмим әрәм:
Һәр эшен, һәрбер төшен бер-бер күземнән үткәрәм.
Моңлы булса, мин дә моңлы, шат икән «ул»—мин дә шат,
Мин аның алдында чакта җөмлә хәсрәттән азат.
Тешләрен бер күрсәтеп көлсә тирә-як яктыра.
Ул көлә, көлгән саен ул бер матурлык арттыра.
Чын матурлык мәнбәгы[3] ул, чын мәхәббәт чишмәсе.
Җиргә яңлышлык белән төшкән бер оҗмах чәчкәсе,

Көндезем төннән караңгы ул янымда булмаса,
Күкрәгемдә ут та янмый ул көлеп яндырмаса.
Ул мәләкне күрми калган көнләре ауру булам,
Мин аңар йөгерәм, күрим дип, канлы багрем сызласа.

---

[1] Санәм — һәйкәл, статуя.
[2] Тәгзим итү — олылау, хөрмәтләү.
[3] Мәнбәг — чыганак.

Әйләнәмне каплап алган кап-караңгы бер болыт,
Өстемә якты төшерми ул«кояш» яктыртмаса.
Кай вакыт хәсрәт йозагы берлә күңелем бикләнә,
Шул йозакны гөл кебек керпек белән тик ул ача.
Моңлы күңлем өстенә ул күз нурын яудырдисә
Шатланам мин; шатлыгымнан җан янып күккә аша.
Гөл битеннән бер генә үпсәм кызу ирнем белән,
Бар вежүдемне илаһи бер мөкатдәс нур баса.
Авызы кәүсәр, төкереге абөлхәяттан[1] тәмлерәк,
Тик шуның берлән генә үлми тора янган йөрәк.

Бу шигырьләрне язам мин моңланып һәм шатланып,
Шул сөеклемнең ике зур күзләреннән нур алып.
Энҗеләр эзләп чумарга ул гына тик юл ача,
Бу шигырьнең бер юлы булмас иде ул булмаса.
Ул канатланган фирештә, ул миңа илһам бирә,
Мин сулып беткән булыр идем, фәкат ул җан бирә.

ЧӘЧЕ

Җансыз ул чәч, ул бирелгән шул матурның иркенә,
Ул матур селкенсә гөлдәй, ошбу чәч тә селкенә.
Кай вакытта ул матурлый шул матурның аркасын,
Беразы яшереп тора бәрхәт колак һәм алкасын.
Кай вакыт сүтелеп төшә дә ал яңаклар өстенә,
Ал-кызыл гөлдәй яңакларның бераз урнын күмә.

СУЛГАН ЧӘЧКӘ

Бер вакыт мин кереп зур бакчага
Чәчкәләрне кыйлдым тамаша,
Төрле төстә, төрле чәчкәләрне
Күреп шунда күзем камаша.
Ал, кызыл, ак, сары, көрән, зәңгәр—
Тезелгәннәр ниндәен матур!..
Гүя күктән монда сибелгәннәр,
Биреп торыр өчен җиргә нур.
Күзнең явын алып тора болар,
Әйтерсең лә җәннәт бакчасы,
Бигрәк матур шунда бер чәчкә бар,
Нак бу чәчкәләрнең патшасы.

---

[1] Абөлхәят — тереклек суы.

Бал кортлары йөри шул тирәдә,
Кунар-кунмас кына борылып,
Назлы чәчкә шунда өрелеп тора,
Очып китәр төсле нур булып.
Сандугачлар сайрый шуңа карап,
Төн буенча күзен йоммыйча,
Аның яннан үткән күбәләкләр
Китә алмыйлар аңа кунмыйча.
Хәйран булып мин дә карап тордым:
Шушы икән дип, күңел бизәге.
Кызарган ул янып көнгә каршы,
Нак гашыйкның янган йөрәге.
Уйладым мин шунда: шул чәчкәне
Күкрәгемә алып кадарга,
Әрәм итәр төсле булдым да мин,
Кыя алмадым кулым сузарга.
Үзем киттем, ләкин ике күзем
Калды шул чәчкәгә бәйләнеп,
Шул чәчкәне тагын бер күрим дип,
Өч көннән соң килдем әйләнеп.
Ни күз белән күрим!.. Ул чәчкәнең
Сабагы бар, үзе өзелгән,
«Кайсы явыз куллар өзде икән?» дип,
Яшь тәгәрәп чыкты күземнән.
Башым түбән төште, җиргә бактым,
Кергән кебек булдым зинданга,
Ни күз белән күрим, шул чәчкәне
Кемдер ташлап киткән тузанга.
Җирдән алып бик тиз, карыйм аңа,
Күрәм, җансыз кебек булган ул,
Кызыллыгы бетеп, төсе киткән,
Җирдә ята-ята тулган ул.
Их, кызганыч, нинди чәчкә сулган!..
Сулдырды икән моны кем кулы?
Кая киткән, төннәр буе сайрап,
Моны мактап торган былбылы?..
Кая киткән моның күргәннәрне
Сокландырган нурлы чаклары?..
Минем шигырем мәүзуг булган
Ул илаһи серле чаклары?..
Сизми калдым шунда, бу дөньяга
Лагнәт әйткәнемне кычкырып.
Бу чәчкәне шунда салып куйдым
Хәтер дәфтәренә кыстырып.

Ошбу сулган чәчкә бу көнгәчә
Елы күкрәгемдә саклана,
Һичкем белми торган ошбу серләр
Назлы йөрәгемдә саклана.

1921

* * *

Картайдыра дөнья, картайдыра, акырынлап хәлдән
тайдыра,
Колач җәеп алда үлем тора, күңел шуны уйлап кайгыра.
Төн ягыннан җилләр искән саен, гомер яфраклары шаулаша,
Кайберәүсе шунда өзелеп төшә, төшү белән аны ком баса.
Кайберәүсе шунда чак-чак тора, көтә соңгы минут
җиткәнен,
Җилбер-җилбер килеп сөйли шунда матур җәйге көннең
үткәнен.
Кай вакытта бердәм шаулашалар ачуланган ачы җил белән.
Ерлашалар шунда кайгы ерын җан кисәрдәй ачы тел белән.
Исәр тагы ачы, салкын җилләр, коелырлар болар һәммәсе,
Шулар белән бергә җиргә сеңәр хәсрәт белән аккан күз яше.

ШАТЛЫК БЕЛӘН ХӘСРӘТ

Шатлык белән хәсрәт—болар икәү игезләр.
Төскә, буйга башкалар, буйга, сынга тигезләр.
Кайда гына барсаң да берсе йөрер янында,
Хәсрәт китәр читкәрәк шатлык килгән чагында.
Хәсрәт читкә китсә дә, озак тормас, тиз килер,
Хәсрәт килеп җитүгә, шатлык артка чигенер.
Шушы ике нәрсәнең арасында гомергә
Йөри торгач сыкыранып, керерсең син кабергә.

1922

* * *

Гомерем бинасына менеп барам,
Үтте инде көчле чакларым.
Авыр газап, төрле хәсрәт белән
Кырык ике баскыч атладым.

Һәр атлаган саен уң вә сулда
Күреп үттем тирән чокырлар.
Бу чокырлар хәрап, төбе тирән...
. . . .

1923

* * *

Кырым, Кырым диләр иде, Кырымны да күрдем мин,
Кара диңгез буйларында ерлар ерлап йөрдем мин.
Кырым, Кырым диләр иде Кырымнары шушы икән,
Үзе матур, җире ямьле, һавалары хуш икән.
Диңгез, диңгез диләр иде, диңгез бик матур икән...

1926

АДАШКАН

Киң кырдагы чиксез кар диңгезе
Уртасында, каты буранда,
Ялгыз юлчы, юлдан адашкан да
Тик бер үзе шунда калган да
Юл эзләнеп йөри, әрле-бирле,
Тирән карга батып биленнән.
Баш әйләнгән, күзләр пәрдәләнгән,
Чыга алмый баткан җиреннән...
Выж-выж искән усал, салкын җилләр
Кар буранын куып уйната,
Өйрелдереп сугып төрле яктан
Юлчы мескенкәйне кыйната...
Авар-аумас торган гәүдәсенә
Төрле яктан килеп кар сыра...
Туңган иреннәрен чак-чак ачып,
Ярдәм сорап:—Ааа... ааа..!—кычкыра...
Тавышы чыгу белән авызыннан
Шәп җилләргә кушылып югала...
Хәлсезләнә юлчы, чак тын ала,
Көче бетә, чак кузгала...
— Әх, юл тапсам... җәйсә очыратсам
Мона шунда гына бер кибән!..
Дип әйткәч тә авызы йозакланды...
Ауды тирән карга йөз түбән...
Буран һаман уйный, һаман гөжли,

Чокыр-чакырларны тигезли...
Ялгыз юлчы, буран тулкыннары
Уртасында, карга күмелде...
Ялгыз тормыш ничек авыр булса,
Ялгыз юлчы шулай адаша...
Маяксыз юл белән киткән кеше
Һәлак була... үзен кар баса.

НИГӘ КИРӘК ИДЕ...

Миңа ник ачарга кирәк иде
Кешеләрнең мәҗрух[1] йөрәген...
Миңа ник карарга кирәк иде
Мазлумнарның[2] моңлы күкрәген...

Ник йөрмәскә иде башкалардай
Үзем өчен генә ау корып,
Һәрбер эштән үземә файда уйлап,
Мәгәр үзем өчен кайгырып...

Шәп булачак икән кешеләрнең
Эчке серләренә бакмасам...
Мин аларның кайнар йөрәк маен
Үз йөрәгемә китереп якмасам.

Йөген тарталмаган, арган атка
Чаклы карап торгач, кызганып,
Ничек рәхәт үтсен минем гомер,
Һәр вакытта торгач сызланып...

1927

СУКЫРЛАР

I

Һәр көн очрыймын мин берничә рәт
Урамнарда йөргән чагымда...
Тома күзсез булган сукырларга...
Бүген берсен күрдем тагын да:
Һәрбер басар җирен алдан эзләп,
Җиргә бәреп бара таягын...
Адым саен уйлап... Иплэп кенә,
Саклык белән баса аягын...

---

[1] **Мәҗрух** — яралы.
[2] **Мазлум** — җәберләнүче.

Колак салып, бераз тыңлап тора
Һәрбер күпер, һәрбер чат саен...
Әллә нинди авыр хисләр белән
Уйга калып, жыера маңлаен...
Ах... күрсәңче шунда бер генә рәт
Каршы яктан кемнәр килгәнен...
Балкып торган кояш нурларында
Матур хатын-кызлар йөргәнен ..
Бер күрсәңче'.. Төрле чәчкәләрнең
Емь-емь иткән төрле төсләрен...
Күккә чыгып торган тау башларын...
Күзге кебек Идел өсләрен...
Бер күрсәче!.. хатын, баласының
Нинди төстә икән йөзләре ..
Юк!.. Бу матурлыкларны күрүдән
Мәңге мәхрүм аның күзләре...
Аппак яры белән пәрдәләнгән
Күзләренә кара... Бер кара!..
Нинди авыр моңнар, авыр уйлар
Белән капланган ул, бичара!..
Йөзе кара[1] аның!... Аның йөзе
Мәңге уйга баткан төследер...
Шуннан аңла!.. Аның йөрәгендә
Кайгы-хәсрәт нинди көчледер...

II

Бүген мин, шул сукыр кебек булып,
Күзне йомып йөреп карадым...
Таяк белән, алдан җиргә сугып,
Тик бара алдым берничә адым.
Белмим кайсы якка барырга да,
Белмим кайсы җиргә басарга...
Күрмим каршы яктан кемнәр килә...
Мәҗбүр булдым күзне ачарга...
Ә, бит теге сукыр, мескен сукыр...
Мәҗбүр мәңге шулай йөрергә...
Зар-интизар бит ул гомер буе
Бер генә рәт якты күрергә...
Сукырларның эчке моңнарыны
Чынлап тасвир өчен җитми көч...
Авырлыкның яздым меңнән берен.
Ярдәм итеп-итмәү сезнең эш...

---

[1] КаранГЫ магнәсендә.

ҮЗБӘКСТАН СӘНАИГ НӘФИСӘСЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧЛАРЫНА

Килгәнсез кунак булып безнең илгә,
Сез күптән якын безнең күңлебезгә...
Былбыл кебек, моңлы сайрап бераз гына
Безләрне ташлап китә торган көзгә...
Шәрыкның күп заманнан килгән моңын
Сәхнәдә күрсәттегез бүген безгә.
Советның биргән ирке аркасында,
Юл чыкты сезнең белән күрешергә...
Моннан соң мәңге-мәңге насыйп булсын
Бер-беребезгә кунак булып йөрешергә.
Чия кызыл байракларны кулга тотып,
Теләгән теләкләргә ирешергә...
Безне изгән империалистларга каршы
Барыбыз бердәм булып көрәшергә.
Шәрыкнең зур байлыгын, матурлыгын
Сәнагәт, фән-белемгә кушып биргә...
Асманда[1] очкан данлы шонкар кебек,
Очарбыз карга, козгын җитмәс җиргә.
Тамара ханым, Кари Якуп белән
Бергә килгән аркадашлар—һәммәгезгә
Зур Уралның киң күңелле баласыннан
Чын ихлас, хөрмәт белән сәлам сезгә.

1929

* * *

Ленин иптәш... дисәм, хөрмәтсезлек
Күрсәтелгән кебек була да,—
Искә төшкән саен, хөрмәт итеп:
— Ленин ага... дидем мин аңа.
Яшькә зурлык ягыннан карасаң,
Исәпсез күп безнең агалар.
Ләкин алар Ленин ага янында
Тик бер шәүлә булып калалар...

ТАРИХИ УН ЕЛ

Ун ел—тарихның бер өземтәсе,
Ун ел—тик ул балалар яше.

[1] Асман — күк йөзе.

Ә шунда да кайбер «ун еллар» ның
Мең елда да үтми тиңдәше.
Кайбер йөзләр томанлы төннәргә
Кереп, караңгыда югала.
Уяу көрәш белән үткән еллар
Берәм-берәм аерым санала...
Канлы эзләр генә калдырганнар
Үткән йөзләр безнең күңелдә.
Сөйләнәләр шомлы тарихларга
Чик бирелгән бәйрәм көнендә...
Урал җанлы булса сөйләр иде
Үз башыннан ниләр узганын
Кешеләрнең бер-берсенә дошман
Булып, берсе берсен кырганын...
Йөрәк яргыч, ямсез күрнешләрне
Мең елларча карап торганын...
Әмма сөйли алмас иде безгә:
Элек «Башкыртстан» булганын.
Сөйләр иде: ирек өчен булган
Канлы көрәшләрне күргәнен,
Кукрәгендә үскән эшчәннәрнең
Дошманнарын ничек җиңгәнен...
Азатлыкка юллар ачар өчен,
Кылычларын айкап йөргәнен,
Җиңү ерын ерлап, дошманнарның
Уртасына барып кергәнен...
Тыңла, Урал, хәзер күңелләнеп,
Яңа дәртләр белән янасың,
Эшчән балаларың белән бергә
Кешелек дөньясына барасың.
Сиңа каршы торган кара көчне
Тотып, аяк-кулын бәйләдең.
Котлы булсын азатлыкка чыккан
Шушы ун еллык зур бәйрәмең!..

* * *

Бак урамга, анда нинди шәп тузан,
Мин бүген чыкмыйм урамга куркудан.
Мин урамга бу сагәт чыксам әгәр,
Шул тузанга манчылыр бит үпкәләр.
Шул минутта башланыр көһ-көһ ютәл,
Язмыйм инде артыгын—шунда җитәр.

II

КЕШЕЛӘР[1]

Барма якын, багзесе тартыр сине эскәк кебек,
Багзесе ертыр тәнеңне, гүя чәнечкәк кебек.
Әксәре кыйлмый фәрык[2]: яхшы белән яман нәдер?—
Йөк ташудан башка эшне белмәгән ишәк кебек.
Кайгы, хәсрәт белән тугдың һәм шулай гомрең үтәр,
Ахмак ул, дип хөкем итәр, булсаң да син Бисмарк кебек.
Тындыручы юк-югын, тик болгатучы—бихисап,
Болгатырлар дөньяны батмандагы ишкәк кебек.
Тугры юлда сабит улырлар дип син уйлама,
Мең пигамбәр килсә килсен бунлары дагвәт өчен.
Һәрберенең күзләре төшкән урын тик бер урын,
Җаннарын фида кылырлар әксәре шөһрәт өчен.

МӘҖЕЛЕС

Эчемлекләр тора алда, дус-ишләр унда һәм сулда,
Егерме җирдә шәм янган кебек балкый хәят монда.

Кунаклар тезелешеп түрдән, күңелләр сафланып кердән,
Бу мәҗлесне матурларга, гүя шатлык үзе кергән.

Берәү саз сыздыра анда, итеп тәэсир бөтен җанга,
Сыза сазны матур «Сакмар» га һәм моңлы «Кара урман»га.

Берәүләр ерлыйлар шунда матурлар, нечкә билләрне,
Ураллар, Ашказарлар, Агиделләр һәм дә Димнәрне.

Берәүләр шунда ерларга хәзерләнгән, аяк баскан,
Берәүләр шунда бер дусты белән утырып, кочаклашкан.

Берәүләр шатлыгыннан нишләрен белми, чаба куллар.
Тагы шунда бу мәҗлесне матурлыйлар хатын-кызлар.

Бөтен мәҗлес тула нурга, «берәүләр» шунда бер көлсә
Дидем шунда: «Бөтен гомрем шулай матур үтсә...»

. . . .

«УЛ»

Үзен мактыйдыр «ул» инсан күбенчә,
Күп эш кылган кебидер үз-үзенчә.

---

[1] Бу шигырьнең, шулай ук елы күрсәтелмәгән башка шигырьләрнең дә язылган вакытлары билгеле түгел.
[2] Әксәре кыйлмый фәрык — күбесе аермый.

Сүзенчә моннан артык һич кеше юк,
Сүзе күп, әмма бер кылган эше юк.
Ни файда бар коры сүздә, әмәлдә,
Егетлек һәм каһарманлык—гамәлдә.
Үзең белмә, кеше күрсен эшеңне.
Шулаймын димә, тик тор, кыс тешеңне.

* * *

Алга омтылдым өмет берлә, күрәм дип якты көн,
Бушка китте бар өмет, әврелде көннәр төн булып.
Ялтырап торган теләкләр, күктәге йолдыз кебек,
Инде мин җиттем, дигәндә җилгә очты көл булып.
Бер заман алдымда күрдем гөл-чәчәкле бакчалар,
Мин аяк баскач кына әврелде бакча чүл булып.
Каргалар шатлык белән торган вакытта дөньяда,
Мин һаман моң, зар белән сайрап торам былбыл булып.
Әллә нинди бер ирек берлә халыклар шатлана.
Мин торам веҗдан ташында магнәви бер кол булып.
Бар халык гафләттә йоклый, җаннары сүнгән тәмам,
Әмма мин һич күз дә йоммыйм, бер төнем бер ел кебек.

КЫРДАГЫ ЧӘЧӘКЛӘР

Ал-кызыллы нурдан укмашкан чәчәкләр җилбердәп,
Иң матур кызның колак яфракларыдай өлпердәп,
Утыралар кырда кояшка каршы төрле нур чәчеп,
Башларында вак кына чыклар торалар мөлдерәп.
Энҗе төсле ошбу чыклар, ялтырап емь-емь итә.
Чәчәкләрдән аркылы алтын кебек нурлар үтә.
Шунда бер япь-яшь кенә күбәләк очып уйнап йөри,
Ул кунар-кунмас йөреп бу чәчәкләрне селкетә.

ЭНӘ БЕЛӘН ЕПЬ

Бер вакыт епь зарланып әйтә энәгә:—Әй, энә!
Һәр вакыт син эшләгәнгә мин яталмыйм тик кенә.
Чөнки миндә һич ирек юк, син, муеннан әләктереп,
Юрга ат төсле чабасың, бер чыгып та бер кереп.
Көнне төннәргә катып син эшләсәң дә һәр заман,
Ярты тинлек файда итмисең, ялангач син һаман.

Башкаларның бәхтен эзләп тик чабасың син, юләр.
Син ялангач, башкалар атлас киемнәр киделәр.
— Әй, гомерлек иптәшем, әй, сердәшем, әй, епь кенәм!
Көн-төн эшләп тә ялангачмын, моны мин бик беләм.
Бик беләм мин: бер дә баймас һәм бөтәймәс эшчеләр,
Чөнки бездә һич ирек юк, көчлиләр тик көчлиләр.
Күрмисеңме соң минем арттан биләү көчләп тора.
Син бөтен эшнең серен һәм хикмәтен шуннан сора.

* * *

Чын бәхетләр эзләп йөручегә
Тыныч җәннәт бәхте кечкенә.
Җанга азык биргән иң зур бәхет,
Иң зур рәхәт—мәгәр эш кенә.

Ни кызык бар коры матурлыкта,
Төрле-төрле эшләр булмагач,
Завод, фабриклары кычкырышып,
Эшчеләре кайнап тормагач.

Сарайлары тамук, ашлар заккум,
Хезмәтчеләр ямсез зобаный
Булып күренделәр. Шул вакытта
Сагына башладым мин дөньяны.

Без тораек монда җәннәт кебек,
Кайберәүләр торсын тамукта.
Без йөрик гөлләр арасында,
Кайберәүләр янсыннар утта.

* * *

Өметләр булдылар да беттеләр дә...
Аяз, шатлыклы көннәр үттеләр дә...
Сөекле йолдызым берлән арамда
Болыт капланды, төште шомлы пәрдә.

Үзе юк, тик сүзе китми күңелдән
Өзелде чәчкәләр күңлем гөленнән.
Иңер вактындагы саба җиленнән
Сәлам көтәм матур, моңлы илемнән.

Ирексез читлегендә моңлы былбыл
Өзеп сайрый, тезә моңнар яшеннән.
Канат талпып очарга эзлидер юл,
Хәбәр дә килми назлы чәчкәсеннән

* * *

Һәр минутта, һәр адымда саф күңелләр эзләдем,
Тапмадым, тик сызыла-сызыла артта калды эзләрем.
Ах, минем булды авыр вактым, йөрәкнең ялкынын
Һич берәү дә белмәде, тик артта калды сүзләрем.
Мин көтә торгач матур иптәш вә саф, пак чын йөрәк,
Суынды күңлем, бетте майлар, арды, талды күзләрем.

* * *

Юк, кирәкми, миңа сузмагыз сез
Шарап салган ямсез стакан...
Ул агуны эчмим, кулга алмыйм,
Сугарылмасын аның белән җан!

Юк, кирәкми, алмыйм бирсәгез дә,
Аның серен беләм: дөньяны
Боза, пычрата һәм ямсезләтә,
Шуңа күрә эчмим мин аны.

Эчтем аны элек, газап чиктем,
Соңра инде эчми башладым.
Алдымдагы тулы стаканны
Түктем, үзен ватып ташладым.

* * *

Этнең кешеләрне саклау өчен
Төннәр буе өреп йөрүенең
Магнәсен һаман аңламыйм.
Чиркәүләрнең даң-доң кагуларын,
Мәзиннәрнең азан тавышын

Аңламыйм да, шуңа тыңламыйм.
Тынлау кая!.. Хәтта нәфрәтләнәм,
Тавышларын ишетеп җирәнәм...
Кешеләрнең акылын саташтырып,
Саф миләрен бозып, агулап
Торуларын уйлап чиркәнәм.

* * *

Сөт кебек ак, тонык су кебек пак,
Таза булган берәр нәрсәгә
Айрым күрнеп тора әллә кайдан
Кеп-кечкенә бер тап төшсә дә.

Аслы кара булган әйберләргә
Күпме тап төшсә дә беленми,

Кара әйбер өстендәге кара
Таплар читтән карап күренми.

* * *

Ялкынланып яндым бер вакытта,
Байтак кеше килде яктыма.
Куркам: яктым әз-мәз кәми барып
Җитмәсен дип сүнәр вактына.

Гәүдә әкренләп туза бара,
Йөрәк тибә, нәрсәдер сизәм.
Элек ләззәт тапкан нәрсәләрдән
Ераклаша барам һәм бизәм.

Кышка керсәм ничә айлар буе
«Өй тоткыны» булып торамын.
Үзем өйдә, әмма еракларда
Йөри, җиһан гизә уйларым.

* * *

Тын алып булмый инде бер иркенләп,
Хәлем артка бара айлап түгел көнләп.
Үпкәләргә тулган чиксез микроблар
Үлемгә әзерлиләр әкренләп.

Кайчакта, искә алып сау чагымны,
Ер ерлап сынап карыйм тамагымны.
Бер-ике сүз әйткәч тә тын кысыла,
Туктыймын очлый алмый азагыны.

* * *

Шайтан алгыр! Нәрсә булды соң миңа?
Төрле яктан шөбһә тулды күңлемә.
Ник болай ун көн болыт, бер көн аяз?
Ни өчен ун көн ватык, тик бер көн төзек.

Кай вакыт күңлем тыйнаксызланса да,
Күп тәэссердән йөрәк сызланса да,
Күп вакыт үз-үземне нукталыйм,
Разый булмый баш анархистланса да.

* * *

Бер ягым тау, күкрәк киереп тора,
Яшел яфракларга төренеп.
«Мин матур бит, миңа карагыз!»
Дип мактангандай читтән күренеп.

Таудан түбән баксаң, борыла-борыла
Агып ята Кама шым гына.
Карый безнең уйнап-көлуләргә
Бер сүз әйтмәенчә, тын гына.

Аның шулай шым, тын агуларын
Булды карап торган чакларым.
Ялгыз гына, башны кулга куеп,
Уйлап моң утырган чакларым.

Йөрдем борылмалы сукмаклардан
Эчтән генә ерлап, шатланып,
Матур агачларга, анда сайрап
Торган кошкайларга сокланып.

Ялгыз гына йөргән чакларымда
Моңлы кошлар иптәш булдылар.
Шул кошлардан, шушы нурлы таудан,
Агар судан матур нәрсә бар?

Әллә бармы?
— Белмим, бармы икән соң?
— Болардан да матур бар иде.
Берәү түгел, алар байтак иде,
Һәммәсен дә минем җан сөйде.
Алар кемнәр?
Алар менә монда
Бергә торган шушы кешеләр,
Хәл җыярга килеп,
Уйнап-көлеп
Бергә-бергә йөргән эшчеләр.

Сезнең белән үткән гомерем...
Күңелем чиксез-чиксез шатлана.
Тагын берне сөйгән идем, сөюен,
Ансын әйтмим, ансы—сер кала.

* * *

Юеш, болытлы көн булу белән
Тагын ыграк сызлый күкрәк.
Миңа хәзер, нурын чәчеп торган
Кызу кояш, коры көн кирәк.

Миңа шулай кирәк,
Әмма авылда иген үсәр өчен кар кирәк.
Бик тиз генә җирләр кипми торган
Мул су белән килгән яз кирәк.

Төзәлмәсә төзәлмәсен күкрәк,
Хәзердән үк аяз булмасын.

* * *

Беләбез без!.. Сиңа дустыр «фәләннәр»,
Сиңа дошман икән «фәлән әдәмнәр»!..
Дип әйтерләр дә иптәш кайберәүләр,
Бер әйбер белмәенчә шелтәләрләр.

Үзең дә белмәгән эшне тагарлар,
Йөрәгеңә зәһәрле үк кадарлар,
Синең гайбеңне тырышып эзли торгач,
Матур эшне начар бу дип табарлар.

Менә шул чакта син бик нык сабыр ит,
Аларның сүз сөйләп беткәннәрен көт.
Соңыннан: белмәгән эш турысында,
Өреп торма!.. диген, ләм ялтәфит үт.

* * *

Аһ, кыен! Мин алда бик зур куркыныч эшләр сизәм,
Гәүдә монда, әмма җан берлән ничә илләр гизәм.
Нинди илләр! Күп сөйләргә бармый тел, тып тукталам,
Сыймый күкрәккә йөрәгем, хәл бетә, чак тын алам.
Аптырап мин үз-үземне барча уйлардан тыям,
Аһ, кыен! Чиксез олуг диңгездә мин ялгыз йөзәм.

ЮЛДАН

(Туган җиргә)

Китәм синнән вакытча, әй туган җир һәм эссенгән җир!..
Миңа син, мин сиңа күптән иләшкән һәм төшенгән җир.
Зарымны, шатлыгымны һәммәсен уртаклашып бергә
Үсеп, чәчкә атып, ничә еллар киченгән җир.
Синең аулак берәр урнында моңланган вакытларда
Күземнән мөлдерәп кайнар яшем тамган вә сеңгән җир.
Үзем киткән саен алга, күңел артка таба тарта,
Сиңа булган сөю шигыре ераклашкан саен арта.
Синең өстеңдәге хәсрәт белән кайгыңда да тәм бар,
Карыңда, салкыныңда, яңгырыңда серле бер ям бар.
Җәнүп былбыллары килмәс иде җәйләрендә җәйләргә,
Әгәр син булмасаң җәннәттән артык ямле җәйләрдә.
Котып йолдызы ник соң бер урында мәңге кузгалмый
Тора, чөнки сине сөйгәнгә, ул синнән күзен алмый.
Кырымны мактаган чакта, «бу дөнья җәннәте!» диләр.

Шулай да юктыр анда Агидел, Дим, Ашказар, Инҗәр.
Күңел кандилләрен киткәндә синнән яндырып киттем.
Шуның нурында язган бу шигырьне калдырып киттем.

* * *

Алтын затын җирнең астыннан да
Казып, чукып, эзләп табалар...
Кадерләре беткән нәрсәләрне,
Җиргә күмеп, өстен ябалар...

Күргәнем юк энҗү чыккан җирне,
Ләкин диңгез астында, диләр.
Энҗү булган өчен микән аны
Су астына төшеп эзлиләр?..

Алтын белән энҗү кадерлеләр
Югалтмаган өчен төсләрен.
Кайда торсалар да тутыкмыйлар,
Төрле таплар басмый өсләрен.

Син үз эшеңдә саф кеше булсаң,
Алтын я энҗүдәй күрерләр.
Сине һич вакытта күмә алмаслар,
Сиңа чын бәһаны бирерләр.

Син үзең саф булсаң,
Пычрак нәрсә
Сиңа үз тәэсирен итә алмас.
«Әтәч карашлары»[1] бетәр сиңа,
Һич вакыт та бәһаң югалмас!

* * *

Яратамын бу дөньяда һәрбер эшне,
Язны, көзне, матур җәйне һәм дә кышны,
Яратамын һәрбер, һәрбер матурлыкны,
Аккан суны, анда сайрап торган кошны...

Шулай ук мин яратамын кешеләрне,
Чын күңелдән эш эшләгән эшчеләрне.
Һәр вакытта үз эшендә ихлас белән
Эшләп йөргән зурларны һәм кечеләрне.

Яратамын авылны, ул
Ничек тора,

[1] Әтәчнең энҗү табу мәсьәләсе күптәннән бар булган бер тәмсил (басня). М. Гафури.

Берсе сабан сөрә, берсе урак ура.
Яратамын заводларны, берсе анда
Чүкеч суга, берсе каты сталь кыра.

Туганкайлар, никтер ямсез күренә бер эш,
Әйтерсең лә ул эш миңа тәмсез емеш.
Ул да монда чыгып үз язганың җырлау...
Чык та, шунда сезгә карап:
Ай-вай килеп, дөнья җимерелгәндәй итеп,
Ерла имеш...

РӘНҖЕМӘ...

Ана сөтен рәтләп иммәгәнгә җүтәллимен... җаным,
рәнҗемә,
Рәтле, матур тормыш күрмәгәнгә җүтәллимен...
җаным, рәнҗемә.
Мин кешечә йөри алмыйм ахры... нишлим табигатем
шул булгач?..
Кешеләрчә гомер сөрмәгәнгә газапланма, җаным, рәнҗемә.
Син телисең миннән бик күп нәрсә, мин аларны тәгәл
бирә алмыйм.
Синең теләкләрне бирмәгәнгә, артык янма, артык
рәнҗемә...
Ихтимал, син былбыл кошлар кебек, телисеңдер
күккә очарга,
Очма, бераз тор һәм түз дигәнгә яңлыш мәгънә
бирмә, рәнҗемә.
Нинди кошлар ташлап китәрләр соң йон үсмәгән
зәгыйф баласын?
Шундый хикмәтләрне сөйләгәнгә чит күрмә син,
җаным, рәнҗемә.

* * *

Чәйнәп ташлар идем патшаларын,
Буып алыр идем җаннарын,
Ач этләргә өләшеп бирер идем
Итләрен һәм кызыл каннарын.

Каравылчы итеп куяр идем
Вәзирләре белән ханнарын,
Иң-иң кирәк җиргә тотар идем
Кеше талап җыйган малларын.

Яңагыма кулым куймас идем
Очрасам да, хаҗәтем төшеп,
Аларга мин тәрилкә тотканчы,
Йөрер идем коры су эчеп.

ЧӘЧҮ БЕТКӘЧ

Кичә генә язгы чәчү беткән,
Кыр өстендә шау-шу басылган.
Гөрләп, шаулап йөргән машиналар
Эш бетереп кайткан басудан.

Кара диңгез кебек җәелеп яткан
Совхоз, колхозларның җиренә
Читтән караганда кара бәрхәт
Җәеп куйган кебек күренә...

Чыпчык түгел, чебен кунарлык та
Җир өстендә чүп-чар калмаган.
Бу кырларга, иске кием кебек,
Ызан белән ямау салмаган.

ДУСЛАРГА... ҺӘММӘСЕНӘ!

Ишек кага төрле-төрле кеше:
Хәерче дә, мәсьүл эшче дә,
Дус-ишләр дә, ерак җирдән килгән
Үзем һич белмәгән кеше дә.

Һәрбер ишек каккан кешеләргә
Әйтә торган ике сүзем бар:
— Мәрхәба!.. Хуш килдең!.. дигән сүзләр,
Өстәвенә ачык йөзем бар.

Кунак өйгә кереп утыргачтан,
Керсез күңлем белән гәпләшәм.
Нәрсә бар, тагын нәрсәләр юк,
Чын йөрәгем белән сөйләшәм.

Туры килсә шунда чәй эчәбез,
Булган нигъмәтләрне ашыйбыз,
Чәй аралаш, килгән кунак белән,
Озак мөсахәбә ясыйбыз...

Шулай һәр кемне мин каршы алып,
Саулык теләп тагын озатам...
Берничә көн үтәр-үтмәс борын,
Теге кунакларга шак катам.

Алар булып чыга түбән җанлы,
Сүз ташучы алчак бәндәләр...
Һәрбер сүзне борып яманлыкка
Башка җиргә барып түгәләр...

Ару гына таныш дип йөрисең,
Булып чыга шымчы ул кеше...
Пак сүзләрне пычрак белән буйи,
Бу эш нинди әдәм көлкесе!..

Әй, туганкай, миннән гыйбрәт алып,
Мондый кешеләрдән бул ерак.
Ялган аек булып алдашканчы,
Чын исрек булу яхшырак...

ЯЗ!..

Кояш нурын болыт капласа да
Яз—язлыгын итә, эретә...
Карлар бетеп, кара җир яшәреп,
Сандугачлар сайрар көн җитә.

Җирнең йөзен, кара чатыр кебек,
Кара болыт каплап ятса да,
Яз—язлыгын итте, үлән чыкты
Көнгә каршы булган бакчада.

Кояш, бара торгач, җиңеп чыкты,
Җир йөзенә карап көлде ул.
Салкын кара болыт, саф кояшның
Көчле нурларына бирде юл.

Нурдан булган кояш җәдрәләре
Ертыкладды болыт пәрдәсен.
Зифа буйлы ялангач кызлардай
Күрсәтте ул бөтен гәүдәсен.

Күрәм: ертык болыт кисәкләре
Куркышып читкә китәләр,
Китәләр дә... бераз бару белән
Төтен кебек таралып бетәләр.

Төтен һәр вакытта тиз югала,
Тиз тарала торган нәрсә ул.
Һәм шулай ук һәммә караңгылык
Кояш нурларына бирә юл...

* * *

Мин Мәскәүгә бардым берничә рәт,
Байтак җирен иттем тамаша,
Анда төнгә керсәң, яктылыкка
Читтән барган күзләр камаша.

Юлым төшеп мин Мәскәүгә бардым
Бер-бер артлы ике-өч ел аша.
Кызыл Мәскәү, данлы Мәскәү шәһәрен
Бераз итәрмен дип тамаша.

— Мәскәү бит ул! Җитә башлагач та
Күңелеңә яңа дәрт керә.
Берәү торып:
— Мәскәү күренә!—дигәч,
Йөрәк үз-үзеннән сикерә.

Мосафирлар шундук сырлыгалар
Вагон тәрәзәсе төбенә.
Чынлап та бит алда
Тулкынланып яткан ут диңгезе күренә.

* * *

«Өзлексез эш атнасына күчү»
Иллә яхшы булып төште дә:
Бер-бер артлы килгән көннәр үтә
Бер туктаусыз булган эш белә.

Ике мең ел буе эшсез торган
Якшәмбә дә эшкә җигелде.
Дин буявы белән буялып йөргән
Шимбә, җомга артка чигенде.

СЫНАУ КӨНЕ

Әй, син, дәртсез егет,
Куркак егет,
Куян кебек йөрәксез егет!..
Данлы тормыш, каты көрәш
Өчен яраксыз һәм кирәксез егет.

Шундый дәртле көндә шулай дәртсез
Булалармы, әй, син, пешмәгән!..
Гәүдәң үскән,
Ләкин батырлыгың белән дәртең һичбер
үсмәгән...

Синең яшьтәшләрең дәртләренә
Сыя алмый уйнап көләләр...
Кызыл Армиягә алынуны
Бик зур шатлык итеп күрәләр.

«Сөйгән кызым кала...» дип уйласаң,
Кем сөя соң синең кебекне?
Җанлы кызлар сөя, янып торган,
Гайрәт белән тулган егетне.

. . . .

* * *

Һәр кайда да тормыш тулкынлана,
Диңгез кебек шаулап кайнаша,
Бөтен халык көтә зур үзгәреш,
Йөрер хәл юк урамнар аша.

Каты давыл астында калгандай,
Калтырана дошман кешеләр,
Ялт-йолт итеп торган яшен төсле
Ашыгып, кызып йөри эшчеләр.

Анда кайнап торган күренешне
Сөйләп бетәр хәл юк тел белә.
Зур көрәшне башлап җибәрергә
Тик бер сигнал гына көтелә...

Сигнал булу белән кузгалырга
Әзер тора көчле беләкләр.
Пуляләргә каршы барыр өчен,
Ашкыналар утлы йөрәкләр.

Бәрелеш минутлары якынлашкан
Саен, күтәрелә күңелләр.
Каушата алмас төсле бу көрәштә
Нинди генә авыр үлемнәр.

Бу көрәштән безне куркыта алмас
Төрле куркынычлар, газаплар.
Алга барудан да туктата алмас
Жандармлар, атлы казаклар.

ДИҢГЕЗ ЯНЫНДА

Тулкыннары ярга чәпчеп, чәпчеп,
Берсе-берсе белән сөйләшеп,
Шомарып беткән йомры ташлар белән
Үткән тарихларны серләшеп,

Берсе өстеннән берсе сикерә-сикерә,
Өскә таба вак-вак нур чәчеп
Торган зур диңгезне карап тордым,
Шул матурлыкларга көнләшеп.

Кай вакытта диңгез тып-тын ята,
Кояш нуры юл-юл сызылган,
Аллы-гөлле, күкле-зәңгәр юллар
Күк читенә карап сызылган.

Киң кочагын ачкан күккә карап,
Чит-читләре күккә тоташкан,
Диңгез өстен тагы да матурларга
Нурлар явып тора кояштан.

Шунда озын чәчле, көмеш тәнле
Кызлар басып ташлар өстенә,
Бераз карап торгач, колач җәеп,
Сикереп төшеп диңгез эченә,

Тын диңгезгә матур тавыш биреп,
Су чәчрәтеп йөзеп китәләр,
Нур эчендә нурлы гәүдәләре
Берсе-берсен узып китәләр.

Көмеш балык кебек гәүдәләрен,
Өстән йөзгән кара чәчләрен,
Хәйран калып карап торган вактым
Булды, ак тәннәрен, матур төсләрен.

* * *

Бүген бер бик матур, назлы чәчкә
Өзеп алып күңлем гөленнән,
Салып куйдым шушы альбомга мин;
Уйлыйм шунда үзем күңелдән:
Нинди матур чәчкә, нинди нурлы!..
Тирә якка төшкән шәүләсе,
Шушы чәчкәдән дә матур микән
Альбом иясенең гәүдәсе?
Шушы чәчкә кебек кызыл булып,
Яна микән назлы йөрәге?
Сандугачның дәртле йөрәгедәй
Тибә микән назлы йөрәге?

БАЛ КОРТЫ ҺӘМ КИГӘВЕН

Җәй көненең нурга чумган ямле көне.
Чәчкә аткан үләннәрнең һәрбер төре.

Көнгә каршы җем-җем иткән бу чәчкәләр
Кайберсе вак, кайберәүсе яхшук эре.

Кайберсе ал, кайсы-берсе кызыл төстә.
Аңкып тора һәрберсе бер төрле истә.
Шушы төрле чәчкәләрнең арасында
Йөриләр бал кортлары кызу эштә.

Һәрбер корт әрле-бирле очып йөри,
Чәчкәләрдән бал чыкларын эчеп йөри.
Җәй көнендә күбрәк эшләп калыр өчен,
Бер урыннан бер урынга төшеп йөри.

Шунда йөргән бал кортының берәүсенә
Шул урында бер кигәвен очрады
Һәм, шунда ук, бал кортыннан көлә биреп:
— Нихәл, син?..—дигән хәл сорады.

— Нихәл син, монда нәрсә чукчынасың?
Чәчкәләрдән бер очасың, бер кунасың?
Әммә соң сезнең кортлар гаҗәп халык,
Көн буе эштән алмый йөри башын.

Безнең рәхәт! Йөрибез бу киң яланда,
Торабыз бүген монда, иртән—анда.
Нигә кирәк сезнең кебек бергә тормыш
Корып, эшләп йөрү мондый хуш заманда?—

Корт җавап бирде болай кигәвенгә:
— Безнең теләк—эшләп калу яхшы көндә.
Бергәләп тормыш кору аркасында,
Бал ашап көн күрәбез бергә-бергә.

Без шулай бергә эшләү аркасында
Ни чаклы бал бирәбез кешеләргә.
Ә үзебез карамакта кеп-кечкенә...
Хуш хәзергә!.. Вактым юк күп сөйләргә...

Кигәвеннең бал кортына кәефе китеп,
— Их, сез, дурак!—диде, безләп очып китте.

УРАК УРГАНДА

Күңелле дә була кай чагында
Сөйгән кызың булса янында.

Арыганыңны син дә белдермисең,
Белдерәсе килми аның да...

Бер-береңә карап дәртләнәсең,
Бер-береңнән узышып урасың...
Көлтәләрне бәйләп торган чакта
Нурлы йөзен карап торасың...

Шунда сиңа яңа көч бирәдер
Гафиф кызның тирле йөзләре...
Күңелләргә бетмәс дәрт бирәдер
Эш кызының уйчан күзләре...

Искә төшә шунда бу дөньяда
Ник торганың, нигә урганың...
Аның белән сине бергә кушкан
Эшне күреп шатлана каның...

Шунда урган җиргә күзең төшеп:
— «Бу җир—бәхет җирләре!..» дисе
Эшнең магнәсен аңлап алгач,
Эчтән акрын гына көйлисең...

Бара торгач, ул да ерлый башлый,
Шул вакытта күңел киңәя...
Беләкләргә яңа көчләр керә,
Авыр көлтәләр дә җиңеләя...

Якын күренә ерак җирнең башы,
Көлгән кебек була кояшы...
Кояш нуры белән бергә кушыла
Эш кызының матур карашы...

ЛЕНИНИЗМ МИНЕМ МАЯГЫМ

Совет властенә гомеремдә
Итмәдем мин һичбер каршылык,
Сыйнфи дошманга йөрәгемдә
Саклаганга бетмәс тарчылык.

Совет яклы булдым, аңа каршы
Торган чакларда да күп халык,
Батырларча советны якларга
Кулыма каләм атлы ук алып.

Дөрес, кай чак тормыш баткагында
Тайгалады минем аягым.
Ләкин бик тиз табып алдым
Сүнмәс Ленинизм маягын!..

ПАРЧАЛАР

Бөек бәйрәм бүген, искитәрлек,
Алда тора тагын зур теләк.
Шул зур теләкләргә җитәр өчен
Таулар чаклы гайрәт, көч кирәк.

Кызыл байрак тотып, бәйрәм ясап,
Алга таба ярып барабыз.
Тәваф итә торган кагбә белән
Ерак түгел безнең арабыз.

Алгы сафта торсын кулларына
Корал тоткан көчле эшчеләр.
Артка чиксен, безнең сафтан чыксын,
Иманнары зәгыйф кешеләр.

* * *

Ялгыз тора-тора эчең пошып,
Күңлең төрле уйга чумса да,
Ни эшләргә белми аптыраудан
Йөдәү сиңа авыр булса да —

Чыда мондый гына авырлыкка,
Эзлә үз күңлеңнән изге юл.
Ялгызлыгың төрле кешеләрдән
Чагылудан да авыр булмас ул.

* * *

Утыз ел сакладым вөждан,
Утыз ел сатмадым вөждан,
Шуны саклар өчен бик күп
Авырлыклар күтәрде җан.

* * *

Укыйм кай чагында Дәрдмәндне
Алып ташлый күңелдән барча дәртне.
Булыр төсле булам мин гүр иясе,
Аның шигыренә башка ни диясе?

* * *

Бер адым алга басам да,
Әйләнәм мин артыма,
Кайда басканнар икән, дип,
Күз саламын халкыма...

Шул вакыт мин бик югары
Кош кебек очсам әгәр,
Ә алар һаман шулай
Баскан урында торсалар...

* * *

— «Үткән» бишьеллык»ның уңышлары
Ничек соң?..» дип сораучыларга,
Безнең өчен үткән бишьеллык эш
Үзе җавап бирә аларга.

* * *

Без электән дә урак урган, печән чапкан кеше,
Эш белән маңлай тирен агызып азык
тапкан кеше.
Эш белән җәннәт ясыйбыз кап-кара
кырларны без...

* * *

Шатланам мин: чыкса яңгыр җил-давыллар
куптарып,
Ташласа төп-тамыры белән зур агачлар актарып.
Кай вакытта мин телимен бик озак төн булганын,
Ялтырап таң атмавын, ачмавын төн юрганын.
Шарт та-шорт, гөлдер дә гөлдер шаулатып
күк күкрәсә,
Җил, давыллардан, яшеннәрдән җир өсте
тетрәсә.

* * *

Эшләр яхшы, бәхет төгәл чакта
Таныш-белешләрең очраса,
Әллә кайдан каршы көлеп килеп
Исәнләшеп хәлең сораша.

Эшең кире китеп, алга барган
Юлларыңа төшсә киртәләр,
Таныш кешеләрең очрасалар,
Күрмәмешкә салынып үтәләр.

* * *

Дөньяның бар җиреннән монда иркен,
Очалар төрле кошлар төркем-төркем...
Башка җирдә ел торудан бик күп артык.
Җәй көне авылларда тору бер көн...

* * *

Көтмичә һичбер кемнән, һичбер ярдәм,
Сикердем бик куркыныч биек ярдан...
Төштем дә саф энҗеләр эзләдем дә,
Калкынып, өскә килеп чыктым аннан.

* * *

Шатлык кадерледер кайгы-хәсрәт
Белән йөргән өчен аралаш.
Егет кеше кайгы-хәсрәтләргә
Куян кебек куркып карамас.

* * *

Үзем бармын, үзем бермен, үземдә көч
белән иркем,
Мине мәҗбүр итәлмәс әллә нинди эшкә
һичбер кем.
Туры юл эзлимен дип юлга чыктым, якты
шәм кулда.
Маяк чәнечкән булып, юл күрсәтеп, сез
тормагыз юлда.

* * *

Егет тә генә кеше, ай, шул булыр:
«Кире кайтмас әйткән сүзеннән».
Ышанмаган кеше булса әгәр,
Килеп сорасын ул үземнән.

* * *

Әгәр дә мин бурыч алсам берәүдән,
Аңар һәр көн дә бер очрыйм эзендә.
Әгәр дә мин бурыч бирсәм берәүгә—
Күрәлмим атналар буе эзен дә.

* * *

Елы кояш көлеп карагачтан
Бездә шатлык ничек артмасын,

Ничек чыдап торсын салкын карлар
Ничек бозлар эреп акмасын?

* * *

Һәр кеше булыр өчен магнәле
Җитмәгән вакыт, аңа иртә әле.
Безнең көннәр кешеләрне магнәле
Итәр өчен көрәш белән үтә әле.

* * *

Эш эшләп кыш буенча киттем арып,
Өч атна яттым монда даруланып.
Хәл җыйдым, кәефем яхшы ук яхшыланды,
Өемә кайтып китәм аруланып.

* * *

Түбәнчелек итсәң гакылсызга,
Миннән курка дип уйлар,
Бәласеннән эмин булыр өчен
Катышмасаң, эре дип уйлар.

* * *

Юлаучылар туктап ут яктылар,
Чәй эчтеләр һәм ял иттеләр,
Ат ашатып, бераз торганнан соң,
Кузгалдылар, алга киттеләр.

Балкып калган утлы күмерләре
Сүнеп, капландылар көл белән,
Күп тә үтми калдык көлләре дә
Очып таралдылар җил белән.

Түп-түгәрәк булып торып калды
Ут ягылган кара җир генә,
Монда хәят бетте. Тик ер ерлап
Үтеп китә искән җил генә.

* * * [1]

. . . .
Мөмкин булса шунда берәр бакал
Күтәрегез минем өчен дә.

[1] Бу өземтә—Башкыртстан язучыларының беренче съездын котлап язган шигырьнең ахры. Башы югалган.

Уен-катыш әйткән бу бакалның
Ни булса да ярый эчендә.

Һичбер ирлек түгел өйдә торып
Тыңлап яту илнең үсүен.
Искелекне җимереп, тау-ташларны
Ватып яңалыкка күчүен.

* * *

Ни мәгнәсе бар соң: ярты-лаш сау,
Ярты ауру үткән гомернең.
Синдә һәр көн артып, күренеп торса
Билгеләре ямьсез үлемнең.

* * *

Ник кылычтан курыксын ул җаннан өмет өзгән
кеше.
Ник судан качсын эссе утка янып көйгән кеше.

* * *

Күңел йөзә яры күренмәгән
Чиксез уй диңгезе эчендә.
Шаулап торган тулкын арасында,
Диңгезнең иң тирән төшендә.

* * *

Күзләреңнән әллә нинди мәгнәле серләр укыйм,
Тел белән әйтелми торган төрлечә сүзләр укыйм.
Кып-кызыл ирнең арасыннан күренгән
тешләрең—
Не күрәм дә шул урыннан дәвәри
мансурлар укыйм.

* * *

Кай вакытта шундый яна йөрәк,
Белми янганлыгын ни өчен.
Шулай итеп юкка дөрләп янып
Әрәм генә итә үз көчен.

* * *

Яз житәр, җәйләр килер дә,
Җир йөзе ак нур булыр.
Чәчәкләр, гөлләр белән кырлар
Вә урманнар тулыр.

Сандугачлар, төрле кошлар
Сайрашырлар зык кубып,
Җирдәге чүп-чар вә пычракларны
Ташкыннар юар.

* * *

Эч пошып китә чыгып йөрмәгәнгә,
Таныш-белеш, дус-ишләрне күрмәгәнгә,
Читлеккә ябылып куйган арысландай,
Йөримен бер бүлмәдән бер бүлмәгә.

* * *

Сөеклем, син әгәр булсаң кызыл гөл,
Сибәр идем сиңа күз яшемне,
Шулайтеп үстерер идем үзеңне,
Гомергә алмыйча синнән күземне.
Әгәр булсаң иде син назлы чәчкә,
Сине саклар идем салкын кыраудан.
. . . .

* * *

Күк йөзендә йөзә зур болытлар,
Берсе өстенә берсе капланып.
Кара мәрмәр тауның өсләренә
Өеп куйган кебек ак мамык.

* * *

Уйлап-уйлап торып хәйран калам
Бу эшләрнең аслы нигезен...
Кай чагында үтә алмый торам
Киң һәм тирән тормыш диңгезен...

* * *

Чәчәкләр бәйләмен тоткан
Нәфис ак куллары берлән,
Үзе дә шул чәчәк төсле
Матур нурларга өретелгән.

* * *

Чәчәк ул, ул—чәчәк төсле,
Күреп хәйран калам шунда.
Күренде ай, кояш бергә
Кушылган төсле каршымда.

* * *

Син миңа рәсмеңне бирмә.
Ихтияҗ юк рәсмеңә,
Чөнки рәсмеңне язып
Алганмын инде күңлемә.

Бу рәсем бик, бик матур, тик
Ул ясалган кул белән.
Әмма күңлемдә язылган
Рәсмең ясалган нур белән.

* * *

Елмаеап, назлы кулыңнан син миңа
сондың шарап,
Мә, шуны эч, дип син әйттең, елмаеп,
күзгә карап.

* * *

Уңайсызлык килә дә ул, китә дә ул,
Кайгылы уй була да ул, бетә дә ул.
Ир-егеткә авырлыклар зарар итмәс,
Әгәр дә ул табып алса бер туры юл.

* * *

Төнгә каршы туган айдай мин туармын эш белән,
Мин гөнаһ кылмам, әгәр кылсам юармын
эш белән.
Яу килер, мин куркынып чикмәм
карыш та артыма...
Тамчыдай итмәм хиянәт биргән изге антыма.

III

ҖӘННӘТ КӨТКӘНДӘ[1]

(Поэма)

I

Таң иртәдән башлап төнгә чаклы,
Күздән карап сату иттергәч,
Алучылар беткәч... кибете эчен
Җыештыртып, эшне бетергәч...

Итагәтчел булган хадимнәрен
Алдан чыгарып, кибетен бикләгәч,
Аргамакка утырып өйгә кайткач,
Көлеп каршы алгач яшь кәләш...

Тимер сандыгына салып куйгач,
Бүген сату иткән акчаны,
Әйтеп бетермәслек киң бер шатлык
Чолгап ала иде Сафаны.

Анда, нак базарның уртасында,
Төрле маллар тулган зур кибет,
Монда—җиһазлы йорт, матур кәләш,
Алда тәмле шорпа, симез ит.

Аннан кыздырылган тәмле күркә.
Җә булмаса симез каз ите,
Аш алдыннан «кәгеп» җибәрергә
Алда тора «күгәрчен сөте».

Аш алдыннан «төшереп» ашап беткәч,
Гырылдатып өч-дүрт кикергәч,
— «Биргәнеңә шөкер, алла!..» дигәч,
Ашау шартын җиренә җиткергәч...

Аның күңле тәмам тынычлана,
Ул шатлана иде тагын да,
Шатлык шәүләләре уйнап торган
Төсле була иде янында.

Чәйгә чаклы алыш-бирешләрен,
Тагын бер мәртәбә карагач,
Бүген сату иткән акчаларын
Тәмам ләззәт белән санагач...

[1] Бу поэма языльш бетмәгән.

Кайдан товар алып, ничек сату
Файдалырак булуын уйлагач,
Үзенең бер кемнән дә алданмавы
Турысында шиге калмагач...

Чәй алдыннан тагын бер аз «кәгеп»,
Варениялэп, тирләп чәй эчкәч,
Яшь кәләше белән андый-мондый
Эшләр турысында сөйләшкәч...

Аның күңле тагын күтәрелә
Иде, шушы рәхәт эчендә,
Хәйлә катыш төрле елмаюлар
Күренә башлый иде төсендә...

Алыш-биреш сату планнарын
Уйлап бераз идәндә йөргәч,
Яшь кәләше, назлы тавыш белән,
— «Йоклар вакыт җитте бит...» дигәч,

Тагын берәр бакал эчкәннән соң,
Йокы бүлмәсенә кергәндә...
Өске киемен салып, эчке күлмәк
Белән калган хатынын күргәндә...

Шатлыклы бер рәхәт каплап ала
Торган иде аның йөрәген,
Ходасына шөкер итә иде
Биргән өчен бөтен теләген...

Йокы бүлмәсенең идәненә
Җәелгән зур иран паласы,
Хуш ис аңкып торган иркен бүлмә,
Сулар өчен җиңел һавасы.

Тәнгә сизелмәслек мамык ястык,
Ефәк юрган, акбаш кровать,
Кием шкафлары, комодлары—
Һәммәсе дә асыл, яхшы зат.

Йокы бүлмәсенә барып кергәч,
Матурлыкның барын да күргәч,
Эчке күлмәк белән калган кәләш,
Аның каршысында киерелгәч,

Сизми кала иде, шатлыгыннан,
Кроватька барып ятканын,

Исле гөлләр белән чолгангандай
Сизә иде үзенең җанын...

Тирбәлдереп торган рәхәтлекләр
Каплый иде аның йөрәген.
Тагын ходасына шөкер итә
Иде биргән өчен теләген...

II

Сафа байның күнлек эше шулай.
Шушы җиргә килеп бетә дә,
Әллә нишләп шунда тәмле уйлар
Белән йокысы ачылып китә дә.

Шарап белән томаланган башы
Уйлый башлый иде «җәннәт»не.
Үлеп терелгәчтен мөэмин-
мөселманнар күрә торган ләззәтне.

Яшь чагыннан бирле муллалардан
Ишетеп килгән оҗмах сыйфатын
Күз алдына китереп ята торгач,
Истән чыга иде яшь хатын.

Сигез оҗмахның ул берәүсенә,
Шиксез керәмен, дип белә иде,
Аның хыялында йөргән җәннәт
Күз алдына болай килә иде:

Мәңге якты... чиксез зур булган җир,
Һич исәпсез зур-зур бакчалар.
Ул бакчалар тулы виноградлар,
Әфлисуннар, хөрмә, алмалар.

Җимешләрнең берсен өзеп алсаң,
Урнына тагын берсе үсә,
Торып өзәргә дә хаҗәт төшми,
Шап итә дә өзелеп төшә.

Тәмле итле төрле симез кошлар
Баш очыңнан очып үтәләр.
Шул тирәдә әрле-бирле очып,
Мөэминнәрнең әмрен көтәләр.

Закускага кирәк була икән,
Шундук пешеп алга төшәләр,

Ашап тую белән тагын терелеп,
Пыр-пыр итеп очып китәләр...

Ул кошларның шунда кайберләре
Гелән сайрап кына торалар,
Көйне-көйгә ялгап, тавышларын
Әллә мең төрлегә боралар.

Алар шулай төрле тавыш белән
Пар, пар булып сайраган чакта,
Мәкәрҗәдән алган органнарың
Торып торсын шунда бер якта...

Мирфәйзәнең гармон уйнаулары
Болар тавышы янда бик түбән,
Ямсез булып кала, әллә кайчан
Эштән чыккан, күптән искергән.

Эчәм дисән, агач асларыннан
Чишмә булып ага шәраплар,
Шундук чумырып алып эчәр өчен
Әзер тора алтын савытлар.

Коньяк кебек башны авырттырмый,
Эчкән саен дәртне арттыра.
Укшытмый да болар, костырмый да
(Юк шул, алар түгел шул сыра).

Алай гына түгел, миске-гамбәр
Белән печәтләнгән шешәләр,
Шулардагы төрле шарапларны
Оҗмах әһелләре эчәләр.

Шундый шарапларны хур кызлары
Үз куллары белән бирәләр,
Алтын бакалларны алда тотып,
Кыска көйгә ерлап эчрәләр:

— «Ничек килдең син безгә,
Төшмәенчә диңгезгә?..
Кадерле кунак син безгә
Ни хөрмәт итик сезгә?..»

«Болар кайдан килгәннәр,
Каракүл бүрек кигәннәр,
Шулар ич безнең сөйгәннәр,
Безнең өчен килгәннәр...»

Сафа, шушы кызыкларны уйлап,
Шатлыгыннан елмаеп көлә.
Үзенең дә шул хур кызларына
Каршы ерлар ерлыйсы килә:

«Алып бирим ак тапас,
Матур булырсың таккач,
Карама кеше сүзенә
Үз күңелең яраткач».

«Бүген төнлә бер төш күрдем,
Акбүз атка атландым.
Күргән төшем раска чыкты
Сезне күреп шатландым»...

Эчтән генә көйләп бу ерларны
Ләззәтләнә, хыял киңәя,
Хур кызлары ерлап торган кебек
Була «Бала Мишкин» көенә.

Җәннәтләрдә булган матур тормыш
Болар гына түгел аныңча:
Анда булган ләззәт-рәхәтләрнең
Һич исәбе юк аныңча.

Анда ашап-эчү, уйнап-көлү,
Гыйш-гашрәт сөрү дисеңме,
Төрле җирдә булган кызыкларны
Барып карап йөрү дисеңме.

Әгәр йөрим дисәң дөл-дөл кебек
Оча торган җитез пораклар[1],
Җәннәт кырларында гөлләр ашап,
Сөтләр эчеп үскән шәп атлар.

Үзең теләү белән шул атларның
Берсе чабып алдыңа килә,
Күзне йомып кире ачу белән
Меңәр чакрым җиргә җиткерә.

(Нигә юктыр анда аэроплан,
Автомобиль, пароход, тимер юл?
Анда фабрик-заводлар булмагач,
Булмасалар гаҗәп түгел шул).

---

[1] **Порак** — канатлы мифик ат.

Ничек булсын анда эшче халкы
Эшли торган фабрик-заводлар,
Андый «түбән» халык булган җирдә
Нинди рәхәт, нинди зәвык бар?

Анда һәрбер нәрсә баштан-аяк
Тик кодерәт белән эшләнә,
Шунысы рәхәт, яллап эшләтмисең,
Анда ихтыяҗ юк эшчегә.

Анда официантлар булсалар да,
Бер тин алмый хезмәт итәләр.
Дөньядагы кебек, аш китергәч,
Нәчәй-фәлән өмет итмиләр...

Анда бакчаларның уртасында,
Җәүһәр, якутлардан сарайлар,
Сарай тәрәзләренең пәрдәләрен
Ачып хур кызлары карыйлар.

Сарайларның ишек башларында
Яндырылган кызыл фонарьләр
Булмаса да һәрбер җәннәт әһле
Үз сарайларыны табалар...

Сарай әйләнәсе, бакчалары
Тулган төрле чәчкәләр белән.
Шушы чәчкәләрдән тирә-якка
Төрле-төрле хуш ис бөркелә.

Асыл ташлар белән бизәкләнгән
Беседкалар гөлләр эчендә.
Аллы-гөлле нурлар чәчеп йөзгән
Балыклар бар күлләр эчендә.

Ул бакчалардагы сукмакларга
Төрле төстә ташлар сибелгән.
Юлны ике яклап аллы-гөлле
Чәчкә аткан гөлләр тезелгән...

Синең хезмәтеңә әзер тора
Яп-яшь кенә таза вилданнар,
Ресторандагы официантлар
Төсле менә дигән гыйлманнар.

III

Сарайларның ишекләре алтын,
Көмеш баскычлардан менмәле,
Аерым бакча эчендә һәрбер сарай,
Үзе җитмеш өчәр бүлмәле.

Бүлмәләргә кергәч, шак катарсың,
Күргәч ыкчым кроватьларын.
Чүп була да куя дөньядагы
«Варшавский кровать»ларың...

Түшәк, ястык, мендәр, юрганнарның
Тышлары гел бархет-ефәктән,
Колак мендәрләрнең тирәләрен
Кружевалар белән читләткән...

Шыгырдаган җефәк кружевалар,
Ә төсләре төрле-төрлеләр,
Монда китереп сатсаң аршынына
Һичбер сүзсез ун сум бирерләр...

Уйлар шунда җиткәч, Сафа абзаң:
— «Уф...» дип, бер көрсенеп куя да,
Ләззәтле уй белән, йокымсырап,
Менә тагын шулай уйлана:

«Менә шул сарайларның берсенә,
Бер көн мотлак мин дә керәм, ди.
Күз күрмәгән колак ишетмәгән
Төрле ләззәтләрне күрәм», ди.

Йокымсырап китү белән, Сафа,
Сарай ишеген ачкандай була.
Ялтлап торган көмеш баскычына
«Бисмиллә!.. дип баскандай була.

Менә бердән җитмеш өч хур кызы
Көмеш тавыш белән көләләр,
— Мәрхәба, хуш, Сафа, килдегез!..—
Дип, йөгереп аңа каршы киләләр.

Һәрберсе күптән таныш кебек:
—Әйдә, җаным!—дип сүз салалар,
Алданрак йөгереп килгәннәре
Шундук подручком алалар...

Көнләшәләр Сафа абзаңны,
Бер-берсеннән кызганышалар,
Аны төрле яктан сырып алып,
Көлә-төшеп сүзләр кушалар:

— «Җиде мең ел сине зарыгып көттек,
Әйдә, элек миңа кер, диләр.
Синә хәзерләнгән хөрмәтемне
Рәхим итеп кереп күр», диләр...

Ә аларга каршы башка кызлар,
— «Ул барыбызның уртак яр... диләр.
Башлап үзегезгә чакырырга,
Сездә ни артыклык бар?..»—диләр.

Шулай һәрберсе элек үзен
Башлап тәкдим итә Сафага.
Бик күпләре: «Миңа кермәс ул...» дип,
Төшә бик зур кайгы-хафага.

Сафа шак ката да кала шунда,
Белми тора кая барасын,
Кисеп әйтә алмый, хәйран кала,
Кайсы кызны элек аласын.

Үзенең ике хатыныннан башка,
Аңа таныш кызлар күп кенә
Булган булсалар да... хур кызлары
Каршысында алар чүп кенә

Икәнлеген уйлап бераз торгач:
— «Лутчы сез тотыгыз шобага,
Кайсыгызның кулы очка чыкса,
Шул үз бүлмәсенә мине ала.

Чөнки гүзәллектә, матурлыкта
Сез берегездән берегез артык,
Ничек кенә итеп мактасаң да,
Бетмәс сездә булган матурлык»...

Дигән сүзләр белән хур кызларын
Мактап, үзенең белемен күрсәтә,
Алыш-бирештәге тәҗрибәсен
Искә алып, акыл өйрәтә.

Аның бу сүзләрен ишетү белән
Хур кызларының берсе йөгерә,

(Белмим, аның исме әллә Дилбәр,
Әллә Әсма, әллә Мәстүрә)...

Күп тә үтми ул кыз алып килә
Үзе белән бик озын җефәк.
Хур кызлары шобага тота башлый
Берсен-берсе алгарак этеп.

Алтын беләзекле ап-ак куллар
Җефәк тасма буйлап тезеләләр,
Хур кызлары:
— «Миңа чыкса иде!.. диләр,
(Эчләреннән өзеләләр...)

Аппак кулларыннан чыккан нурлар
Ялт-йолт итеп Сафага төшә...
Кул артыннан куллар өскә үсә,
Күтәрелеп җитмеш өчкәчә...

Бара торгач, куллар урнашып
Бетте озын җефәк тасмага...
«Сафа әфәнде»не башлап кунак итү
«Бәхте» килеп чыкты Әсмага.

Зур өметтә торган хур кызлары
Хәзер нишләргә дә белмиләр.
Сафа абзаңны кулы очка чыккан
Әсма җаннан көнлиләр.

Аптырагач:
— «Такдир шулайдыр...» дип,
Аны күтәреп алып китәләр,
Дәртле ерлар ерлап, хөрмәт белән,
Әсма бүлмәсенә кертәләр...

Йомшак, нурлы куллар уртасында
Барган чакта Сафа тирбәлә,
Күргәч хәйран кала төрле җиһаз,
Белән бизәкләнгән бүлмәгә..

Күргәне юк иде аның мондый
Хөрмәтләрне Мәкәрҗәдә дә,
Әпипәгә, Камалига барып
Өчәр йөз сум акча түксә дә.

Күргәне юк иде бу хөрмәтне,
Зур байларның мәҗлесендә дә,

Корбан чалып, бик күп кунак җыеп,
Бик зур бәйрәм иткән көндә дә...

Каршысына басып хур кызлары:
— «Һәммәбезнең дә син хуҗабыз,
Безләр синең өчен яратылдык,
Синең өчен генә торабыз...

Җиде мең ел буе сине көттек,
Менә бүген килеп күрештек,
Синең белән күрешү бәхетенә
Бүген генә килеп ирештек.

Синең дөньялыкта муллаларны
Чакырып ашаткан һәрбер бәлешең,
Рамазанда биргән фитырларың,
Хәер иткән бакыр-көмешең,

Мәчет алдындагы ятимнәргә,
Карт-корларга биргән тинләрең,
Бик күп синең, җәннәт өмет итеп,
Хәер-садака биргән җирләрең...

«Гамәл дәфтәре»нә язылып барган
Һәр ел саен чалган корбаның,
Корбан итен пешереп мәҗлес ясап,
Укыттырган һәрбер коръаның...

Безгә маглүм иде: аш артыннан
Җәннәт сорап дога кылганың,
Савап өмет итеп, тәһарәт алып
Йөрер өчен тоткан комганың...

Синең шул эшләрең аркасында
Бөтен гөнаһларың җуелды.
Синең хөрмәтеңә бу сарайның
Ишекләре ачык куелды.

Шунда торган җитмеш җидебез дә
Бер ходайдан сиңа бирелдек.
Хөрмәт белән сиңа хезмәт итәр
Өчен каршыңа тезелдек...

Бу сагаттә булсаң Әсма янда,
Аннан безнең янга барырсың,
Чират белән йөреп бүлмә саен,
Рәхәт күреп, ләззәт алырсың...»

Диләр, шатланалар, көлешәләр,
Берәм-берәм килеп күрешәләр.
— «Мин җарияңне кабул итеп ал...» дип,
Һәр кайсысы кулын үбәләр.

Сафа эре генә ул кызларга карап:
— «Рәхмәт!» дия, баш ия.
Бу минутта Сафа берничә йөз
Җариясе булган хан, гуя...

Тәбрик итеп беткәч, хур кызлары
Чыга Әсмасыннан башкасы.
Бер бүлмәдә икәү генә калгач,
Утыралар кара карышы.

Сафа, хәйран калып, искитәрлек
Ләззәт сизә шунда үзендә,
Үз сурәтен күрә ул матурның
Көзге кебек матур йөзендә.

— Әй, матур соң үзе!.. Яңа аткан
Аллы-гөлле чәчәк шикелле.
Нинди матурлар да матурлыкта
Моңа җитмәс... Хур—дек хур инде...

Гөл чәчкәсе кебек кызыл ирен,
Алмадай бит, кашлар кыелган,
Шул матурлык белән куштанлыгы,
Сизгерлеге бергә җыелган.

Аның күргәне бар матурларны
Ике-өч кенә түгел, дистәләп.
Утырганы да бар ул аларны
Сөеп, бергә ашап-эчкәләп.

Хатын-кызлардагы матур сыйфатларны
Нык тикшереп, нечкәләп,
Әмма Әсмадагы матурлыклар
Бетә торган түгелдер сөйләп...

Сафа, ни дип сүз башларга белми,
Карап тора аның йөзенә,
Күңелләрне үзенә тартып торган
Нурлы, матур, серле күзенә.

Бераз торгач, энҗе чәчкән кебек,
Сүз башлады Әсма:

—Җаным! ди.
Сине көттем ничә мең ел буе,
Ишетелде безгә даның... ди.

Синең егетлегең, үткерлегең
Күптән маглүм иде безгә, ди.
«Кайчан гына монда килер икән!..»
Дип, интизар булдык сезгә, ди.

Сине үз янымда күрү белән
Булган кайгы бетте, хәсрәтем.
Синең кебек оста сәүдәгәргә
Насыйп булу безгә бәхет, ди.

Безнең һәммәбезне сиңа хаслап,
Күптән яраткан бер хода, ди.
Мин дә сиңа махсус яратылганмын,
Ышанмасаң менә, кара!—ди.

Дип әйтте дә үзенең аппак кулын
Китереп салды Сафа тезенә.
— Ни әйтәсең моңа?—дигән кебек,
Үзе карый Сафа күзенә.

Сафа, кысып тотып беләгеннән,
Аппак кулның сыртын караса
Аптырый да кала:
— «Менә хикмәт!
Менә шатлык, менә тамаша!..

Чынлап та бит:
«Сафа өчен бу кыз»
Дип язылган аппак беләккә.
Сафа шатлыгыннан:
— Әлхәмдолиллаһи, ирештем, ди, теләккә.—

Менә нинди тормыш!.. Бу тормышка
Җаның корбан итсәң дә ярый,
Сату итеп җыйган акчаларны
Учлап-учлап түксәң дә ярый...

Бу кыз белән кушылу шатлыгыннан
Бер туктаусыз эчсәң дә ярый,
Мондый матур кызның кулын түгел,
Табан астын үпсәң дә ярый.

Мондый җәннәт биргән бер аллага
Аздыр күпме шөкер кылсаң да,
Аның ризалыгын табар өчен
Елга дүрт-биш корбан суйсаң да...

. . . .

— «Җәннәткә мин ничек җиңел кердем?
Мөнкир-Нәкир»не дә күрмәдем?
Кылдан нечкә, кылычтан да үткер
«Сыйрат күпере»н дә үтмәдем.

«Мәхшәр җире»ндә булмадым мин,
Үлчәнмәде «гамәл дәфтәрем»,
Ахры садакаларым аркасында
Җиңел булды авыр эшләрем.

«Бәхет булгач, шулай һәрбер җирдә
Шат торасың, уйнап көләсең...
Бәхтем аркасында гөнаһларым
Гафу ителделәр, күрәсең?..

Нишләр идем әгәр дөньядагы
Төрле хәлләремне белсәләр?..
— «Ник син анда шундый-мондый эшләр
Эшләдең?..»—дип сөаль бирсәләр?

Нишләр идем «фәхешханә»ләрдә
Булган эшләремне сизсәләр?..
Дистәләгән кызлар белән эчеп,
Фарсит иткәнемне күрсәләр?..

Сафа шул уйларда торган чакта
Әсма бер як читкә ишарә
Итү белән, калын атлас пәрдә
Күтәрелде ике уртада.

Пәрдә артында шәрык ысулынча
Зиннәтләнгән зур зал күренә.
Йомшак җефәк көрпә,
Вак-вак мендәр тезгән түренә.

Яшел төстә булган атлас белән
Өретелгән бөтен стена.
Бизәкләнгән өстәл утыртылган
Персидский палас өстенә.

Бу өстәлгә төрле ашамлыклар
Белән бергә төрле эчемлек
Әзерләнгән гаҗәп тәртип белән,
Сафа анда кермәстән элек...

Санап бетерерлек түгел анда
Булган закусканың төрләрен.
Сафа үз гомрендә күргәне дә
Юк боларның кайсы-берләрен...

Төрле гөлләр, төрле чәчкә аткан,
Күрү белән күзләр камаша.
Гөлләр арасында вак-вак кына,
Төрле-төрле кошлар сайраша

Ул бүлмәдән килгән һава белән
Бөркеп тәмле хуш исләр чыга.
Ул бүлмәгә күзне салу белән
Керер өчен күңел ашыга...

Сафа хәйран калып торган чакта,
Әсма аның кулыннан тота:
— Рәхим итсәгез лә, әфәндем,—дип,
Шул бүлмәгә кертеп утырта.

Өстәл тулы төрле-төрле шарап,
Төрле җимеш һәм кош итләре.
Әлван-әлван нигмәтләрне күргәч,
Кымырҗына тамак төпләре...

Сафа, эреләнеп, шатлык белән
Түр башына иплэп утыргач,
Хәзер «чын җәннәт»тә икәненә
Һич шөбһәсез күңеле утыргач...

Бриллиантлар белән бизәкләнгән
Бик зур гына алтын бакалны
Әсма кулына алып, ул бакалга
Салды шунда торган шарапны.

Шуның төсле үк икенче бакалга
Шарап салып алды үзенә.
Бер бакалны Сафа әфәндегә
Такдим итте, карап күзенә.

Сафа үз бакалын Әсма белән
Чәт-чәт чәкештереп алды да,

Төбенә чаклы эчеп, бакалны
Җире куйды Әсма алдына.

Бу шарапны эчкәч, коньяк белән
Шампанский чыкты исеннән.
(Без дөньяда шулай эчә идек,
Дип уйлады үзе, эченнән).

Әсма такдим итә шарапларны,
Сафа аллы-артлы төшерә.
Күп тә үтми, бик шәп кәефләнә,
Бара торгач яхшы ук исерә...

Бераз закускалап ала да ул,
Бик яхшылап тагын да эчә.
Үткән заманнарны искә төшереп,
Бик дәртләнеп сүзгә керешә:

— Беләсеңме, күзем, җан кисәгем,
Мин дөньяда ничек тордым?!, ди.
Оста сату итү аркасында
Искиткеч шәп тормыш кордым, ди.

Ике этажлы шәп йорт салдырдым,
Йөрдем менә дигән атларда.
Һичбер акча кызганып тормадым
Мәкәрҗәгә барган чакларда...

Күрсәң иде минем магазинны,
Исең китәр иде, җанкаем...
Берничә мең сумнар файда итә
Торган идем шуннан ай саен...

Минем приказчиклар минем алда
Песи кебек йөриләр иде.
Минем конторама бер вакыт та
Рөхсәтсез кермиләр иде...

Ялгыз минем тире заводымда
Йөзгә якын эшчем бар иде.
Мин барганда алар, каршымда
Калтыранып торалар иде...

Сизсәм берәрсенең каршылыгын,
Аны шунда ук чыгара идем.
Аның урнына һичбер сүзсез
Эшләүчене алала идем...

Минем байлыгымның каршысында
Алар һәммәсе дә чүп иде.
Берсен кусаң, икенчесе әзер
Тора. Чөнки алар күп иде...

Алар аяк баса алмый иде
Минем тора торган йортыма...
Бик нык ачулансам бирәрсенә
Бирә идем аның сыртына...

Минем мәҗлесемә килә иде
Муллалар һәм таныш, белешләр.
Ашата торган идем мин аларга
Гөбәдия белән бәлешләр...

Оҗмах!..
Дөрес, монда һәр нәрсә бар:
Кош итләре, төрле җимеше,
Шарабы да бик күп, әмма юк бит
«Гөбәдия» белән «бәлеше».

Әх, Әсмакай... Кулда кодрәт булып
Син дөньяга бер барсаң иде!..
Гөбәдия белән бәлешләрне
Сиңа да бер ашатсаң иде...

Валлаһи дим, телең йотар идең!..
Ышанмасаң менә, аш өсте—...
Диде дә ул чиксез бер комарлык
Белән бер стакан тагы эчте.

Әсма аңа:
— Анда тагынниләр эшләдең?
Дип сөальләр бирә.
Сафа аңа каршы:
— Сөйләп бетерерлек түгел,—ди дә кикерә.

Кикерә дә:—Мин, ди, товар алыр
Өчен Мәскәүгә күп йөрдем, ди.
Савва Морозовны, Ивановны—
Һәммәсен дә үзем күрдем, ди.

Әмма байлар да соң чукынганнар!..
Байлыкларын күрсәң исең китә.
Аларның һәрберсе үз алдына
Ничә миллион белән эш итә...

Алар болай урыс булсалар да
Сәүдә өчен яхшылар иде.
Күпме товар алсаң да бирәләр,
Анда безнең почет бар иде.

Шунысы бик кызганыч!..
Хәзер алар,
Яна торганнардыр тамукта.
Мин җәннәттә рәхәт утырганда
Алар газапланалар утта..

Шундый акыллылар, шундый байлар!..
Шундый зур эш күргән әдәмнәр!
Никтер иман китерә белмәгәннәр...
Бер уйлаган чакта әрәмнәр.

Әгәр, алла кушып, безнең кебек
Алар чын мөселман булсалар,
Билләһи дим, син дә яратыр идең,
Әгәр монда килеп торсалар.—

Әсма башка төрле шарап белән
Тутырып такдим итте бакалны.
Һәм дә бирде:
— Хатыннарың ничек иде?..
Дигән серле сөальне.

Сафа ул шарапны тын да алмый
Тамчысына чаклы эчте дә,
Ык-мык итеп торганнан соң диде:
— Алар нигә кирәк соң сиңа?..

— Болай гына сорыйм, мин аларның
Кемлекләрен беләсем килә...
Сафа, теләр-теләмәс рәвештә,
Сүз башлады чытык йөз белән:

— Әй, Әсмакай, сүзең әрәм итеп,
Аларны син лутчы сорама.
Дөресен әйтсәң, алар бәрхәт янда
Чүпрәкләрдән теккән корама.

Алар инде шунда...
Җитәр, әйтмим.
— Я, әфәндем, нәрсә? әйтсәнә!
— Әйтсәм әйтим, җаным: ул хатыннар
Җирәндерә сине үпсә дә...

— Ник соң алай булгач алар белән
Бергә торып, гомер итәсез?
Шундый хатыннарга үзегезне, эрәм итеп,
Ник ир итәсез?..

— Аларны без сөяр өчен түгел,
Йортны карар өчен тотабыз.
Гәүдәләре китсә күз алдыннан,
Үзләре дә шундук онытыла...

Әгәр дә бик ялыксак алардан,
Чигеп тормыйбыз без хәсрәт.
Аларны без күздән югалтабыз,
«Хәрам, талак!..» дисәң өч рәт...

Дөнья хатыннары тиз тузалар,
Тик син белмисең шул, җанашым.
Алар шулай тиз искергән өчен
Берсеннән соң берсен аласың...

Берер бала табу белән алар
Көзге чәчәк төсле сулалар.
Матурлыгын мәңге саклый торган
Сезнең кебек түгел шул алар...

Эчә торгач, Сафа нык исерде,
Шарапларны түгә, агыза.
Шулай исерүенә карамастан,
Биргән берсен эчә тагын да.

Дәртләнде ул хәзер зур дәрт белән,
Нурлы йөзен үпте Әсманың...
Кулын кысып:
— Я, бер ерлап җибәр!..
Дип, ерлавын үтенде аның.

«Әфәнде»се кушкач, Әсма аның
Әмеренә каршы тормады.
Ул бик матур итеп Сафа һичбер
Ишетмәгән бер көй ерлады.

Бу көй бик шәп, әмма ни өчендер
Бик үк ошамады Сафага.
Шуның өчен:—Яхшы ерлыйсың...—дип,
Өстән генә әйтте Әсмага.

Көй бик озын, шуның белән бергә,
Аңлашылмый бик күп сүзләре.
Моннан бик күп артык «Бала Мишкин»,
«Касимский Ибрай» көйләре.

Шуннан соң ул башын чайкап алды,
Кулын әрле-бирле болгады,
Бутады да:
— Мин дә ерлыйм әле
Бер-ике ер, Әсма, тыңла!—ди.

Сафа бер бакалга шундагы шешәдән
Күздәй итеп тутырып алды да,
Бик зур хөрмәт күрсәткәндәй булып,
Куйды аны Әсма алдына.

«Стаканың төпләрендә

. . . .

Русларның сөйгән исме

. . . .

. . . .

Ул карлыккан, ямсез тавыш белән
Ерын чак-чак кына очлады.
Очлады да:
— Бик шәп булыр иде
Скрипка, гармон булса,—ди.

Шулай бик күңелле утырганда
Бик шәп тавыш купты кайдадыр...
Ни дә булса анда бер нәрсә бар,
Ни дә булса анда гауга зур.

Сафа, бу тавышка аптырашка
Калып тәрәзәдән караса,
Ни күз белән күрсен, анда кемдер
Хур, гыйлманнар белән талаша.

Ул кешегә хурлар ялыналар,
Тирәсендә йөгереп йөриләр:
— Әфәндем, кил, зинһар тукта инде,
Кил, зинһар тынычлан!—диләр.

— Бәй, бәй! Бу ни гаҗәп?
Бу бит безнең Мәхмүт бай бит,
Ул нишләп тора?

Кулы белән кемгәдер селтәнә,
Үзе бик ямсезгә кычкыра.

Ул тартыша, дулый, кычкырына,
Һич берәүне санга санамый.
Сафа чыдамады, йөгереп чыгып
Китте, аңа-моңа карамый.

Чыгу белән хур һәм гыйлманнарны
Ерып-ертып керде уртага.
Каршысына басып, хөрмәт белән
Шәпләп сәлам бирде ул аңа.

Ул, Сафаны күргәч, басыла төште,
Тарткалашуларын ташлады.
Сафа:
— Нәрсә булды, Мәхмүт абзый?..
Дигәч, тагын сүзгә башлады:

— Әлхәмделилла без, ходай кушып,
Булдык хәзер җәннәт кешесе.
Беләсең бит, нәрсә тели шуны
Эшли ала җәннәттә кеше.

Минем сараемда бүген бик зур
Мәҗлес ясады хур кызлары.
Шул мәҗлестә иң нык сөйгән кызым
Минем әйткән сүзне тыңламый.

— «Күлмәгең сал, ялангач бие!»—дим,
Ә ул шунда миңа карыша.
Ул җитмәгән кебек, мине мыскыл
Итеп иптәшенә күз кыса.

Ул гына да түгел, бер яшь гыйлман
Минем кызны подручком ала.
Бу хурлыкка чыдар хәлем калмый,
Шунда минем ачу кузгала...

Бу сарайлар белән хур кызлары
Бирелгәннәр минем иркемә.
Ә ул, оятсыз... Көпә көндез
Кулын суза минем милкемә.

Алар белми мине: мин дөньяда,
Миллион белән эш күргән кеше!..

Ни теләсәм шуны эшли алган,
Җиренә җиткергән кеше.

Минем эшләремне дөньялыкта
Меңәрләгән эшче эшләде.
Шулар арасыннан һичберәүсе
Минем сүзгә каршы төшмәде.

Минем алдымда кул каушырып торды
Зур хәзрәтләр, мәшһүр ахуннар.
Шундый бер кешегә карышырга
Монда кемнең генә хакы бар?..

Берничә рәт кердем мөселманнар
Эше белән губернаторга.
Губернаторлардан курыкмаганны
Сездән генә нигә куркырга?

Ничә еллар буе булып тордым
Шәһәр думасының әгзасы.
Ни теләсәк шуны эшләдек без,
Кулда булды шәһәр думасы.

Минем туганнарым, кодаларым—
Һәрбересе мәшһүр кешеләр.
Миллионерлар булып көн иттеләр,
Шулай ул дөньядан күчтеләр.

Минем бер туганым турысында
Риза казый бер китап язды.
Кодам Вәли Яушев вафат булгач,
Баттал китап язып чыгарды...

Менә ул шуларга ачу итеп,
Ташлап чыккан сарай бүлмәсен.
Ачуыннан салган да ыргыткан
Өстендәге «оҗмах хөлләсен.

. . . .
. . . .

ХИКӘЯЛӘР, ОЧЕРКЛАР

СЕРЛЕ БЕР МӘХӘББӘТНЕҢ ТАРИХЫ

I

«...Син аның хакында, аның белән булган мөнасәбәт һәм мәхәббәт хакында тәфсила, шагыйранә иттереп хат язарсың әле. Ләкин хат язганда вак-төяк нәрсәләргә чаклы яз. Син бит аны чынлап та яратасың, син аның алдында булган вакытта бөтенләй үзгәрәсең, үзеңне онытасың, бу бер. Икенче, мин киткәч, аңа булган мәхәббәтең ни дәрәҗәгә җитәр, бу сөю ни рәвешле дәвам итәр... шуларның һәрберсен язарсың әле...» дип киткән идең.

Аерылышу вакты җитеп, кулны-кулга биргәч, син шул сүзләрне тәкрар иттең. Бер-ике минут кадәре кулны җибәрми тордың, һәм:

— «Мин әйткән сүзләрне онытма. Синең башыңнан үтәчәк шушы самими мәхәббәтнең тарихын беләсем килә, чөнки бу мәхәббәт синең хәятыңда бик мөһим урын тотачак. Ихтимал, ул сиңа мәхәббәт мәнбәгы булып, Җәбраил кебек рух биреп торыр, син шуның аркасында, аның аркылы вәхи алып, тагы да ялкынлы шигырьләр язарсың, аның күзләреннән балкып торган хәят нуры сиңа яңадан яңа хәят биреп торыр»,—дидең. Син бу сүзләрне вагон тәгәрмәчләренең шалтырый башлаган тавышлары астында тәмам иттең. Синең иң соңгы сүзең дә: «Син яз, мин дә җавап язармын», булды.

Шушы аерылышуга байтак вакытлар үтте. Бу вакытларның һәр көне, хәтта һәр сагәте, мәхәббәт нурлары белән язылган ләүхәләрдән гыйбарәт бер матур китап рәвешен алып, минем күз алдымда ята. Мин ул китап рәвешен алган мәхәббәтем тарихын һәр көн бер мәртәбә күз алдымнан үткәреп чыгам. Коръән ятлаган казый кебек, кечкенә нөктәләренә чаклы ригая итеп тәкрарлыйм. Менә шул мәхәббәтем тарихын баштан алып шушы мәктүпне

язган минутка чаклы язып сиңа җибәрәм. Бу нәрсә синең күңелендә бөтен бер тәсаввыр калдырсын.

Мин аны сөя башлавымның тарихы болай булды:

Үзеңә мәглүм, сөюдә кешенең ихтияры юк. Һәрбер матур нәрсәне күрү белән, кеше гадәттә шул нәрсәгә соклана, шуны үзенеке итәсе килә. Үзенеке итәргә мөмкинлек тапмаса, даимә шуны үзенә якын хис итә, шуның тәэсире белән исерә. Адәмнәрдәге сөю тойгысы төрлечә була. Кайберәүләр табигатьне, аның аерым кисәкләрен сөя. Кайберәүләр гомуми инсаният дөньясын сөю белән мөбтәла була. Кыскасы, һәр кемдә бер нәүг сөю-сөелү һәвәсе бар. Кай берәүләрдә бу сөю артык көчле булып, ул һәр нәрсәнең үзендә бер матурлык күреп, шуларга бәһа куярга, шулар хакында янарга ярата. Ләкин бу ярату аның ихтиярыннан тыш бер нәрсә була.

Чәчкәләр арасыннан китеп барганда шуларның берсен аерым яратасың, шунда табигатьнең әллә нинди серләрен укыйсың. Ул сиңа якын күренә, аны күңелеңнең эченә утыртып куясы килә. Ләкин аның үзендә шул матурлыктан башка сиңа бер дә мөнасәбәт булмый. Ул синең януыңны, яратуыңны сизми дә, шулай да ул сине яндыра, күңелгә мәхәббәт ялкынын яндыра. Табигатьнең башка кисәкләрен сөюдә дә шушы кагыйдә үзенең хөкемен йөртә.

Бу сүзләр минем «аны» сөя башлау тарихына сүз башы урнына гына язылдылар.

Хатын-кызлар да бакчадагы чәчкәләр кебек. Шуларның арасыннан берсе күңелгә артык якын күренә, матур булып хис ителә. Башта ул хатын-кызның таныш фәлән булуы һич лазем түгел. Үз гомеремдә беренче мәртәбә күргән бер матурны чын күңелдән ятатып, шуның өчен яна башлау вакыйгаләре бик күп очрый. Минем «аны» сөя башлавым да шулай иттифакый күрүдән булып китте. «Ул» башта миңа таныш түгел, чит бер кеше иде. Мин «аны» я урамда күреп үтә яки башка берәр җыелыш урыннарында гына очрата идем. Күргән саен мин аның матурлыгын күреп, аның рухында үземне тәсхир итә[1] торган бер көч барлыгын сизә башладым. Һичбер танышлыгы, мөнасәбәте булмаган хәлдә, ул миңа таныш, минем рухыма бик якын мөнасәбәте булган кеше кебек күренә башлады. Нindидер бер көч мине көннән-көн аңа таба тарта, рухымны аның рухы алдына сәҗдә итәргә өнди, аның гыйшкы белән янарга мәҗбүр итә иде. Очраган вакыт-

[1] Тәсхир итә — «сихерли», үзенә карата.

ларда миңа таба карамый китсә, мин шуның өчен яна, әгәр әз генә күзенең очын төшереп китсә, шатлана идем. Бер дә юкка шулай янып йөрүемдә бер рәхәтлек сизә, шуннан ямь таба идем. Хатын-кызларның матурлыкларын тасвир итеп шигырь яки башка берәр нәрсә язсам, күз алдыма таныш булмаган ... не китереп бастырып, шуңар карап шигырь яза идем. Шул рәвешле йөри торгач, аның матур сурәте минем күңлемә тәмам кереп утырды. Минем күңелнең иң кадерле урны «аңа» тәхет булып әверелде. Мин аны таныш булмаганы хәлдә шул чаклы янып сөйсәм дә, «аның» белән танышуны уйламый, күңлемә дә китерми идем. Беренче танышуым гаять иттифакый бәхеттән генә килеп чыкты:

Ул бер көнне минем бер танышым белән килә иде. Танышым мине күргәч, туктап күреште. Шул ук минутта «аның» белән таныштырып күрештерде. Бер дә көтелмәгән бу бәхеттән мин аптырап киттем, каушап киткән кебек булдым. «Ул» да, электән таныш кеше кебек, минем бәгызе бер язган нәрсәләрем турында сүз башлады. Бу күрешү шул рәвешчә бик садә булса да, минем күңлемдә тагы бик нык эз калдырды. Мин шул көнне, фатирыма кайткач, «Яңа танышым» дигән шигыремне яздым.

Шул танышудан соң, мин аны күргәндә күрешә, аның белән сөйләшә башладым. Хәзер «ул» очраган вакытта күрешә, исәнләшеп китә башлады. Шулай очраган саен, аңа булган сөю хисем арта гына, рухани аңа якынлаша гына бара идем. Ләкин ул, минем үзен сөюем хакында, бер нәрсә дә белми иде.

Бер вакыт шул ук иттифакый рәвештә «аңа» очрадым да, сөйләшеп бара торгач, ул мине үзләренә кереп чыгуымны үтенде. Аның үтенүе, «әйдә, безгә кереп чыгыгыз» дип әйтүе дә бик табигый иде. Мин, көтелмәгән бу чакырылудан бик шатландым, бер дә уйлап тормый, «алар»ның фатирларына кердем.

Бу керүемдә мин аның янында яхшы ук озак утырдым. Мәҗлесенә күрә матур сүзләр дә табылды. Әллә нинди бер мөнасәбәт белән мәхәббәт хакында да сүз ачылды. Мин бу бабта, яхшы ук ихлас белән, бераз сүз сөйләп ташладым. Ләкин сүзләремнең ясалма булмавы маглүм иде. Чөнки мин мәхәббәт хакында ясалма сүзләр булуын уйлый да алмый идем.

Шушы утырыштан соң, безнең рухлар арасында мөнасәбәт башланган, рухларыбыз бер-берсенә якынлашкан

кебек күренде. Бу якынлык минем тарафымда күптән булса да, аның ягыннан бүген генә башланган кебек сизелә иде. Бу якынлыкның тәкәллеф-фәләннән булмавы да күренеп тора иде.

Аларга шушы баруымнан соң, «аны» тагы да бер-ике рәт очратып сөйләштем. Ул инде, бик күптәнге таныш кебек, бер дә тәкәллефсез-нисез сөйләшә иде. Хәзер инде мин дә борынгы кебек каушап китми, үземнең бәгызе бер хисиятемне ачыктан-ачык сөйли ала идем. Аның белән танышлыгым шушы дәрәҗәгә җиткән вакытта, мәсьәләнең серенә син дә төшендең.

Хәтерендәдер, сихырлы, мәхәббәт белән чолганган май аеның иң матур бер киче иде. Бу кичтә нәрсәдер безнең икебезне дә исерткән кебек, гадәттән тыш моңландыра, яндыра иде. Шунда без көймә белән Идел өстендә йөрергә уйладык. Ләкин, вакыт бик соң булганга күрә, бу фикребездән кайттык. «Аларга» каршырак булган алма бакчасында сайрый торган сандугачның моңлы матур тавышы безне тагы да моңландыра, тагы да күңелләндерә төште. Әнә шул кичне бөтен тирә-як серле бер мәхәббәт, әллә нинди моңлы бер матурлык белән чолганып алынган кебек иде. Шунда никтер мин «аларга» керик, дидем. Аларга керергә артык бер сәбәп тә юк иде. Ләкин ниндидер бер көч мине шунда тартты. Мин керә башлагач, син дә каршып тормадың, кердең. Шулай итеп без аларга кергәнебезне сизми дә калдык. Алар безне яхшы ук илтифат белән каршы алдылар. «Ул» бик шат, хәтта гадәттәгедән дә шат иде. Мин «аны» күргәч, үземне оныту дәрәҗәсендә бер төсле сыйфатка кердем, бу синең дә диккатенне җәлеп итте. Шунда син, тик торганчы дигән кебек итеп, мандолинаны алып уйный башладың. Синең, күзләреңне бер урынга текәп, елмая төшеп кылларны чиртеп матур көйне сыздырып җибәрүең, безнең барыбызны да уйга чумдырды. Гүя ки син музыка белән безнең рухларыбыз арасындагы мөнасәбәтне эзли, аларны бер-берсенә тагы да бәйли төшәргә җеп эрли идең. Мин «аның» матур, серле күзләреннән, беләсеңме, башка күзләрдә булмый торган мәгънәле сүзләр укый башладым. Ул шунда күзен тутырып елмая, елмайган вакытта бөтен битен, күзләрен матурлык каплап китә дә, тирә ягына нур чәчә иде. Ул барган саен шатлана, моңая, матурлана бара иде. Мин «аны» элек тә матур, аерым матур күрә идем. Бүген аерым матур күренде. Мин аның илаһи матурлыгы, серле көче тәэсирендә изелә башладым. Ләкин бу изелү башка бер

тәэсир астында изелү кебек тәмсез, авыр түгел, киресенчә, җанга рәхәтлек, матурлык бирә торган бер изелү иде. Бу минутта, гүя минем рухым нур диңгезендә йөзгән кебек йөзә, «аның» көчле матур күз караву белән эри иде. Шул вакытта мин аның матурлыгын үзенә әйтәсем килде. Үзенең матурлык алиһәсы исмен алырга мөстәхыйк[1] булуын үзенә белдерәсем килде. Миндә шушы уй барган саен көч алды. Шулай итеп мин аңа хәмдесәна[2] урнына ярату, мәхәббәт сүзләрен тезеп, аның алдына егыласым килде. Ләкин әллә нинди көч, минем телемне беркетеп, бәйләп куйган кебек, урыннан кузгалырга ирек бирми иде...

Син, кулыңдагы мандолинаны алдыңа куеп, янында утырган теге кеше белән сөйләшә башладың. Шунда мин, үземдә бер көч сизеп, аның йөзенә туйганчы карадым. Аның күзләре, әнә теге кара күзләр, әллә нинди серле караш белән миңа карап, нәрсәдер әйтергә теләгән кебек булып торалар иде. Мин әллә кайчаннан бирле әйтә алмый йөргән: «Син матур, син сөелер өчен яратылгансың, син бөтен матурлыклардан югары, синең рухың һәммә нәрсәдән өстен...» дигән сүзләрне тезеп алып китмәкче булып авызымны ачтым да ләкин әйтә алмадым. Шунда ул минем әйтәчәк сүзләремне әллә кайчан сизеп өлгергән иде, ул минем күз карашымнан рухымның янганын белгән, күзләр аркылы рухлар әллә кайчан бер-берсен сәламләшкән иде. Аның шул матур күзләрендә: «Син бит мине яратасың, шуны әйтмәкче буласың, әйт, мин бер дә ачуланмам, әйт», дигән сүзләр аерым-ачык күренеп торалар иде. Уф, шул вакыттагы күзләр аркылы эчтәге серле мәхәббәт иҗекләренең укылу ләззәтен белсәң!..

Шуннан соң мин аңа: «... кил әле, сиңа аулакта кызык кына бер сүз әйтәсем бар...» дидем. Бу сүз белән мин сезнең шөбһәгезне бетермәкче була идем . Ул, минем бу сүзләремнән көлде дә: «Әйдә, ул нинди сүз икән?..» дип, сөальле бер караш белән елмаеп, күрше бүлмәгә чыкты. Бу вакытта аның йөзендә җиддият катыш бер елмаю күренә иде. Ул минем яныма ук утырып, минем аның үзен әллә кайчаннан бирле гөнаһсыз саф бер ярату белән яратуымны сизгән кебек:

— Я, нәрсә әйтмәкче идең, әйт,—диде дә туп-туры күзгә карады. Мин, Җәбраиле килгән пигамбәр кебек, рухани кабзиятләнеп[3] киттем, балкып торган йөзенә йотлыгып

[1] Мостәхыйк — хаклы.
[2] Хәмдесәна — мактау.
[3] Кабзиятләнеп—каушап.

карадым да, кулын кулыма алдым. Ул, бер дә исе китмәгән кебек, минем әйтәчәк сүзләремне көтә иде. Шуның белән бәрабәр, ул минем сөю хакында сүз башлаячагымны белеп, үзенең хәрәкәт вә мөгамәләсен шуңар муафик рәвештә йөртә иде. Аның шул мөгамәләсе, шул юлда аңлап хәрәкәт итүе миңа җиңеллек бирде. Мин хәзер нәрсә әйтүдән дә тартыну дәрәҗәсеннән үттем. Ул инде мин нәрсә әйтсәм дә гафу итәчәк бер хәлдә күренә иде. Ул тагы бер мәртәбә сөальле караш белән карады. Шунда мин: «Син миңа, үзеңнең матур икәнеңне әйтергә, үзеңне яратырга гына рөхсәт ит, минем үзеңне яратып йөрүем, синең нурыңнан үземнең язачак шигырьләрем өчен ут алганга ачуланма», дидем. Ул матур бер елмаю белән елмайды да: «Мине ул дәрәҗәгә куйсагыз, яратуыгыз чынлап та шулай көчле булса, рөхсәт, яраткан кешегә ачуланып буламени?» диде. Ул, мине каушатмас өчен, бик җиңел, уен катыш кебек итеп мөгамәлә итә иде. Аның сүзеннән соң шушы сүзләрне әйттем: «Әнә теге бакчада сайрый торган сандугач кемне мактый? Ул җәйге айлы төндә көн буе кемгә мәдхесәна яудыра, ул кем өчен яна, ни өчен төн буенча мәхәббәт уты белән сызлана? Ул бер чәчкәгә, әллә әнә күктә йөзгән айга, я булмаса табигаткә гашыйклыгыннан шулай моңлана, сызлана микән?.. Сандугачның сызланганын аның магшукы беләме, сандугачның аның белүендә эше бармы? Юк. Менә мин дә сине шул сандугач чәчкәне яки айны, я булмаса бөтен табигатне яраткан кебек яратыйм, шушы айлы кичтә мин янып, сызланып сиңа мәдхесәна укыйм. Син минем шул сүзләремне тыңла, шул рәвешле яратуыма рөхсәт бир, ачуланма, шул рәвешле яратуыма ачуланмассың бит?..» дидем.

Бу сүзләрнең ясалма булмый, чын күңлемнән чыккан булуын «ул» бик ачык белде булса кирәк, үзгәреп китте, йөзендә мине кызгану хисе заһир булды[1], һәм «Яратуыңа рөхсәт, яратуың өчен шатланырмын гына», диде.

Шул вакыт мин әллә шатландым, әллә аның күз карашы астында җиңелдем, һич уйлап тормый аның рухани көче, җисмани[2] матурлыгы алдында тез чүктем, аның үрелгән чәчләреннән артып, ак яңакларыннан чукланып салынып торган чәчен сыйпап: «Син матур бит!» дип сөальле бер караш белән битенә карадым. Үзенең рөхсәте

[1] Заһир булды — килеп чыкты.
[2] Җисмани матурлыгы — тән, гәүдә матурлыгы.

белән үзенең матурлыгын үзенә сөйли башладым. Үземнең рухымның иркен бөтенләе белән аңа тапшырдым. Менә мин аны шул минуттан соң сандугач чәчкәне яраткан кебек яраттым. Чәчкә тирәсендә йөргән күбәләк кебек рухани аның рухына сәҗдә иттем.

Аның матурлыгын үзенә әйтеп, яратуымны белдерүем, әнә синең белән йөргән май аеның шушы айлы кичендә булды. Ул төн—минем хәятымның иң нурлы, шатлыклы бер сәхифәсен мәйданга китергән көн. Бу төн мин үземнең күңлемдә күптәннән бирле сакланып йөргән мәхәббәтне үзенең урнына куйдым. Әнә шул кичтә ул миңа үзен яратырга рөхсәт итте.

Менә шушы, минем хәятта иң югары урын тоткан кичтән берәр атна үткәч, син... шәһәренә киттең. Киткән вакытта син шушы хатның башында язылган сүзләрне әйткән идең. Минем тарих хәятымда мөһим урын тотачак мәхәббәт тарихының башы шул рәвештә башланып китте. Икенче хатымда моннан соңгы хәлләрне язармын әле. Син минем тарафтан җибәрелгән мәктүпләрне[1] укып, минем мәхәббәтем хакында тулы бер фикер хасил итәрсең дә, үзең әһәмият биргән нәрсә хакында канәгат хасил[2] кылырсың.

II

... Бу мәктүбем элек җибәргән мәктүбемнең дәвамы кебек булыр ахры. Син аерылган вакытта әйткән сүзләреңне хатыңда да тәкрарлыйсың. «Аның» хакында булган мәхәббәтем вә сөюемә гаид[3] нәрсәләрең бик җөзьиләре[4] дә үзем өчен бик кадерле. Шуңа бинаән, мин аның хакында яза башласам, сүземнең артык озынга киткәнен сизми дә калам. Сүзләремдә мантикыйлык[5] бер дә ригая[6] кылынмый торгандыр. Җөмләләр матур тезелмидер, ләкин син хатның тышкы күренешенә әһәмият бирмә. Ул җәһәте синең өчен дә, минем өчен дә мөһим нәрсә түгел. Мин үземнең «аның» белән булган мөхәббәтем хакында сүземне дәвам иттерим, син тыңла. Моны укыганнан соң бу хактагы мәхакәмәңне язарсың.

---

[1] Мәктүп — хат.
[2] Канәгат хасил кылырсың — канәгатләнерсең.
[3] Гаид — бәйләнешле.
[4] Җөзьи — вак кисәк.
[5] Мантикыйлык — эзлекле бер тәртип, бәйләнеш.
[6] Ригая кылынмый — сакланмый.

Шулай, әнә шул көннән, ягни яратуымны аның үзенә әйтеп, аны яратырга үзеннән рөхсәт алган көннән башлап, мин рухымда чынлап та бер үзгәреш сизә башладым. Ул үзгәреш тә: «Көндәлек эшләрне илтифатсыз калдырып, һәр вакытта мәхәббәт хакында уйлау, аны сөюдән хасил булган ләззәт белән рухани азыкланудан гыйбарәт иде». Мин шуннан соң дөньяның вак-төяк нәрсәләрен илтифатсыз калдырып, даимә «аның» хакында уйлыйм. Шул аның хакында уйлаудан гомуми бер мәхәббәт, илаһи бер сөю туган кебек була.

Хәтерендә юкмы, мин һәр вакытта: «Миндә гадәти тел белән тагриф[1] ителмәслек мәхәббәт кайнаша, мин бөтен дөньяның матурлыгын сөям: минем мәхәббәтем өчен җир йөзенең кызлары, былбыллары, кырлары, чәчкәләре, урманнары, таулары, ага торган сулары, кошлары, айлары, йолдызлары—һәммәсе дә мәүзуг[2] булалар» ди торган идем. Шуңа карап, бу саналган нәрсәләрнең һәрберсе минем янган йөрәгемнән чыккан шигырьләремә мәүзуг булалар иде. Вакты белән мин сандугач хакында яздым. Матур кырларны, агар суларны тасвир иттем. Төрле кош-кортлар минем мәсәлләрем өчен мәүзуг булдылар. Җәйге көннең айлы кичләре, кыш көненең йолдызлы төннәре, җир йөзенең челтерәп аккан сулары—һәрберсе ничә мәртәбәләр минем шигырьләрем аркылы зекер ителеп[3] үттеләр. Ул җир йөзенең хур кебек кызлары да мәүзүг булудан котылмадылар.

Югарыда әйтелгән үзгәрештән, ягни аны сөя башлаган вактымнан соң, ул саналган нәрсәләр минем шигырьләремә мәүзуг булу мәртәбәсеннән төштеләр. Хәзер аларда бер җәһәттән караганда шигърият, күңелгә кереп утырырлык матурлык булса да, тик минем сөйгәнем... нең бер сыйфатына охшаганга күрә генә шулай матур күренәләр. Мәсәлән, сандугач сайрауын мин әле дә яратам, ләкин бу яратуым «аның» тавышына ошаган һәм ул мәхәббәткә тәрҗеман булырлык бер моңга малик[4] булган өчендер. Тулган айда әле дә шигърият, серле бер матурлык күрәм, ләкин айның ундүртенче кичәсе «аның» йөзенә ошаганга күрә шулай матур күренә дип беләм. Ал, кызыл чәчкә бик матур, чөнки ул «аның» кызыл иреннәренә ошый. Табигатнең башка матур нәрсәләре дә шулай...

---

[1] Тагриф итү—аңлатып бирү.
[2] Мәүзуг—тема.
[3] Зекер ителеп—искә төшерелеп, әйтелеп, язылып.
[4] Малик—иә.

шундый вакытта күзгә күз очраша да мин тиз генә күземне алам, үзем, оялгансымак булып, кызарып китәм яки урынсыз булса да көләм. Менә, шундый хәлләрдә аның күзендә нур, йөзендә тәбәссем[1] заһир була да шундый матур хәлгә килә ки, аның бу вакыттагы матурлыгы әйтеп бетергесез була.

Бу мәктүбнең башындагы сөаленә җавап урнында язган бу сүзләргә ничек карарсың, үз фикреңне язарсың әле.

Шушы хатны яза башлаган көнне, минем бәхеткә каршы, «аларның» өйләрендә кечкенә генә мәҗлес булды. Бу мәҗлескә мин дә чакырылган идем. Бу мәҗлестә миннән башка тагы бер-ике танышым да бар иде. Мәҗлес башта ук күңелле иде. Мәҗлес мөкәммәл[2] генә хәзерләнеп, бәгызе бер эчемлекләр дә өстәлне матурлап утыралар иде. Бүген мине исертер өчен андый нәрсәләргә артык ихтыяҗ да юк иде. Чөнки мин күрү белән дә рухан исерәм, иң әгла[3] шараплар эчкән бер хәлгә киләм. Бүген бигрәк тә шулай булды. «Ул» бүген башка көннәргә караганда да шатрак һәм рухлырак иде.

Мин католик гыйбадәт ханәләрендә булгалыйм. Аларның шунда уйналган музыкаларын яратам. Әле күптән түгел, мин тагын аларның зур бәйрәмнәренең гарәфәләрендә, гыйбадәтханәләренә бардым. Шунда, гыйбадәтханәнең михрабында, хәзрәте Мәрьямнең бик матур, беләсеңме, руханият өстенә җисмани җәһәттән дә матур рәсме тәбәссем итеп тора иде. Ул, читтән караганда, нурга гарык[4] булган яки үзеннән тирә ягына нур чәчеп торган рәвештә тора, башын бер якка аз гына кыйгайтып, моңлы кеше кебек уйда тора иде. Менә бүген «Ул» да нак шул хәзрәте Мәрьям кебек иде. Аңа карау белән руханый һәм җисмани яктан рухка шатлык китерә, күңелгә матур бер хис тудыра, үзеңне үзең оныттырырлык бер хәлгә китерә иде. Мин «аны» элек тә, һәр вакыт, хәзрәте Мәрьямгә ошата торган идем. Ләкин «ул» бүген бигрәк тә ошаган иде: аның капкара кашы, күзенең агы зур булып уртасындагы карасы руханый бик көчле булуы, битенең озынчарак булып, башын уйга чумган кеше кебек бер якка авыштырыбрак торуы бөтенләй хәзрәте Мәрьямгә охши иде.

---

[1] Тәбәссем—елмаю.
[2] Мөкәммәл—житкелекле.
[3] Әгла—иң яхшы.
[4] Гарык булган—баткан, чумган.

Мин «аның» шул сыйфатына карап: «Әллә кайчан үлгән хәзрәте Мәрьямне тагзим[1] иткәнче, менә шушы хәят мәнбәгы[2] булган... ны тагзим итү әллә ничә өлеш артык», дип уйлый идем.

Мин «аның» хәзрәте Мәрьямгә охшаганын үзенә әйттем, ул: «Чынлап та шулаймыный? Син инде мине әллә нәрсәләргә охшатып бетердең...» дип көлде.

Мин: «Менә бер көнне католикларның гыйбадәтханәләренә барып кара әле, чынлап та син анда үзеңне көзгедә күргән кебек күрерсең» дидем. «Ул» берәр көнне минем белән шунда барырга вәгдә итте.

Бу күңелле мәжелес бик озак дәвам итте. Җәйнең матур төнендә «аның» белән, озак кына иттереп, аларның бакчаларында утырдык. Әллә ниләр, әллә ниләр сөйләп беттем. Эчемлекнең сөйләргә көч бирү хассәсе дә[3] күп ярдәм итте. Мин бу төндә җисмән дә, рухан да исрек идем. Шунлыктан мәҗлеснең үткәне сизелми дә калды. Дөньяның чиксез хәсрәтләрен шундый матур җәйге көндә шарап эчкән хәлдә сөйгәнең янында үткәрү генә бетерә ала. Уф, шундый мәхәббәт кичләре мәңгелек булып китсә, ә... кояшка һичбер ихтияҗ булмас иде.

IV

...Син яну хакында изахат[4] сорыйсың. Син минем януымның бер нәрсәдә чикләнүен телисең. «Аның» хакындагы мәхәббәт мөнасәбәте белән бөтен табигаткә гашыйк, табигат мәфтүне булуымны дәгва кыласың... Минем бере артыннан берсе барып торган мәктүпләрне укыганнан соң, януымның сәбәпләре турысында тулы бер фикер хасил итә алырсың әле. «Аны» сөюем белән бөтен табигатне дә сөюем арасында гаҗиз калырлык нәрсә юк. Мин мотлака[5] сөю, яну өчен яратылган кеше. Син минем хәятымның тарихын күптәннән тагкыйп[6] итеп барасың. Шул вакытларда син даимә минем януымны күргәнсеңдер. Мин бу көнгә чаклы да нәрсәдер эзләдем. Үземнең рухымны сәҗдә иттерерлек көч вә матурлык табарга тырыштым. Күңлемдә-

---

[1] Тагзим итү—олылау.
[2] Хәят мәнбәгы—яшәү, тереклек чишмәсе.
[3] Хассәсе—үзенчәлеге.
[4] Изахат—аңлатмалар.
[5] Мотлака—һич шиксез.
[6] Тагкыйп итү—күзәтеп бару.

ге мәхәббәтне куярга урын эзләдем. Шул максатка ирешү юлында юлда очраган һәрбер матурлыкка баш бөгеп, яшь түгеп киттем. Үземнең рухыма табигат эченнән урын тапкансымак булганга күрә, табигат мәфтүне булдым. Шуның матур якларын күргәндә яндым, сызландым. Менә шулай килә торгач, «аңа» очраштым. Ул гына минем рухымда сакланган мәхәббәтне аңлар, ул гына минем күз яшемне күрер кебек булды. Мин инде «аның» өчен яна башладым. «Ул» кызыл гөл булса, үзем сандугач булдым. Төннәр буе йокламый җырлап чыгу минем өчен ләззәт кенә. Мин барыбер янарга тиеш кеше, мин янам. Янмый, сызланмый үткән хәятны тормыш дип уйлый алмыйм. Андый хәят, андый үлек төсле тормышның һичбер әһәмияте юк. Мин кайда гына барсам да шул януым, мәхәббәтем аркасында гына тора алам.

Мин бу язның бер аен авылда үткәрдем. Торган авылым Дим буеның иң матур урнында, кодрәт кулы белән ярагылган кебек бер җирендә иде.

Авылның сул ягында Дим суы белән, аның әллә кайларга сузылып җәелеп киткән болыны ята. Шул болыннан Дим суы төрле якка борылып, борылып ага. Авылдан караганда, яшел болын уртасыннан төрле якка борылып аккан Дим суы көмеш ука кебек булып күренә. Болынның төрле җирләрендә утырган өем-өем таллар аерым шагыйрәнә булып, болынны бизәкләп торалар. Авылның кыр ягы урман, тау булып, бу як үзенә башка бер матурлыкка чумган.

Шушы матур табигат эчендә утырган авылга бару белән, мин исрек дәрәҗәсенә килдем. Минем мәхәббәт һәм сөю белән мөбтәла[1] булган рухым монда килгәч тә шул сөюендә, шул януында дәвам итте генә түгел, тагы да артыграк яна башлады.

«Ике мәхәббәт бер күңелгә сыймас» диләр. Мин бу сүзгә, бер җенестән булган ике нәрсәне бер үк вакытта бер тигез сөеп булмау хакында әйтелгән сүздер дип мәгнә бирәм. Югыйсә минем «аны» сөюем белән бер үк вакытта шушы авыл табигатен сөюемнең бергә җыелуы, болар хакында януымның бер күңелгә сыйуы бер дә гаҗәп эш түгел.

Мин авылга килгәч, рәтләп чәй дә эчми, югарыда әйтелгән агачлык арасына чыгып киттем. Мин матур бер урынга җитеп, яшел үләннәр арасына егылганнан соң,

---

[1] Мөбтәла булу—дучар булу.

озак та үтми кояш батты. Бу вакытта агач яфраклары арасында, төнләргә урын эзләп йөргән вак кына кошларның канатлары агач яфракларына бәрелеп, матур гына тавыш чыгаралар иде. Кайбер кошлар, үзләренең соңгы сәламләрен әйткән кебек, соңгы сайрауларын сайрыйлар иде. Бераздан соң агач арасы бөтенләй тынлыкка батты. Эңгер вакты җитәр вакытта, әллә кайда, куе яфраклар арасында, сандугач сайрый башлады. Ул үзенең моңлы, дәртле, үткен, тәэсирле тавышы белән мәхәббәт җырларын, сөю көйләрен тезеп алып китте. Менә шул минуттан башлап тирә мәхәббәт, илһам белән тулган кебек булды. Ул шул сайравы белән бөтен табигатне үзенә сәҗдә кылу дәрәҗәсенә китерде. Шул вакытта, сандугачның, мәхәббәт сандугачының, алдына барып тезләнәсем, бөтен табигат исменнән аңа тәшәккер[1] итәсем килде. Ул бөтен табигаткә гашыйклыгыннан шулай сайрый. Аның дәрте эченә сыймаганга күрә талпынып-талпынып җырлый. Үзенең сөйгәнен мактап күккә күтәрә. Ул сайраган вакытта табигат үзенең матурлыгын арттырган кебек булып китә. Сандугачны сәламләп каршылаган кебек булып елмая.

Шул матур табигат эчендә, сандугачның моңлы тавышы астында, мин исердем, серле бер мәхәббәт дәрясында йөзгән кебек булдым. Шул киң мәхәббәтне кочаклыйсым килде. Шунда ятып, мәңге шулар белән бергә каласым килде. Шулар белән бергә, бөтен мәхәббәтне үзенә җыйган гали бер көч янына китәсем килде. Мәхәббәт алласы алдында сәҗдә кыласым килде. Ул алла минем янган йөрәгемне күрсен дә, шунда үзенең кодрәт кулы белән мәңге бетми торган мәхәббәт чәчкәсен үстерсен иде, дигән уйга килдем. Ул тәңре алдында «ул» да булсын иде, теге сандугач та сайрап торсын иде, әнә теге агач арасында күренеп, җиргә көмеш кебек нур чәчә торган ай да үзенең нурын арттыра төшеп, каршыда йөзсен иде, без шунда бергә мәңге бетми, фани[2] булмый торган бер хәлгә әверелсәк иде дим. Мин шунда, «аның» янына гына утырып, мәхәббәт хакында сөйләр идем, күз яшемне аның күкрәгенә тамдырып, үземнең утым белән—гыйшык уты белән аны да яндырыр идем. Мин аның тирә-ягына гөлләр—мәхәббәт гөлләре үстерер идем. Без шул вакытта теге мәхәббәт хакында сайраган сандугачның тавышын тыңлар идек. Мин аның матур күзендә балкып торган

---

[1] Тәшәккер итү—рәхмәт уку.
[2] Фани булу—бетү, юкка чыгу.

нурлар аркылы күкрәгендә янган серләрне укыр идем. Мин шул мөхитнең эчендә өретелгән серләрне, матурлыкларны үземнең шигырьләрем белән тәрҗемә итеп, аңа сөйләр идем, ул шунда чын тормышта, матур мәхәббәт эчендә утырганын күреп шатланыр, көләр иде. Анда түгелгән күз яшем мондагы кебек хәсрәтле, моңлы булмас, бәлки гөл чәчкәсе кебек шифалы булыр иде дип уйлыйм.

Мин шушы хыял белән шул урында байтак вакытлар утырдым. Шунда алган матур уйларны түкми-чәчми генә алып кайтыр өчен әкрен генә торып авылга кайтырга уйладым. Ләкин минем бу кайтырга теләвем табигый кебек түгел иде, мин үзем алга барсам да бөтен бәхет артта калган сизелә, минем артымнан бик зур көч мине тартып, җибәрмәскә теләгән кебек була иде. Серле тынлыкка чумган урманны, сайрап торган сандугачны ташлап, әдәмнәр арасына, вак тормышка, кайту бик зур гөнаһ кебек тоела иде. Күккә карасам, андагы ай һәм йолдызлар мине үзләренә чакырган булалар иде. Авыл янында тын гына агып яткан Дим суы, үзенең кочагын ачып, мине чакырган кебек булып айга каршы көлеп ята иде. Шушы минутта «ул» да, шушы серле кичнең мәгнәсен белеп, әллә нинди уйларда утыргандыр кебек күз алдыма килә иде. Бәгызан[1] үзенең кара чәчен икегә аерып, ак йөзенең ике ягыннан алга таба салындырып, матур күзләре белән күктәге айга карап, агач буйлап киләдер кебек булып китә иде.

Мин фатирыма кайтып кергән вакытта, төннең байтак вакты үткән иде. Урынга яткач та бик озак вакытлар йокыга китә алмый яттым. Ерак түгел су буенда сайраган сандугачның тавышы әле дә ишетелә, ай һаман әкрен генә йөзеп күктән җиргә карый иде. Мин сөйгән нәрсәләр— шул җөмләдән «ул» да, ерак булсалар да минем янымда гына, хәтта йөрәгем эчендә кебек булып сизелә иде.

Авылдагы бер айлык хәятым һәр вакыт бер рәвештә үтте. Галибән[2], кояш чыкканда мин, фатирымнан чыгып, табигать эченә атыла идем. Бер аздан соң өйгә кайтып, кымызларны алып, тагын тау башына чыгып, шуннан тирә-якны карап төрле уйга чума идем. Төштән соң Дим буена төшеп аның тын тугаенда йөри идем.

---

[1] Бәгызан—кайчагында.
[2] Галибән—күбесенчә, еш кына.

Менә, мин шулай авылда да яндым, авылда да гашыйк булып йөрдем. Андагы табигатне сөйдем. Сүз башы «ике мәхәббәт бер күңелгә сыймас», иде бугай. Мәхәббәт бу рәвешле булганда бер күңелгә ун мәхәббәт тә сыярга мөмкин. Бу бит асылда ике-өч мәхәббәт түгел. Бу шул— янган йөрәктән чәчелгән чаткыларның төрлечә булып тармакланып китүләреннән генә шулай булып күренәләр. Мин шулай табигатнең матур җәһәтләрен—һәммәсен дә сөям, шуның белән бергә «аны» шуларның һәммәсенә тәңре итеп таныйм. «Ул» минем сөйгән нәрсәләремнең һәммәсеннән өстен, һәммәсеннән югары. «Ул» аларның бөтенесенә алла.

Бу мәктүпне авылдан кайтыр вактымда яздым. Шәһәргә кайтып «аны» күреп сөйләшкәч, аның нурыннан үземә нур алгач, киләчәк хатымны язармын.

19 . . . ел.

V

Мин... дә шәһәрнең кысынкы тормышына кайттым. Авылда күз җитмәс кырларга өйрәнгән күз, мондагы кысынкы тормышны күргәч, ятсынып китте. Авылда хыял, уй белән мәшгул булган күңел монда эш, эш өстенә (эш) белән мәшгул булачак. Ямсез мөхит мине дә үзенең ямсез тормышына сөйрәп кертәчәк. Мине шул үзенең кысынкы низамнары, әллә нинди бойрыклары, әллә нинди кануннары белән изәчәк. Менә мин шул низам дигән, канун дигән нәрсәләргә буйсынуны, рухымның шулар белән чикләнүен теләмим. Бу дөньяны тарсынган рух андый нәрсәләр эченә ничек сыйсын?.. Мондый әллә нинди вак идеяләргә бина ителеп, шул вак кына хыялларны гамәлгә кую өчен сызылган сызыклар, шул сызыкларның эчендә торырга мәҗбүр булулар—рух өчен бик зур хыянәт. Имеш, синең һәрбер хәрәкәтең низамның бер маддәсенә туры килсен, имеш, син һәрбер эшеңне канунга туры китереп эшлә, шуннан кыл чаклы да аерылма, имеш, син һәрбер эшеңнең хакында шул кануннар буенча мәсьүлсең[1]!.. Шушы ямсез, рухка хилаф булган нәрсәләрне йөкләргә мәҗбүр булу кебек авыр нәрсә булырмы?.. Шушы нәрсәләргә баш иярга сине көчләп мәҗбүр итәләр. Шуңа итагәт итмәде исәң тиешле җазаңны көт тә тор!.. Вак әдәмнәрнең башбаштаклык һәм хыянәтләрен чикләү өчен чыга-

---

[1] Мәсьүл—җаваплы.

рылган шундый вак нәрсәләргә, шуңа һич катнашы булмаган кеше дә итагат итәргә мәҗбүр. Синең хөрриятеңне әллә нәрсәләр белән чикләп, рухны үрмәкүч авына эләккән чебен кебек тоталар. Бу көчләүләр шәһәрдә бигрәк ачык күренә. Атлаган саен, низамның берәр маддәсенә хилафлык итмәдем микән дип, куркып атлыйсың. Шуның өчен, шәһәр тормышы хөр һәм иркен тормыш түгел. Мондагы тәкәллеф, мондагы ваклык минем рухыма бөтенләй хилаф. Шунда да шушы кысынкы, ямсез тормышка кайтып керергә мәҗбүр булына. Монда, дөньяны төзәтәм дип, әллә ниләр, әллә ниләр эшләп йөриләр. Ләкин мин бу халыкның мәҗелесеннән ике тиенлек тә кызык тапмыйм. Минем рухым бу тормышка бөтенләй чит. Имеш, бүген фәлән урында җыелыш, фәлән мәсьәләләр каралачак, шунда бар да әллә ни чаклы гомереңне үткәр имеш!.. Миңа ул җыелышның, ул мәсьәләләрнең ике тиенлек тә тәгаллекы[1] юк. Әнә кич булу белән күктә ай калкып чыкты, әнә йолдызлар берәм-берәм күренә башладылар. Әнә, әкрен генә искән сәба җиле белән агач яфраклары селкенешеп нәрсәдер сөйләшәләр, әнә тегендә бер матур, үзенең сөйгәнен исенә төшерепме яки табигатнең матурлыгын күрепме, бик моңлы тавыш белән җырлый... Менә минем өчен чын хәят шуларны тамаша итүдә, шуларның серләренә төшенүдә генә. Әгәр дә шулар булмаса, миңа да хәят булмас иде. Менә кич, айлы кичтә үземнең сөйгәнем каршында, аның сүзен тыңлап утыру, шул гына миңа хәят бирә, шул гына минем тормышымны тормыш итә ала.

Шәһәр тормышының шул магнәсез яклары шәһәргә керү белән рухка кер салган кебек булды. Мин үземне пычрак бер мөхиткә кергән кебек хис иттем. Кайту белән «аларга» бардым. «Аны» күреп, шәһәрнең биргән ямсез тәэсирен җуймакчы булдым. «Ул» минем кайтуымны белмәгән иде. Безне күрү белән «ул», тулган ай кебек балкып, каршы чыкты. «Ул» бик матурланган, бите яңа гына пешеп алланган алма кебек кызарган иде. «Ул», күрү белән, әллә кайдан көлеп:

— «А, авылга кымызга киткән кешеләр кайтты!..— дип, шатлык белән каршы алды. Аның рухындагы матурлык йөзенә чыгып, битендә балкып тора иде. Мин аңа әллә нәрсәләр, авыл хәятларын сөйләмәкче булып кайткан идем, үзен күргәч бу уйларымның һәммәсе дә әһәмиятсез кебек тоелды. Сөйләргә теләгән нәрсәләремне, хәлфә алды-

---

[1] Т ә г а л л е к—бәйләнеш.

на барган бала кебек, оныттым да калдым. Теге сандугач сайрап тора торган кичләрдә хыяли күз алдымда тәҗәссем[1] иткән матурның хәзерге минутта үземнең каршымда басып торуы күңелдәге нәрсәләрнең бөтенесен оныттырды. Ул бүген бигрәк шат, бигрәк күңелле иде. Авылның матур тормышын ташлап шәһәргә кергәннән соң алынган ямсез тәэсир, күңелсез манзара[2], хәзер матурлыкка әйләнде. Бер ай буенча моның йөзен күрми тора алуыма хәйран калдым.

Барган җиреңдә сагынылган бер кешене күреп сөйләшү, аның нурлы йөзен күрү кебек күңелле нәрсә булырмы?.. Мондый вакытта сүзләр матур чыга, йөзгә нур тула, бер-береңне йотардай булып рухланып утырасың. Ул бер ай эчендә үткәргән тормышыннан байтак нәрсәләр сөйләде. Мондый вакытта мин аның сүзләренең магнәсен уйлаудан бигрәк, шул сүзләрне сөйләгән вакыттагы матурлыгын карыйм. Ул аны үзе сизми. Сандугач кебек, сүзләрен тезә генә бирә. Хәлбуки, мин кай вакытта аның сөйләгән нәрсәсенең магнәсен искәрми калам.

Авылдан кайтканнан соң аның белән булган мөнасәбәт, шул рәвешле, мәхәббәт нигезенә корылып барды. Мин аны яратканнан-ярата бардым. Эшләр шулай бик күңелле барганда мин аның каршында бик зур гөнаһлы булдым. Сөйгәнең каршында гөнаһлы булу чыннан да авыр һәм күңелсез нәрсә бит!.. Бу эш болай булды:

Син, минем кай вакытта эчеп, бөтен дөньяга төкереп, мәхәббәт исреклеге белән хәмер исереклеген бергә җыеп, кәеф-сафа сөрә торган гадәтем бар икәнен беләсең. Эчү, исерү өстән караганда ямсез нәрсә. Мин исерек кешене яратмыйм. Ләкин күңелдә ялкын булып, эчүнең төп магнәсен белеп, хәмерне мәхәббәт уты белән бергә яндырсаң, гади кешеләр аңламый торган бер нәтиҗә, бер рәхәтлек бирүен беләм дә, шул рәхәтлеккә ирешү өчен эчәм. Күңелендә мәхәббәт уты булмаган гади кешеләргә эчү һичбер тиеш түгел. Чөнки алар барыбер аның магнәсен аңламыйлар. Аларның тупас табигатьләре хәмер белән нечкәрми, бәлки тупаслана, ямсезләнә төшә. Хәмер миңа бөтенләй башкача тәэсир итә. Мин аны эчсәм бөтен нәрсәләрне үтә күргән кебек булам. Каршымдагы нәрсәләр, кешеләр үзләренең эчләрендәге серләрен яшерә алмыйлар. Алар үзләренең шул минуттагы яшерен уйларын үзләре үк укып

---

[1] Тәҗәссем итү—гәүдәләнү.

[2] Манзара—күренеш.

торган кебек булалар. Моннан башка хәмернең күңелдәге кер һәм тапны калдырмый, сафландыру хасияте бар. Хәмернең бу хасияте, ихтимал, миңа гына сизелә торгандыр. Шулай да ул, дәрәҗәсеннән үтмәсә, күңелне, чынлап та кешенең күңлен керсезләндерә, гөнаһсыз ясый. Бу хәлгә килгәндә минем алдымда һич пәрдә, яшерен сер, гали куәт калмый. Фәкат мин үзем генә калам. Эчүнең иң матур чиге шушы халәттә була. Шул халәттә туктаганда мин ачылып китәм. Пигамбәрлек итәм. Күңлемдәге хәсрәтләрне юып ташлап, сабый бала кебек гөнаһсыз бер хәлгә киләм. Ләкин мин эчү бабында кай вакытта ифрат китәм. Мин эчүнең бу дәрәҗәсендә үзем генә калам. Минем халәт рухиямне чыннан да аңлаган яки минем мондый хәлгә килгәнемне электән күргән кеше бер дә гаҗәпсенми. Чөнки ул минем айнык вакытта янганымны күреп, тагы да янар, дөньяны онытыр өчен эчкәнемне бик яхшы белә.

Менә шундый бер чиксез эчкән вактымда «аларга» барган идем. Ул вакытта ул өйдә иде. Ул мине башка вакыттагы кебек ригая итеп каршы алды. Мин аның янына утырып фәлсәфә сата башлавым хәтеремдә. Менә мин шул вакытта бәгызе бер сүзләр белән «аны» көнләү дәрәҗәсенә җиткәнмен. Аның керсез күңлен керләрдәерәк магнәсез сүзләр әйткәнмен. Бу сүзләр, бу утырулар томан аркылы күренгән нәрсә кебек кенә хәтеремдә калган. Китәр вакытта мин үземнең хата фикердә булып, тиешсез сүзләр ычкындырганымны аңлап алдым. Минем бу тиешсез мөгамәләм, аны көнләү дәрәҗәсенә җитүем аның миңа булган карашын үзгәрткәндер дип куркып, мөгамәләмне яхшырттым, хаталарымны төзәтергә тырыштым. Эш шул дәрәҗәгә җиткәч, мин курешеп кайтып киттем. Иртә белән кичәге эшләр һәммәсе күз алдына килеп бастылар. Мәсьәләне баштан аяк тәхлил[1] иттем. Вакыйгаләрне берәмләп күз алдына китереп тәртипкә салдым. Гөнаһның үземнең якта икәнен уйлап: «Ул инде моннан соң мине күрмәскә гаһед[2] иткәндер, бу соңгы күрешүе булгандыр», дигән карарга килдем. Моннан соң аның гыйшкы белән янсам да, аларга бармаска, аны күргәндә ничек тә читкә китәргә уй беркеттем. Бу эш минем өчен үлем белән бер булса да, минем гөнаһымны шулай иткәндә генә бер нәүә бетереп булыр төсле күренде.

Шул аны күрмәскә карар биргәннән соң, мин үземне

---

[1] Тәхлил итү—тикшереп чыгу.
[2] Гаһед—ант, вагдә.

ятим бала кебек хис иттем. Минем бу тәэсиремне тирә ягымдагы бөтен әшиялар[1] белгән кебек булды; агач яфраклары бер-берсенә бәрелеп мине сөйлиләр, мине кызганалар кебек тоелды. Ай да ялгыз гына моңланып, ялгызлыкның хәсрәтен, авырлыгын әйтә кебек сизелде. Кайда гына барсам да күңелсез бер моңлылык күрә идем. Күңелнең бер ягы аларга барып, аннан гафу үтенергә куша, шуңа дәлилләр эзли. Икенче ягы, шул аерылу сәбәбеннән, үлгәндә дә бармау ягын куәтли иде. Мин шушы ике көчнең муазәнәтен[2] ике көн саклап йөри алсам да шуннан артык сабыр итә алмадым. Беренче көнне, йомышым булмаса да, аларның йортлары яныннан үтеп киттем. Кечкенә генә бер сылтау тапсам да керәчәк идем, ләкин таба алмадым. «Ул» үзе дә күренмәде. Шуннан кайткач, «Адашкан гашыйк» исемендә шигырь яздым. Чыннан да мин хәзерге минутта караңгы урында, юлсыз калып адашкан кеше кебек идем.

Икенче көнне мин алар яныннан үтеп барганда, алар гаиләсеннән берәү очрап: «Әйдә, нигә безгә керми китәсең, бу арада син бик сирәкләдең, ул нинди эш!..» дип мине көчләгәнсымак алып керде. Бу эш минем өчен бик зур һәм урынлы сылтау булды. Мин, зур гаепле мәхкум кебек, курка-курка гына кердем. Аңа очрый калсам, ул да минем белән сөйләшсә, ни рәвешле сүз башларга кирәк икәнен алдан тәгаен итеп куйдым. Мин, залга кереп, үземне алып кергән кеше белән гади сүзләрне өстән генә сөйли башладык. Ләкин «ул» күренми иде. Бәгъзе бер галәмәтләрдән аның өйдә икәне беленеп тора иде. Ул минем килгәнемне, үзе өчен янганымны белә торып та һаман чыкмый иде. Мин бу кеше белән сөйләшеп утырсам да һичбер сүзем мантыйклы булып чыкмый, җөмләләрем арасында бәйләнеш тә күренми иде. Мин инде утырырга да, чыгып китәргә дә белми ике уртада калдым. Минем өчен эшнең төбен аңлап, аның үпкәсе ни дәрәҗәдә икәнен белеп, шуңар үлчәп эш күрү мәтлүп[3] иде. Шул рәвешле байтак утырганнан соң, ул үзенең бүлмәсеннән чыкты да, салкынрак күрешеп, исәнлек сорашудан башка сүз әйтми, үз юлына китте. Аның бу хәрәкәте, бу үпкәсе озак дәвам итмәвен белсәм дә бик күңелсезләндем, аңа түгел, үземә үзем ачуландым. Алдымдагы кояшым болыт асты-

[1] Әшиялар—әйберләр, нәрсәләр.
[2] Муазәнәт—тигезләнү.
[3] Мәтлүп—кирәк, яхшы.

на кереп югалган кебек булдым. Күңелемнең иң авырткан җиренә чәнечкән кебек тоелды. Бүген алардан нииһаят дәрәҗәдә кайгылы рәвештә кайттым. Шул тәэсир белән «Болыт астындагы ай» дигән шигыремне яздым. Бу хат шушы айның болыт астына яшеренгән күңелсез вактындагы күңелсез сүзләр белән тәмам булды.

VI

...Мин һаман да аны сөю белән мөбтәла. Бәгызан мин аны бөтенләй онытырга уйлап, үземнең хосуси эшләремә керешмәкче булам. Язарга керешкән башка әдәби әсәрләремне тәмам итәргә уйлыйм. Ләкин булмый; ул минем күз алдыма килеп баса да бөтен планнарымны җимерә. Гүя ки ул миңа: «Бу магнәсез дөньяда вак нәрсәләр белән вакыт уткәрмә, фани дөнья фәкать мәхәббәт аркасында гына матурлана ул, хәятның бөтен матурлыгы шунда гына, син мәхәббәт белән генә үз рухыңны яшәртә аласың, тормыш артыннан йөрүне үзенең әһелләренә куй, алар шул вак тормыш артыннан чапсыннар» ди. Үзен күргәндә аның бөтен вөҗүде шуны укый. Күзләре белән минем җанымны үзенә әсир итә. Аның бер мәртәбә елмаеп каравы төннәр буена рухымны мәшгуль итәргә җитә.

Әвәлге мәктүбемдә аның миңа карашы үзгәргәнен язган идем. Шул мөнасәбәт белән мин аны онытырга тырышып карадым, булмады. Мин, шәм тирәсендә очып йөргән перванә[1] яки чәчкә тирәсендә йөргән күбәләк төсле, аның тирәсендә йөрүдән үземне коткара алмадым. Аның салкынлык күрсәтүе минем мәхәббәтемне арттырды гына. Шул вакыйгадән соң аларга тагы да бардым. Бу вакытта ул ялгыз иде. Бу күрешүдә ул борынгы кебек салкынлык күрсәтмәде, мине гафу иткән кебек хәрәкәт итте. Мин сүземне аның хәтерен калдыру ягына бордым. Ул минем игытизар[2] урнында сөйләгән сүзләремне әһәмият биреп тыңлады. Шуннан соң аның йөзендә борынгы көләчлек, сүзендә борынгы мөлаемлык туды. Шулай итеп мин аның бәхиллеген алдым, минем хакымда булган ышанычсызлыгын бетердем. Минем шушы лайобали[3] хәрәкәтемнән туган кечкенә аңлашылмаудан соң миңа борынгы матур, ышанычлы карашы белән карый башлады. Моннан соң аның хәтерен калдырмаска үз-үземә вәгдә

[1] Перванә—күбәләк.
[2] Игытизар—гафу үтенү.
[3] Лайобали—игтибарсыз.

бирдем. Күрәсең, ул миңа чынлап ачуланмагандыр, ул чынлап ачулана беләдер дип ышана да алмыйм. Андый матур, саф рухта гади адәм балаларында була торган ачу сыйфаты булырга мөмкинме соң?.. Имеш шундый фирештәдә гади адәм балаларында була торган ачулану дигән ямсез сыйфат булсын!.. Ул бик рәхимле, аның шул матур сыйфаты йөзендә балкып тора. Аның көзге кебек җаны, сөт кебек ак күңле бөтен таплардан мөнәззәһ[1]. Аның миңа ачуланган кебек булуы, шулай уйлаганымнан гына килгән бер нәрсә, соңра, аның шулай булуы минем ямсез булган бер гадәтемне бетерергә генә ярдәм итте. Мондый эш, ягни аның ачуы, пигамбәрләрдә булган рәвешле мине кызганудан гына чыккан бер нәрсә икәнен, мин аның хәрәкәтләреннән аңлыйм. Ул дәрәҗә генә ачу, икенче магнә белән әйткәндә минем урынсыз кыйлануымны үземә белдерер өчен генә булган хәрәкәт, ходайда гына була торгандыр дип уйлыйм.

Шулай итеп, мин шул вакыйгадән соң аны тагы да матур күрә башладым. Гарәп шагыйре әйткәнчә: «Аның йөзенә караган саен, йөзе матурлыгын арттыра гына бара». Аның йөзен эчемнән генә ихтирам итеп утырам. Бәгызан аны сөйсәң иде, матур битен бер генә рәт үпсәң иде, дигән уйга киләм. Ләкин бу эш аның хөрмәтен югалтыр, дәрәҗәсен төшерер кебек була да фикеремне кире алам. Мондый эш андый алиһаның голвиятен[2] югалтыр кебек була, минем сөюемнең бәһасын бетерер төсле күренә. Шундый вакытта мин бик авыр бер хәлдә калам. Ник соң аның белән күрешкәндә кулын гына үпмәдем, ник матур чәчен бер генә рәт сыйпамадым, дигән уй белән үземне борчыйм. Күрешеп киткәннән соң үземне үзем шелтәлим. Шулай итсәм минем янган рухыма шыйфа булыр иде, ул миңа тагы да рух бирер, мин тагы да әллә нәрсәләр язар идем, дип уйлыйм. Аннан аерылган вакытта күңлемнән әллә нәрсә өзелеп төшеп калган кебек була. Бик зур бер нәрсә югалткан төсле булам. Аны күрүем өчен ни чаклы шатлансам, аерылып китүем өчен шулай хәсрәтләнәм. Аны сөймәгән булсам бу хәсрәт, бу кайгыру булмас иде дип уйлыйм. Ләкин чынлап уйласам, бу эшләрнең һәммәсе аны саф сөюемнән килгәнен беләм. Мин ахры чиксез сөю өчен яратылганмындыр, ахры шул гыйшык, мәхәббәт бабында ут йотып йөрер өчен туганмындыр.

---

[1] Мөнәззәһ—ару, пак.
[2] Голвиятен—бөеклеген.

VII

... Син теге мәхәббәтнең дәвамы хакында сорап, бу сөалең белән минем күңлемдәге җәрахәтне ачарга сәбәп буласың. Мин инде бу хакта бер сүз дә язмаска, бу «серле мәхәббәт» не шул серле көенчә калдырырга үземә гаһед биргән идем. Чөнки мин бу хакта күп яндым, матур төннәрдә күзләремне дә йоммый күп уйландым, аны сөя башлаган көннәреннән башлап бу көнгә чаклы тик аның сурәтен күз алдымда тотып, тик аңар гына табындым. Аны күргән вакытларымда үземне онытыр бер хәлгә килеп, җанымны аның җаны—гәүдәсе алдында кол иттем. Менә шушы рәвешле сөюнең нәтиҗәсе мин уйлаганча булып чыкмаганын күреп, бу «серле гыйшык» ның кулыннан үземне үзем азат итү юлына кердем. Минем бу сүзләрем сиңа бик кызык тоелыр, син шул чаклы сөйгән... не онытырга теләвемә тәгаҗҗеп[1] итәрсең... Ләкин менә минем ошбу хатымда язылган соңгы сүзләрне укыгач, мине магзур күрерсең.

Сүзне «серле мәхәббәт» хакында башлыйм.

Бу сөюне серле мәхәббәт дип йөрүемнең сәбәбе шушы:

Югарыда әйтелгәнчә, минем аны янып сөюем бер кемгә дә маглүм түгел. Моны бер кемгә дә белдермәскә тиешлелеге хакында үземә үзем гаһед бирдем. Бу сөю шулай серле булырга, әдәм балалары белү дәрәҗәсеннән югары торырга тиешле. Хәтта ул үзе дә минем ни чаклы өзелеп сөюемне, моның галилеген мин аңлаганча аңлый алмый торгандыр. Мин аны илаһи, гөнаһсыз, магсум[2] сөю белән сөям. Минем сөюемдә тузан чаклы да кер, ярма чаклы да хәйлә юк. Чөнки мин аны ихтиярсыз сөйдем, андагы матурлыкны күзлексез күңлем күзе белән күрдем, аның рухында янган ялкынга пәрдәсез ирештем. Ләкин минем шул чаклы саф сөюемне ул аңламаска тырышты, икенче төрле әйткәндә, минем йөрәгемдә янып, балкып торган мәхәббәт нурлары аның тибеп торган күкрәге астына яшерелгән йөрәгендә гакс[3] итмәде. Күп тәҗрибәләрдән соң, мин аның минем мәхәббәтемә бәһа куя белеп-белмәве хакында шөбһәгә төштем. Әгәр дә ул минем мәхәббәтемә бәһа куймый икән, әгәр дә ул вак сөюләр белән минем изге, олуг сөюемне аерып ала алмый икән—аны көчләндереп сөюемдә һичбер магнә калмаячак. Минем җәүһәрем урынсыз җиргә әрәм булачак, дигән уйга

---

[1] Тәгаҗҗеп — гаҗәпләнү.
[2] Магсум — саф, пак.
[3] Гакс итмәде—чагылмады.

килдем. Мәхәббәт һәм самимият[1] бер яктан гына булганда аның рухка азык бирә алмавына төшендем. Аны тәҗрибә итү хакында тоткан юлымны аңлатыр өчен, түбәндәге сүзләрне язам:

Мин анда, соңгы вакытларда, әллә нинди рухани үзгәрешләр күрә башладым. Шушы үзгәрешләрдән соң мин аны һәр вакыт тышкы сыйфатка карап йөргәнсымак күрәм. «Ул» минем үзе өчен янган йөрәгемнең аһларын күрми, минем күңел җәрахәтен сизми төсле күренә. Ул үзенең күңел көзгесе белән минем күңлемне күрергә, мине шуңа карап такдир итәргә тиеш иде. Ләкин анда шул эчке хиссиатка игтибар итү, шуңа карап мәхәббәтнең дәрәҗәсен тәгаен итү тойгысы күренми. Минемчә, нәрсәнең яки берәр кешенең тышкы гүзәллеген күреп, шуңа гына хайран калу, эчке хасиятләрне[2] бөтенләй күздән төшерү—хакыйкаткә, бигрәк тә мәхәббәтнең чын магнәсен аңлауга маныйг[3] буладыр. Тыштан караганда бик матур кешеләр була ки, ләкин аларның рухларында бер тиенлек тә хикмәт булмый. Андый кешеләр чын матурлыкның нәрсә икәнен белмиләр, шунлыктан аларда чын ярату белән ярату, мәхәббәт нурлары белән балкып яну дигән нәрсә булмый. Шуның өчен андый кешеләр матурлыкка чын бәһа куюдан гаҗиз булалар. «Син матур, мин сине үлеп яратам», дигән сүзләрдән башка сүзләр таба алмыйлар. Мәсәлән, мин аны ятатып, аның артыннан йөреп гыйшык хакында лаф оручыларны, аның матур күзләренә карап һуштан яза язып утыручыларны күрәм. Алар аның вежүдендә бөтен матурлыкларны таба торганнардыр, җаннары белән аның хакында әллә ниләр эшләмәкче булалардыр, ләкин алар аның бәһасын белүдән, аны чын магнәсе белән такдир итүдән бик күп түбәннәр. Алар чәчкәне бер сагәтлек кызык өчен өзеп алып та, соңра урамга ташлап китә торган тәрбиясез балаларга ошыйлар. Мин аның хакында энҗе кебек шигырьләр язып, аның матур сыйфатларын көмеш кебек ак кагәз өстендә энҗе тезелгән кебек тезгәндә, аның гади күзләр күрә алмаслык матурлыкларын күреп дөньяга чыгарганда, теге бичара «гашыйклар» аның хакында бер юл язудан гаҗизләр. Аларның күңел күзләре сукыр, рухлары тупас булганга күрә, аның матурлыкларын тасвир итүдән мәхрум-

1 Самимия́т — чын күңелдән, эчкерсез.
2 Хасият—үзенчәлек.
3 Маныйг—киртә.

нәр. Тыштан караганда әдәм сыйфатлы булып та рухлары шундый тупас булган бу бәндәләр хакында нәрсә әйтергә? Илаһи булган серле мәхәббәтне бәрәңге, шалкан белән бер күргән бу гашыйклар турысында ни сөйләргә?.. Менә аның шундый бәндәләрнең яратулары белән минем яратуымны бер күрүенә, бәгызан аларга әһәмият биреп каравына рухан янам, ярату хакында аның рухка карый алмавын, йөрәккә карап хөкем итмәвен күреп аптырыйм. Мин бу көнгә кадәр бик сизгеч, нечкә йөрәкле дип йөргән... нең мәхәббәтне шулай гади кешеләр аңлаганча аңлавын күреп хәйран калам. Кай вакытта, «Ул аңлый торгандыр, ләкин минем назлы йөрәгем белән уйнар өчен юрамал шулай хәрәкәт кыйла торгандыр» дигән уйга төшәм. Һәр ике хәлдә дә мин үземнең кодеси[1] сөю белән сөюемне гади сөюләр белән алмаштырасым, илаһи мәхәббәтнең кодсиятен югалтасым килми, шуңа күрә бу гыйшыкны инде ул үзе дә белмәсен, бу сөю «серле мәхәббәт» нең нурлы бер тарихы булып кына калсын дигән уй белән, мин аны онытырга тырышам, моннан соң аны күрми, аның өчен януымны үзенә белдерми читтән генә янып йөрмәкче булам. Шулай итеп, әкренләп мин аннан бизә алырмын, иң азында йөрәкнең әрнүе бераз басылыр дип уйлыйм. Шулай итеп мин ничек тә аннан күңлемне биздерергә тиешле. Әле соңгы вакытларда минем шушы эшем файдасына аның тарафыннан бәгызе бер эшләр дә сизелеп үтте. Бу эшләр өчен әчтән януымны яшерә алмыйм. Ләкин ул чын мәхәббәткә бәя куюдан түбән булса яки белә торып шулай хәрәкәт иткән булса мин шул юлны тотарга, мәхәббәт утларын үзем генә йотарга мәҗбүрмен. Мин мәктүбемнең башындарак аның тышкы сыйфатларга әһәмият биргәнен язган идем бит. Аның шул эше барган саен сизелерлек бер хәлгә килә башлады. Башта мин аның бу эшенә карап, әлбәттә, борчылдым. Аның кебек җир фирештәсенең вак халыклар гадәтенә нярүенә ачындым. Аны үзенең гали тәхтеннән, шагыйрьләр генә күрә торган дәрәҗәсеннән төшә башлаган кебек сиздем. Минемчә, ул олуг булырга, үзен ваксытмаска, үзе рухан бер кемгә дә сәҗдә итмәскә, бәлки башкалар аның алдында табынырга тиеш иде. Ихтимал, минем бу фикерләрем аны ниһаят дәрәҗәдә олуг күрүемнән яки аны башкалардан көнләвемнән килә торгандыр...

[1] Кодеси — изге, мөкаддәс.

Лəкин ни генə булса да, бу уйның кирəк кайсын гына алсаң да бу сүзлəр аның хөрмəтенə язылалар. Чөнки андагы матурлык, бик сирəк хатын-кызларда гына була торган җазибият[1], бер мөхəррир яки шагыйрьне тəрбия итəргə, шул мөхəррир яки шагыйрьгə рухани азык биреп торырга, шуның рухын үстерергə лаеклы булып яратылган. Ихтимал, аны ходай үзенең матурлык сыйфатын белдереп торыр өчен, шагыйрьлəр аның йөзенə карап əллə нинди серле шигырьлəр язсын өчен яраткандыр. Əгəр дə мин əйткəнчə ул шулай илһам бирү кодөсиятен югалтса, үзенең матурлыгыннан шагыйрьлəрне мəхрүм итсə, аның аерым рəвештə яратылган җазибияте əрəм булачак, матур чишмəнең комлы сəхрага кереп югалып əрəм булуы кебек, файдасызга əрəм булачак. Йөзенче мəртəбə əйтə торгандырмын инде: аның бөтен вөҗүде матурлык нуры белəн сугарылган. Аның шул матурлыгыннан талантлы бер шагыйрь əллə нинди серле илһамнар алачак, мəхəббəт шəрхе[2] хакында əллə ни чаклы могҗиз[3] шигырьлəр язачак. Менə ул шул серне аңларга, «серле мəхəббəт» кə бəя куярга тиеш иде. Үзенең нуры тирəсенə килеп очкан күбəлəк кебек бер шагыйрьне үзенең нурыннан, серле карашыннан мəхрүм итмəскə тиеш иде. Əгəр ул моның киресен эшли икəн, үзенең матурлыгын шагыйрьлəрнең шигырьлəренə мəнбаг[4] булудан саклап, икенче бер нəрсəгə əрəм итə икəн, əлбəттə, бик зур җинаять иткəн булачак. Шуның өчен мин «аны» магбуд[4] итеп тотарга телəдем, шигырьлəрем белəн «аны» җиде кат күклəрдəн югары күтəрдем, ай-кояштан артык күрдем. «Аны» вак халыкларның зəһəрле күзлəреннəн, бозык уйларыннан сакларга тырыштым. Лəкин... Лəкин... эшлəр мин уйлаганча булмады. Шуның нəтиҗəсендə мин үземдəге аны күрергə телəп тору арзусын[6] үтерергə тырыштым: аны күрми калган көннəрем авыр, булса да, аның хиялымда булган сурəтен кую бик мөшкил булса да түзəргə карар бирдем. Гадəттə аны очрату мөмкин булган урыннарга барудан тартындым. Аның хакында язылган шигырьлəрне бер урынга җыеп куйдым. Шушы юл белəн аны оныту чарасына керештем.

---

[1] Җазибият — үзенə тартучылык, (сөйкемлелек).
[2] Мəхəббəт шəрхе — мəхəббəтен аңлату.
[3] Могҗиз — искиткеч.
[4] Мəнбаг — чыганак.
[5] Магбуд — алла, тəңре.
[6] Арзу — телəк.

Шушы уйлар белән йөргәндә мин аны үзем күрергә теләмәгән бер урында күрдем. Ул анда бераз утырып чыгып китте. Аны шунда... янында күрү мине борчыса да, ул эш минем йөрәгемә зәһәрле ук кебек кадалса да икенче бер җәһәтне уйлау теге зәһәрнең агуын бетергән кебек булды. Бу эш аннан күңлемне суындырырга бик зур ярдәм итәр төсле күренде. Хәзер аның белән минем арада бик зур аждаһа җыланы яткан кебек сизелде. Ул шул аждаһа җыланының авазында йотылып, мәңге һәләк булачак бер фирештә, ләкин зәһәрле фирештә кебек тәҗәссем итте. Мин: «Инде ике арада сызык сызылды, бер-беребезне кушмаслык тирән чокыр казылды», дип уйладым. Үзем шулай уйласам да төн буе рәтле йоклый алмадым. Аның теге алдымда баскан сурәтен куарга тырышсам да көчем җитмәде. Бәгызан ул елмаеп, күзен күккә таба карап торган кебек күренде...

Шушы көннән соң, мин аны бер атна буенча бер дә күрмәдем. Үзем аларга аяк та басмадым. Күңлемнең бер ягы аларга барырга кушса да, каршы төштем. Бу вакытта, анасыннан аерылып калган яшь бала кебек, боек булсам да, күңлемдә булган керсез мәхәббәт мине җуата иде, мине иркәли иде. Ул мәхәббәт әле һаман синең кулда, шулай булгач кайгырма, ди иде. Шул бер атна эчендә йөрәгем аз гына басылды. Шуннан соң мин үземдә тынычлык сизгән кебек була башладым.

Ләкин икенче бер вакыйга тагы бу хисне кузгатты. Бу да—аңа иттифаки[1] теге җирдә очрау иде. Ул бу күренешендә әллә нишләп агарган, төзсезләнгән кебек күренде. Бөтен вөҗүде салкын кебек сизелде. Мин аны кызганган кебек булып, аның хакындагы уйларыма үкенгән кебек булдым. Бу вакытта аның янында әллә нинди кысык күзле, авызына каты борчак капкан да, сүз әйтсә төшеп китәргә торган кебек авызлы, шадрарак, тәбәнәк кенә мәшьүм[2] бер хатын бар иде. Башсыз — ач калган коры арыш башагы кебек, бу хатын, гүяки, аның матурлыгын бетерергә, бәхтен югалтырга, кызу канын имәргә торган кара җылан кебек күренде. Мин аны моннан бер ай элек зур бер җыелышта да шул хатын белән йөргәнен күреп шулай агуланып калган идем. Моның матурлыгыннан зәһәрле рәвештә файдаланырга йөргән бу хатынга

---

[1] Иттифаки — очраклы.
[2] Мәшьүм — шомлы.

шунда да ачуым килгән иде. Сихерче карчыкларга охшаган щушы кысык күзле, мәшьүм хатынны тәкрар күрү, саф сөткә төшкән тычканны күрү кебек, ямсез тәэсир итте. Ул хатынның ямсез елмаюы, көчләнеп йомшаклык күрсәтергә тырышуы—һәммәсе дә аның хакында ачуымны гына кабарта иде. Ихтимал, мин аның үзен генә күргән булсам иде, һуштан язу дәрәҗәсенә килеп хөрмәт итәр идем, бер минут та сабыр итә алмый аның алдына егылыр идем. Ләкин теге арыш башагының булуы шулай итмәвемә зур сәбәп булды. Бу күрешүдә мин аның белән рәсми рәвештә генә сөйләшеп утырдым. Шатлыгымны тышка чыгара алмадым. Мин аны кызгандым. Шундый халык арасында йөрүе өчен борчылдым, көнләдем. Үзенең матурлык, алиһәлек дәрәҗәсен белмәве өчен эчем пошты. Икенче җәһәттән, моңлы гына нур чәчеп торган күзен күреп ут эчендә калган кебек булдым. Ләкин бу ут борыңгы мәхәббәт кебек яндырмый, башкачарак иде. Алар чыгып киттеләр. Ул чыгып киткәндә үземне ничек тәныклы тотарга тырыштым. Шулай, мин аны бөтенләй онытырга тырышам. Аның хакында булган бәгызе бер вакыйгаләр (болар аның дәрәҗәсен төшерергә дәлил булып бетмәсәләр дә...) «аны» онышу юлында ярдәм итәрләр дип уйлыйм. Син моннан соң «аның» хакында сүз кузгатып минем эчемдә янган утны тәкрар кабындырырга сәбәп булма. Чөнки мин «аның» белән булган мөнасәбәтне өзеп, аны күрүдән ваз кичә алсам да, аның йөрәгемдә калган матур хиялын бөтенләй чыгарып ташлый алуыма ышана алмыйм. Аның беренче танышу вактында, соңра айлы төннәрдә алдымда басып торган вакытларында йөрәгемә кереп калган илаһи бер сурәте бар, ул сурәт аның хәзерге көндәге сурәтенә башка, әнә шул сурәт, шул илаһи матур... минем йөрәгемнән мәңге чыкмас, мин ул минутларны мәңге онытмамын... Ләкин ул сурәт теге ямсез хатын белән йөргән ...түгел. Бәлки шуннан аерылып калган мөкаддәс... дер. Ул һаман минем назлы йөрәгем эчендә үскән кызыл гөл чәчкәсенә каршы баскан да, шунда нурлы күзләрен тутырып, гөл өстендә аны мактап сайраган күңел сандугачыма карап тора. Минем күңлем, нак борынгы айлы кичләрдәге кебек, аның матурлыкларын санап төрле шигырьләр укый...

191... нчы ел. Январь.

VIII

...«Соңгы вакытларда нәрсәләр язасың? Бигрәк нинди эшләр белән мәшгул буласың?..» дигән сөальләрең, соңгы ике-өч ай эчендә үткән хәятка әйләнеп карарга, шул көннәрнең моңлы сәхифәләрен актарырга мәҗбүр итте. Мин соңгы вакытларда теге әсәрне бераз яздым. Соңра төрле сәрләүхәдә[1] язылган, төрле мәүзугда кыска-кыска байтак шигырьләр язылган икән. Синең хатың мөнасәбәте белән шуларны тәкрар карадым. Боларның күбесе мәхәббәт хакында. Мәшгул булу мәсьәләсенә килсәк, менә бу сөаленә җавап бирү яхшы ук читен эш. Мин асылда көнлек эшләрне, ягни дөньяви эшләрне, мәшгулият җөмләсенә кертә алмыйм. Иртүк торып эш урнына барып, анда һәркем кебек, өскә йөкләтелгән эшне машина кебек эшләү, ай тулгач жалованне алып, шул акчага кирәк нәрсәләрне алып дөня көтү—болар һәммәсе дә вак эшләр. Боларда җан өчен ике тиенлек тә азык юк. Кайбер бәндәләр үзләренең хәятында шундый эшләрдән генә ләззәт алып йөри торганнардыр, ләкин аларның рухлары да шуңа муафыйк рәвештә түбән яратылганнардыр дип уйлыйм. Минем өчен дөньяда җан азыгы, рухны тәрбия итә торган магнәви азык кирәк. Мин шундый магнәви азык бирә торган нәрсәләргә генә әһәмият бирәм. Бу эш миндә табигый. Яз, җәй—менә бу ике фасылдагы җир өстендәге матурлык, күкнең шуларга елмаеп серле рәвештә карап торуы, сандугачның шул матурлыкларны күреп сайравы, матур хатын-кызларның йөрәкләре тибеп ашкынуы—болар һәммәсе дә җан азыгы булалар. Минем рухымны шулар гына тәрбия итә алалар. Минем рухым шуларның нурлары белән сугарылып торса гына тиешле җимешне бирә ала. Хәзер кыш көне. Табигат үзенең матурлыгын югалтты. Күктәге ай һәм йолдызлар елмаймыйлар. Сандугач елы якка китте. Менә шулар булмагач, минем рухымны мәшгул итүче нәрсәләр дә бетте. Ләкин аңа карап рухым талпынудан, югарыга очарга теләүдән, мәхәббәт бакчасындагы кызыл гөлләргә карап сайрау һәвәсеннән туктамый. Ул һаман үзенә мәшгулият эзли. Азыксыз тора алмый. Туң табигаттән, кышның буранлы, серле озын төннәреннән әллә нәрсәләр табарга тырыша. Ләкин канәгать итәрлек нәрсә тапмый. Болай да булмагач, матур хатын-кызларның серле күз карашларыннан, аларның матур елмаюларыннан рух алу юлына керә. Дөресен әйткәндә, хатын-кызлар-

[1] Сәрләүхәдә — исемдә.

ны табигатнең иң гүзәл чәчкәләреннән исәпләп, җан шуларның серле күләгәләре астында торуны минут саен арзу итә. Ләкин җанны канәгатьләндерерлек, үзенең нуры астына алып тәрбия итәрлек хатын-кызлар бик сирәк бит!.. Менә мин шундый хатыннарны таба алмыйм. Тыштан караганда бик матур булып күренгәннәре сөю һәм коддөси мәхәббәтнең нәрсә икәнен аңламыйлар. Болар нак төскә матур булып та, хуш истән мәхрүм калган чәчкәләргә генә ошыйлар. Кызганыч шундый хатыннар!.. Матурлык белән нечкә хис бергә җыелган хатыннар чыннан да бик сирәк бит. Күп вакытта аларның нечкә хисләре вак-төяк нәрсәләр, тагы да тупасландырып әйткәндә, кием-салым кебек тышкы нәрсәләр белән зәһәрләнгән була. Алар матур күренер өчен шундый тышкы матурлык җитә дип аңлышалар. Ләкин бу эштә бик зур хаталык итәләр. Әгәр бер хатынга ходай тарафыннан матурлык бирелгән икән, ул инде иске палас ябынып йөрсә дә матурлыгын югалтмый. Хатыннарның матурлыклары өстенә рухлары сизгеч булса, менә шул вакытта алар сизгеч йөрәкле кешеләрне үзләренә әсир итә алалар. Андый хатыннарга карап, аларның нурлы карашларыннан илһам алу—бу бик матур һәм күңелле эш. Алар рухны нурландыру, җанга азык бирүне үзләренең серле карашлары белән үти алалар. Менә мин шундый хатыннарны бик сирәк очратам. Чынлап та, шулай үзенең дәрәҗәсен белүче хатыннар бик сирәк. Матур хатыннарның бик күбесе үзләренең тышкы матурлыкларына гына карап горурланалар да, шул горурлары сәбәпле, хәйләле ирләрнең тозагына төшкәнне белми дә калалар. Хатыннар хакындагы сүз озынга китте бугай, әйтергә теләгән сүзем «үземне мөсәххәр[1] итә торган хатыннарның сирәк булуын» әйтеп кенә китү иде. Чынлап та, мин үземнең рухымны галиләндерә торган хатыннарны гомеремдә бер-ике мәртәбә генә очраттым. Аның берсе инде күптән бу дөньядан югалды. Ләкин аның күңелемә калдырган нурлы тәэсире әле дә күз алдымда тора. Икенчесе, мин аның хакында сиңа күп хатлар язган... иде. Мин моннан элек язган хатларымда аны күккә күтәрдем. Иң соңгы хатымда аның үзем теләгән дәрәҗәдән түбән төшә башлаганын бәян иттем. Әлбәттә, аның сәбәпләрен дә яздым. Һәм язган хатыңда аның хакында сүз кузгатмауыңны үтендем. Ләкин мин аның хакында

---

1 Мөсәххәр итү — «сихерләү», үзеңә карату.

язмый үтә алмавымны игтираф[1] итәм дә, аның хакында түбәндәге сүзләрне язам.

Күңел талпына дигән идем. Чынлап та, талпынган күңел үзенә карап сайрар өчен гөл кебек бер хатынның күз алдында булуын тели. Тели генә түгел, бу эш минем өчен мәҗбүри бер нәрсә. Минем даими янган күңлем шунсыз тора да алмый. Мин «серле гыйшык» кулыннан азат булуны теләп карадым, ләкин барып чыкмады. Мин азат булам дигән саен магнәви әсир була бардым, турысын әйткәндә, үзем чыгып киткән читлеккә үзем барып кердем. Бу эш шулай булды:

Мин... нең серле кулыннан, күз каршыннан ычкыну өчен тырышып бактым. Бераз гына максадка якынлашкан кебек тә булдым. Шул рәвешле йөргәндә, кышның матур бер кичендә, йөрергә чыктым. Күңел бу дөньяны тарсына, әллә кайда ашкына иде. Айның иң тулы вакты булып, ул соң дәрәҗәдә балкып, тик җир өстен генә тамаша кылган кебек карап тора иде. Төпсез күктәге йолдызлар җымылдашып мәхәббәт җырларын сөйләп, серле рәвештә йөзәләр иде. Мин шул нурлы күк астында йөреп, барган саен моңга чумдым. Әллә нинди бер мәхәббәт алдында баш иясем килде. Шул ниһаясез[2] күкнең иң серле урыннарына барып, шундагы мәхәббәт алласы алдында утырасым килде. Нак шул минутта... нең нурлы сурәте күз алдыма килеп басты. Басты да ул мине үзенә таба чакыра башлады. Мин, аннан бизәргә карар бирүемне уйлап, кире чиктем. Аның күңелгә ошамаган сыйфатларын күз алдында ямсез рәвештә күрергә теләдем, булмады. Соңгы бер көрәшү булыр дидем дә, аларга таба киттем. Шул вакытта ай көлгән кебек булды. Мин шуннан намусланып кире китәргә теләдем. Ай икенче төрле көлде. «Мәхәббәт алай булмый ул, ул синең теләгеңнән тыш бер нәрсә» дигән кебек булды. Шуннан соң тагы алга атладым. Йөрәгем калтырый иде. Үземне-үзем уйламаска тырыша идем. Нак дәрьяга ташланырга, бу дөньядан мәңге китәргә барган кеше кебек бара идем.

Барып кердем. Ул үз бүлмәсендә ялгыз гына эчке киемнән иде. Мине күргәч, киң бер нәрсәгә өретенде. Мин аның каршысына утырдым. Аның шул вакыттагы матурлыгын күрү белән аның хакындагы ямсез уйларның һәммәсе дә югалды. Мин бөтенләй шатлык диңгезендә

[1] Игтираф итү — тану, гаепне үз өстенә алу.
[2] Ниһаясез — чиксез.

йөзгән кебек булып калдым. Бу минутта, гүяки, аның белән минем арада һичбер пәрдә юк иде. Үземне көзгедән ничек күрсәм, аның эчендәге уйларны шулай күрә идем. «Ул», мин шөбһә белән караган нәрсәләргә, үзем сорамыйча ук, үзе сөйләп бирде. Теге урынга баруының сәбәпләрен сөйләде. Ләкин хәзер аның сөйләвенә яки аның шуларны сөйләргә тиеш күрүенә үзем дә ояла идем.

(Ахры бар).

ХОКУКСЫЗЛАР[1]

I

Вәли шәһәрнең бер читендәрәк булган бер урамда, үзенең йортына янәшә салынган кечкенә лафкасында бакали товарлары белән сату иткәндә, аны тирә күршеләреннән башка рәтләп белүче дә юк иде әле. Ул шул лафкасында сату итеп ару гына хәлләнде. Хәзер аның лафкасындагы төрле товарларыннан башка байтак акчасы, аты, сыеры булып өлгерде, тормышы юлга салынды.

Ул үз эшләренең бу көндәге барышыннан, сатуның яхшы гына алга китүеннән бер яктан риза булса да, үзеннән бай булган кешеләрне, шәһәр уртасындагы зур базарда, магазиннарда сату итүчеләрне күргәндә, үзенең хәзерге дәрәҗәдә генә сату итүеннән дә, тормышыннан да канәгать итми, тагын бая төшәсе, тагын да матуррак торасы килә иде. Ул бигрәк тә, шәһәр уртасындагы зур базарда матур магазиннарда сату итүчеләргә карап аларга кызыга, үзенең дә шулар кебек сату итәсе килә, базарда кечкенәрәк булса да бер кибет алып, шунда сату итүне бик зур бәхетлелеккә санап, күңеленнән һаман шуны уйлап йөри иде.

Ул кичке чәйне эчәр алдыннан, бу көнге сату иткән акчаларны санаганда да, аларны санап беткәч, электән җыя килгән запас сумасын алып караганда да, һаман да базарда кибет алып, шунда сату итүне уйламый калмый башлады. Ул, шул уй белән бүген сатудан килгән файданың беразын шул запас сумага куша, башкаларын иртәгә товар алырга әзерләп куя да, алдагы көндә базарда магазин ачуны, ул магазинның әллә кайдан күренеп торуын, үзенең дә, башка байлар кебек, яхшы йортлары булуын күз алдына китереп, тирән уйга бата торган иде.

---

[1] Язылып бетмәгән.

Аның шулай һәр көнге сату иткән акчаны санавы, шәһәр уртасыннан кибет алып, шунда сату итүне, агай-эне арасына керүне уйлавы һәр көн кабатлана торган бер эш булып китте. Ул бу эшләрне уйлаганда, иң мөһим берәр фәнни нәрсәне иҗад итүне уйлап утыручылар кебек, күңлен тәмам шул эшләр өстендә йөртеп, башын бик нык эшләткәнгә күрә, хатыны Хәмдиянең үзенә биргән сәальләрен ишетмәү дәрәҗәсенә килә, тик акчаларны санап бетеп, теге уйларыннан башы бераз бушангач кына хатынына карап:

— Син нәрсә сорадың әле?—дип, аның сораган сүзен кабатлата, тик шуннан соң гына аның белән сөйләшеп китә иде.

Вәли, күңлендә йөргән бу зур фикерне, бара торгач, үзенең генә эченә сыйдыра алмый хатыны Хәмдиягә дә әйтергә уйлады. Һәм үзенең чиксез мөһим уен әкренләп белдерергә теләп:

— Ай-һай, кешеләр кебек зур базарга кибет ачып, шунда сату итәсе иде!.. Монда ничаклы гына тырышсаң да бер чамадан арттырып булмый. Вак-төяк нәрсәләр белән генә сату итеп зур эш чыгару авыр. Кеше арасына керер өчен эшне зурайтырга кирәк...—дип сүз башлады. Мондый зур эшкә Хәмдиянең тиз генә акылы җитмәгәнгә күрә, бер нәрсә дә әйтә алмый аптырап калды. Вәли, Хәмдиянең шулай аптырауда калачагын, бу турыда тиз генә бер сүз дә әйтә алмавын белә иде. Шуңа күрә, ул бераз уйлап торганнан соң:

— Әле бүген Кәшфулла абзый белән сөйләшеп утырдым. Ул әйтә—«Нигә, Вәли, син зур базарга килеп кибет ачмыйсың? ди. Синең кебек сәүдәгәр кешегә анда азаплану эшмени ул», ди. Мин әйтәм—«Безнең бу эшкә көч җитәр микән соң, монда сату итәр өчен зур сума кирәк бит!.. дим. Ул әйтә:—Ник көч җитмәсен! Сату итә белгән кешегә мал табыла ул. Андагы сату белән монда сату итү бер түгел. Агай-эне ясап, зуррак эшләргә катнашу ягын карарга кирәк...—ди. Бер караганда аның сүзләре бик дөрес. Шуның өчен, мин дә зур базарга кибет ачу кирәклеге уена килдем. Шунда кибет ачмый булмас ахры...—дип, Хәмдиягә карап алды да, аның берәр сүз әйткәнен дә көтми:—Монда сату итү—марҗалар, хатыннар эше генә. Бер кадак керосин, ярты кадак шикәр, бер ачмуха чәй, бер чирек май, бер кап шырпы кебек нәрсәләр сатып күпме генә файда итәсең? Зур базарда ваклап саткан кебек, күпләп тә җибәрәсең. Анда сату итүчеләргә

карап торсаң ис китә. Төрле товарларны үлчәп өлгерә алмыйлар. Шул ук арада күпләп тә җибәрәләр. Ә без монда, тишектән тычкан чыкканын зарыгып көтеп утырган песи кебек, алучы килгәнен көтеп утырабыз...—дип, байтак сөйләнгәннән соң—ятып калганчы атып калырга кирәк. Куркып торсаң бер эш тә чыгарып булмый ул,—дип, гайрәтләнгәнсымак, Хәмдиягә күзен ташлады.

Хәмдия бу турыда нәрсә әйтергә дә белми бераз торганнан соң:

— Анда да кибет алсаң бу лафканы нишләтербез соң, монда кем сату итәр?—дигән сөальне бирде.

Вәли, кулындагы чәйне готылдатып эчеп бетергәннән соң:

— Монда сату итәргә әллә кем кирәкми. Әзер малны сатарга һәр кемнең кулыннан килә. Шәйди (үзләрендә берничә ел эшләгән малай) мондагы сату рәтенә төшенде инде. Ул итәр, үзең дә чыгып булышырсың, күз-колак булырсың... — диде.

Вәли зур базарга товар алырга киткән чакларда, Хәмдия лафкага чыгып Шәйдигә булышлык итү аркасында товар бәһаләрен бераз белгән булса да, эш бөтенләй Шәйди белән икесе өстенә калуын уйлап куркып китте. Бу эшне өстенә алырга авырсынган кебек:

— Ай-һай, без ул эшне булдыра алырбыз микән? Шәйдинең ат белән сыерны карыйсы да, өйдәге вак-төяк эшләрне дә эшлисе дә бар бит...—(дип) үзенең карашын әйтте.

Вәли Хәмдиянең бу сүзләрне әйтәчәген белеп, алдан җавап әзерләп куйган кебек, кыза төшеп:

— Син һаман хатынныгыңа барасың. Эшне зурәйтәм дисәң, андый юк-бар нәрсәләргә карап торырга ярамый. Әллә син гомер буена шушы лафка белән генә торырбыз дип уйлыйсыңмы? Шәйди йорт эшләрен эшләгәндә үзең сату итәрсең. Бер дә булмый икән, лафканы ябып торырсың. Шулай да Шәйдигә бик нык күз колак булып торырга туры килер. Һәр кемнең бармагы үзенә таба кәкере, кешегә ышанып булмый. Ул болай юаш кебек күренсә дә, юаштан юан чыга диләр. Тәмне тамак булып кәнфет-мазар гына ашап йөрмәсен. Аннан соң, зур базарда эшләр рәтләнеп китсә, бу лафканы бөтенләй ябу да кыен булмас. Ансын алда эшләрнең баруына карап эшләрбез,—дип сөйләп алып китте.

Аларның бу көнге кичке чәйләре бик озакка сузылды.

Гайнулла исмендәге сигез яшьлек балалары әллә кайчан ятып йоклады. Алты яшендәге Сагидә йокысыннан уйанып көйсезләнде. Кулына биргән канфетны да, варения ягып биргән ак күмәчне дә ташлады. Тик ул «хәерче бабай килә, күп җыласаң үзеңне капчыгына салып алып китәр» дип, тәрәзәне чиертеп куркыткач кына кире урнына ятты. Ул йоклап киткәч, Вәли белән Хәмдия тагын да бик озак сөйләшеп утырдылар. Ниһаять, Хәмдия, дөнья көтү, сату-алу эшләрен белүдә үзенең белемсезлегенөстенә алгандай булып, Вәлинең корган планнарына, сөйләгән сүзләренә кушылган рәвештә:

— Мин тик болай гына әйтәм, ие, шулай шул, алай булгач, шулай итәрбез шул...—дигән кебек сүзләр белән Вәлинең сүзләрен йөпләп утырды. Вәли Хәмдиянең һәрбер сүзгә «ие, шулай шул» дип, тәмам риза булганын күргәч, күңелләнеп китте. Алар шул эшләр турында бик озак сөйләшеп утырганнан соң, йокларга яткач та һаман шул эшләр хакында уйлап, бик күп вакытлар йоклый алмый яттылар. Тик беренче әтәч кычкырганнан соң гына, алар томанлы рәвештә йоклап киттеләр.

Боларның төшләренә дә бүген, зур магазиннар, әллә нинди товарлар, шәп атта йөрүләр, тагын әллә ниләр кереп бетте. Вәли дә, Хәмдия дә әллә ничә рәт уфлап уяндылар. Йокыга китәр-китмәстән аларның күз алларына тагын әллә нәрсәләр күренеп, тагын да уяныр-уянмас төрле догалар укынып йоклап китәләр иде...

Болар шулай озын вакыт утырып, төннең әлләни чаклы вактын үткәреп, болар ятканнан соң гына, үзенең урнына яткан Шәйди дә, үзенең аруына карамастан, үзенең эшләре, Казан артындагы авылда ялгыз калган әнкәсе... кичә күрше марҗага керосин үлчәгәндә аз гына чайпылдырып, аз гына керосинны читкә түккән өчен Вәлинең ачулануы хакында уйлап, бик соң йоклап китте. Шулай итеп, бүген Вәли дә, Хәмдия дә, Шәйди дә соң яттылар. Яткач та күп уйладылар. Аларның һәр өчәвесе, алдагы көннең бәхтен, алдагы көндә рәхәт тормыш көтәләр, алдагы матурлык яки ямьсезлекне күз алдына китерәләр иде...

II

Вәли, бара торгач, күптән уйлап йөргән теләгенә ирешге. Ул, төрле сәбәпләр белән эше чобалып, сәүдә эшенең йомгак очларын югалтканнан соң лафкасындагы товарларын сатарга мәҗбүр булган берәүнең товарлары белән

лафкасын, бик арзан гына алып, шунда кереп утырды.

Дөрес, Вәли бу зур эшкә «тәвәкәлләгәндә» бик күп баш ватты. Электән җыеп килгән акчалары гына җитмәгәнгә күрә, йорт янындагы кибетендәге бераз товарларын сату өстенә бер аз бурычка да керде. Яхшы ук зур кибеттә үзе генә сату итеп өлгерә алмаслык булгач, тагын да арзанлы бер малай—приказчик алырга мәҗбүр булды. Шушы эшләрне юлга куйганчы күп йөрергә туры килде. Шулай итеп, курку белән өмит арасында, үзенең күптән уйлап йөргән зур теләгенә ирешеп, шәһәр уртасындагы зур базарда кибет хуҗасы булып, сату итәргә керешеп китте. Бу чаклы зур эшкә керешеп, бурычка кереп киткәндә, башта, эшнең ахры ничек булып чыгарын уйлап курка төшкән булса да, бер-ике ай сату итү белән, эшләрнең яхшы якка таба барганын күргәч, аның куркулары бетте. Ул хәзер үзен чын сәүдәгәрләр рәтенә кергән кебек, чынлап та хәзер «сатучы—сәүдәгәр» исмен алырга хаклы булган кебек хис итте. Хәзер аның каршында кешеләр ике төрле: сәүдәгәрләр, сатучы була алмаган гади кешеләр булып, ике сыйныф, ике бүлем булып күренә башлады. Ул әле үзе, чынлап та теге мәшһүр байлар кебек булмаса да үзен шуларның юлларыннан баручы, шуларның кечкенә балалары урнында кебек (итеп) уйларга керεште. Аныңча бөтен гакыл байлыкта гына булып, бай кеше гакыллы була, яисә гакыллы кеше бай була булып күренә, шуңар күрә, ул үзеннән зур булган мәшһүр байларны чиксез акыллы кешеләр дип фараз иткән кебек, ярлы кешеләрне үзеннән түбән, гакылсызлар, дип уйлый иде.

Ул шулай, үзеннән зур байларны, үзеннән гакыллылар, алар дөньяда тора беләләр, дип уйлаганга күрә, байларның бөтен эшләренә, аларның хәрәкәтләренә, йөреш-торышларына таклид[1] итүчән булып китте:

Мәсәлән, Садыйк бай сөйләгән чакта тавышы калын булып, мөгердәп чыга, Әхмәт бай сүз арасында тамак кырып, күркә кебек горылдап куя. Вәли менә боларның шул кыяфәтләрен, аларның гакыллы бай булуларыннан килгән аерым бер хасият дип белеп, үзе дә шулар кебек булырга тырыша, тавышын Садыйк бай тавышы кебек юан, калын чыгарырга, сүз арасында Әхмәт бай кебек тамак кырып куярга маташа иде. Ул шулай тавышын юан чыгарганда үзе дә шатланып китә, барган саен байлыкка таба барган кебек хис итә иде.

[1] Таклыд итү — охшарга теләр, ияру.

Ул байларның бу эшләренә таклид иту белән генә канәгат итми, башка эшләренә, йөреш-торышларына да таклид итеп, бөтен эшләрдә алар кебек булуны зур эшләрдән саный башлады.

Сатулар рәтләнгән саен ул байларда күренгән бер сыйфат, күренгән бер нәрсәне үзендә дә булдырырга тырыша... Аның гает һәм җомгаларга киеп бара торган туны, Садыйк байның туны кебек гаҗәп кыйммәтле затлардан тегелгән булмаса да, шуңар ошатып тегелгән, бүреге Әхмәт байның бүреге кебек иң кыйммәтле каракулләрдән тегелгән булмаса да, зурлыкта, фасонда шуңа ошатылып ясатылган иде. Ул бу тун белән бу бүрекне киеп җомга һәм гаетләргә барганда үзен бик шат хис итә, теге байларның кечкенә үрнәкләре дип уйлый, алар утырган сафларга якынрак утырырга (үзен) хаклы саный иде.

Ул байларга сату-алу эшләрендә, башкаларга кешесенә карап мөгамәлә итәргә, шулай тышкы күренешендә аларның һәрбер эшләренә таклид итеп, шулар юлыннан барырга тырышса да, аларның өй тормышларын кереп күрмәгәнгә, өй тормышын шуларча ясый алмаганга эче пошып йөри башлады.

Ул байларның һәммә эшләре дә гакылга бина кыйлынып эшләнә торган булуында шөбһә итмәгәнгә күрә, үзе аларның сыйфатлары белән сыйфатланса, алар торган кебек тора алса, байлыгы да артыр, шөһрәте чыгар кебек була иде.

Бер көн ул, Садыйк байның кибете алдыннан үткән чагында, аның йомыш-юлга йөри торган малаена ачулан-ганын күреп үтте. Шуннан ул, менә малайларга ачуланган да, ничек ачуланырга кирәк икән дип, үзе дә Шәйдигә һәм яңа алган малаена Садыйк бай кебек ачулана башлады.

Вәли шул вакытта Садыйк байга сәлам биргән иде. Дөрес, шул чакта, Садыйк бай Вәлигә туры карамый, аның сәламен дә рәтләп алмый калдырды. Ләкин Вәли «зур байның шулай эре» булуына бер дә аптырамый, бәлки, «бай булгач шулай булыр инде, әле без алар рәтенә җитмәгән бит...» дип үзен юатып, Садыйк бай өстенә кер төшерерлек уйга төшүдән сакланды.

Ул байларның атка утырып, кучер белән генә йөрүләренә бик кызыга иде. Ул әле үзенең аларча шәп аргамакларны матур дишлаларга җиктереп, мәһәбәт кучерләр белән йөрерлек байлыгы юклыгын белә, шуның өчен хәзергә уртача гына булса да ат алып, гади тарантас белән йөрүне муафыйк күреп, өендәге аты өстенә тагын бер ару-

рак ат һәм яңа тарантас алып җибәрде. Кай вакытта Шәйдине кучергә утыртып, үзе түргә утырып базарга чыга, кибет ябык көннәрне урамда йөреп кайта торган булды. Бу йөрү әле чын байларча йөрү кебек булып бетмәсә дә, үзен байлык юлларының бер баскычын атлаган кебек хис итте.

Ул шушы сыйфатларны үзе сизсә дә, әле аны тирә күршеләреннән башка кешеләр бай дип карамаганга эче поша иде. Ул шул уй белән йөри торгач җәмагать эшләренә катнашып, халык күзенә күренергә, халык арасында игтибарлы кеше булырга, һич булмаса, мәхәлләнең абруйлы, галим-голамәләргә якын бер гражданы җөмләсенә керергә тели башлады.

Ул, шул теләгенә ирешер өчен сирәкләп, мәхәлләнең арурак кешеләрен, берничә мәхәлләнең мулла-мәзиннәрен ашка чакыргалый, гает көннәрендә, гаеткә барган чагында вак акчаларны, башкалар күреп торырлык рәвештә, садакага өләшә, берәр нәрсә файдасына яки мәсҗет, мәдрәсәгә утын алыр өчен акча җыйганда өр яңа түбәтәен кулына тотып, сафлар арасында акча җыеп йөри, шулай итеп игтибарлы булуны уйлый иде.

Аның болай дин өчен, мәхәллә өчен тырышулары бушка китмәде: бер җомга көнендә, мәхәллә мөтәвәллиләре сайлаганда, Вәлине дә мөтәвәлли итеп сайладылар. Ул бу эшне бик зур шатлык белән каршы алды. Мәхәллә мулласының:

— Вәли әфәнде, сез хәзинәдар булырсыз инде... —дигән сүзен ишеткәч, башы күккә җитте. Бу морадына ирешкәч, ул инде байлыкта, игтибарлыкта тагын бер баскыч күтәрелгән кебек сизенде. Үзен шул мәхәлләнең ин гакыллы бер кешесе, иң эшлекле бер агзасы, хәтта шул тирәнең башлыгы кебек итеп фараз итә башлады.

Мәхәлләнең игтибарлы кешесе, башлыгы, мәсҗетнең мөтәвәллисе булгач, җомга һәм гаетләргә чалма кими баруны килештерми үзенә чалма алды. Ул инде җомга, гаетләргә барганда тун астыннан чапан да киеп, тәмам бер такуа кеше кебек булып китте. Башкаларга исәнләшергә теләгәндә башын югары күтәреп кенә, ияк кагып кына исәнләшә торган булды.

Үзе шулай булу белән генә калмый, ун яшьлек Гайнулласына да читек-кәвеш, өстенә җөббәгә охшатып тегелгән бишмәт, башына фәс кидереп, үзе белән бергә гает һәм җомгаларга алып бара башлады. Хәзер аның кечкенә Гайнулласы, шушы киемнәр аркасында, мәхәлләнең ярлы

кешеләре балаларыннан әллә кайдан ук аерылып күренә иде.

Мәхәлләнең мөтәвәллисе булу да, эшләрен, йөреш-торышларын шулай үзеннән югары байларга каратып, аларга ошатып йөрүе дә, аның сәүдә эшләренә комачаулык итмәделәр. Ул барган саен сумаланды. Өй янындагы кибете китергән файда бик аз гына күренеп, аны бөтенләй япты. Аның урнына базар кибетен зурайтты. Товарларын арттырды, төрләрен күбәйтте. Ләкин әле ул үзенең һаман зур байлар арасында танылып бетмәвен, алар арасына керә алмавын, алар белән бер мәҗелестә утырырга туры килмәвен уйлап борчыла, алар авзыннан:

— Вәли уңган егет булып чыкты, тиз арада гына ничаклы байлык хасыйл итте... — дигән сүзләрне ишетәсе килә иде.

III

Вәлинең эшләре шулай яхшы гына юлга салынып барганда Европа сугышы чыгып китте. Күп кешеләргә, эшче, крестьяннәргә, бик күңелсез хәлләр тудырган, күз яшьләре агызган бу сугыш башта ук Вәлигә аның киресенчә булып чыкты. Сугыш чыгу белән файда бермә-бер артты. Сугыштан элек алынып куелган капчыкларны ике-өч хакы белән сатты. Кайбер товарлардан сумга-сум файда итте. Шулай итеп бу сугыш Вәлигә көтелмәгән бәхет ишеген ачты.

Бик аз вакыт эчендә унар мең сум файда итеп ташлау, аның күңлен үстереп җибәрде. Ул хәзер үзенең бай, чын бай булачагына чынлап та иман китерде. Сума арту белән, кибеттә товар, товар арту белән эш артты. Шәйди белән соңыннан алган малай өстенә тагын бер малай алды. Теге кибет бәләкәй күренеп, икенче зур кибет алып малларын шуңар күчерде. Хәзер аның бу кибетенең ишекләре түбәсендә, эре хәрефләр белән путаллап язылган: *„Вәлиулла Әхмәт угылы Нигмәтҗановның төрле маллар сәүдәсе“*, дип язылган зур вывескасы әллә кайдан ялтырап күренеп тора иде. Шушы эштән соң аның күңеле тагын да күтәрелеп китте.

Хәзер шул чаклы мал, шул чаклы акча булгач, шәһәрнең чит урамында, кечкенә өйдә торуны үзенә һич бер төрле килештерә алмый башлады. Бигрәк тә сугыш аркасында йорт-җирләрнең бәһаләре бик төшеп китү, башка байларның борынгы йортлары өстенә әллә ничә җирдә

кырык-илле, хәтта йөзәр меңгә чаклы йортлар алулары, кайберәүләр авзыннан: «Вәли тәмам аякка басты, зур сумалы булды, эшләрен юлга салып җибәрде...» дигән сүзләрне ишетү аның бу теләгенә көч биргән кебек булды. Йорт-җир бер алынып куелса, һичбер бәһасен югалтмый торган нәрсә, «гөмерлек милек» дигән уйлар белән, шәһәр уртасыннан йорт алырга карар биреп, агай-энеләр арасында бу хакта сүз ачып, арзанрак йорт табылса алырга теләге барлыгын әйтеп йөри башлады.

Күп вакыт үтмәде, аңа, ире сугышта үлгән бер полковникның тол калган хатынының... урамында йортын сатарга теләвен хәбәр иттеләр. Йорт шәһәрнең урта җиренә якын, хәтта Садыйк байлар белән бер урамда булу өстенә, хакы да артык кыйммәт күренми торган булгач, Вәли йортны алып, унбиш көн эчендә күчеп тә өлгерде. Ләкин борыннан иркен, шәп тормыш өчен салынган алты-җиде бүлмәле өйгә Вәлиләрнең борынгы йорт җиһазлары җитәрлек тә, муафик та булмаганга күрә, яңа мебельләр алырга да туры килде. Күчеп китә торган кешеләр кулыннан алынган бу җиһазлар да, торган бәһаләреннән күп арзан һәм зат нәрсәләр булып чыктылар.

Шушы йорт һәм йорт җиһазларына берничә ун мең сумлар расход чыгуга карамастан, Вәлинең сәүдә эшләре борынгыча барды. Өч-дүрт айдан соң аның иткән файдалары йорт-җир һәм җиһазлар алырга чыккан расходларны каплап өлгерде. Йорт бөтенләй файдага калды.

Вәлиләр яңа алган йортларына күчкәннән соң, эчке тормышларында да үзгәреш ясарга туры килде. Элек тегеге бәләкәй йортларында торганда, өй эче эшләренә Хәмдия үзе генә җитешә, бөтен эшләрне үзе башкара, аш-суларга чаклы үзе пешерә иде. Хәзер зур йортка күчкәч, бер кеше генә эшләп өлгерерлек булмый башлады. Аның өстенә башка бай хатыннарының берничә асраулары булуы, үзләренең йорт эшләре белән пычранып йөрмәүләре дә боларның күзләренә бәрелде. Хәмдиянең күңеленә: «Бай хатыны бул да, чучка кебек пычранып эшләп йөр имеш!..— дигән уй төште. Ул бу уйларын Вәлигә дә әйтеп, аның да күңеленә төшереп куйды.

Вәли, Хәмдиянең бу хаклы таләбен, байларчарак торырга булган теләген, читкә какмады. Бәлки туры килсә, арурак, үскәнрәк берәр асрау алырга кушты. Күп тә үтми, ире сугышка киткән, берничә айдан бирле хат-хәбәре килмәгән япь-яшь бер хатынны асрау итеп алдылар. Электән асрау белән торып өйрәнмәгән Хәмдиягә, шундый ас-

рау белән тора башлау башта бик сәер тоелды. Аңа нинди хезмәтләр йөкләтү, бу өй эчендә аның хокукының мыйкдарын билгеләү, аның йөреш-торышындагы хәрәкәтләрен чикләү аны Вәлигә күрсәтеп-күрсәтмәү кебек хәлләр аның башын ватты. Ат кебек таза, тулы бер хатынның күз алдында йөрүе, Хәмдиянең күңелен кытыклаган кебек булды. Ләкин башка байларда шундый берничә асрау булуын, бай булгач, шунсыз торып булмавын, аның ничаклы таза һәм матур булса да асрау, тамак асырар өчен боларда хезмәт итүен, үзенең хозяйка—бу йортның төп хуҗасының никахлы хатыны икәнен, шуның өстенә, асрау хакында теләсә ничек мөгамәлә итәргә, аны кысарга, тиргәргә үзенең хаклы булуын уйлап күңлен басты.

Бу өйгә, шәһәр уртасына күчкәч, шәһәр читендәге киемнәр дә ярамаган, алар белән байлар урамында йөрү мәслихәт тә, муафик та булмаган кебек күренгәч, киемсалым да башкачарак кирәк булыр кебек тоелды. Шуңа карап, алар үзләренең дә, Гайнулла белән Сагыйдәнең дә киемнәрен үзгәртеп, яртылаш «русчалатып» тектерә башладылар.

Элек алар кибеттә хезмәт итүче ике малайны һәм Шәйдине үзләре белән өйдә, кухнә тирәсендә, тоталар иде. Бу өйгә күчкәч, аларны бу өйдә тоту бер дә генә дә мәслихәт эш кебек күрми, ат сарайлары янындагы, борыннан теге баяр хатынының кучере тора торган ике тәрәзәле кечкенә йортта торырга куштылар.

Шулай итеп, зур йортка күчү, боларның тормышларын да икенче рәвештә куярга сәбәп булды, икенче төрле әйткәндә, иске тормышны яңа формага әйләндерергә мәҗбүр итте.

Хәзер Вәли үзенең тормышыннан яхшы канәгат итсә дә, үзенең әле һаман теге зур байлар арасына кереп китә алмавына, алар тарафыннан танылмавына эче поша, ул бу эшне, үзенең «игтибарлы кеше» булып җитә алмавыннан күрә, шушы теләгенә ирешер өчен бер форсат көтә иде.

IV

Көзгә каршы... шәһәренең Җәмгыяте Хәйриясенең гомуми җыелышы булу хакында шушы шәһәрдәге бер бай тарафыннан нәшер ителеп килә торган «Заман» газетасында иглан чыкты. Газетадагы игланда, гомуми җыелышның көн тәртибе болай куелган иде:

«Җыелышта каралачак мәсьәләләр:

1. Җәмгыяте Хәйрия өчен йорт алу;

2. Сугышта мәҗрух булган солдатларга, мөселманнар исменнән лазарет ачу;

3. Яңа агзалар кабул итү;

4. Агымдагы эшләр.

Җәмгыяттә каралачак мәсьәләләр бик мөһим булганлыктан, агзаларның килүләре үтенелә. Агза булмаган кешеләргә дә керү ихтияри. Агзаларга аерым чакыру кагәзләре җибәрелмәс.

Җәмгыяте Хәйрия идарәсе.»

Сугыш вактында сәүдә белән көрәйгән базар сатучылары арасында бу хәбәрләр бик мөһим булып күренде. Газетада игълан чыгу белән, каралачак мәсьәләләре турысында, бигрәк тә, Җәмгыяте Хәйрия исменә йорт хакындагы беренче маддә хакында кызу мөзакәрә[1] һәм өндәүләр башланды. Шакирҗан дигән байның, Җәмгыяте Хәйриягә йорт алырга башлап зур гына сумалар бирергә нияте барлыгы сөйләнде.

Байлар тарафыннан ясалган аш мәҗлесләрендә Җәмгыяте Хәйрияне йортлы, аяклы-күзле итеп, нигезләндереп калу хакында күп сүзләр булды. Милләтне алга җибәрү өчен, бу эшнең бик зур ярдәме тию турысында сүзләр булды.

Яңа күтәрелеп килгән сәүдәгәрләр дә бу җыелышта үзләренең хәзер булып, ярдәм кулларын сузарга тиешикәнлекләрен күз алларына китерделәр. Зур байлар әһәмият биреп караган бер эш булгач, безнең Вәли дә бу эшне бик мөһим, кирәкле эштер дип фараз итте. Хәтта эчендә үзенең күпме иганә бирәчәген, җыелышта акча җыелуның барышына карап бу чаманы арттырырга мөмкин икәнен уйлап куйды.

Гомуми җыелыш ясау көне, сату-алу эшләре булмаган көнгә (якшәмбегә) каратылып куелган иде[2].

. . . .

— Хәйрулла әфәнде Әхмәтев!..

— Нигмәтҗан Терегулов...

— Гомәр әфәнде Еникиев!..

— Заһир хәзрәт!..

— Җиһаннур хәзрәт Ишгильдин...

---

[1] Мозакәрә — фикер алышу.

[2] Кулъязма шунда өзелә. «Хәйрулла әфәнде Әхмәтев»... дип башланып киткән урынга хәтле булган өлеше (IV бүлекнең уртасы) табылмады.

— Приказчиклардан Садыйк әфәнде Касыймов!..—дигән тавышлар белән зал яңгырап китте. Секретарь, Хәйрулла әфәнде Әхмәтев, көлә төшеп яза, исем фамилияләр бик күп һәм бер исем фамилия бер юлы әллә ничә кеше авзыннан әйтелгәнлектән, тәкрар сорап, халыкның артык тавышланмауларын үтенә иде.

Иң байлардан башлап, күзгә күренерлек кешеләрнең исем фамилияләре әйтелеп бетә язганда, рәис урыннан торып, хәзер кандидатларның җиткәнен әйтеп, туктарга кушты. Һәм боларны берәм-берәм тавышка куеп чыкты. Ниһаят, иң күп тавыш алу игтибары белән:

Шакирҗан әфәнде Алимгулов; Садыйк бай Кадриев; Хәлим әфәнде Карачурин; Җиһаннур хәзрәт Ишгильдин һәм Хәйрулла әфәнде Әхмәтев—комисия агзалыгына сайланган булып чыктылар. Ләкин Садыйк бай Кадриев, үзенең картлыгын һәм сәүдә эшләре күплеген әйтеп, үзен магзур тотуны, үзе урынына башка берәр яшрәк кешене сайлауны мәслихәт күреп, сайланудан отказатса итте. Аның гозерләрен халык күпчелеге мәслихәт күреп, аның кандидатурасын кире алдылар һәм аның урынына приказчиклардан Садыйк әфәнде Касыймовның сайлануын үтенделәр. Ул үзенең хуҗасы Хәбиб Нәгимевнең күзенә карады. Хәбиб әфәнде, аның ни өчен, ягни, «Син нәрсә әйтерсең? Рөхсәт итәрсеңме?»—дигәнсымак, үзенә хуҗа итеп каравын сизеп алды һәм аның өмитле рәвештә сөальле каравына җавап биргән кебек: «Садыйк Касыймов бик мәслихәт»—дигән сүзне өстәп куйды. Хәбиб Нагимевнең сүзеннән соң, Садыйк Касыймов та лазарет ачу комиссиясенең агзасы булып сайланды.

Боларга кандидат буларак:

Нигмәтҗан әфәнде Терегулов, Заһир хәзрәтләр сайландылар. Сайлану эшләре беткәч, бу комисия агзаларына: акча табу, лазаретны оештыру юлларын карау һәм бу мәсьәләне бик ашыктырып, тизрәк эш башлау кебек вазифалар[1] йөкләтелде. Шуның өстенә, яңа сайланган комиссия агзаларының такдимнәре буенча, шушы җыелышта ук список төзелеп, акча җыю чарасы күрелә башлады.

Шакирҗан бай бу эштә дә беренче булып биш мең сум яздырды. Бу юлы Садыйк бай Кадриев тә Шакирҗан байдан калышуны тиешле күрмәде, күрәсең, ул да биш мең сум яздырды. Бу юлы Хәбиб Нагимев тә, карт әтисенең киңәшен көтеп тормыйчы ук:

[1] Вазифа — бурыч, йөкләмә.

— Безнең Нагимев фермасы исменнән биш мең сум язуыгызны үтенәм...—дип, биш мең сум яздырды. Шуның белән боларның һәрберсе, үзләре биргән сумаларны әйткәндә хөкүмәт тарафыннан килгән вәкилгә карап куялар иде. Хөкүмәт вәкиле дә бая «әллә кемнең» мөселманнар өстенә тап төшереп сөйләгән сүзләрен оныткан кебек булып, шатлык белән елмаеп утыра башлады.

Бу байлар артыннан башка ваграк байлар, үзләренең чамаларына карап, төрле сумада иганә яздыра башладылар. Бу юлы да димләшүләр, күбрәк иганә итәргә кысташулар булды. Безнең Вәли, лазарет ачу өчен язылганда да, үзенең тиңдәшләреннән арттырып бирде. Бу вакытта аңа тагын да: «һиммәтле, рәт белүчән, яшь бай...» дигән төсле караган кебек булдылар. Иганә яздырмаган кеше сирәк калды.

Җыелышта булмаган кешеләр арасыннан иганә җыю эшләрен дә шушы «лазарет ачу комиссиясе» нә тапшырганнан соң, агзалар кабул итү башланды. Ләкин бу эш, керергә теләүчеләрнең исем, фамилияләрен әйтеп үтү белән, биш-ун минут эчендә тәмам булды.

Агымдагы эшләрдә артык тикшереп торырлык зур мәсьәләләр булмаганлыктан, озакка сузылмады. Алар арасында бер ятим карчыкның ярдәм сорап биргән гаризасы белән, бер картның гаризасы бар иде. Карчыкка ике сум ярдәм бирергә, картны тикшерүне җәмгыятьнең идарәсенә тапшыру белән эш тәмам булды.

Рәис җыелышның ябылуын игълан иткәч, җыелган халыклар груһ-груһ булып тарала башладылар.....

. . . .

V

Кич сагәт 9 ларда, кибет ябып кайтканда да шат иде ул. Элек ул һәр көнге сату акчаларын алып кайтканнан соң, башка бер нигә дә карамый, язу өстәле астына үз кулы белән салып бикләгәннән соң гына юынып аш өстәленә килеп утыра, шуннан соң гына сөйләшә башлый торган иде. Бүген өйгә кайтып кереп өстендәге калын тышкы киемен салып куюю белән зур гына яулыкка төргән акча төргәген кесәсеннән алып, эре генә рәвештә, хатынына биреп.

— Мә, шул нәрсәне алып җыеп куй әле—дип, үзе бит, кул юарга кереште.

Хәмдия ул биргән төргәкнең акча икәнен тотып карау

белән белде һәм салмаклыгын, күплеген белер өчен кебек, кулы белән селкеп караганнан соң, маглүм акча җыя торган урынга илтеп куйды.

Вәли әле һаман сүз башламаса да, йөзе шат, тик сүзне кайдан башлап алып китәргә белми торган кешеләрчә бер хәлдә булганлыктан гына сүз башламый торганлыгы әллә кайдан сизелеп тора иде.

Ул, Хәмдия әйтмичә үк аш өстәле янына утырып, икенче кесәсеннән бүген чыккан «Заман» газетасын алып, авзын пышылдатып теге мәкаләне карарга кереште. Бераз укыганнан соң, үзеннән-үзе көлеп җибәрде. Хәмдия аның токтымалга көлгәнен күреп:

— Сиңа нәрсә булды, тик торганда көлеп утырасың?..—дип сорагач, тагы да кәефләнә төшеп:

— Менә, газет язучыларны әйтәм әле: кичәге җыелышны басып та чыгарып өлгергәннәр. Габдулла абзый кушкандыр инде...

Хәмдия кулындагы тәрилкәсен өстәлгә куеп:

— Нәрсә дип язганнар соң?—дип сорады.

Хәмдиянең соравы, Вәлигә сүз ачкан кебек булды, һәм ул, газетаны алдына алып:

— Нәрсә дип язсыннар. Билгеле инде: бик зур эшләр эшләнде. Яхшы байлар зур иганәләр бирделәр, дип мактап бетә алмаганнар,—диде һәм Хәмдиягә бер рәт карап алганнан соң, иганә итүчеләрнең исемнәрен тезеп алып китте. Үзенең исеменә җиткәч, авзын тагы да зуррак ачып:—«Вәлиулла әфәнде Әхмәтҗанов 3 мең сум...» диде дә бераз туктап торды. Соңра, үзеннән аз сумалы иганә бирүчеләрнең исемнәрен әһәмиятсез генә итеп укып чыкты.

Хәмдия, тагын әллә нәрсә көткән кебек, Вәлигә карап торганнан соң:

— Шул гынамы? Алар сине мактап язсыннар иде...— дип, коры исем, фамилия язылуга гына канәгат итмәгән кебек бер сөаль бирде.

Вәли аның сөаленә җавап биргән кебек:

— Шулай язгач та җитәр: 15—20 мең сум биргән байларны да шулай гына язганнар инде. Байлар рәтеннән төшерми, шулай язгач аз эш түгел. Шулай да язылмасаң ничек булыр иде?..— дип куйды.

Аш ашалып беткәнче сүз шул тирәдә йөрде. Аштан соң чәй эчкәндә, Вәли тагы да бик мөһим эш бар кебек сүз башлап:

— Син, әле күптән бирле шуны әйтергә йөри идем:

агай-эне очраган саен:—«Я, Вәли абзый, яңа йортны кайчан котлыйбыз? Алай ярамый!»—диләр. Чынлап та Галим-голамаларны, агай-энеләрне җыеп коръан укытып, фатыйха алырга кирәк иде. Әллә алдагы җомгаларның берсендә чакырып алабызмы?—диде. Хәмдия, Вәлинең бу фикерен шатланып каршы алды:

— Аны мин дә уйлап йөри идем. Әле бер көн Әхиярләрдә ашта утырганда абыстайлар да биткә бәрделәр: — «Хәмдия, сезне йорт алган диләр, бик шәп дип сөйлиләр, я, качан күрсәтәсез инде?.. әллә бик баеп киткәч тә фатыйха кирәк булмый башладымы?...»—дип, тезеп алып киттеләр. Аларга башка хатыннар да кушылып: — «Кирәк, бик кирәк!.. йорт алып, коръан дә укытмагач, ул ни эш була...» — дип колагымны тондырдылар.

Вәли абыстайларның сүзләрен хаклы күргән кебек, көлә төште:

— Әйтерләр шул... Кай арада безнең йорт алганны белеп беткәннәр!—дип, гаҗәпсенгәнен белдереп куйды, һәм,—алай булса, шушы киләсе җомгага тәвәкәлләп чакырып алыйк. Барыбер чакырмый булмый инде, — дип, чакырырга карар бирделәр.

Хәмдия тагын да күтәрелеп китте. Хәзер үк чакырырга хәзерләнгән кебек булып, аш өстәлен җыештыра башлады.

Шул арада, кемнәрне һәм күпме кеше чакыру хакында сүз китте.

Хәмдия, борын үзләре шәһәр читендәрәк торган вакытта йөрешә торган кешеләрнең исемнәрен телгә ала башлаган иде, Вәли аның сүзен бүлде:

— Безнең чакыра торган кешеләр күп. Бер юлы гына чакырып бетеп булмас. Аларны икенче вакытта чакырырбыз. Иң элек менә: Садыйк абзый, Шакирҗан абзый...—дип, шәһәрнең байларын, алар соңыннан шәһәрдәге биш мәхәлләнең муллаларын санап китте.

Хәмдия, мәҗелесне алай бик зурдан—шәһәрнең иң зур байларын чакырудан башланыр дип уйламаган күрәсең, ул аптырап китте:

— Алай бик зурга китә бит, алар безгә килерләрме соң? Без аларга тиешле кадер-хөрмәтне күрсәтә алырбызмы соң? — дигән сөальләрне бирде.

Вәли, Хәмдиянең сайдан йөзгәнен белеп, көлә төште:

— Чакыргач килерләр... Ник килмәсеннәр. Хәзер алар безне таныдылар инде. Аш-су хәзерләргә хатыннар чакырырбыз, — дип, Хәмдияне канәгатләндерер (лек) рә-

вештә, үзенең дагвасын исбат итте. Һәм Вәли теләгәнчә карар да бирелде.

Шуннан соң, кемнәрне һәм күпме кеше чакыру хакында сүз китте. Вәли сул кулын күтәреп, бармакларын җәеп, уң кулының баш бармагы белән ишарә бармагын җәеп:

— Садыйк абзый берәү...—дип, сул кулының чәнчә бармагын китереп тотты. — Садыйк абзый берәү... Шакирҗан абзый икәү, Әхмәтҗан абзый өчәү, Хәбиб абзый дүртәү, Латиф бай бишәү...—дип, зур байларны санап беткәннән соң, шәһәрнең биш мулласын һәм кайбер мөәзинен санаганнан соң, ваграк байларны санарга кереште. Сул кулының бармаклары берничә рәт саналып чыктылар...

... Мәҗелес булды. Чакырылган кешеләрнең һәммәсе дә килде. Вәли абзый үзенең өенә шундый зур байларның килүенә, аларның бу мәҗелестә утыруларына ниһаят кәефләнде. Бу үзенең «зурлар» га катыша башлавының башы булып күренде. Шулай итеп, мәҗелес бик шәп үтте.

Шул мәҗелестән соң бераз вакыт үтү белән Вәли абзыйга шушы рәвештә (язылган) чакыру кагәзе килде: *„Ходай насыйп итсә, җомга көн 12 нче февральдә җомгадан соң сагәт 2 дә туй мәҗелесенә рәхим итүегезне үтенәбез.*

Хөрмәт белән Садыйк Мифтахеттин угылы

Кадриев“.

Вәли абзый, бу чакыру кагәзен алгач, үзенең зурлар арасына керүенә тәмам ышанды. Ул инде шәһәрнең могтәбәр кешеләре җөмләсеннән булуына канәгат хасыйл итте...

Менә бер вакыт февраль инкыйлабы булды. Патша төшерелгән, министрләр хибес ителгән, дигән хәбәргә Вәли абзый башта ышанмады. Бу эшләр һичбер аның гакылына туры килмәде. Ул, бу мәсьәләнең очына үзе генә барып чыга алмасын белеп, «гакыллы» кешеләрнең бу эшкә ничек караганлыкларын белү юлына төште. Ул урамга чыгып, андагы һич исәбе юк халыкның кызыл әләмнәр күтәреп нәрсәдер җырлап китеп барганын күргәч, аптырап китте. Ул бер яктан куркынды, әллә нәрсә җимерелгән, дөнья яңарып киткән кебек күренде. Ләкин һәммә кешенең дә йөзендә шатлык әсәрләрен күргәч, үзе шатланырга тырышты. Ул бара торгач, нәмаеш[1] ясап йөргән халык-

---

[1] Нәмаеш — демонстрация.

ка катнашмый бер як читтә торган, бу нәмаештә ни өчендер тәм вә ләззәт тапмаган «гакыллы башларга» очрады. Вәли абзый аларны күргәч шатланды. Теге кызыл флаглар арасыннан йөргән халыклар гакылсыз булып, бала-чага булып күренде. Ул флаг артыннан йөрүчеләр ярлылар, эшчеләр генә булганга күрә, аларның бу йөрүләреннән бер магнә дә чыкмас, дип уйлап алды. Ул әкрен генә теге каракүл бүрекле иптәшләре янына барып исәнләште. Ләкин ул, аларның йөзләрендә никтер борынгы шатлыкны, теге әйбер сатып файда иткән вакыттагы йөз яктылыгын күрә алмады. Алар ни өчендер, хәзер бу шатлык дөньясыннан, ирек нәмаешеннән мәхрүм ителгән кебек торалар, бу нәмаешкә катышу аларга мотлак харам кебек читтән генә карыйлар иде. Вәли абзый, үзе бик гакыллы дип йөргән Сираҗи янына барып: «Эшләр бик гаҗәп булып китте бит әле; шулай ук эш барып чыгар микәнни?!.» диде дә бик сөальле иттереп карап куйды. Сираҗи бер дә исе китми генә: «Шатланырга иртәрәк әле; аюны үтереп беткәч тиресен бүлгән яхшы» — дип куйды. Вәли абзыйга бу сүз бик магнәле булып һәм эчендә булган шөбһәле бер нәрсәгә җавапсымак булып күренде. «Бу халык юкка алданып кына шатланалар», дип уйлады. Хосусән бу нәмаештә Садыйк бай, Әхмәт бай, Иван Карпов, Николай Кондратиевич Шубин кебек зур байлар бер дә күренмәгәч, моның ялган шатлык булу ихтималы барлыгын уйлап куйды. «Әгәр дә чынлап шатланырлык эш булса, төпле бер вакыйга булса алар да шушы халык җыелышына килерләр иде», дип куйды да, шунда ук янындагы итче Әхмәтҗанга карап: «Ник соң монда рәтле кешеләр күренми, Садыйк абзый белән Әхмәт абзыйлар да юк?» — дип сорады. Әхмәтҗан: «Мондый эшләргә ашыгып катнашырга ярамый, бүген болай, иртәгә ничек булуын кем белә?.. Садыйк абзыйлар — алар төптәнрәк уйлый торган кешеләр, алар бик ашыгып чыкмаслар» — диде. Бу сүздән соң Вәли абзый тагын иркен тын алды. Бу эшләр бер төш кебек нәрсә генә булып күренә башлады. «Садыйк абзыйлар булмагач, әлбәттә, рәтле нәрсә түгелдер», дип фараз итте. Болар байтак вакыт карап торгач, Сираҗи:

— Монда торып тамак туймас, кайтырга кирәк, монда йөрү эшсез кешеләр өчен генә яхшы, — дип, үзен үзе юаткансымак ясалма рәвештә көлгән булды да, янындагы иптәшенең аркасына кагып: — Әйдә, малай, теге ике кип нәрсәгә ия бар, шуны бүген кулдан җибәрик, бәһа яхшы. Моннан бер нәрсә дә чыкмас, боларның товарлары саты-

лып беткән, — дип, кулын кулга сугып куйды. Сираҗиның бу сүзеннән соң болар һәммәсе дә көлделәр.

Иксез-чиксез байраклар һаман дулкынланып алга үтәләр иде. Шул байракларның артыннан эре хәреф белән татарча язылган бер ике байрак килеп чыкты. Бу байрак тирәсенә җыелган кырык-илле кеше татарча марсельеза җырлап баралар иде. Безнең «гакыллы башлар» моны күрү белән шулай таба карый башладылар. Боларның тәннәрендә эсселе-суыклы әллә нәрсә йөргән кебек булып китте. Нәрсә әйтергә дә белми аптырашып калдылар. Тик Сираҗи гына: «Болар да чыккан бит әле! Боларга нәрсә кирәк икән, араларында бер рәтле кеше (юк) ичмасам», — диде. Калганнары Сираҗиның сүзен җөпләп: «Болар бит шәкертләр, байлар ашын ашап симергәч, чыдаша алмый йөриләр...» дип көлделәр. Ләкин боларның көлүләре үзләренең генә эчен яндыра торган бер көлү иде. Бу көлү—җылау алдында булган зәһәрле, ачулы көлүгә ошый иде. Кызыл байраклар үтеп китте. Ләкин халык артыннан барырга боларның аяклары тартмады. Болар гаеткә җитешә алмаган ялкау мужик кебек мәэюс[1] бер рәвештә кайтып киттеләр. Безнең Вәли абзый бүген бер нәрсәгә дә төшенә алмады. Ул халыкның ни өчен йөргәнен, нигә шатланганын һичбер аңлый алмады. Ул бигрәк тә бу нәмаештә «гакыллы» кешеләрнең булмавына аптырый иде. Ул, шуны уйлап, бу вакыйганең чын булуына шикләнде, бу эшләрнең чынга чыкмавын тели башлады.

Шул нәмаеш көненнән атна-ун көн үтәр-үтмәс инкыйлапның чынга әйләнүенә һәр кем ышанды. Гакыллы зыялилар, гакыллы түрәләр, бигрәк гакыллы байлар—һәммәсе дә төсләрен алмаштырып суллашып киттеләр. Һәр төрле эш башында алар күренә башлады. Әллә нинди исемдә яңа идарәләр, яңа оешмалар төзелде. «Милли» эшләр кайнашып, һәр кем шуның тирәсенә җыелды. Садыйк бай белән Әхмәт байның йортында һәр көн зыялиларның[2] җыелышы булды. Байлар да, зыялилар да «хөр» булып, халык файдасын күзәтүче булып әверелделәр. Бүгенге җыелышта Садыйк бай белән Гариф учитель, тагы үзендә хезмәт итә торган Нури—бер рәттән утырып шул ук мәсьәлә хакында мөхакәмә итәргә муаффәк[3] булдылар.

---

[1] Мәэюс — өметсез.
[2] Зыяли — укымышлы, интеллигент.
[3] Муаффәк булдылар — ирештеләр.

ҮЗ БАШЫНА ҮЗЕ ҖИТТЕ

I

Хәким, башының чатнап авыртуына, йөрәгенең чиксез нык тибүенә чыдый алмый, уянып китте. Бу вакытта аның бөтен гәүдәсе калтырый, тәне кыза, тын алырга өйнең һавасы җитмәгән кебек була, шулар өстенә бик авыр бер нәрсә тамагыннан атылып чыгарга торган кебек булып тора иде. Ул, күзен ачып, тирә-ягына каранды. Тирә-ягы чиксез караңгы булып, бер генә дә яктылык әсәре күрә алмады. Үзенең кайда, нинди җирдә ятканын белергә, кичә нәрсәләр булганын, кайда йөргәнен башына китерергә теләде. Ләкин булдыра алмады. Коры чүпрәк белән сөртеп алган кебек кипкән авызы, ярылырдай булып типкән йөрәге, янып барган эче, башының әйләнүе—бер нәрсә уйларга да ирек бирмәделәр. Аның су эчәсе килүе чиктән тыш ашкан иде. Ләкин анда, ул суны эзләп табарлык көч тә, кайда су барлыгын белерлек аң да булмаганга күрә, су табудан өмет өзгән кебек, урында ятудан башка әмәл тапмады. Шул арада, аның башыннан өзек-өзек күренешләр бер-бер артлы үтә башладылар. Кабыл гына, кичә кичтән иптәшләре белән эчә башлавы. ...Аның артыннан ук әллә кем белән сүзгә килүе... кем беләндер кочаклашып җырлавы — тагын әллә нәрсәләр үтеп киттеләр. Шуның артыннан әллә кемнәр аны кыйнарга килгән кебек булды да, сискәнеп китеп, акылын башына җыярга тырышып, үзенең ялгыз гына ятуын исенә төшерде, сонра:

— Нигә һаман таң атмый икән?.. Нигә бу чаклы караңгы икән?..—дигән уйлар башыннан үтте.

Аның башына килгән уйлар бик тиз алмашынып, эшнең очына чыгарга ирек бирмиләр иде.

Барган саен йөрәгенең тибүе көчәйде. Калтырануы артты. Су эчәргә теләве чиктән ашты. Тирә ягын капмалап, үзенең кайдалыгын белергә һәм су табып эчәргә уйлап урыннан торырга теләде, ләкин булдыра алмый, кире урынына ауып төште.

Шул вакытта, караңгылык эчендә кемнәндер кыштыр-кыштыр йөрүе һәм:

— Эт кебек булып кайткан, бөтен киемнәрен эштән чыгарып беткән!..—дип сукранып сөйләшүе колагына керде.

Хәким шул вакытта гына хәзер үзенең өендә икәнен, сукранып йөрүче кешенең хатыны Нәгыймә булуын белде дә, көч-хәл белән:

— Нәгыймә, Нәгыймә!..—дип эндәште.

Нәгыймә, кулындагы нәрсәсен ташлап, Хәким янына килеп:

— Нәрсә бар тагын?—дип сорады.

Хәким, бүген таңда, шушы минутта, уларга яткан ауру кешенең тавышы белән:

— Су гына бир әле, янып барам...—дигән сүзне әйтә алды.

Нәгыймә, рәнҗүле тавыш белән:

— Әллә кайда йөреп, күрмәгәндәй эчәсең дә, эштән чыгып кайтасың!..—дип сөйләнә-сөйләнә, зур чүмеч белән салкын су китереп бирде.

Хәким башын чак-чак күтәреп, калтыранган куллары белән чүмечне алып, ашыга-ашыга суны эчеп бетергәннән соң, урынына ауды да, хәлсез һәм калтыравыклы тавыш белән:

— Таң ата микән әле? Нигә лампа яндырмый караңгыда йөрисең?..—дигән сөальләрне бирде.

Нәгыймә һаман борынгы рәнҗүле тавыш белән:

— Әллә күзең тонганмы, өстәлдә янып торган лампаны да күрмисең! Шулай күп эчеп йөрсәң, күзсез дә калырсың әле!..—дип сукранды.

Нәгыймәнең бу сүзләреннән соң, Хәким сискәнеп китте, әлегә чаклы булган калтырану, сызлануларын исеннән чыгарып:

— Чынлап әйтәсеңме?.. Ник соң мин бер нәрсә дә күрмим?

— Синең белән сөйләшергә вакыт юк әле. Анда бөтен киемнәреңне эт итеп кайткансың, әллә берәрсе белән бәйләнешкән инде. Чучка кебек пычракта ятып аунагансың бит!

Хәким, калтыранып китте дә, башын тотып:

— Чынлап та бер нәрсә дә күрмим, миңа җиде төн уртасы кебек караңгы... Башым ярылган кебек чатный, йөрәгем чыгардай булып тибә...—Ул башка сүз әйтә алмады.

Нәгыймә куркып китте, тиз генә барып, өстәлдә торган лампаны Хәкимнең каршысына алып килеп, күзе алдына тотты да:

— Менә лампа, балкып янып тора, кара әле лампага!—диде.

Хәким гадәттән тыш ямьсезләнгән күзләрен әйләндереп, лампага таба карап:

— Юк, бер нәрсә дә күренми!.. Уф!.. — дип, урнына ауды.

Нәгыймә, бик нык каушаганлыктан, кулындагы лампасын чак-чак төшереп җибәрмәде һәм калтыранган тавыш белән:

— Син сукырайгансың!.. Нәрсәләр эчкән идең соң?..— дигән сөальләрне биреп, елаган, курыккан кебек тавышлар чыгарды.

Хәким:

— Нәрсә булсын, спирт... гарный... әллә, белмим, нәрсә эчергәннәрдер!.. (диде).

Нәгыймә, әрнүле тавыш белән:

— Бетмәде бит шул адәм башына җитә торган агулары!..—дип, сукыранып еларга кереште.

Аның бу тавышына балалары уянып, әниләре янына килеп җиттеләр.

Нәгыймә,

— Әтиегез сукырайган!..—дигән сүзне кабатлады. Балалар баскан урнында катып калдылар.

Нәгыймә, пышык-пышык җылап:

— Әнә кояш та чыгып килә, аны да күрмисеңме?— (диде).

Хәким, карады да:

— Юк, аны да күрмим. Мин хәрап булдым. Күздән яздым!..—дип, йөз түбән капланды. Өй эчендә аптыраш туды. Артык куркудан Нәгыймә дә, балалар да җыларга да, җыламаска да белми торган бер хәлгә килделәр.

Хәким тыныч ятырга теләсә дә, булдыра алмады; эчен уып, бөтерелә, газаплана башлады:

— Кайда, тагын су бир әле...

Китерелгән суны тагын эчте. Ләкин ул су да аның янып барган эчендәге кызулыкны бетерә алмады. Ул урын өстендә аунарга, эчен уарга кереште.

Аның шулай газаплануын күргәч, Нәгыймәнең куркуы тагын артты.

— Үлә бит... Бар әле, Кәрим бабаңны чакырып чык,— дип, зур улына күрше Кәрим картны чакырып чыгарга кушты.

II

Дүрт-биш минут үтүгә Кәрим карт йөгереп килеп керде:

— Нәрсә бар, килен?..

— Нәрсә булсын, энә үләргә ята, үзе бер нәрсә дә күрми...

Кәрим карт та каушап китте. Тиз генә Хәким янына барып:

— Җә, ни булды сиңа?.. Бигрәк тә күп җибәргәнсеңдер шул... Алай кирәкмәс иде,—(диде).

Хәким, артык борчулы һәм бик хәлсез бер тавыш белән:

— Эш начар, Кәрим абзый... Ай, бик авыр!—дип, тагын газапланырга кереште.

— Күрмисеңдәмени?..

— Ю-ук!

Кәрим карт Нәгыймәгә борылып:

— Нәрсәләр эчкән иде соң? (—диде).

— Аның нәрсәләр эчкәнен кем белсен. Кичә озын төн уртасында иптәшләре китереп ташлап киттеләр. Бер нәрсә дә белми иде. Төн буе үлек кебек ятып, таң алдыннан гына кузгала башлады.

— Усман, шулай эчә торгач, күзсез торып калды бит...

— Үзе исән калса гына ярар иде...—Нәгыймә, соңгы сүзләрне җылау катыш сорау белән әйтте.

— Кая, салкын сулы чүпрәк белән башын ябарга кирәк.

Нәгыймә кирәк нәрсәләрне әзерләп китерде.

Кәрим карт,

— Күзсез көе калса да, яхшы булмас. Әнә Усман шулай күзсез көе калып эт көнендә тора бит!—дип, сөйләнә-сөйләнә Хәкимнең башына сулы чүпрәк ябарга кереште.

— Уф, су кирәк!..

Тагын су китерделәр. Хәким, суның беразын гына эчте дә, укшырга кереште. Бераз гына укшу белән эчкән сулары атылып чыгып, идәнгә чәчелделәр. Аның төсе агарып, иреннәре күгәреп китте. Аз гына тын ятканнан соң, тагын да укшырга кереште. Бик нык көчәнеп укшыганнан соң, эрен кебек саргылт күбек катыш нәрсәләр чыга башлады. Ул укшыган саен бөтерелә, үзен кайда куярга белми газаплана, борчыла иде.

— Ничек, әзрәк ару булмыйсыңмы?—диде Кәрим карт.

— Ю-у-к... янам... башым ча-т-ный, күзләрем атылып чыгарга торалар...

— Күрмәгәндәй эчмәскә кирәк иде. Шул эчү... Күпме кешеләрнең башларына җиткәнен күрә торып эчәләр бит!.. Янып үләрең бар бит...

Аның бу сүзләренә каршы Хәким бер сүз дә әйтмәде. Аның урнына Нәгыймә:

— Һәр вакыт әйтә киләм мин аңа... Бер көн шулай күп эчеп, үлемнән чак калган иде. Гыйбрәт алмагач, алмый бит!—дип, көрсенеп, калтыраган иренә карап башын селкеде.

Хәкимнең газаплануы артканнан артты. Тирә-ягындагы кешеләрдә эше булмаган кебек, гырылдап ямьсез тавышлар чыгара башлады. Нәгыймәнең дә, балаларның да, Кәрим картның да куркулары артты.

— Агулы нәрсәләр аның эчен тырный инде. Булмаса, духтыр китерергә кирәк,—диде Кәрим карт.

— Больниска диң инде...—диде Нәгыймә.

Хәким, күкрәгенә таба бөгелгән башын язып, аякларын сузды, тагын җыелды һәм көч хәл белән генә:

— С-с-у!...—диде.

Су китерсәләр дә рәтләп эчә алмый, чүмечне этәреп җибәрде дә, башын мендәргә куеп әрле-бирле селкергә кереште. Ул хәзер бер бөгәрләнә, шунда ук аякларын сузып җибәрә, бер йөз түбән төшә, әз генә ятып торгач, тагын чалкан төшеп эчен уарга керешә иде.

Кәрим карт:

— Малайның рәте китеп бара, син әйткәнчә, больниска алып бармый булмас...—дип, Нәгыймәгә карады һәм шунда ук:

— Мин ат алып килим, син сулы чүпрәк белән башын чылата тор,—дип, чүпрәкне Нәгыймәгә биреп, үзе чыгып китте.

Бераздан соң, Хәкимне күтәреп чыгарып арбага утырттылар да, ике ягыннан тотып, больниска алып киттеләр.

III

Кичкә каршы Кәрим карт тагын керде. Бу вакытта өйдә балалар гына иде.

— Җә, балалар, әниегез һаман кайтмадымыни әле?..

— Юк...

Ул кайгырган рәвештә балаларга кайгылы күзләрен төшереп алды да, тирән көрсенеп:

— Һәр вакытта эчмә, эчмә, эчеп эшкә кергән кешене күргәнем юк, дип әйтә килдем мин аңа...—диде. Балалар җавап кайтармадылар.

Кәрим карт артык сүз әйтмәде. Ул бераз уйланып утырганнан соң, чыгарга теләп урыннан торганда, хәле бетеп, Нәгыймә кайтып керде.

— Үлде!.. Әй бәхетсез балалар, атагыз үз башына үзе җитте!..—дип, балаларын кочаклап җыларга кереште. Аның тавышына балаларның да җылау тавышлары өстәлде.

Кәрим карт баскан урынында катып калды. Ул, бу авыр күренеш һәм бу авыр хәбәрдән артык борчылганлыктан, нәрсә әйтергә дә белми иде. Тик бераз карап торганнан соң гына:

— Мона, һичбер көтмәгәндә булган үлем... Духтырлар да терелтә алмадылармыни?—дигән сөальне бирде. Нәгыймә көчен җыеп:

— Тырыштылар да, булдыра алмадылар. Әллә нинди агулы эчемлекләр эчкән, монда килеп җиткәнче үк эчәкләре эштән чыгып беткән диделәр...—дигән сүзләрне әйтеп җыларга кереште, һәм,

— Ярырга кирәк диләр,— дип өстәде.

— Андый үлем белән үлгәннәрне закон ярырга куша шул... үзе дә, мона бу балалар да жәл инде!..—диде Кәрим карт.

Бу вакытта, аның картлык белән кипкән күзләреннән яшь бөртекләре тәгәри һәм шул яшьле күзләре аркылы Нәгыймә белән балаларга карап:

— Ул үзе үлде. Ләкин менә сезне хәсрәткә төшереп, өй тулы балалар калдырып үлде. Шунсы бигрәк тә авыр!..—дигән сүзләрне әйтә иде.

— Хәким, күп эчеп, күзләре сукыраеп, янып үлгән!..—дигән сүзләр күршеләргә дә, тирә якка да таралды.

Аларның белеш-танышлары, күз күргән кешеләре:

— Кичә генә исән кеше, бүген юк!..

— Мин аны кичә иртән урамда очраткан идем, шундук исрек иде...

— Артык күп эчәдер иде шул...

— Эчүнең ахры шулай була инде ул...

— Үз башына үзе җитеп туктады...

— Үзе тагы бер хәл. Хатын белән балалары кызганыч!—дип сөйлиләр, һәм,

— Башкаларга гыйбрәт инде бу!..—диләр иде.

УЛ БУ ЭШЛӘРНЕҢ БУЛАСЫН АЛДАН БЕЛГӘН ИДЕ

(Май бәйрәме шатлыгы астында)

Беренче майның киче.

Төрле төстәге электрик утлары белән нурга чумган мәйдандагы иптәш Ленинның һәйкәле тирәсендә халык сыеша алмый.

Мондагы халык диңгезенең шатлыкларын, туганлыкларын күргәндә хайран калмаслык түгел.

Дүрт-биш ел элек:

— «Менә тиздән шундый күренешләр, шундый туганлыклар булыр...» дип әйтсәң, күп кешеләр ышанмаслар иде. Бүген күз белән күргәч, берәү дә:

«Булмас!...» дип әйтә алмый. Башка бәйрәмнәр онтылганнар...

Ураза бәйрәмен, пасхаларны уйлаганнан соң, бу бәйрәмгә чагыштырып карыйсың да: «Чын бәхет бәйрәме менә шушы шул», дисең.

Кемдер анда:

«Монда бәйрәм ичмаса!..» ди.

Иптәш Ленинның өстән шатланып карап торган мәһабәт гәүдәсенә карап, «Бу бәйрәмнең булуына башлап син сәбәпче булдың», дигән кебек шак катып торучыларның хисабы юк.

Кемдер анда:

«Мескен, үзе бу шатлыкларны күрә алмады... күрсә ни эшләр иде икән?» ди. Шушы сүзне өзелеп әйтүчегә диккат белән карадым. Ул бер карчык икән, күзләрендә яшьләре мөлдерәп тора. Карчык кеше шуннан артык сүз таба алмагандыр. Ләкин аның сүзләре миңа бик нык тәэсир итте, аның күз яшьләренә карап, электән дә йомшак күңел тагын да нечкәрде.

«Үзе шушы шатлыкны күрә алмады!»—Мескен карчык артык шатлыгыннан башка сүз таба алмый. Соңра, бит ул үзе Ленин хакында укып белгән кеше түгел.

Тик аның күрсәткән юлы белән кешеләрнең шулай бергә туганлашуларын, обший бәйрәм ясауларын күрә.

Ленинны өйрәнә алмаган, безгә күрсәтеп калдырган юлларын төшенеп җитмәгән... Аның бик ерак алдагы көннәрне күреп, шушы көрәшкә чакырып әйткән сүзләрен ятлап алмаган бик күп кешеләр, шулай:

«Мескен. Үзе шушы шатлыкларны күрә алмады?!» ди торганнардыр.

Ләкин хаталаналар... Ул бу көннәрнең булачагын, туганлык белән бәйрәм итәчәкләрен алдан белеп, ерактан күрде. Ул «мескен» түгел! Хәзер безнең күз алдында гәүдәсе белән басып, таглиматы бөтен кешеләргә юл күрсәтеп тора. Аның кебек бәхетле, аның кебек алдан күрүче кеше мескен буламы соң?!

— Ах, ул ничаклы бәхетле!.. Аның башлаган юлы артасында бердәмлек белән нәрсәләр эшләнми!.. Нинди күңелле бәйрәмнәр ясалмый! Зур бәйрәмнәр ясап эшче-крестьяннәр үзләренең көчләрен бөтен дөньяга күрсәтәләр бит!..

Бу көннәр... бу кичәләр... Ничек күңелле, кызыл әләмнәрен югары күтәреп килгән яшь пионерлар, комсомоллар, мона магрурана[1] йөргән шат эшчеләр...

Менә төрле милләтләрнең тигезлек белән катнашып ясалган дуслык бәйрәмнәре!

Шуларны күр(әсең) дә, син аны:
«Мескен!..» дисеңме?
Аның кебек бәхетле тагын кем бар икән соң?
Әйтегез шуны миңа!..

1925

ГАРМОН ТАВЫШЫ

I

Көзге төн булса да, төн аяз һәм ай яктысы булганлыктан, караңгы түгел. Авыл, киң басулар уртасында, тын гына йоклап ята. Җиткән кызлар, аулак өйгә җыелып, кич утыралар. Мин кечкенә булгач, авырсынмадылар. Һәм артык яшерен сүзләргә дә кирәк тапмадылар. Куллары эштә булса да, күңелләреннән әллә ниләр уйлап, телләре белән авыл җегетләренең исемнәрен тезәләр:

— Салих... Әбәү шуның күзләре!.. Тычкан күзе кебек кечкенә.

— Әлмәри малае бишмәтенең төймәләрен дә каптырып йөри белми!..

— Гыйззәт—бүреген кырын салып йөргән була!..

— Вәлинең борны озын, шуның борыннан тартасы иде...

— Әә соң, Габдерәхим! Авызыннан сүзен алыр хәл юк...

---

[1] Магрурана — горурланып.

Һәрбер җегетнең бер сыйфатын сүләп көләләр, мыскыл итәләр... Ләкин эчләреннән аларны яраткалыкларыкүренеп тора. Мин кенләшеп куям. Шуның өстенә кайуйларын миннән яшерер өчен, сүзләрне бозып, мин белмәгән телдә сөйлиләр:

— Вәснәли кичничә безнең уснурамнан үснүтеп баснара. Ә үснүзе беснезгә таснаба каснарый, миснин көснеләм. Уснул кыснызара...

Мин дә зирәк малай бит: аларның яшрен сүзләрен аңлап алдым, ул кыз:—«Вәли кичә безнең урамнан үтеп бара, ә үзе безгә таба карый!.. Мин көләм, ул кызара...» димәкче була.

Шундый сүзләрдән соң, шаркылдашып көләләр.

Берсе, минем аңлаганымны белде күрәсең:

— «Бусну масналайның түснүбәсе тиснек мәллә?—ди.

Беләм мин, беләм: алар егетләрне яраталар, ләкин миннән яшермәкче булалар, ул кыз миннән шикләнеп: «Бу малайның түбәсе тишек мәллә?..» ди.

Әйтерсең, аңласам әтиләргә кайтып әйтәм...

II

Ерактан гармон тавышы ишетелде. Кызларның төсләре үзгәреп китте... Шундук, кулларындагы эшләрен ташлап, лампаны баса төшеп, тәрәзәгә ябырылдылар.

Кайда кызлар кич утырганны егетләр сизәләр бит: алар бу турыга җиткәч, йөрешләрен әкренәйтеп, гармонны киерә төшеп, тагын да дәртлерәк уйный башладылар. Берсе, гармонга кушылып, җырлап җибәрде:

Таң әтәчләре кычкыра,
Әллә таң ата микән?..
Тәрәзәдән карап кала,
Әллә ярата микән!..

Кызлар шатланып киттеләр. Берсе берсен төртешеп, тәрәзәдән чыгардай булып, карыйлар, үзләре пырых-пырых көлешәләр...

— Салих гармон уйный, Сәлим җырлый,—диделәр. Үзләре белеп торалар тагын...

III

Гармон белән җыр тавышы ераклашкач кына, кызлар лампаны күтәреп, эшләрен кулларына алдылар. Ләкин алар тирән уйга чумганнар, моңга батканнар, хәзер егет-

ләрне мыскыл итеп көлмиләр иде. Аларның моңнары эчләренә сыеп тора алмады: Нәгыймә апа кубызын алды да, кып-кызыл иреннәре арасына куеп, матур бармагы белән кубызның телен чиертә башлады. Фатыйма аңа:

— Урамнардан үткән ай үзе икән,
Кулларында яшел музыкан..
Урамнардан үткән чакларында
Күрмн үтеп, ничек түзәйкән?..

дип әкрен, ләкин бик моңлы иттереп жырлый башлады. Сәлимә, авызына капкан оек энәсен дә онытып, тыңларга кереште.

Бу күренеш матур да, моңлы да, кызганыч та иде...

Яшь кызларның янып торган күңелләре тар читлектән чыгып, ирек теләгәндер, матур жыр һәм матур көйне якыннан тыңлап, иркен һавага чыгасылары килгәндер шул... (хәзер шулай уйлыйм).

IV

Иртәнгесен чәй эчкәндә эти:

— Бүген төннә рәтләп йоклый да алмадым; инде йокыга киттем дигәндә гармон белән жырлап үтеп, йокымны качырдылар. Үткән гомерләрем искә төшеп китте... Кем уйный соң анда?—диде.

Мин балалык сафлыгы белән:

— Салих гармон уйнады, Сәлим жырлады,—дип әйткәнемне сизми дә калдым. Бу сүздән соң апа кызарып китте. Миңа күз кысып куйды.

Әти шундук эләктереп алып:

— Син, малай, кайдан белдең? Әллә кызлар янына керделәрме?—дип, кыска гына сөаль биреп, минем күзгә карады. Мин тәрәзәдән карап белгәнлегемне әйтеп, чак котылып калдым.

— Кара син аларны, музыканы кайдан тапканнар да, кайдан өйрәнеп өлгергәннәр, бу чактагы яшьләр таш астыннан табарлар, агай!—ди.

«Музыка картларның да йокыларын качырган икән... Ә үзләре яшьләргә ачуланмакчы булалар»... дип уйладым.

Шулай матур, моңлы, дәртле тавышларны ишеткәндә яшьләр дә, картлар да әсәрләнми кала алмыйлар.

Кәккүк айларын, сандугач сайрый торган язны һәркем көтеп ала. Боларның тавышларын ишеткәндә арган кешегә көч, күңелсез кешегә дәрт кереп китә, ләкин санду-

гач сайраулары, кәккүк кычкырулары бик вакытлы. Адәм баласы музыканы кирәксенә:

— Скрипка кылларының сызлануы белән йөрәк бергә сызлана.

— Мандолинаның кыллары селкенгәндә йөрәк бергә селкенә...

— Гармон белән йөрәк бергә тибә.

— Духовой оркестр уйнаганда аякларның басулары үзгәреп китә.

Музыканың тәэсире элек тә шулай иде, хәзер дә шулай, мәңге шулай китәчәк...

V

Шушы арада матбугатта: «Авыл яшьләре арасында гармон» дигән бер мәсьәлә кузгалды. «Яшь юксыл» газетында бу хакта байтак язучыларның фикерләре басылды. Шуларны укыгач, моннан бик күп еллар элек, бәләкәй чакларда, гармон ишеткәндә яшьләрнең һәм картларның ни рәвешле эсәрләнүен күрүем искә төште.

— Бу мәсьәләне кузгату нигә кирәк икән?—дип әйтүчеләр булыр.

Җан азыгы булган музыка хакында сүз кузгату бик кирәк эш. Гармон—авылларга бик күптәннән кергән уен коралы. Ул үзенең простойлыгы, уйнарга өйрәнергә җиңеллеге һәм башка уен коралларыннан арзанлыгы аркасында авылларга таралып өлгергән. Тик ул борынгы яшьләрнең картлардан, муллалардан куркып мунчаларда, печән асларында яшереп асралуы, караңгы төннәрдә урамнарда гына уйналуы аркасында, түргә менү хокукын ала алмый калган, «батрак» булып килгән бер нәрсә. Карт байлар, муллалар сандыклы уен белән грамофонны өстәлләренә куеп уйнатсалар да, гармонга «шайтан коралы» исме биреп, аны күргән бер җирдә ватып ташлаганнар...

Хәзер авылларда музыка кирәк. Мөмкин була икән, гармоны, скрипкасы, мандолинасы бергә булсын да, яшьләрнең буш вакытларында авыл халкына концерт бирерлек бер хәлгә килсеннәр.

Комсомоллар, аңлы яшьләр гармонда уйнау эшләрен, башка эшләргә зарар итмәслек рәвештә, тәртипкә куюп, гармон һәм башка музыка коралларыннан файдалану юлларын билгеләү эшләрен үзләре карарга тиешләр.

Эш үз вактында эшләнеп, музыка үз вактында уйналса гына күңелле була ул...

Шәһәрләрдә шулай куелган.

1926

ДӘРТЛЕ ЕГЕТЛӘР

I

АБЗЫЙ КАЙТА—МИН КИТӘМ

Пушкин урамыннан китеп барган вакытта, каршыга бер яшь егет, мине таныган кеше кебек, әллә кайдан көлеп килә...

Мин: «Бу егет нигә болай таныш кеше кебек көлеп килә икән?»—дип уйладым да, аны узып китә башладым.

Ул минем турыга килеп җиткәч, туктады да:

— Исәнме әле, абзый...—дип кулын сузды.

Мин аның йөзенә диккат белән карасам да таный алмадым.

— Туган, мин бит сине таный алмадым. Син кайдагы егет буласың соң?—дидем.

Ул көлә төште дә:

— Мин бит... авылының... улы булам, танымыйсыңмени?—диде.

Ул шулай дигәч кенә, аның Габдулла абзый улы икәне кылт итеп хәтремә төште:

— Шулай бит әле... Син ул вакытта гәүдәгә бәләкәй идең, хәзер ничек үсеп, үзгәреп киткәнсең... Синең абзыең да бар иде бугай?—дидем.

Ул якынлашып китте:

— Әйе, бар иде. Ул хәзер красноармеец булып... шәһәрендә тора. Быел кайта инде,—диде.

Үземнән-үзем: «Кара әле, болар яңа гына яшь малайлар иде... Хәзер үскәннәр дә, берсе красноармеец булып быел елын тутырып кайта, ә монысы үсеп менә дигән егет булган»—дип уйладым, һәм:

— Син соң калага ни йомыш белән килдең?—(дидем).

Ул, киерелә төшеп:

— Каралырга килдем, иртәгә каралам...—диде.

Үзе кунакка килгән кеше кебек шат. Мин аны каралып кызыл гаскәрлеккә алынуга ничек караганлыгын белер өчен:

— Үзеңне алып куйсалар нишләрсең соң?—дидем.

Ул минем бу сөаләмә аптырап киткән (дәй) булды һәм күзләрен тутырып миңа туры итеп карап:

— Алсалар бик күңелле булыр иде дә, әле чир-фәләи табып алмый калмасалар ярар иде дип куркам,—диде.

— Нигә, син шулай кызыл гаскәрлеккә китүне бик теләп торасыңмени?.. Абзыең кайтып җитмәгән бит әле,— дидем.

— Ник теләп тормаска? Анда минем кебек егетләр дә бармагач, кем бара соң? Хәзер безгә чират! Абзый кайта—мин китәм,—диде.

Егетне шикләндереп булмавын аңласам да, тагын да ныклап аңлар өчен:

— Ә соң абзаң ничек яза? Кызыл гаскәрдә йөрүдән зарланмыймы? Авылны сагына торгандыр әле,—дидем.

Шул сүздән соң, ул үзе миңа, әллә ничек, шикләнеп карады:

— Әллә... абзый, мине юрамалый шаяртасың инде? Ул нигә зарлансын ди? Син әйткәннең киресенчә, ул үзенең Кызыл Армиядә йөрүенә шатланып яза: «Монда килеп дөнья күреп кеше булдым, авылда гына яту белән кеше бер нәрсә дә аңламый икән. Башта кыен булыр төсле иде, хәзер кайтасы килми, кызыл казарма җәл кала инде. Мин кайтуга син хәзер булып тор...» дип яза,—диде.

Дәртле егетнең теләге зур, ихласы шәп икәнен хәзер чынлап төшендем.

— Рәхмәт, туган, шулай кирәк... Хәзер кызыл казарма тормыш мәктәбе ул... син аны күрми, ишетеп тә шулай икәнен аңлагансың. Алынып баргач, үзеңнең дә кайтасың килмәс әле,—дим.

— Шулай, мин үзем теләп китәм, ауру гына тапмасалар ярар иде. Болай ауруым юк-югын да,—диде.

— Ну, хәзергә хуш, алынгач минем фатиргә барып чык. Тагын да сөйләшеп утырырбыз, монда гына сүз бетмәс,—дип, аерылып киттем.

— «Хәзерге егетләр куян кебек куркак түгелләр шул. Үзләре теләп алга китәргә атлыгып торалар. Боларның кулларына мылтык бир дә, шуннан кара да тор...» дигән шатлыклы уй белән алга киттем.

II

ПУЛЕМЕТНАЯ КОМАНДАГА ЯЗЫЛГАН

25 нче сентябрьдә Осоавиахимның яңа төзелгән полкына смотр булды.

«Дворец труда» янындагы зур мәйдан күңеллеләр белән шыгырым тулган иде.

Монда 16—17 яшьтәге яшь үсмерләрдән башлап, 15—20 шәр ел эшләгән карт эшчеләргә чаклы сафка тезелеп, командный составның килүен көтәләр иде. Һәммәсе шат була икән. Төрле авырлыкка да хәзер булып, үзара сөйләшәләр:

— Мин пехотага язылдым...

— Мин пулеметная командага...

— Мин атлыларга...

Ә кызлар,

— Мин санитарнаяга язылдым,—дип шау киләләр. Әйтерсең туйга барырга хәзерләнәләр.

Гаскәри башлыклар һәм профсовет кешеләре, мәсьүл эшчеләр килделәр.

Смотр «ура» тавышлары астында үтте.

Тәбрик сүзләре сөйләнде. Яңа төзелгән күңелле полкка Башкырт Советы тарафыннан кызыл әләм тапшырылды. Адрес такдим кылынды.

Меңләгән күңеллеләрнең бу рухлы күренешләре совет дусларының йөрәкләренә зур дәрт, җимерелмәс өмет биргән кебек, дошманнарның йөрәкләренә салкын су сипкән бер рәвештә иде.

Шатлык белән өйгә кайтып, уйланып утырганда, мәктәптә укучы берничә яшьләр килделәр. Алар белән бүгенге смотр һәм Осоавиахим полкы турында сүз китте Берсе:

— Мин пулеметная командага язылдым,—ди. Икенчесе дә шунда язылган икән. Язылып өлермәгәннәре үзләренә шундый утлы корал тирәсен эзлиләр.

Мин боларны сынар өчен:

— Ярый ла хәзер языласыз. Ә соң сез өйрәнә алырсызмы? Сугыш була калса шүрләмәссезме?—дигән сөалне бирдем, һәм: —Сез, санитарный полк кебек урынга язылган булсагыз ничек булыр иде соң!—дигән сүзне өстәдем.

Малайлар намусланып киттеләр.

— Әллә инде... абзый безне куркаклар дип белә. Без өйрәнербез дә, эшләрбез дә. Санитарныйга язылып артта йөрү егетлекмени ул?

— Әх, пулемет белән алдан барып тыр-тырр-тырр сиптерү нинди күңелле!—диләр. Үзләре хәзер сугыш чигендәге кеше кебек булып кулларын арлы-бирле бутыйлар. Боларның һичбер курку әсәрләре юк.

Егетләр дәртле, борынгы заман яшьләре кебек мәми авыз күренмиләр.

Әллә кайдан дәрт алганнар, әллә кемнәр боларга рух биреп өлгергәннәр.

Алар белән сөйләшеп, үзем дә дәртләнеп киттем. Озак кына утыргач, алар чыгып киттеләр.

Мин,—«Кичә берсе, абзый кайта, мин китәм, дип китәргә теләп торганын белдергән иде, болары, еллары җитмәс борын, үзләре теләп торалар...»—дигән уйда калдым.

Чынлап та:

—Дәртле егетләр!

— Дәртле зурлар, дәртле картлар хакында ник язмыйсың? Алар юкмени?—дип әйтерсез. Ләкин, ул чыныккан һәм үткән көрәшләрдә үзләрен күрсәтеп, дәрт, гайрәтләрен исбат иткән, соңра, һәр вакыт хәзер булып, кичәге смотр көнендә сафка тезелгән (зурлар) хакында язып тору артык булыр, дип уйлыйм. Яшьләр белән бер рәттән, кирәк кайда булса да, хәзер торган алар миллионлап санала.

Алар, миллионнарча яшь, дәртле көчләр белән һәр вакыт бер сафта торачаклар, бу—маглүм.

Бу көчләр бер сафка тезелеп торганда, безнең ирекле Совет иленә һичбер дошман аяк баса алмас.

Бу көчләр, бергә укмашкан хәлдә, дошманнарның йөрәкләренә хәүеф, куркыныч салып, бөтен дөньяны тыныч тормышка алып чыгу хезмәтен үтәрләр.

— Шулай түгел!—дип кем әйтә алыр?..

1927.

ДИҢГЕЗ АРТЫНДА

Көйле фельетон

Нинди эшләр юк дисез бу дөньяда,
Бик борынгы Европа һәм Азияда...
Сез хәзергә бу икесен гафу итеп,
Көлмәенчә сез аларны кимсетеп,
Бер карагыз әйдә диңгез артына,
Диңгез артының мәдәни халкына...

Анда бардыр Америка—ул яшь әле,
Гомере дүрт йөздән дә[1] күп үтмәс әле.
Аз гомердә бик күп алга китсә дә,
Фән-белемдә иске җирдән үтсә дә
Ул егетнең бик кызык яклары бар,
Ис китәрлек бик кызык чаклары бар...
Шул кызыкларга хәзер чынлап карыйк,
Бергәләп кайберләрен тыңлап карыйк:

(көйсез)

1. Американың Вашингтон шәһәрендә ак тәнле халыкларның (ак сөякләрнең) негрлар белән бер җирдә су коенулары ярыймы?—дигән бәхәс башланды һәм бу хакта хөкүмәткә запрос бирелде.

2... шәһәрендәге университетта укучы ак халыкның малайлары, негр малайлары белән бер җирдә укымаска карар бирделәр (ягни, алар белән бер рәттән утырып укырга гарләнәләр).

3. Тимас каласында, бер ак тәнле баланы үтерүдә шикләнеп, ирле-хатынлы негрларны тереләй утта яндырдылар...

Аларның янган чактагы газапланып елашуларын радио аркылы бөтен Америка тыңлады.

4. Америкада этләр өчен теш докторлары була башлады. Бу докторлар Америка байларының этләренә алтын тешләр куеп йөриләр...

Башкалар һәм башкалар...

Сез ничектер, мин үзем хәйран калам,
Шул хәбәрләрне китергәч телеграмм

Ул болай читтән: бәхетле мәмләкәт,
Төрле яктан алга киткән бик җәһәт.
Ис китәрлек алга киткән ул халык,
Анда фән... Анда һөнәрдә алдалык...
Уйласаң ул якларын исләр китә,
Һәммә җирдән алдын анда техника...
Безгә маглүм: каһвәсе[2] һәм сөтләре,
Бик матур һәйкәл[3] салынган этләре...

---

[1] Американың ачылуы — 1492 нче елларда. (М. Гафури искәрмәсе).
[2] Қаһвә — кофе.
[3] Үткән ел анда бер эткә һәйкәл—памятник салалар. (М. Гафури искәрмәсе).

Кайбер этләр мәшһүр адәмләр белән
Бергә ашыйлар ди, мадамлар[1] белән...
Билгеле фордзоннары һәм Фордлары,
Илле-алтмыш катлы мәшһүр йортлары...
Белгән ирләр анда бик туклык диләр,
Америка һич күрми ул кытлык диләр...
Без аларны бай дибез, шуннан карап,
Анда байлык... әмма монда эш хәрап!..
Һәр вакыт читтән караганда эш шулай,
Син үзең ярлы, бүтәннәр барсы бай...
Синдә карлы кыш... аларда яз кебек,
Күршенең үрдәкләре дә каз кебек...
Уйласак без Америка да нак шулай,
Мең вә миллионнан бере данлыклы бай...
Әллә юк дисезме анда ярлылар...
Билгеле, бер байга миллион ярлы бар...
Бу җәһәттән эш шулай ул дөньяда,
Үзләре магрур алар фәүкылгадә[2].
Гарләнәләр җирле халыклар белән
Бер рәттән су керергә елгада...
Соңра алар үзләре бик күп укып,
Алга киткәннәр алар шул аркада...
— Без эреләр... Ул түбән халыклар белән
Без утырмыйбыз!.. диләр, бер партада...
Үзләреннән берсе үтерсә кеше,
Коткаралар ул кешене суд белән...
Әмма негрларны юк-бар шик белән
Шул урындук яндыралар ут белән...
Сүзне кыскартканда булды эш булай:
Ул халык тик үзләре пак, ак сөяк.
Ул халык алдында негр һәм кытай,
Башкаларның һәммәсе дә вак-төяк.
Башкалар чүптән начар, эттән түбән,
Инде сезгә моннан артык ни кирәк?..

(Көй үзгәрә)

Үз итекләрендә тар булгачтын
Дөнья киңлегеннән ни файда?..
Ансат кына башка халыкларга
Киң тигезлек биргән җир кайда?..

---

1 Мадам — ханым әфәнде, кадерле бай хатыны. (М. Гафури искәрмәсе).
2 Фәүкылгадә — гадәттән тыш.

Читтән карап, читтән ишетеп кенә:
— Анда матур икән?.. дибез ул.
Безнең монда гына бөтен халык
Аермасыз-нисез ул...

1927

ОКТЯБРЬ РЕВОЛЮЦИЯСЕНЕҢ ТАҢЫНДА

Өч-дүрт көн була инде—Петроградтан телеграмма юк. Көн-төн туктамый хәбәр йөртүче телеграмма чыбыклары тынлыкта торалар... Халык арасында, колактан-колакка, төрле хәбәрләр йөри...

— Петроградта эшчеләр баш күтәргәннәр икән...

— Ач халык: «Икмәк!.. Икмәк!»—дип, государственная дума алдына барганнар икән...

—Солдатлар фронтка бармый, эшчеләргә кушылганнар икән,—диләр.

Ләкин бу сүзләрне бик яшерен рәвештә генә сөйлиләр. Сөйләшер алдыннан тирә якка карап алалар. Шуның белән бергә, бу «имеш хәбәрләр» генә кешеләрне канәгатьләндерми. Ничек булса да эшнең асылын беләсе килә. Шикләнеп тә куялар.

— «Имеш» сүзләргә ышанып харап булып куймыйк. Эшчеләр ишетә күрмәсен!—диләр.

Телеграфтан хәбәрләр килмәү өстенә, мондагы зур түрәләрнең, гаскәр башлыкларының борыннары төшкән. Йөреш-торышларында үзгәреш сизелә. Аларның йөзләре агарып, шомлы рәвештә ямьсез ачулы күренәләр. Элек аякларын бик ныклап басып, очраган бер солдаттан честь бирдереп йөргән горурлы офицерлар, баскан җирләренең йомшаганын сизгән кебек, шикләнеп, куркып атлыйлар. Шушы галәмәтләргә караганда—ни дә булса бер нәрсә бардыр...

Искечә мартның беренче-икенче көннәрендә бу шөбһәләр тагын да арта төшәләр. Колактан-колакка сөйләшүләр ешайдылар.

Язның матур, кояшлы көне булуга карамастан, түрәләрнең, гаскәр башлыкларының йөзләрендәге аклыклары кызармый. Күзләрендәге ачулары басылмый.

— Күрәсең, аларга андагы зур вакыйгалар хакында яшерен телеграмма килеп, алар үзләренең соңгы көннәре җиткәнен сизә торганнардыр... Шуның өчен мартның елы

кояшы да аларның йөзләрен кызарта алмый, туңган йөрәкләренә тәэсир итеп, елылык бирә алмыйлар.

17 нче ел, мартның иртәнге кояшы бик матур. Аның нурлары эшкә барган эшчеләрне сөеп каршы алды. Иртәнге язгы саф һава кысылган күкрәкләрне киңәйтеп җибәргән кебек булды. Эш кораллары да борынгы кебек авыр түгел, уйнап торган кебек торалар.

Эш башлаганнан соң, күп тә үтми, берничә йөз эшчесе булган заводның конторындагы телефон ашыгып шалтырый башлады.

Заводның мөдире, ашыгып барып, телефон трубкасын кулына алып:

— Кем бар, нәрсә кирәк?—дип сорады да, үзе каршы җавап бирми, тик:—Ну-ну... Шуннан? Әйт, әйт! Ай-хай, ай-хай... Чын булырмы икән?—дигән сөальләрне тезә башлады. Бу вакытта аның йөзе бер агара, бер күгәрә, кулы калтырый, күзләре бер түбән төшә, бер түшәмгә карыйлар иде.

Аның шундый ашыгыч сөальләре, йөзенең агаруы конторадагы язучыларга да, эш белән кереп мөдирне көтеп торган эшчеләргә дә тәэсир итеп, алар һәммәсе дә мөдирнең калтыраган гәүдәсенә, агарган йөзенә карап торалар.

Мөдир, сүзен бетереп, телефонның трубкасын элеп куйды да, күңелсез генә булып урнына килеп утырды.

Конторадагылар аның гадәттән тыш бер эш хакында хәбәр алганын сизеп, нинди хәбәр икәнен беләселәре килде һәм берәр минут тынлыктан соң, араларыннан берсе:

— Әллә берәр уңайсызлык бармы?—дип сорады.

Мөдир, йөзендәге күңелсезлекне бетереп, йөзенә шатлык бирергә тырышкан кебек:

— Без көткән минутлар җитте. Петроградда зур ихтилал[1] булып, иске хөкүмәт алмашынып, яңа хөкүмәт утырган. Борынгы министрлар арестовать ителгән, патша төшерелгән,—дип, тирә ягындагыларга карады. Аның соңгы сүзләре тирә ягындагы кешеләрнең:

—Ура!.. Ура!..

— Залим[2] хөкүмәт беткән!

— Патшаның тәхте җимерелгән!—дип кычкырган тавышлар сафында югалды...

Өч минут эчендә бу хәбәр заводдагы бәтен эшчеләр арасына таралып өлгерде. Завод эчендә шау-шу башлан-

[1] Ихтилал — революцион кузгалыш.
[2] Залим — явыз.

ды. Шатлык тавышлары яңгырады. Эшчеләр унар-унбишәре бер урынга җыелып, сөйләшергә керештеләр.

Теге башта марсельеза җырлаган тавыш бөтен бинаны яңгыратып җибәрде.

Шуның артыннан ук бер төркем эшчеләр конторага килеп керделәр.

Мөдир бу эшне «башбаштаклык» дип уйлады булса кирәк, кәефсезләнде, моңарчы рөхсәтсез кермәгән эшчеләрнең болай төркеме белән конторага тулуларына чыдап тора алмады.

— Нәрсә бар ул чаклы, нигә конторага туласыз?— диде. Ләкин аның күзләренә чыккан ачуын күрүче, әйткән сүзләрен ишетүче булмады. Эшчеләрнең тавышлары аның сүзләрен юкка чыгардылар.

Аз гына сөйләшкәннән соң, бер эшче йөгереп барып, стенада торган патша сурәтен тартып төшерде дә идәнгә атып бәрде.

Аның тузаннары тирә якка таралып, эшчеләрнең аяк асларында югалды. Бер минуттан соң, ул сурәтнең тетелгән кисәкләре эшчеләрнең аяк асларында калып, сынык рамнары идәндә таралып яталар иде. Аны хәзер кызганучы яки аннан куркучы юк. Мәгәр мөдир генә аңа кызгангансыман карап куйды һәм артык борчылган кыяфәттә, калтыравыклы тавыш белән, янындагы берәүгә:

— Алай ашыгырга ярамый. Әле алдан ниләр буласын белеп булмый...—дигән сүзләрне мыгырдады. Ләкин патшаның тетелгән сурәтенең өстенә карап басып җырланган:

— Ташлыйк, туганнар, иске дөньяны...

Бетсен аяктан аның тузаны...

дигән тавышлар астында, аның бу куркак йөрәгеннән чыккан әкрен тавышы башка бер кемгә дә ишетелми калды.

Зур шатлык бөтен кулларны эштән бушатты, күзләр урамга ташланды. Күңелләрдә бу зур алмашынуның ничек булганын аерып белү арзусы тулды.

Күп тә үтмәде, контора ишегеннән берәү кереп, эшчеләрнең уртасына басып: «Патшаның төшерелүен, министрларның арестовать ителүләрен...» дип ашыгып сөйләгәннән соң, эшчеләрнең хәзер урамга чыгарга, шатлык нәмаешләре ясарга кирәк икәнен әйтте. Аның бу сүзләре тагын шатлык тавышлары белән каршы алынды.

Тагын бераздан соң урамнан:

— Ура, Ура!—тавышлары ишетелде.

Әллә кайда, еракта, ихтилал җырлары җырлаган тавышлары яңгырый башлады. Шуның артыннан ук кызыл флаглар күтәргән эшче төркемнәре үтәргә керештеләр. Шунда ук бу заводның эшчеләре дә урамга чыгып тезелделәр һәм, кайдандыр кызыл флаг алып, алга киттеләр.

Бер сәгать эчендә зур урамнар кызыл байраклар күтәреп алга, зур мәйданга, барган эшчеләр белән тулып китте. Боларның бердәм җырлаган җыр тавышлары, ура кычкырулары һавага күтәрелде. Кайсы йортлардандыр чыгарылып урамга ташланган патша сурәтләре аяк астында калып изелделәр.

Аяклар нык басалар, куллар кызыл байракларны нык тотканнар.

— Алга, алга!—тавышлары тулкынлана...

— Кайдан чыгып өлгергән бу чаклы күп халык?

— Кайдан җыелган шул арада бу чаклы күп кызыл байраклар?—дип гаҗәпкә каласың.

Меңәрләгән халык шатлык нәмаешеннән кайтуга, урамнарда ашыгыч телеграммалар сатыла иде.

Һәр кемнең тизрәк алып, тизрәк укыйсы килә. Бу телеграммаларда: Петроград ихтилалының тәфсилы[1], министрларның, арестовать ителеп, Таврида сараеннан Петропавловский крепостька озатылулары, патшаның ни рәвешле төшерелүе һәм аның Псков шәһәрендә, икенче мартта сагат 5 тә падишалыгыннан ваз кичәргә мәҗбүр булып, елап язган соңгы манифесты вә башкалар басылганнар иде.

Бу телеграммаларны укып эшчеләр шатланалар. Читтән карап торучыларның йөзләре агара, калтыраналар. «Ахры хәерле булсын...» дип, иреннәрен калтыратып, дога кылалар.

Завод мөдире шатлык намаешенә чыкмый калуга уңайсызланды. Ләкин ул эшчеләр белән бер рәттән күп бара алмады, үзендә әйтеп бетергесез уңайсызлык сизеп, сафтан аерылып чыгып, зур өйнең урамга чыккан ишеге төбендә торган юан бер кеше янына барып башын иеп күреште. Алар ашыгыч телеграмманы алып күз йөртеп чыкканнан соң, бер-берсенә карашып нәрсәдер сөйләштеләр дә, ачулы күзләрен урамдагы эшчеләр төркеменә ташладылар.

Чөнки алар бу нәмаештә бөтен теләкләре җимерелүен

---

[1] Тәфсилы — тулы хәбәре.

сизәләр, моннан соң эшчеләрне кол итеп тота алмавларын күрәләр иде.

Бу күрнеш революцияне теләмәгән кешеләр өчен, авырдыр шул!

Ләкин йөз миллионлаган эшче-крестьян өчен бу зур алмашыну әйтеп бетергесез шатлык бирә. Алар зур өмет белән кулларына кысып тоткан кызыл байракларын җилфердәтеп, көчле адымнар белән алга—Октябрь революциясенә таба баралар.

Февраль революциясенең матур таңында Октябрь көтеп, шуңа юл хәзерлиләр һәм—яшәсен революция!—дип кычкыралар иде.

1927

ЙӨЗГӘ-ЙӨЗ КАРШЫ КИЛГӘНДӘ

(Гражданнар сугышы вактындагы күренешләрдән)

I

Сәлимә:

— Әнә, әтиегез кайтты!—дигән сүзне ничек әйткәнен дә сизми калды. Ул үзенең ире Тимербайның кайтканын тәрәзәдән күреп, шул сүзләрне әйтте дә, аңа каршы йөгереп чыкты. Тимербайның анасы—Гөлбанат әби, эрләп утырган орчыгын тәрәшлегә чәнчеп, урыннан торды. Биш яшьлек Шакир, сәкедән тырмашып төшеп, ишеккә таба йөгерде.

Тимербай өйгә кереп, өйдәгеләр белән күрешеп бетүгә, Сәлимә белән Гөлбанат әби икәүсе бердән:

— Бер дә көтмәгәндә кайттың. Без әле, исән генә булса ярар иде (дип тора идек), сугыш бик каты бара, дип сөйлиләр,—дигән сүзләр белән Тимербайга карадылар, һәм:

— Инде бөтенләй кайткансындыр бит?—дигән соальне дә биреп өлгерделәр.

Тимербай, бер дә ашыкмыйча гына киемнәрен салаcала:

— Шулай туры килде. Ләкин бөтенләй түгел, бер генә көнгә... Әле сугыш бетмәгән бит,—диде. Аның бу сүзе Сәлимәне дә, Гөлбанат әбине дә тынычсызландырып җибәрде. Алар тагын да икәүсе бердән:

— Без тагын бөтенләй кайткансындыр, дип шатландык,—диделәр.

— Болай да кайгырырлык эш юк. Мона тиздән бөтенләй дә кайтырбыз,—диде Тимербай.

Аның бу сүзенә каршы Сәлимә бер нәрсә дә әйтә алмады һәм әйтергә ярамас кебектер булды. Тик Гөлбанат әби генә:

— Без сине юксынабыз да торабыз шул. Сине тизрәк кайтарасыбыз килә,—дигән сүзләрне әйтте.

Шакирның боларда эше юк иде. Ул иң элек әтисе салып куйган соргылт бүрекне алып башына киде. Аннан соң, почмакка сөяп куйган винтовканы карый башлады.

Сәлимә, Шакирның винтовка тирәсендә азапланганын күреп:

— Балам, аңа тия күрмә! Әллә кая атылып-нитеп китәр,—дип, тиз генә кулыннан тотып үзе янына алып килде.

Тимербай, салкын кан белән генә:

— Карасын, күреп үссен. Бер вакыт ул үзе дә шуны тотып көрәшкә чыгар,—дип, баласының башыннан сөйде һәм аның күзенә карап:

— Мин красный армеец булам, совет җирен саклыйм, дип әйт әле,—дип, башыннан сыйпады.

— Мин трасный булам, сугышка барам...

— Вот малатчина!.. шулай кирәк. Каян белгән ул аны?—диде Тимербай.

Сәлимә, баласының өстенә карап:

— Күрше малайлары икегә бүленеп, бер ягы аклар, бер ягы кызыллар булып сугышалар бит. Шулардан күрә торгандыр,—(диде).

— Кем малайлары аклар була соң?

—Мона гаҗәп төсле инде ул. Локман бай, Гатият лафкачы малайлары аклар булып чыгалар. Шаһи абзый, йөгерек Сирай малайлары—кызыллар булып алар белән сугышалар.

Тимербай башын селкеде дә, Шакирга карап:

— Минем балам кызыллар ягында булыр,—диде.

— Аның шулай булыры күренеп тора инде,—диде Сәлимә.

— Шулай кирәк!..

II

Чәй кайнап, чәйгә утыргач, сүз авылга, мондагы тормышка күчте.

— Монда эшләр ничек соң? Безнең турыда нәрсәләр сөйлиләр?

—Төрле як төрлечә сөйлиләр инде. Шатлыклы хәбәрләр дә, куркыныч хәбәрләр дә сөйләнеп кенә тора.

— Миңа үзебезнең якта булганнарның сүзләре кирәкми. Алар инде безнең җиңүебезне телиләрдер. Ә соң тегеләр ниләр мыгырдыйлар?

— Аларның сөйләгән сүзләрен тавык та чүпләп бетерә алмас. Кызыллар ягыннан сугышкан кешеләргә тешләрен кысып кына торалар! «Мона тиздән аклар килерләр әле. Шул вакытта сәләмәләрнең кирәкләрен күрсәтерләр. Ашаганнарын ничек косарга белмәсләр. Озакка бармас, безнең очта да туй булыр...» диләр. Ул инде суга барыр хәл юк, хәзер сырып алалар да ярлыларның хатыннарын битәрләргә керешәләр...

Тимербай көлде дә:

— Аларның туйлары булып үткән инде,—диде, һәм, йөзенә ачу чыгарып:—әнә шул елы ояларында торып яткан этләрнең арка таянычлары булган акларны себереп ташламый торып, безгә тыныч көн юк! Аларның көннәре күп калмаган инде,—диде.

Ул бик һәйбәтләп, ни өчен сугышуының сәбәпләрен сөйли башлаганда Гәрәй карт килеп кергәнгә, аның сүзе бүленеп калды:

— Исән кайттыңмы, туган?..

— Бик исән, тимер кебек.

Гәрәй карт көлде:

— Син үзең дә Тимербай бит, шулай тимер кебек булырга кирәк. Я, шул акларны кайчан бетерәсез инде? Безгә шуны әйт әле.

— Бетәрләр, Гәрәй агай, бетәрләр. Алар һәрбер фронтка каршы торып карыйлар да, ләкин күпкә бара алмаслар.

— Бетсеннәр иде инде, каһәр суккыры нәрсәләр! Ату бер дә тынычлап эшкә керешеп булмый. Әле мона бу чигенүләрендә дә безнең ярлы халыкка бик күп җафалары тиде. Сез кызыллар яклы, дип теңкәгә тияләр... Әнә бит Хәйрулланы алып киттеләр. Алар җинеп, тагы килә калсалар, безне терелəй тотып ашарлар. Карт көнем булмаса, бүгеннән кулыма мылтык алып, үзләренә каршы китәр идем,—дип көрсенеп куйды.

Тимербай, тагы да гайрәтләнә төшеп:

—Рәхмәт, агай, дәртеңә! Ләкин син яшьләр барында тыныч бул. Эшче-крестьян гаскәрләренә йөзгә-йөз каршы килгәндә, алар качуларын гына беләләр,—диде.

—Анысы шулай инде, күптән түгел күзебез белән

күрдек. Бүредән өреккән сарык көтүе кебек ашыгып чиктеләр. Әгәр дә озак торсалар бик күбебезнең башыбызга җитәчәкләр иде. Сине күргәч, күңлем тынычланып калды. Ә соң теге, Ленин дигән башлыгыгыз, исән-саудыр бит? Аны бик гайрәтле, акыллы, дөньяны күп күргән үткер, кәттә кеше диләр.

Гәрәй картның бу сүзләре Тимербайга кызык та, матур да тоелды. Ул көләч йөз белән Гәрәй картка карап:

— Бик исән. Әлбәттә, ул син әйткәнчә, һәрбер эшне тикшереп, белеп эшли торган зур акыллы, бик күп белемле кеше. Шуның өчен, аны бөтен дөнья белә.

— Бәй, аңламый ни! Без инде һәр вакыт сөйләп кенә торабыз.

— Гомер булса, тагын күп нәрсәләр аңларбыз әле. Бу сугыш топ-тымалга гына чыккан сугыш түгел бит. Эшчекрестьяннәрне әнә шул үзегез белгән ерткычлар кулыннан мәңгегә азат итү өчен бара.

— Аларын бик аңлыйбыз инде. Син соң әле үзең кайсы яктагы сугышта булдың? Бу сугыш дөньяны кругом әйләнеп алган, диләр.

— Без Урынбур[1] фронтында идек тә, мона хәзер Көнчыгыш фронтына барабыз.

— Әле син шулай тагын китәсеңмени? Үзең дә сугыштан курыкмый торган кеше булып чыктың инде,—диде Гәрәй карт.

— Без монда, иптәшләр белән, бер генә көнгә кердек, иртәгә китәбез. Аннан соң, Гәрәй агай, курку дисең, анда куркып ярамый инде. Алардан куркып торсаң, алар бит безнең өстебезгә атланырга, бугаз каныбызны эчәргә хәзер торалар. Дошманнар безне җиңеп, Октябрь революциясен җимереп, властьне үзләренең кулларына алсалар, эшче-крестьяннәрне мәңге коллыкта тотачаклары билгеле бит. Шуларны күз алдына китергәндә җаны булган кеше чыдап торамы соң?! Фронт ул үзе кешегә көч бирә. Бер өйрәнеп киткәч, анда безнең өчен кызык кына кебек күренә башлый. Мона мондый тын авылда тору әллә нигә күңелсезсымак күренә. Шуның өчен, дошманнарны җиңми торып күңелне тынычлатырга, кулдан коралны ташларга тиеш түгел!—дигән сүзләрне тезеп алып китте. Ул бу сүзләрне үзенең гаиләсе янында түгел, ә бәлки күп кешеләр җыелган зур җыелышта речь сөйләгән рәвештә

[1] Урынбур — Оренбург (хәзерге Чкалов) шәһәре.

күтәренке сөйләде. Ул, үзе дә шуны сизенгән кебек, сүзләрен йомшарта төшеп:

— Кызыл гаскәрләрнең җиңүләрен теләп, өйдә генә торган кешеләргә сугышны күз алдына китерү авыр, куркыныч та булып күренә торгандыр инде, ләкин безгә алай күренми ул. Сугыш җирендә күп йөреп өйрәнгән кешегә, төрле якта атылган снаряд тавышлары—кызларның өмә белән тары төюләре, яисә киндер тукмаулары кебек күңелле булып ишетелә башлый. Анда тик дошманнарыңны җиңеп, тизрәк аларны артка чиктереп, аларның позицияләрен алу ягын карыйсың. Берәр авылны дошман кулыннан алу нинди күңелле була?.. Шәһәрләрне алу шатлыгы бәйрәмгә әйләнә...

Тимербай сүздән туктагач, аның сүзләренә исләре китеп торган Гәрәй карт, Гөлбанат әби, Сәлимә—өчәүсе бердән уянып киткән төсле булдылар.

— Без ни, монда куркып өйрәнеп беткәнбез инде. Җиңелмәсәләр генә ярар иде, дип куркабыз да торабыз,—диделәр.

Гәрәй карт, озын сакалын сыйпап төшергәннән соң:

— Алар җиңә калсалар, безнең кебек халыкка көн булмавы билгеле инде. Әле бит аклар җиңелә торып, алар яклы кешеләр монда нәрсәләр сөйлиләр... Әгәр алар җиңә калсалар, барыр җир, батар күл таба алмабыз,—дип тирә ягына каранды.

Хәзер алар өчәүсе дә, Тимербай шушы сагәт эчендә үк винтовкасын алып сугышка чыгып китсә дә, бер сүз дә әйтмәслек хәлгә килделәр. Һәм Тимербайга шулай сугышка китәргә, кызыл гаскәрләр белән бер сафта торып аклар белән сугышырга тиеш икән, дигән уйга төштеләр. Акларның җиңеләчәкләрен күз алларына китереп, тынычланып калган кебек булдылар.

Иртәнгесен, Тимербайны озатырга әзерләнгәндә, алар шулай тынычлар иде.

Тимербайның иптәшләре килеп, болар белән исәнләшеп китәргә җыенулары, аларның кунакка китәргә әзерләнгән кебек шатланып сөйләшүләре, Тимербайны озату минутлары күңелле бер төскә кереп китте.

— Ну, әйдәгез, иптәшләр... дә үзебезнең полкка барып җитәргә кирәк.

— Гөлбанат әби, исән бул. Мона без акларны җиңеп кайткач, иркенләп сөйләшербез әле.

— Сәлимә, син әллә еларга әйтәсеңме? Балалар кебек булма.

— Юк ла...
Алар берәмләп күрештеләр.
Шул вакытта арага бәләкәй Шакир да килеп кысылды.
— Әни, мин трасный булам...
Аның бу сүзеннән соң, һәммәсе дә көлделәр:
— Кара син аны! Хәзердән үк красный армеец булырга хәзер тора!..
Тимербай аның аркасыннан сөйде:
— Ник булмасын, булыр шул. Хәзер акларны җиңү генә түгел бит. Октябрь революциясен саклап алып барырга алды көндә дә кешеләр кирәк. Аны саклау, Локман бай малайларының кулларына бирелмәс бит!..
— Я, хушыгыз!
— «Октябрь малае», син дә исән бул, зур үс!..

1930

ДЕНЩИК МӘХМҮТ

(Коллык заманыннан бер күренеш)

Мин яңа бүлмәмә беренче килгәндә миңа ишек ачкан һәм кухнядә балык әрчеп утырган солдат—Мәхмүт исемендә башкырт егете булып чыкты. Бу егет, үзенең әйтүенә караганда, бер байга ялчы булып йөргәндә үткән ел патша хезмәтенә алынган да, алты айлар чамасы казармада торганнан соң, шушы офицерга денщик итеп бирелгән булган икән...
Хәзер аның үзен Миша, Мишка дип йөртәләр. Ул бу «яңа исем»не үзләштереп бетергән.
Офицер яки аның хатыны бариналың «Миша!» дип кычкыруларын ишетү белән:
— Так точно, ваше благородие,—дип кулына тоткан әйберсен ташлап йөгерә торган җанлы машина кебек бер нәрсәгә әйләнгән.
Шулай, бу өйдә торучылар төрле катлам, төрле сыйныф кешеләре булып чыктылар. Болар арасында хезмәт иттеручелек белән хезмәт итүчелектән башка һичбер мөнасәбәт юк иде.
Денщик Мәхмүт миңа бик тиз үзләшеп китте. Аның минем белән болай үзләшеп китүе, үзенең көнлендәге моңнарын миннән башка уртаклашучы булмаганлыктан икәнлеге миңа маглүм иде.
Мәхмүтнең тормышы һәм положениесе байтак яктан

аш пешерүче хатын белән бер төслерәк булса да, ирекле булу һәм ул файдалана торган хокуклардан файдалану ягыннан бик күп аерыла иде.

Мәсәлән, ашчы хатын базарга чыкканда, башка җирләргә барганда тротуардан йөрергә, теләгән җиренә керергә, өйдә торганда, үзенчәрәк торып, хуҗа хатыны һәм офицер белән утырган көенчә сөйләшергә, бәйрәм көннәрендә аларның рөхсәтләре белән таныш-белешләренә барырга, төннең маглүм бер сәгатендә ятып йокларга хаклы иде.

Мәхмүткә килсәк, ул тротуардан йөрергә, теләгән җиренә керергә, утырып сөйләшергә, офицер үзенең хатыны белән вечерларга, балларга, театрларга барган көннәрдә алар кайтканчы чишенеп йокларга хаксыз иде.

Ул, кухнядәге бөтен пычрак эшләрне эшләргә мәҗбүр булу өстенә, офицер һәм аның хатынының өс-баш һәм аяк киемнәрен чишәргә тиеш булып, шулар өстендә сәгатьләрчә утыра, магазиннан яңа гына алып кайткан кебек ясап куя, шулай да һаман шелтә күрә, ямьсез сүзләр ишетә торган иде.

Офицерның хатыны кухняга бик сирәк, тик Мәхмүтне берәр эш өчен тиргәргә генә чыга, түфли, галош кебек берәр нәрсәне Мәхмүтнең алдына алып бәрә дә:

— Ишәк, мужик, пычрак, хайван!—дигән сүзләр белән тиргәп беткәннән соң, «лачт» иттереп йөзенә төкереп китә иде.

Мәхмүт, тиргәлеп беткәнче аяк өсте басып, офицер хатынына честь биреп тора, аңа каршы бер генә сүз дә әйтә алмый, тик ул чыгып киткәч кенә, битендәге төкрекләрне сөртеп, бик авыр бер хәлдә уйланып торганнан соң, тагын эшкә керешә иде.

Кайчагында Мәхмүт аларга уенчык урнына, аларның күңелләрен ача торган бер нәрсәгә әйләндерелгәнлеген бик еш очрата идем.

Офицер кызмача булып алгач, үзенең кадерле этен алып чыга, аны өсләтеп Мәхмүтне талата, аның өстенә сикертә, ә үзләре бу эштән тәм табып, көлеп рәхәтләнәләр иде.

Мәхмүт, офицерлар өйдә юк чакта минем янга кереп утырып, без икәү аның авыр положениесе, күргән хурлыклары, көннән-көн изелеп артка китүе турында сөйләшсәк тә, аны бу тормыштан йолкып алырга һичбер юл таба алмый аптырашта кала идек... Чөнки аның һичбер җиргә

шикаят[1] итәргә хакы юк иде. Шикаят итсә яки аларга каршы берәр сүз әйтсә, тагын да үзе гаепләнәчәк булганга, ул шул ямьсез тормышка түзәргә, «сабыр итәргә» тиешле иде...

Бер төнне мин куркынычлы тавышка уянып киттем. Кухня ягында:

— Мин сине хәзер атам да үтерәм!—дигән ирләр тавышы белән бергә:

— Куй инде, гафу ит,—дигән хатыннар тавышы белән, икенче бер хатынның:

— Боже мой, һәләк итә бит,—дип еламсыравы ишетелә иде.

Мин чыдап тора алмадым, тиз генә өстемә киенеп, кухняга чыктым. Мин чыкканда офицер Мәхмүткә карап наганын төзәп тора, Мәхмүт, честь биргән көе, куркынычлы бер тавыш белән:

— Так точно, прости, пожалуйста!—дигән сүзләрне тәкрарлый, офицерның хатыны иренең кулын тотып:

— Бер юлга гафу ит инде,—дип ялына һәм хуҗа хатыны нишләргә белми кулларын уып: «Боже мой...» дигән сүзен кабатлый иде.

Офицер наганын төзегән көенчә:

— Мин сине эт урнына атып үтерермен, ник син «Марс»ны күзәтеп торып, өйгә алып кермәдең!—дигән сүзне тагын кабатлады. Хатыны ялынып:

— Шундый түбән бер кеше белән кулыңны пычрату ярамый бит!—диде.

Хуҗа хатынының:

— Господин офицер, ул бит адәм баласы, әзрәк кызганырга кирәк,—дигән сүзенә каршы, офицер:

— Нинди кеше булсын ди ул? Минем этем аңа карагында мең мәртәбә артык!—дигән җавапны бирде.

Мин, нишләргә белми аптыраштa калдым. Хатынына карап:

— Нишләгән соң сезнең ул этегез?—дип соравыма каршы, ул:

— Кунакка барган идек, «Марс» алдан кайтып киткән. Менә бу нәрсә аны ачып кертмәгән. Хәзер «Марс» әллә кайда,—дигән җавапны бирде. Мин чыдый алмадым.

— Бер эт өчен шулай кызу кирәкмәс иде, этегез икенче бер этләргә ияреп йөри торгандыр, менә кайтып килер әле,—дидем.

---

[1] Шикаят — жалоба.

Офицер миңа ачуланып карады.

— Сезнең бу эшкә катнашырга хакыгыз юк. Нәрсәгә син бер ишәкне яклыйсың!—диде.

Эш шул җиргә җиткәндә, кухня ишеге төбендә нәрсәнеңдер тырнанганы һәм бер этнең шыңшу тавышы ишетелде.

Бу аларның «Марс» лары иде. Ишектән кергәч тә, алар этләрен кочаклап алдылар. Офицерның ачуы басылды. Шау-шу тынды. Шулай да офицер, үзенең ачуын басар өчен, наганының сабы белән Мәхмүтнең иягенә бик нык итеп кагып куйды да:

— Эт кайтмаса, мин сиңа күрсәтер идем!—дип, этен ияртеп, үзләренең ягына кереп китте.

Мин урынымнан кузгалмый, шак катып, хайран калып Мәхмүткә карап тора идем.

Мәхмүт, офицер кереп киткәч тә, берәр минут чамасы честь биргән көе торды да, тирә-ягына каранып алганнан соң үзенең учына төкерде. Ләкин ул төкрек түгел, кан иде. Мин Мәхмүтне соң дәрәҗәдә кызганып, авызын чайкатырга ярдәм иттем. Авызыннан кан килү басыла төшкәч, үземнең бүлмәгә алып кердем. Без, бер-беребезгә бер сүз дә әйтми бик озак карашып торганнан (соң):

— Кайгырма, туган, бу эшләргә бер вакыт чик куелыр. Аларның үзләренең авызларыннан кан костырырлар!—дидем.

Мәхмүт миңа яшьле күзләрен терәде дә:

— Ул көннәр булыр микән, агай?—диде.

— Булыр, тормыш болай барырга тиеш түгел!—дидем.

Шулай торганда «Миша!»... дигән тавыш ишетелде. Мәхмүт агарынып калтыранган көе, минем бүлмәдән чыгып китте. Мин аның яшьле күзләре белән:

— Ул көннәр булыр микән, агай...—дигән сүзләрен уйлап уйга калдым. Һәм үз-үземнән:

— Булыр, аларның авызларыннан кан костырырга вакыт җитәргә кирәк!—дигән сүзләрне әйттем.

Мин бу бүлмәгә кереп өч ай торганнан соң, бөтен дөнья сугышы башланды.

Мәхмүтләрнең полклары беренче чиратта фронтка озатылдылар. Шулар белән Мәхмүт тә китте. Ул киткән вактында шат иде. Миңа, күрешкән вактында:

— Сугыш куркыныч булса да, бу тормыштан да авыр булмас. Шуның өчен мин шатланып китәм. Агай, сиңа рәхмәт,—диде.

Мин аның кулын кысып:

— Хәзер винтовкалар үз кулыгызда. Сез аларны алга төзәгән кебек, артка төзәргә дә ихтиярлысыз!—дип, озатып калдым.

Ул шулай бөтен дөнья сугышына китте. Хәзер, Кызыл Армиянең 13 еллыгында, мин шул «коллык замана» сын нәфрәт белән күңлемнән үткәрәм. Хәзерге тулы хокуклы, үзләренең ирекләрен саклар өчен хәзерлек күргән кызыл армеецларне күреп шатланам, аларны котлыйм.

1931

БЕЗ АЛАРНЫҢ ЙӨЗЛӘРЕННӘН БЕЛӘБЕЗ[1]

(Ярым җидди)

Бер кешенең йөзеннән һәм аның хәрәкәтеннән фикрен белү, аның эчендә кайнашкан уйларын аңлау дигән нәрсә була.

Кеше дигән нәрсә, үзенең фикрен һәм уен, мөгамәләсендә булган чынлык һәм риасын, ничаклы гына яшерергә теләсә дә, йөзе, күзе, авызы—кыскасы бөтен кыланышы, аның эчендә яшеренгән, пәрдә астында торган чын төсен күрсәтеп тора.

Төрле эшләр хакындагы яшрен уйларны тышка чыгармый саклый ала торган кеше, белмим, булыр микән?

Бу эшнең вак-төякләрен бер якта калдырып, шушы соңгы елларда булган сәяси эшләрдәге аерымлык хакында берничә сүз язып үтәргә кирәк була.

Биш ел үзе артык озын гомер түгел. Ләкин шушы биш ел эчендә үткәрелгән зур вакыйгаләр, искиткеч алмашынулар, борынгы «кибар»[2] бай да, «мирза», «түрә» ләрнең башлары белән әйләнеп төшүләре, руханиларның дәрәҗәләрен югалтып, иң кадерсез бер бәндә булып калулары җәһәтеннән караганда бик озын гомер кебек санала.

Шушы биш (ел) эчендә нинди генә төскә кергән кешеләр булмады да, нинди генә эшләр эшләнмәде?..

Бу биш ел, асылда, акның-ак, кызылның—кызыл, эшченең эшче һәм аның дошманнарының эчләре янып йөргәнен күрсәтә торган тәҗрибә дәвере булды.

Боларның арасыннан берәүне мисал итеп алыйк:

Миңа бик күптән таныш булган бер кеше бар. Бу кеше элек зиалый һәм шәп тормышлы кешеләр җөмләсен-

[1] Язылып бетмәгән.
[2] Кибар—югары катлау кешесе.

нән булып, борыңгы «рәхәт» вакытларда байлар тирәсендә йөри торган иде. Мөселман дөньясы өстенә төшкән «мөһим» мәсьәләләрне хәл кылу, мөселман галәмен сәгадәткә[1] ирештерү хакындагы эшләрнең һәр берсенә катнашып, шул груһ халыкның уртасында була торган иде.

Аларның изге вакытлары, «гасыр сәгадәтләре» үтеп, эшче-крестьян халкы арасында бер тиенлек тә кадерләре калмагач, бу кеше үзенең юлын үзгәртә төште. Мәсьүлиятле[2] булган урыннарга кергәндә яки очраганда бик ачык йөзле булган булып, гүя, үзе дә шушы алмашуны теләгән кешеләр җөмләсеннән булырга тырышты.

Мин моны һәр вакыт диккат итеп, аның кыланышларын тикшереп йөрүдән кызык таба башладым. Ләкин аның эчендә бөтенләй икенче фикер булганын, «зарурат»[3] буенча шулай риаланырга мәҗбүр икәнен бик ачык белә идем.

Шулай итеп мин аны биш ел буенча тикшереп килдем.

Ул да, мин дә һаман да бер шәһәрдә торып, һәр вакытта очрашырга туры килгәнгә күрә, аны тикшерү бик уңай иде.

Мәсәлән, ул миңа бер очрауда бик ачык булып, э икенче очраганда аның йөзендә үч алу чаткылары күренеп, күзендә ачу галәмәтләре балкып тора торган иде.

Бер ук кешенең, шул ук бер танышына шулай каравының магнәсенә бара торгач төшендем. Аның йөзендәге бу алмашынулар гражданнар сугышы вактында бигрәк ачык күренә торган иде.

Февраль революциясеннән соң, аның йөзендә ачу галәмәтенә караганда, шатлык күбрәк була торган иде. Ул әле, ул дәвердә, мөселман эшләренә якыннан катнашып йөрде.

Октябрь революциясеннән соң, аның йөзе күбрәк вакытта караңгы һәм ачулыга әйләнде.

Минем, аңа диккат итеп, тикшерә башлавым да шул вакыттан булды.

Кичә ул миңа очраганда бик ачык йөз белән сәлам биреп, баш иеп киткән иде.

Ә бүген очрадым, бөтенләй башка төс алган. Сәлам бирү түгел, баш та ими, ачулы рәвештә кырып карап китте.

---

[1] Сәгадәт—бәхет.
[2] Мәсьүлиятле—җаваплы.
[3] Зарурат—кирәклек.

Аннан аерылгач та, чехларның Самарны алып бире чыкканлыкларын ишеттем.

Теге «йөз»нең ни өчен үзгәргәнен шунда ук сиздем.

Уфа кызыллар кулыннан алыныр вакытта, ул миңа бөтенләй эндәшми башлады.

Уфа аклар кулына кергәч, ул миңа очраганда агулы көлү белән көлеп, мыскыл иткәнсымак, башын күтәреп үтте.

Хәтта мин аның, икенче берәүгә:

— Көннәре бетте, аларның урны әнә тегендә!—дип, төрмә ягын күрсәтеп торганын ишеттем.

Ул үзе дә, иптәше дә, ачулы күзләре белән, минем арттан карап калдылар. «Тегеләр кулына тоттырып бирергә кирәк», дип уйлаганнардыр инде.

Малай бүген йомшаган!.. Әллә кайдан көлеп, миннән элек үзе кул сузып күреште.

— Бу нәрсәләр безнең өчен зарар гына,—дип сәяси сүз башлап китте. Мин гаҗәпсендем. Вактым аз булганга күрә, яныннан киттем.

Ул артына әйләнеп:

— Шулай инде, кунак булып барып утыр, сезнең белән бер утырасы килә иде,—дип, сөйләнеп калды.

— Бу ник болай йомшап киткән, тагын нәрсә бар?—дигән уй белән үтеп киттем дә, «Яңа хәят» газетасын алдым. Мин ул вакытта урамга сирәк чыгып, эшләремне бетерү белән кире кайта идем.

Ул менә нәрсәгә йомшаган икән!..

Эшче-крестьян кызыл яулары Волганы үтеп, Самарны алганнар, һәр җирдә дә алга киләләр.

Томанлырак рәвештә язылган бу хәбәрләрнең астында аклар өчен зур куркыныч барлыгы, кызыл яуларның арслан кебек алга килүләре күренеп тора иде.

Теге «кеше» шушы хәбәрләрне уку белән юлын һәм төсен үзгәртеп өлгергән икән...

Мәсьәлә ачылды.

Аларның бүгенге газеталарында эре хәреф белән (басылган) «Кызыл яуларны туктатып, үзебез һөҗүм башладык, алар чигенәләр,» дигән хәбәр бар иде.

Минем йөрәк «жу» итеп китте. Ләкин бу хәбәрнең иртәгә булмаса, берсе көн безнең файдага әйләнәчәген уйлап, үземне юаттым.

Теге «кеше» тагын очрады. Ләкин кунакка чакыру түгел, рәтләп сәлам дә бирми үтеп китте.

Бер яктан Богрыслан, Абдуллин, Бәләбәйләр кызыл яулар кулына керсә, икенче яктан Сарапул, Минзәлә, Оса һәм башкалар берәм-берәм алар кулына керә.

Фронт безнең бу тирәгә якынлашкан саен, шәһәрдә төрле хәбәрләр, Себергә китүләр күбәйде, хәрәкәт артты.

Миңа бүген:

— Хөрмәтле... иптәш, бүген кич сәгәт 5 тә кунак булып килүегезне үтенәбез. Зинһар калмасагыз иде, бик көтәмен.

Хөрмәт белән...»

дигән язу килде. Шуңа карап кызыл яуларның бик шәп алга килгәнен белдем.

Үзенә, әлбәттә, бармадым. Ике көннән соң халык арасында Дәүләкән, Чишмә сүзләре сөйләнә башлаган иде.

Бу «кеше» фронт хәлләрен ничек болай алдан белеп тора икән, ул миңа моннан өч-дүрт көн элек чакыру кагәзе җибәргән иде, дип хәйран калдым.

Бик ерактан пух, пух, пух... дигән туп тавышлары ишетелә башлады.

Шәһәрдә кызу хәрәкәт башланды... Качалар...

Буран, салкын булуга карамастан, чаналарга төяләп, Себергә таба китәләр...

Чигенгән аклар белән урам тулды. Шәһәрнең төрле җирләренә туплар куйдылар.

Ләкин сугыш булмады.

Кояш баеп караңгы төшү белән, аклар, тавыш-тынсыз гына, шәһәрдән чыга башладылар.

Тик төнлә белән боларның чабып, йорт саен кереп, ат эзләп йөрүләре генә күренә иде.

Иртән торуга, шәһәрнең кояш баешы ягыннан, урамнардан кызыл гаскәрләр керәләр иде инде.

Мин, төн буе йокламый үткәрүгә карамастан, чәй эчү белән шәһәр уртасына киттем.

Анда, урам тулы халык уртасында, зур митинг ясалып ята иде.

Шунда ук теге кеше, минем янга килеп, үзенең шатлыгын белдерде. Ләкин аның йөзендә, иреннәрендә зәһәрле ачу сизелеп тора иде.

Мин аңа артык илтифат күрсәтми үз юлыма киттем.

Шуннан соң берничә көннәргәчә ул миңа, очраган саен баш иеп, сәлам биреп үтә торган булды.

Уфадан илле-алтмыш чакрым чамасында шәрык тарафына киткәч тә бик ерактан күккә күтәрелеп, бик биек койма кебек күгәреп рәттән тезелгән, кайсы бер урыннары кибән кебек югары чыгып торган таулар күренә. Менә болар Урал тауларының тармаклары, яңа Урал тауларыннан аерылып чыккан ботаклардыр. Менә шул тауларга карап бара торгач, алар якынлашкан саен, аларның түбәләре һаман югары күтәрелә барган кебек була. Озын, биек таулар артында калган кебек була башлыйсың. Бер вакыт, биек тауларның янына ук барып җитеп, инде боларның арасына каян керергә дип уйлыйсың. Чөнки алдыңда яшәреп яткан теп-текә таулар нак биек койма кебек ярылып, бөтен тирә якны әйләндереп алган төсле, һәммәсе бер-берсенә тоташып күренәләр Шулай бара торгач, арба юлы куе урман арасында биек таулар арасына кереп китә, ә син шул урман арасына кереп югалдың.

Менә хәзер без күккә күтәрелеп, яшәреп балкып торган бик биек ике тау уртасыннан ташлар өстеннән шаулап, ак күбекләр чәчеп ага торган бик матур елганың буеннан акрын гына китеп барабыз. Юлның ике ягы эре-эре агачлар белән чолганган. Аларның яшел яфракларга төрелгән озын ботаклары юлны аркылы үтеп, юлының ике ягында үскән агачларның яфраклары бер-берсенә кушылып, юлның өстен каплап, күләгәләп торалар. Яр башыннан тәгәрәп төшкән бик зур ташлар юлның ике ягында төзелешеп яталар. Шул ташлар юлда уңайсызлап, шәп барырга ирек бирмиләр. Тау арасыннан барганда кояш рәтле күренми, я аны ире агачлар каплый, я инде биек таулар кояшны бу җирдән яшереп торалар.

Шундый шалтырап аккан ташлы елга буеннан берничә чакырымнар баргач, безнең бара торган юлыбыз югары күтәрелә башлый. Тау гаят текә булганга күрә, әлбәттә, арба өстендә утырып барып булмый. Атларны үз ихтиярларына куеп, арба артыннан җәяүләп барырга туры килә. Бер җир буе баргач, арба тәгәрмәчләре астына таш кыстырып, атларны туктатып хәл җыйдырырга һәм үзең дә хәл җыярга кирәк була. Чөнки гау бик биек булганга күрә хәл җыймый гына менеп җитәргә мөмкин түгел.

Бик озак вакытлар баргач, түбән таба карасаң, баягы

---

[1] Офык даирәсе—күз күреме.

үзең килгән елга буйлары әллә кайда тирән һәм куркыныч булып күренә. Барган саен офык даирәсе[1] зурая. Тирә-яктагы башка тауларының башлары күренә башлый. Түбәндә чакта тып-тын булса да, тауның башына менгәч, җил белән агачлар бик мөһабәт рәвештә шаулап утыралар. Боларның шаулашкан тавышлары колакка бик матур булып ишетелә. Шулай акрынлап, хәл җыя-җыя бара торгач, тауның иң югары урнына барып җитәсең. Тауның иң югары урны галибән[1] ялангач, ягни агачсыз булып яшел үлән белән генә капланган була. Менә шушы урыннан торып, атларны туктатып, тирә якка карасаң, бик ерак җирләрдәге биек тауларның башлары сине чакырып торган кебек, мөһабәт рәвештә, яшелле-зәңгәрле булып балкып яталар. Үзеңне, күккә якын җирдә торган кебек, аерым бер киңлектә, рәхәтлектә сизәсең, таудан төшәсе килми. Һаман тирә-якка карап, шул матурлыкны сәер итеп торасы килә. Яңгырлы көннәр булса, болытлар, таудан түбәнрәк булып, агач башларыннан агалар, үзең бөтенләй томан арасында торып каласың. Бу инде уйсу,—түбән җирдә торган вакытта бөдрә болыт булып күренгән нәрсә. Тау бик биек булганга күрә, болытлар тау белән бер тигез булалар. Икенче төрле әйткәндә, тауларның башы болытларга җитеп торган була.

Юлыбыз һаман дәвам итә. Арба тәгәрмәчләрен үрәчәгә бәйләп куясың да, акрынлап таудан төшә башлыйсың. Шулай бәйләп куймаган вакытта, атлар арбаны туктата алмыйлар. Тагы да ике тау арасына барып төшәсең. Шаулап ага торган елга сине каршы ала. Шулай итеп, балта күрмәгән урманнар арасыннан барган тар гына юл белән китүеңне дәвам итәсең.

[1] Галибән — күбесенчә.

ИСТӘЛЕКЛӘР

ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕМ

Изге күңлем кагбәсеннән көн дә бер таш җимреләә,
Ахры бик күп калмагандыр инде актык гомремә,
Яндырып күңлем шәмен эзләп маташтым изге юл,
Карышыдан искән каты җилдән вакытсыз сүнде ул.

Гомремнең кырык ике басмасын үтеп, кырык өченче басмасына күтәрелгән вактымда, хәятның артта калдырып киткән эзләрен әрчеп, анда утыртылып киткән маякларны яңартып, хәтер дәфтәрендә сызылып килгән тәэссоратларны бер урынга теркәп, пракәндә[1] яткан кагәзләрне бер җиргә җыйнап куярга уйладым. Монда язылган нәрсәләр хыял һәм фаразлардан ерак булып, баштан үткән вакыйгаләрнең, күңел көзгесендә калган сурәтләрнең нак үзләреннән гыйбарәт икәнен әйтеп китүне артык булмас дип уйлыйм.

Әйтергә яраса, бу сәхифәләр минем тәрҗемәи халемнән гыйбарәт булып, мин монда баштан үткән эшләрнең җанга тәэсир иткәннәрен, вакыйгаләрнең мөһим булганнарын яздым. Боларны тәрсим[2] иткән вакытта ифрат һәм тәфриттан[3] бик вә бик нык сакландым. Мохитның тәэсире белән күңлемә нәрсә сызылып калган булса, шуны шул көенчә тасвир итүне беренче максат итеп тоттым. Төрле вакытта язылып ташланган хатирәләрне теркәгән вакытта аларны сайлау, мөһим булганнарын алу юлында да шул әйткән туры юлдан аерылмаска тырыштым. Кыскасы: мин монда язган нәрсәләремнең, үземнең үткән гомремнең көзгесе булуына, ул көзгедә ярты гасырга якын хәятымның тулы һәм ничек үткән булса, шул көенчә күренүенә бик нык диккат иттем. Бергә теркәлгән хатирә дәфтәрләреннән гыйбарәт булган, шул рәвешле бер тәрҗемәи хәл сыйфатына кергән бу әсәрнең кайбер танышларым белән

---

[1] Пракәндә—чәчелеп.
[2] Тәрсим итү—сурәтләп бирү.
[3] Ифрат вәтәфрит—арттырып җибәрү һәм чиктән тыш киметү.

кайбер дус-ишләремнән башкалар өчен, ихтимал, әһәмияте булмас. Шуны уйлап, мин бу әсәрне югарыда әйткән кешеләргә һәм эшче-крестьяннәргә бүләк, бер истәлек итеп язам. Саф күңелле, риасыз дуслар, күз яшьләрен күргәндә хәсрәтләнеп, шатлыкларын күргәндә күңелләнеп үстергән балалар һәм минем әсәрләремне укып әз генә булса да тәсәллә[1] тапкан эшче-крестьян—бу бүләкне кабул итәрләр, дип уйлыйм.

ТУГАН ИЛ

Уфадан Агыйдел буйлап, шәрык җәнүбигә[2] таба 70—80 чакрымнар барсаң, сул ягында бик биек таулар күгәреп күренә башлыйлар. Бу таулар Урал тавының тармаклары булып, берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе биек булып күренәләр. Шул тирәгә җиткәч, Агыйдел, үзенең агышын борып, бераз кояш батышына табарак борылып китә. Уфадан югары карап пароход белән барганда уң ягында бик озын сыртлар, төрле яшелләкләр белән капланган аркалар күренә. Шушы таулар белән аркаларның уртасында, киңлеге берничә чакрымнарга сузылган матур болыннар, төрле агачлар арасыннан Агыйдел тын һәм мәһабәт булып агуында дәвам итә. Бу тирә сандугачларның оясы инде. Монда, җәй көне булса, идел буенда үскән назлы агачларның ботакларында айлы кичләрдә сайраган сандугачларның тавышы белән бөтен тугай яңгырап тора.

Агыйделнең шәрык ягындагы таулар арасыннан Җилем исемендәге зур гына су килеп чыгып, шул матур тугайларның иң матур һәм урта бер җирендә Агыйдел белән кочаклаша. Җилем суы үзенең сафлыгы, ташлар арасыннан агуы белән күргән бер кешене хәйран итәрлек рәвештә матур. Ул үзе шәп ага, ләкин болганмый. Язгы ташкын вактында Җилем суы белән бик күп сал агызып төшәләр. Ләкин ул саллар ике буй бүрәнә чамасыннан озын булмыйлар. Шундый шәп һәм таулар арасыннан әрле-бирле бормаланып, ташларга бәрелеп ага торган судан салларны ярга бәрдерми һәм таратмый агызып төшәр өчен ни чаклы осталык белән җитезлек кирәк икәненә аптырап каласың. Бу эшне тик тау арасында, Җилем суы буенда, үскән башкыртлар гына булдыра ала.

---

[1] Тәсәллә—юаныч.
[2] Шәрык җәнүби—Көнчыгыш-көньяк.

Җилем суы безнең авылдан ике чакрым ярым чамасында. Бу су буе минем бала вактымның җәй көннәрендәге уйнап, кармак салып үткәргән урнымның берсе. Әллә кайдан күренеп торган «Кызыл яр» астында һәм «Иштуган тамагы» дигән җирләрдә, без, балалар, көннең үткәнен белми йөри идек. Язгы сабан белән печән вакыты арасы (июль числосы) күбрәк шунда үтә иде.

Анда күп йөрүебез өчен кай вакытта әтиләр тарафыннан чигәләребезгә алган вакытларыбыз күп булса да, Җилем суы буеның матурлыгы, үтә күренеп торган суда көмеш кебек балыкларның йөзүләре, безнең шул балыкларны тоту теләге белән күзләребезне суга терәп утыруның кызыклыгы—чигәләребездән ут чыгарганчы чабылуларны шунда ук оныттыра иде. Ул төрле якка борылып-борылып йөри, шулай итеп, шул матур җирләрне күбрәк күргә, шуннан чыгып китмәскә тырышкан кебек ага. Агыйдел белән шушы Җилем суының уртасындагы берничә чакрымнарга сузылган болынлыкларны җәй көннәрендә төрле чәчкәләр каплаган була. Шул матур җирләрдә ямьле җәйләрне сайрап үткәрер өчен, җәнүпнең төрле кошлары килеп тулалар. Аларның моңлы тавышы белән бөтен тирә-як яңгырап тора.

Шушы ике суның кочагындагы киң болынлыкның нак уртасына безнең Җилем-Каран авлы ташланган. Табигатьнең иң матур бер урнына ташланган шушы Җилем-Каран авлы минем туган бишегем була инде. Бу авылның эчә торган суы—авылның янында гына бөркелеп, ургылып чыккан зур чишмәдән гыйбарәт. Бу чишмә яр астындагы кисмәк янындагы тишектән көмеш кебек саф һәм мул булып чыга, авылның түбән очына барып, сазлык уртасындагы күлләргә барып югала. Авылдан чирек чакрым ераклыкта Үрге чишмә исемендә икенче бер чишмә бар. Бусы кечкенә булу белән бергә, тагын да матуррак. Көнчыгыш ягы вак әрәмәлек булып, көнбатыш ягы чәчкәләр атып торган яшел чирәмлек булып, безнең авыл кызлары белән егетләренең уенга чыгып, уен-көлке кора торган урыннан гыйбарәт иде. Ләкин заманнар үтү белән ул тирәдәге агачлар кыркылып беткәнгә күрә, хәзерге көндә ул җир борынгы матурлыгын югалта төшкән. (Соңгы елларда бу чишмәнең тирә-ягы сөрелеп басуга әйләнгән инде.)

Җилем-Каран авылыннан өч чакрым китү белән Урал тавының тармакларыннан булган зур таулар башлана.

Өйдән чыгу белән күз алдына шул таулар килеп басып, күңелгә әллә нинди матурлык биреп җибәрәләр. Авылдан чыгып берәр чакрым барсаң, төрле агачлардан гыйбарәт матур урманнарга, әрәмәлекләргә барып керәсең. Шәрык ягындагы кырга чыксаң, биек таулардан булган «Уклы-Кая» дигән тау күренеп ята. Бу тау тирәсендә борынгы вакытларда бик зур ике яу кара каршы килеп, бер як шул тауның тишекләренә ышыкланып, шуның химаясендә[1] сугышканнар. Әле дә булса бу тауның тирәсендә тимер ук башаклары табыла. Шуңа күрә, бу тауга «Уклы-Кая» дип исем биргәннәр. Бу тау бик биек булу белән бергә, кыйбыла ягы ниһаятсез[2] текә, ул яктан менеп-төшеп йөрү мөмкин түгел. Башына менеп, түбән карарга да куркасың. Егылып китсәң эш харап!.. Борынгы вакытта бер башкырт кызы үзенең кияүен шуның башына алып менгән дә, тауның иң текә урыннан төртеп җибәреп, һәлак иткән. Яратмаган кияүеннән шул тау аркасында котылган дип сөйлиләр.

Җилем-Каран авылыннан ерак түгел, «Халаек борны» дигән бер урын бар. Монда да борынгы вакыттагы яулар сугышып, кайсы яктыр, бик күп кырылган. Монда шул вакыттан калган каберләр әле дә булса күңелгә дәһшәт биреп торалар. Үткән яуларны искә төшерәләр.

Бу җирләр миңа бала вактымда ук бик нык тәэсир биргәнгә, әле дә булса шул тәэсирләр күңлемдә сакланып килгәнгә күрә, боларны язам.

* * *

Мин шушы Җилем-Каран авылында, 1880 нче елда туганмын. Әти Нургани исемендә, әни Марзия исемендә булып, мин 10 яшьләргәчә шуларның елы кочакларында тәрбияләндем. Үземне-үзем белә башлаган вакытта әни дә, әти дә исән булу өстенә, Нурислам, Мәһди исемендә ике абзам, Әхсән исемендә бер энем, Фатыйма һәм Сафия исемендә ике апам бар иде.

Әни бик йомшак күңелле булгандыр, күрәсең, мин үзем белгән көннән башлап һәр вакытта аның күзләрен яшьле һәм никтер боек күрә идем. Ул, абзам берәр китапны укыганда да, берәр фаҗигале хәбәр ишеткәндә дә, җыламый калмый иде. Бигрәк тә охрави[3] китаплар укыл-

[1] Химаясендә—ышыгында.
[2] Ниһаятсез—чиксез.
[3] Охрави—ахирәткә бәйләнешле, «теге дөнья» турындагы.

ганда бик нык тәэсирләнеп, йөзендә курку белән өмет катыш галәмәтләр чыга торган иде.

Бу вакытта безнең өйдә иң күп укылган китапларның берсе «Ахры заман» булып, ул атнасына берәр мәртәбә дә укылмый калмагандыр. Ул китапны укый башлау белән безнең йөрәкләрдә ниндидер бер курку башлана, бу курку барган саен арта, ниһаять, кыямәт, ягни заманның ахры алдында була торган җирләрен тыңлаганда калтырана башлый идек. Шуннан соң:

Дәҗҗал мәлгүн чыгу бән Румга[1] баргай,
Биксән мең җәһүт, пәри җәмгы[2] булгай.
Мәһди чыкты дәю аңа хәбәр булгай,
Аннан артык тәкый гаҗәп тыңлары вар...

дигән сүзләр укылганда, китапны укучы агам укуыннан туктала, тыңлаучылар бер-берсенә карап, бу куркыныч көннәрдәге хәлләр турында сөйләргә керешәләр. Әни, абзый һәм күршедән кергән берничә кеше сөйләшкәнне без, балалар, чиксез бер зур дәрт һәм курку белән тыңлыйбыз.

«Дәҗҗалның бер ягында оҗмах, бер ягында тамуг имеш. Үзенә ияргән чиксез күп бозыклар (кафирләр) белән полный музыка уйнап килә имеш. Аның шул уен тавышын ишеткән бер кеше йөгереп каршы чыга, әгәр дә Дәҗҗалга иярсә, ул кешене Дәҗҗал оҗмахына кертә, каршы торса—тамугына сала имеш. Ләкин аның оҗмах дигәне тамуг, тамуг дигәне оҗмах булып чыга икән. Шуның өчен мөселман бәндәләр Дәҗҗалга карышалар, тамугысына керергә тырышалар имеш...

Иң яхшысы, аның килгән тавышын ишетмәү икән. Моның өчен я мәчеткә яки тегермәнгә керергә кирәк була...»

Тыңлаучылар арасында бу турыда озын мәхакәмә китә. Биш-ун юллы сүздән берничә табак нәрсә язарлык сүзләр сөйлиләр. Дәҗҗал фитнәсеннән котылып калу юлларын эзлиләр.

Мин бу вакытта куркуга төшәм. Ләкин безгә урам аша гына гөрләтеп тарткан тегермән мине шатландыра. «Дәҗҗал килә!..» дигән хәбәрне ишетү белән, шул тегермәнгә йөгереп кереп, аның ягына чыгудан котылып калуны уйлыйм. Бу уй башкаларның башына да килә. Алар да: «Ходайга шөкер, әле безгә тегермән якын, шунда керербез,»—диләр.

[1] Рум—Рим.
[2] Җәмгы булгай—җыелырлар, җыелачаклар.

Минемчә, Дәтҗал безнең урамнан түгел, теге зур урамнан—Баһау старшиналар урамыннан үтәр кебек була. Шуны уйлап, мин ул урамдагы кешеләрне һәм малайларны бәхетсезгә исәплим.

Шулай бераз сөйләшкәннән соң, тыңлаучылар бераз тынычлана төшәләр. Тагын абзый укый башлый:

Дәтҗал мәлгун Хорасанга сәфәр кыйлгай[1],
Ислам белмәз бәдбәхетләр шадман булгай.

Мин әтиемнең сүзгә оста икәнен югарыда әйткән идем. Шуның өчен булса кирәк, кыш һәм көзнең озын кичләрендә, безнең өйгә бик еш кына авылның китап тыңларга ихлас кешеләре һәм кайбер күршеләр киләләр, хәтта, мәҗлес кызык (булсын) һәм озакка сузылсын өчендер инде, үзләре акча җыеп калачлар китерәләр иде. Андый көнне безнең өй эчендә аерым күңелле була, бөтен кешеләр әтинең китап һәм хикәя сөйләгәнен тыңлап, аның авызына карап утыра торганнар иде. Ул хикәя һәм башка вакыйгаләрне сөйләгәндә китапны кулына да алмый, баштан ахрына чаклы яттан сөйләгәнгә күрә, тыңлаучылар өчен бик күңелле булгандыр, дип уйлыйм.

Аның «Әбүгалисина», «Хатимтай,» «Сәйфелмөлек» хикәяләрен сөйләве әле дә хәтеремдә тора (башка ваграк хикәя һәм кызыклы вакыйгаләрне «Гаҗаебелмәхлукат», «Нәвадир», «Тутый намә» һәм башка әсәрдән алып сөйләгәнен соңыннан, үсә төшкәч, белдем).

Ул ачуланган вакытларында әнигә ачуланып, аны тиргәп ташласа да, әнигә кул сузганын, ягни аны сугу, кыйнау дәрәҗәсенә җиткәнен күргәнем булмады. Күп гаиләләрдә була торган андай алама гадәт безнең өйгә кермәде.

Әтинең кешеләр белән сөйләшеп утырганда сүз араларына бик еш гарәпчә сүзләр, хәдисләр[2] катнаштырып сөйләве, төрле мөнаҗәтләрне көйләп укуы хәтеремдә бик нык калган. Аларның бик күбесе әле дә минем исемдә торалар...

Зур абзыем—Нурислам бик йомшак табигатле булуы ягыннан әнигә охшый иде. Ул безнең гаиләдәге ир балаларның иң зурысы. Шуның өчендер инде ул бик яшьтән әтинең канат астына кереп, йорт эшләре эшләргә кереш-

[1] Сәфәр кыйлгай—юлга чыгар.
[2] Хәдис—Мөхәммәт (пигамбәр) сүзе.

кән яки мәҗбүр ителгән булса кирәк. Ул татарчаны өйдә генә укып яхшы гына укый башлаганнан соң, мәктәпкә йөрми эшкә керешеп киткән. Ул мин белә башлаганда үсеп җитәргә якынлашкан егет булып, йорт эшләренең һәммәсен дә үз өстенә йөкләгән иде. Ул малларны карый (безнең ул вакытта бер ат һәм колынлы бия бар иде. Сыер, сарык, кәҗә һичбер вакыт булмады), утын ташый, җәй булса печән чаба, кыскасы, бөтен авыр эшләрне ул алып бара иде. Аның шул эшләрен һәм йомшак яхшы күңелле булуын яратыптыр инде, әни Нурислам абзыйны бик ригая итә, ярата, аны Мәһди абзыйдан алда күрә иде.

Икенче агам—Мәһди бөтен табигате белән әтигә ошап, әти кебек сүзчән һәм каты күңеллерәк, үз сүзен сүз итәргә маташучы бер малай иде. Бу агам, өйдә бераз укыгач, Эстәрлегә качып китеп, анда бер-ике кыш укып йөргәннән соң, Оренбург ягына барып берәр ел йөреп өйгә кире урап кайтты. Ул йөргән җирләрендә бераз дөнья күргәнгә күрә, зур агама караганда аңлырак, шуның белән бергә усалрак иде. Ләкин читтә шулай ике ел йөрсә дә рәтле укымаган булса кирәк, ул яктан артык эш чыгара алмады. Мин аның качып тәмәке тартканын күреп ниһаят дәрәҗәдә гаҗәпләнә, аның янына барудан саклана идем.

Энем Әхсән мин белгәндә бик бала булганга күрә, аның хакында хәзергә монда язып торырга хаҗәт юк. Ләкин аны әти, әни бик иркәләгәнгә күрә, мин аннан көнләшүем исемдә тора.

Минем яшьлек вактымда күңелгә иң нык тәэсир калдырган кеше, анамнан соң, Сафия исемдәге апам булды. Башка туганнарым хакындагы тәэссөр[1] вә хатирәләрне бик кыскалык белән бетерергә мөмкин булганда, Сафия апам хакында кыска язып булмый.

Аның: «Сине мин карап үстердем»[2]—дигән сүзләре әле дә булса колагым төбендә яңгырап тора. Чынлап та, мине карап, төрле бәла-казалардан саклап үстерүче, тәрбия

---

[1] Тәэссөр—әсәрләнү.

[2] Бала карау, аны юату кебек авыр нәрсә юк. Мин бала карауның авырлыгын, ятим калып җиңгәйнең балаларын караганда бик ачык белдем. Ул авырлыклар әле дә йөрәгемнән чыкмыйлар. Шуның өчен, Сафия апамның миннәт* итүе хаклы булган...

(*М. Гафури искәрмәсе*).

* Миннәт итү—иткән яхшылыгын кат-кат исенә төшерү.

итеп аякка бастыручы булганлыгын әни дә тәэкит[1] итә иде.

Бу апам төскә матур, буйга зифа булып, артык мөлаем табигатле, нечкә күңелле иде. Әти һәм әни өйдә юк чагында, аның моңлап ерлауларын ишетә торган идем. Ул курай уйнарга да бик оста булып, аулак өйгә кызлар җыелган кичләрдә ул бик моңлы иттереп курай уйный, шундагы кызларның берәрсе ул курайга кушылып ерлый, шулай итеп бик күңелле бер уен кичәсе ясала иде.

Мин җиде-сигез яшьләрдә чакта бу апамны үзебезнең авылдан 20—25 чакрым җирдәге Сакай исемендәге бер авылга, Шәриф дигән бер егеткә кияүгә бирделәр.

Сафия апамның көчләнеп кияүгә бирелүен, әнинең:

— Аны үзе теләмәгән җиргә көчләп кияүгә бирелүгә Сәбәгыйн карт сәбәп булды. Атагыз, шуның сүзенә карап, кызыбызны күрәләтә утка ташлады!—дип зарланып, әрнеп сөйләүләреннән белдем. Әнинең бу әрнүле сүзләре әле дә минем йөрәктән китмиләр.

Апам өчен бер дә көтелмәгән бу кара такдир, татар кызларын һәлак итә торган бу җәбер аның бөтен өметләрен җимергән булса кирәк, ул озатылган вактында соң дәрәҗәдә җылады. Бу фаҗигале туй аның вөҗүденә тәэсир итте. Аның шул вакыттагы әрнүләре, почмакларга утырып җылаулары әле дә булса күз алдымда тора. Аның эчендә янган кемгәдер булган мәхәббәт утын, күңелендә саклаган сөю дәртен аңламадылармы, әллә белеп тә шулай эшләделәрме, ул якларын күз алдыма китерә алмыйм. Ихтимал, аны башкалар бер дә сизмәгәннәрдер. Ләкин мин аның бер кеше өчен янганын шул вакыттагы хәрәкәтләреннән аңлап, бу көн дә куркып, әрнеп китәм.

Мәсьәлә болай иде: безнең өйгә ике-өч йорт аша гына бер егет булып, ул кай вакытта безгә килә иде. Ул безгә килгән вакытта апам бөтенләй үзгәрә, ул урамнан үтеп киткәндә шунда ук тәрәзә төбенә барып, күзен алмый карый торган иде. Мин апамны шул егеттән нигәдер көнләшкән кебек (апамны артык яратудан икәнен хәзер беләм), аны ирештерә, әтигә әйтәм, дип куркыта торган идем. Ләкин апам, моңа карап, мине читкә тибәрми, бәлки мәхәббәтенең бер өлешен миңа да бирә, мине юата, әтиләргә андый сүзләрне әйтергә ярамаганын белдерә иде.

Әлбәттә, минем Сафия апамның ул егетне яратуын сизүемне әтиләргә әйтү ихтималым юк иде.

---

[1] Тәэкит итү—раслау.

Менә ул шулай теге егетне сөеп, шуңа кияүгә чыгу өмете белән йөргән чагында, аны тоттылар да югарыда әйтелгән җиргә кияүгә бирделәр. Ихтимал, аның күрше егете Зәйнеттинне яратуын әти дә сизгәндер. Һәм шуңа үчегеп чит авылга кияүгә биргәндер.

Әнә шул шомлы туй, көчләп укылган никах Сафия апаның бөтен өметләрен җимереп, күңелендә булган ялкынлы мәхәббәте өстенә бозлы яңгыр яуган кебек итсә кирәк: ул туйдан соң бөтенләй күңелсезләнде. Аз сөйләшә башлады һәм аурый да башлады.

Аның шулай рухани газаплану сәбәбеннән туган үзгәрешен күреп:

— «Сафия кияүен яратмаган... Аны көнләшеп сихерләгәннәр... Сихерын кайтарырга кирәк иде...» дип сөйләүләре әле дә булса хәтеремдә тора.

Кыш көнендә бирелгән апамны, җәй көнендә печән алдыннан озаттылар. Минем күңлемдә озатуның яшьле, ямьсез ягы белән бергә, кыңгырау таккан пар атларның тыпырчынып торулары, кыңгырауларның шылтыр-челтер итүләре, апамны көймәле арбага күтәреп утыртулары, озатырга килгән хатын-кызларның күплеге, алар кузгалып киткәннән соң азан әйтүләре кебек тышкы күренешләр бик нык истә калган. Үзенең ата-ана һәм туганнарын, сөйгән илен, туган җирен, күңелендә мәхәббәте сакланган бер кешесен ташлап үзе бер дә яратмаган бер кеше белән утырып, чит бер авылга киткән вактында, апамның ни чаклы авыр бер хәлдә булуын соңыннан уйлап хәйран калам. Бу эш, әлбәттә, йомшак күңелле әнинең йөрәгенә бик нык тәэсир иткәндер.

Ул шулай җылап китте... Аларның атлары күздән югалгач, кыңгырау тавышлары ишетелми башлагач, без өйгә кердек. Хәзер өй эче бик тын, әллә нәрсә, бик зур нәрсә югалган кебек күңелсез иде. Әни бер почмакта җылап утыра, әти, нәрсәдер уйланып, тәрәзәдән карап тора иде. Өй эчендә бер генә минут тору да күңелгә авырсымак тоела, күңелгә каралык китерә төсле күренә. Ни булса да бу өйдән матурлык киткән, монда мәхәббәт беткән кебек хис ителә иде. Чынлап та, бу өйдән мәхәббәт белән янган, мәхәббәтле татар кызы киткән иде шул... Ул үзе киткән, тик монда лагнәтле ачы күз яшьләрен тамызып, аһ-зарларының эзләрен калдырып киткән иде шул...

Күпме вакыт үткәчтер инде, ул ягын әйтә алмыйм,

апам белән җизни беренче рәт кунакка килделәр. Апамның безгә килүе, үзенең туган өенә кайтуы, безнең һәммәбезгә дә бик зур шатлык булды. Аның төсендә бик зур үзгәреш булмаса да, һаман күңелсез булып, кеше белән сөйләшми торган чагында тирән уйга кала иде. Ул шушы кунак булып торган өч көн (дә) күп чыгып йөрми, күбрәк вактын әни белән сөйләшеп үткәрә, кай вакытта мин аның җылаганын күрә идем. Мин хәзер аның яныннан аерылмый идем. Аннан аерылып тору минем өчен авыр иде. Ул үзе мине яныннан җибәрми, бергә йөретә, үзе (белән) бергә утырта иде. Шул аермавыннан алып, ул мине үзе белән Сакай авылына алып китте. Шулай итеп мин, беренче мәртәбә үзебезнең авылдан чыгып, чит авылга бардым, чит илнең суын эчтем, башка авыл малайлары белән танышып, шулар белән бергә йөри башладым.

Бу өйдә без: апам, җизни, мин—өчәү генә идек. Җизни күп вакытта эш белән йөргәнгә күрә, мин апам белән тора идем. Апам һәр вакытта кайгылы, аның күзләре күп вакытта яшьле була торган иде. Мин бу гам, бу яшьләрнең чын мәгънәсенә төшенә алмасам да, аңа карап боега торган идем. Үеннан калган вакытларымны аның янында торып, аның җырлаганнарын ишетеп үткәрә идем. Балалык белән борчылсам яки иркәләнеп китеп артык җибәрелсәм, апам: «Зинһар, туганым, җанымны ком итмә, минем болай да хәсрәтем күп!..» ди торган иде.

Берәр айдан соң, үзебезнең авылга алып кайттылар. Ләкин мин үзебезнең өйдә дә, авылда да ямь таба алмадым. Һич туктаусыз җыладым. Аптырагач, икенче көнне, мине, Акташ авылының бер кешесенә утыртып, апам янына җибәрергә мәҗбүр булдылар. Мин тагын Сакай авылына барып, сөекле апам янында, аның шәфкатьле кочагында тора башладым.

Апам янында ничә ай торуым хәтеремдә юк. Тик апам, алты-җиде айлар чамасыннан соң, язга таба үзе бөтенләй үзебезгә кайтты. Ул аерылып кайткандырмы, әллә озын мөддәткә кунакка кайткандырмы... ул җәһәте миңа мәгълүм булмады. Ләкин инде аның йөзләре саргайган, зур кара күзләре тагын да зурая төшкән, үзе арыкланып, тәмам хәлдән тайган иде. Ул хәзер, үзенең туган авылына кайтса да, рәхәтләнеп йөри алмады; кайту белән түшәккә егылып, күпмедер аурып ятканнан соң, күкрәк хасталыгы белән вафат булды.

Сафия апам үлгәннән соң, әти бераз гына күңелсез йөрсә дә, тиздән борынгы хәленә кайтты. Ләкин әнигә аның вафат булуы бик нык тәэсир иткән булса кирәк, аның бик еш елавы, апамнан калган кайбер нәрсәләрне кулына тотып, әрле-бирле әйләндереп: «Мескен, бу тастымалны өченче ел яз гына суккан иде... тотып та карамаган, күрәсең, нак сугып куйган көенчә тора» (дип), алдына куеп уйга бата торган иде. Аның (Сафияның) үлүе минем өчен бик вә бик күңелсез булды. Ихтимал, моның аркасында килгән тәэссөр минем беренче тәэссөрем булгандыр... Кыш үтеп бетмәгәнгә күрә, апамны күмәргә озата бара алмадым бугай. Тик соңыннан, теге егетнең апамны кара җиргә күмгән вакытта артык нык тәэссөрләнгәнен, хәтта, кешеләрдән яшеренә төшеп, җылаганын сөйләүләре хәтеремдә калган. Шуның белән бергә, апамның озатылган вакытта җылаулары, чит авылда моңаеп җырлаулары, коры сөяккә калып, монда җан бирүләре—һәммәсе, һәммәсе күз алдымда тора, йөрәгемдә әле дә булса чишелмәгән каты бер төен кебек булып сизелә...

Шуның өчен мин бу апам хакындагы истәлегемне, татар, башкырт хатын-кызларының борынгы ирексез яшәүләрен, авыр тормышларын күрсәтә торган бер кара сәхифә иттереп, монда язып үтүне тиешле күрдем.

Бала чаклардагы тормышның якты һәм күңелле вакытлары бик күп булу белән бергә, кай вакытта, күңелсез чаклары да була. Ләкин бу күңелсезлекләр балаларның үзләренә карап кына булганга күрә, тизрәк истән чыгучан булалар. Мәсәлән, хәзер генә бер бала белән бәргәләшеп аласың, мәңге күрешмәслек булып сугышып аерыласың. Бер-ике сагәт тә үтми, шул «дошманың» белән татулашып, тагын да уйнарга керешеп китәсең.

Шуның өчен, бәләкәй вакыттагы хатирәләрнең вак төякләренең бик күбесе онтылган булалар. Хәзер аларны тикшерә башласаң, бик калын томаннарга очрарга туры килә. Тик шул томаннар арасында ялтырап күренеп торган истәлекләрне генә чүпләп алырга мөмкинлек була. Минем күз алдымда, биш яшь белән ун яшьләрем арасындагы булган төрле хатирәләр чобалып, чобарланып күренәләр. Шуңа карап та нинди эшнең кайсы вакытта эшләнгәнен, нинди тәэссөрләрнең кайчан булганын көне, елы белән ачык әйтеп булмый. Мәсәлән, мин шул ук, йөрәгемдә бик нык эз калдырган, Сафия апамның 1888 нче елның җәендәме, булмаса, 1889 нчы елның җәендәме,

озатылганын катгый ачык әйтә алмыйм. (Моның өчен күз алдына кара сәхифәләрне ачып салган борынгы «метрикә дәфтәрләрен» тикшерергә туры килә.)

Бала вакытта балаларның тормышына бик нык үзгәреш бирә торган эшләрнең берсе—аларның башлап укырга керешүләре икәнендә шөбһә юк. Бу эш балалык тарихы өчен бик мөһим һәм онтылмый торган нәрсә. Шулай була торып та, мин үземнең иң элек әтидәнме, әнидәнме укый башлавымны хәтерли алмыйм. «Әлеп-би» укуым, аны тануым исемдә калмаган. Бик якын ихтималга карап, мин әлифбаны, әти күрше балаларын укыткан вакытта карап утырып, шуннан белгән булсам кирәк, дип уйлыймын.

Тик «Һәфтияк» иҗегенә төшеп, «мөкрәмүн», «вәләямәссәннәкүм» сүзләрен укып утыруларым әле дә булса, урны белән, хәтеремдә тора. Бу вакытта минем яшем биш-алты чамасында булса кирәк, мин әтидән укый идем. Ул иртәнге намаздан чыгып, туры мәктәпкә барып балалар укыта да, аннан кайтып, чәй-фәлән эчкәч, безгә сабак бирә торган иде. Сабак белмәүем өчен әтинең ачулануы исемдә юк. Ләкин мин бик күп көлә торган булганга күрә, әти шул көлүем өчен орыша, кай вакытта чигәгә дә чабып җибәрә иде. Шуның өстенә мин күп сөйли торган булганмындыр, күрәсең, әти һәр вакыт мине үзебезнең авылның бик телчән һәм күп сөйләүе белән шөһрәт тапкан «Пачакин Сибгат» кә ошатып, ачулана: «Һай, син, Пачакин Сибгат!..» дип, бик каты тәнбиһләр[1] ясый, ата-ана алдында күп сөйләргә, көләргә ярамауын белдерә, шулай итеп, мине «әдәп» кә өйрәтә иде.

Җиде-сигез яшьләр чамасында булсам кирәк, беренче рәт үзебезнең авыл мәктәбенә барып, шунда йөреп укый башладым. Бу вакытта «Коръан» укый, шуның белән бергә татарча китапларга да төшенә башлаган идем.

Ул вакытта иҗек танып, «Коръан» укый башлау хәзерге көндәге беренче баскыч мәктәптән икенчегә күчү белән бер исәпләнә. Моның өчен ата-аналар бик шатланалар һәм хәллерәк кешеләр, шуның шатлыгыннан аш хәзерләп, укытучыны (күбрәк мулланы) чакырып бәйрәм ясыйлар иде.

Ул вакытта башлап уку һәм иҗек танып китү чиксез авыр булып, бик күп балаларның башлары шул иҗек танудан чыга алмый аптырый иде. Берничә ел мәктәпкә

---

[1] Тәнбиһ—кисәтү.

йөреп тә иҗек таный алмый, «Һәфтияк» укудан үтә алмый, мәктәпне ташлап чыгучыларның проценты 70—80 гә җитә торгандыр дип уйлыйм. Безнең авылларда мәктәп ишегеннән үтмәгән балалар бик сирәк булып та, ул вакытта бөтен авылда язу таный торган кешенең биш-алтыдан үтмәүе шуннан килә.

Иҗек укуның авырлыгына чыдый алмый, бик күп балалар берничә көннән үк мәктәпне ташлап качарга мәҗбүр булалар. Аларны аталары көчлек белән җитәкләп мәктәпкә китереп мулла кулына тапшыра. Алар тагын качалар. Ниһаять, аталары да, балаларының укуларыннан өмет өзеп, китерми башлыйлар иде.

Бер бала этисенең сарыкны суяр өчен җитәкләп алып барганда, мескен сарыкның дүрт аягын терәп, бармас өчен тартышканын күреп:

— «Әй, дурак сарык!.. Юкка тартышып торасың. Әйтерсең, мәктәпкә сабак укытырга алып баралар!» дип, сарыкның тартышуына аптыравы, укуның авырлыгына карап әйтелгән сүз икәнендә шөбһә юк.

Мәктәпкә йөреп укый башлагач, минем эшләр тагы да шәбрәк китте. Әти шунда укытып йөрүче булганлыктан, балалар да артык кырын күз белән карый алмыйлар, шуның өстенә, кайберәүләре белмәгән сабакларын миннән сорап алалар иде. Мәктәпкә йөреп укый башлавымның өченче елында төрек-татарча телне белгәнгә хисаплап, мине гарәпчә укытырга керештеләр. Шул вакытның гөреф-гадәте буенча «Шорүтөссәла», ул беткәч «Таглимоссәла» китапларына төшерделәр. Эш гарәпчә китапларга төшү белән генә калмады, үземнең сабакны белгәч, кайбер яшь балаларга «әлеп-би» дән сабак бирергә яки сабакларын белмәгән балаларның сабакларын өйрәтергә дә куша башладылар.

Мин инде мәктәпкә йөреп укый башлавымның дүртенче елында «Төхфәтелмөлек» һәм «Гайнелгыйлем» китапларыннан сабак ала башладым. Хәзер мине әти түгел, бәлки мулла абзый үзе укыта иде. Бу эш минем вак шәкертләр арасыннан чыгып, «зур укучы» шәкертләр рәтенә керә башлавымның беренче баскычы иде. Минем әле 11—12 яшьләр чамасындагы бәләкәй малай булуыма карамастан, шундый башка кешеләр аңламый торган телдә «зур китаплар» укуым бик зур муаффакият исәпләнә иде.

Минем болай күтәрелә баруым этинең дә башын күккә күтәргән булса кирәк, ул кай вакытларда:

— Минə бу балам хəлфə булыр, мулла кеше булып чыгар,—дигəн сүзлəрне ычкындыра башлады. Минем балалар арасында «игтибар» артты. Мин сабак өйрəткəн балаларның ата-аналары, кече атна һəм җомга көннəрендə, мине өйлəренə чакырып кунак иткəли башладылар. Хəтта кайберəрсе, «Мəҗит—хəлфə була инде ул...» дигəн сүзлəрне үземнең алдымда ук əйтеп куялар иде. Минем кебек яшь малайга аларның бу мөгамəлəлəре, миңа «дəрəҗə» бирүлəре, миңа тəэсирсез калмады. Бик үк мактанып сөйлəнмəсəм дə, əзрəк «эрелəнеп» киттем. Сүз арасында гарəпчə сүзлəр ычкындыргалый башладым.

«Дəрəҗə» күтəрелгəннəн күтəрелде. Яшьлəре минем белəн тиң, хəтта кайберəүлəр миннəн яшькə зур булып та, укулары түбəн булган малайлар минем белəн якын дус булып тору юлларын эзли башладылар. Мин үзем «хəлфə» була торып, Бикмөхəммəт, Закир дигəн малайларның бəлəкəй чанага очланып, мине урам буйлап йөртүлəрен (кататсə иттерүлəрен) əле дə булса уйлап көлəм. Алар аталары Фəйзи бабай белəн Гариф агай кунакка чакырганда да мине шулай бəлəкəй чана белəн килеп алалар һəм соңра китереп ташлыйлар иде. Мин инде унике яшьлəремдə генə булгач, ничек иттереп аларның түр башларында оялмый кунак булып утырганмындыр, кунак булу формаларын ничек килештергəнмендер... Шуларны уйласам, хəзер үзем дə кызарып китəм. Лəкин кунак булып беткəннəн соң, аларның аталары миңа ике яки өч тиен садака биргəндə мин бик оялып, башымны түбəн басып утыруым хəтеремдə.

Лəкин минем авылда «хəлфə» булып «сый-хөрмəт» күреп торуым бик күпкə сузылмады: унөч яшемдə, үзебезнең авыл мəктəбен минем өчен бəлəкəй күреп, мине күрше авылга, шул тирəдə данлыклы булган Үтəш авылы мəдрəсəсенə җибəрү турында киңəш итə башладылар. Бу киңəш, бара торгач, чынга əйлəнде.

93 нче елның көзендə, чана юлы төшкəч, əти мин барачак мəдрəсəнең мөдəррисе, гади мулла гына түгел, Хатыйп хəзрəтне үзебезгə кунакка чакырды. Əти, хəзрəт белəн бераз сөйлəшеп утырганнан соң, мине үзлəре янына чакырды һəм хəзрəт белəн күрештерде. Аның белəн генə калмый, үзлəре янына чəй эчəргə утырырга кушты. Мин бик куркынып һəм оялып, самовар артынарак барып утырдым.

Хатыйп хəзрəт иң зур гəүдəле кешелəрнең берсе һəм

карап торуга мәһабәт иде. Мин аңы күргәч, башта калтырандым. Тик бераздан соң гына бу калтыравым басылды. Мин кереп утыргач, әз генә тору белән эти минем хакта сүз башлады:

— Минә, Мәҗит дигән углым шушы инде.

— Бик яхшы, бик яхшы, һәйбәт бала күренә. Алла гыйлменафыйг[1] бирсен,—диде хәзрәт.

— Хәзрәт, менә бу баламны сезнең тәрбиягезгә тапшырам. Үтәш авылында Хатыйп хәзрәт мәдрәсәсендә Мәҗит хәлфә дигән хәлфә бар, дигәнче укысын иде.— Әтинең бу сүзләрен ишеткәч, башымны түбән бастым.

Хәзрәт үзенең мәһабәтлеген бер дә югалтмый дога кылганнан соң:

— Мулла Нури, безгә ышанып балаңны тапшыруыңа рәхмәт. Бездән укыту, тәрбия бирү. Тәүфик, һидаят бирү—алладан. Баланың файдалы гыйлем алып чыгуына дога кылыйк,—дип, тагын бер мәртәбә дога кылды.

Мин үземне хәзер бу хәзрәткә бөтенләй буйсынган кебек хис иттем. Күңлем йомшап күземнән яшь килде.

Хәзрәтне шулай кунак иткәннән соң, мине шушы көннәрдә үк мәдрәсәгә җибәрергә вагдә биреп, хәзрәтне озатты.

Хәзрәт киткәннән соң, эти белән әни мине үзләре янына чәй эчәргә утыртып, бик зур эш башкарылган төсле, мине вагәзләп алдылар. «Укып кеше булырсың. Тырышып укы! Хәзрәтнең фатыйхасын алырга тырыш!..» дип, миңа карата бик күп сүзләр сөйләделәр. Мин, әлбәттә, аларның һәрбер сүзенә җавап уларак, иягемне кагып, «ярар» дигән җавапны аңлатып утырдым.

Хатыйп хәзрәт шулай безгә килеп киткәннән соң, мине озату турында әзерлекләр башланды. Тышы кызыл кергезиннән, эче кара бәздән, уртасына мамык куйдырып, бишмәт тектерделәр. Гәрчә бу бишмәтнең эче-тышы бергә сырылып, кул белән генә тегелгән булса да, миңа чиксез матур булып күренде. Әни бүрекне сиплән җибәрде. Яңа оек бәйләтеп бирделәр. Алмаш күлмәкнең ертыкларын ямадылар. Әни миңа махсус кечкенә мендәр ясап, кызыл шакмаклы киндер белән тышлап куйды. Чабата ясарга осталыгы белән шөһрәт алган Насыйр бабайдан

---

[1] Гилменафыйг—файдалы белем.

өр яңа башмак-чабата ясатып бирделәр. Шулай итеп, мин, чит авылга мәдрәсәгә җибәрелү аркасында, баштан аяк киенеп алдым. Бу яңалыклар бер яктан мине шатландырсалар да, чит авыл мәдрәсәсенә китү минем эчемне әрнетә иде.

Китү көне алдагы җомга көненә тәгаен ителгән иде. Ул көн бик тиз килеп җитте. Бүген безнең өй эчендә аерым рәвештә җанлылык бара, мине гадәттәгедән артык иркәлиләр, сыйлыйлар, мөмкин кадәре хөрмәт итәләр иде. Минем китүемә бигрәк тә әни әһәмият биреп, ул артык тәэссорләнә иде. Мине озату мөнасәбәте белән кардәш-ыруглардан берничә карт белән карчыклар чакырылды. Алар алдында тагын да минем укуым, тырышырга тиешлегем, киләчәктә «хәлфә» булуым хакында бик күп сүзләр сөйләнде. Алар тагын да бик озын фатыйха кылып, һәрберсе өчәр тиен, бишәр тиен акча да бирделәр. Мондый хәлләрне күргәч, минем йөрәгем тибәргә кереште. Тизрәк китәсе килә башлады.

Мин алып китәргә тиешле нәрсәләр бер җиргә җыелды. Бер кечкенә агач сандыкка, укый торган китапларым белән бергә, бер сөлге, бер пар чынаяк, әчмуха чәй, бер чирек чамасында шикәр салынды. Кечкенә бер капчыкка ун кадак чамасында ярма салынып, аның эченә, түтәрәм каз белән бергә, ярты кадак чамасы туң май куелды. Шул ук капчык эченә бүген генә пешкән зур гына ике арыш икмәге салдылар. Күрше әбиләрнең әнигә булышлык итүләре аркасында, бу әйберләр дәррәү хәзерләнеп беттеләр.

Нурислам абзый әллә кайчан атны җигеп, ишек төбенә шакарып куйган иде инде. Мин, кызыл бишмәтне киеп, кызыл башлы тастымал белән билемне буып алдым. «Юлда кулың өши күрмәсен!..» дип, әни үзенең бияләен кулыма бирде.

Шулай, бөтен хәзерлек тәмам булгач, әти мине үзенең янына утыртты. Башка кешеләр дә сәкегә рәттән утырганнан соң, минем бәхетле булуымны теләп, бик озак дога кылдылар... Шулай дога кылып утырган чакта ук, әни пыш-пыш җылый башлады. Аның җылаганын күреп минем дә күңлем тулды. Үземнең ихтиярымнан башка күзләремнән яшь чыкты. Бирешмәскә тырышып иреннәремне кыссам да, көчем җитмәде, иреннәрем калтыранды. Ниһаять, әти:

— Хуш бул, балам. Тырышып укы. Атна саен кунак-

ка кайтырсың. Синең хәлфә булганыңны күреп үлсәм иде,—диде.

Әтинең шул сүзләреннән соң һәммәсе дә, урыннарыннан торып, минем белән күрештеләр. Кайберәүләре аркамнан сөйделәр. Шулай итеп мине чанага чыгарып утырттылар.

Минем китүемне белгән күрше малайлары да мине озатырга килгәнннәр иде. Мин, ни өчендер, алар белән исәнләшә алмадым. Үземнең җылавымнан куркып аларга туры караудан да сакландым.

Күптән бирле җигүле торган ат, без чанага утырып, дилбегәсен кагу белән, капкадан чыгып та китте. Тик озатучыларның:

— Хуш бул!..—дигән сүзләре генә колагым төбендә яңгырап киткән кебек булды...

Безнең авыл белән Үтәш авылының арасы бик якын булуына һәм әтинең: «Атна саен кунакка кайтырсың...» дип әйтүенә карамастан, никтер мин үземне моннан соң үзебезнең авылга, туган өйгә, мәңге кайтмаска киткән кебек хис иттем. Күңлем йомшап, абзыйга белдермәскә тырышып кына җылап алдым. Абзый, әлбәттә, минем җылаганны сизгән булса кирәк, ул мине юатыр өчен:

— Бер атнадан үзем барып алырмын. Менә бит син нинди зур мәдрәсәгә укырга барасың. Анда уку бик күңелле. Мин шулай укый алмый калдым бит,—дип сөйләргә кереште. Аның сүзләре әлбәттә мине чынлап юата алмадылар. Тик мин бара торгач кына табигый бер хәлгә төшеп, алдагы тормышым турында уйлый башладым.

Иң элек минем күз алдыма бик куркыныч булып: «Кырык беренче» булмасам ярар иде»,—дигән уй килеп басты.

Көз көнендә мәктәпкә, бигрәк тә зуррак мәдрәсәләргә, килгән шәкертләрнең исемнәрен казый (мәдрәсәнең мөдире) яки мулла бер дәфтәргә, аларның килү тәртипләре белән, яза бара. Шәкертләр башлап килгәндә бу эшнең һичбер куркынычы юк. Әмма инде кырыкка таба бара башласа, куркыныч була башлый. Мәсәлән, бүген килгән Гайнетдин дигән шәкерт дәфтәргә кырыгынчы булып керә. Шул сәгәт белән, шәкертләр, моннан соң киләчәк шәкертнең «кырык беренче» икәнен белеп, аны көтәргә керешәләр. Чөнки ул шәкерт бер дә шиксез «пәри-җен баласы» булачак. Әллә ничә дистәләгән, бәлки йөзләгән шәкертләр арасында бу исемне күтәрүнең авыр, хәтта чыдый алмаслык бер хәл икәнен һәркем белә иде.

шәкерт тукталды. Хәзер миңа гайрәт кереп китте. Мин үзем дә аңа бәхәс итмәкче булып:

— Су ничә кыйсем?[1]—дигән сөальне бирдем. Ул аптырап тормады:

— Өч кыйсем,—дип җавап бирде.

— Нәрсәләр?

— Таһир, тоһыр, нәҗес...

— «Таһир» дип нинди суга әйтелә?

— Таһир дип үзе дә пак, башка нәрсәләрне дә паклаучы суга әйтелә.

— Ә «тоһыр» нинди су?

— ...

Рәтләп җавап бирә алмады: «Тукта, мин аны хәзер китаптан карап алам...» ди.

— Син, шәп булсаң, китаптан карамый әйт!..

Шәкерт ачулана башлады:

— Син монда безнең бәхәс итүдән куркып, алдан ятлап килгәч тә...

Алар күмәк, мин әле яңа гына килгән берәү булганга күрә, сүзне озынга җибәрергә курыктым.

— Шулай инде,— дим.

Аларның кайберәүләре мине җиңелгәнгә исәпләп:

— Шулай шул! Кәмәң комга терәлде шул... Карга!—дип, миннән көлделәр. Шулай да кайберсе:

— Ул бит синнән бәләкәй әле; үзе яңа килгән,—дип, мине якладылар...

Шул вакыт кизүнең[2]:

— Таһарәткә!.. Икенде-ахшамга!—дигән тавышы чыкты.

Аның тавышын ишеткән бөтен шәкерт, кулларын сызганып, таһарәт алырга хәзерләнә башладылар.

Хәзер минем алга таһарәт алырга комган юклыгы килеп басты. Әле шәкертләрнең берсе белән дә рәтләп танышып өйрәнмәгәнгә күрә, алардан комган соравы да уңайсыз иде. Комганым булмаса да беләкләремне сызганып, әле без бәхәсләшкәндә минем яклы кебек булып утырган бер шәкерткә: «Минем комганым юк бит. Син миңа таһарәт алырга комганыңны биреп тора күр инде...» дип үтендем. Ул шәкерт, бер дә сүзсез, комган бирмәкче булды һәм мине үзе белән бергә таһарәт алырга алып

[1] Кыйсем—өлеш, кисәк.

[2] Кизү—дежурный магнәсендә. Мәдрәсәдә һәр көн бер шәкерт кизү көтә. Ул мәдрәсәнең мичләренә яга, идәннәрен себерә. Намазга бармаган яки бер-берсен җәбер иткән шәкертләрне тотып, казый алдына хөкемгә китереп тапшыра. (*М. Гафури искәрмәсе*).

чыкты, соңыннан һәр вакыт үзенең комганын файдалану мөмкин икәнен белдерде.

Без таһарәт алып кергәндә кизү, шәкертләрне чыбыклап, намазга куа иде. Мин дә теге комган бирүче шәкерткә ияреп, бу авылның мәчетенә беренче мәртәбә намазга киттем.

Мәдрәсәдә, ахшамнан чыккач, бөтен шәкертләр чәй эчәләр. Минем урындашлар да, катып беткән ашъяулык җәеп, чәйгә утырдылар. Монда ашау нәрсәләре дә, башкалар да аерым. Һәр кем үзенең нәрсәсе булса, шуны ашый. Бер үк урында чәй эчкән шәкертнең берсе арыш икмәге ашаса, берсе бодай күмәче ашый. Берсе шикәрләп чәй эчсә, икенчесе шикәрсез генә чәй эчә. Башта мин болар янына утырырга кыймыйрак торсам да, араларыннан берсе мине үзләре белән чәй эчәргә чакырды. Мин дә эпи белән шикәремне алып болар белән бергә чәйгә утырдым. Чәй эчеп беткәнче без бер-беребез белән үзләшеп киттек. Боларның укулары миннән түбәнрәк булганга күрә, болар миңа бик үк читсенеп карамадылар.

Беренче кич минем өчен күңелсез булды. Үзебезнең өй кешеләре, бигрәк тә эни, күз алдыннан китми басып торган кебек сизелде. Мәдрәсәдә тормыш кайнап торса да, мин кызыксына алмадым. Хәзергә әле минем мәдрәсәнең тәртип һәм низамнарына төшенеп бетмәвем, шәкертләрнең берсе дә якыннан таныш булмавы минем күңелсезләнүемә сәбәп булалар иде.

Алты почмаклы булган мәдрәсәдә йөздән артык шәкерт торуы, аларның ашау-эчү әйберләре, савыт-сабалары, ятак нәрсәләре—һәммәсе дә шунда булганлыктан, мәдрәсә гаят тыгыз булып, салкын кыш булуга карамастан, һәммә кеше тиргә батып, пышыгып утыра. Бүген мин рәтләп йоклый алмадым. Кичтән, берничә сагәткә чаклы, үзебезнең өйне, авылны уйлап яттым. Соңыннан мондагы тыгызлыкка чыдар хәл булмады.

Иртән торгач, намазга барып кайтканнан соң чәй эчкәч, һәммә шәкерт, үзләренең укый торган китапларын алып, сабак хәзерләргә һәм, хәлфәләрдән дәрес ала торганнары, кичә калган сабакларын тыңлатып, яңадан сабак алырга керештеләр. Мин дә үзем белән алып килгән «Төхфә», «Гайнелгыйлем»не алып, авылда чакта укып килгән урыннарын карарга керештем. Минем кайсы хәлфәдән һәм нинди китаплар укуымны хәзрәт үзе тагаен итәргә тиеш булганга күрә, мин аның килгәнен көтә идем.

— Хәзрәт килә, хәзрәт!—дигән тавыш чыгу белән бө-

тен шәкертләр аяк үрә бастылар һәм кул кушырып, хәзрәтнең югары узганын көтәргә керештеләр.

Хәзрәт мәдрәсәгә керү белән, бер шәкерт аның кулындагы озын таягын алып куйды. Икенче шәкерт пимасын салдырып алды. Өченчесе өстендәге толыбын салдырып чөйгә элеп куйды. Хәзрәт, бик мәһабәт рәвештә, үзенә әзерләнгән мендәрләр өстенә барып утырганнан соң, күзләрен әйләндереп тирә ягына күз төшереп чыкты. Шуннан соң гына чалмасын рәтләп, хәлфәләргә сүз кушты. Шуннан соң, ике зур шәкерт аның каршысына, ике-өч аршин ераклыкта, тезләнеп утырдылар да, китапларын идәнгә ачып салып, бисмилла әйткәннән соң, берничә җөмлә укып, хәзрәткә карадылар. Хәзрәт аларның укыган гарәпчә җөмләләренә магнә бирә башлады. Хәзрәт дәрес биргәндә мәдрәсәнең бу ярты өлешендә бөтен шау-шу бетеп, тын булды. Бу бүлемдә тик зуррак шәкертләр генә калып, башкалары теге якка чыгып тавыш-тынсыз гына укырга керештеләр. Хәзрәтнең дәрсе озакка сузылды. Ул алдындагы китапка сирәк кенә күз төшереп ала да, башка сүзләрне болай сөйли иде. Ул дәрес биреп утырганда хәлфәләр дә сүзгә катнашып, бәхәсләшеп китәләр иде.

Ниһаят, дәрес бетте. Хәзрәт мине чакырып алды. Мин авыл мәктәбендә укыган китапларымны алып, калтырана төшеп, аның каршысына барып утырдым. Ул минем бу көнгә чаклы нәрсәләр укыганымны сорашканнан соң, иң соңында укып йөргән «Төхфә» белән «Гайнелгыйлем»нең элек укыган урыннарның кайбер җирләрен укытып карарга кереште. Башта мин бик нык каушадым. Күз алдым чуарланды. Телем тотлыккан кебек булды. Аның сораган сүзләренең беразына җавап бирә алсам да, бик күбесенә җавап бирә алмадым. Хәзрәт кенә түгел, хәлфәләрнең дә миңа туп-туры карап утырулары мине бигрәк тә авыр хәлгә калдырды. Шулай бер ярты сагәт азапланганнан соң, хәзрәт:

— Бик яхшы. Бу китапларыңны Фазлытдин хәлфәдән укырсың. Укырга кабилиятең[1] бар төсле күренә. Сиңа сарыф, нәху (әлбәттә, гарәпчә телнең сарыф-нәхүен әйтә) укырга кирәк. Аның өчен иң элек фарсыча «Як хикаят» укырсың, — диде.

Аның бу сүзләреннән соң мин үземне иркен хис иттем.

Бу урында шуны әйтеп китми булмый. Хәзерге көндә минем сүзләремне укучылар: «Гарәпчәнең сарыф белән нәхүен укыр өчен нигә соң фарсыча укырга?» — дигән

[1] Кабилият — сәләтлелек.

сөалне бирерләр. Аның сәбәбе менә болай: ул вакытта гарәп сарфын укытыр өчен татар телендә китап юк. Мәгәр фарсы телендә (Бохарада язылган), «Шәрхе Габдулла» исемендә бер китап бар икән. Менә шул китап гарәп сүзләрен фарсы теле белән аңлата. Фарсы-таҗик балалары өчен язылган шушы китапны Бохарада укыган татар, башкырт галимнәре үзләре белән безнең бу илгә алып кайтып, үзләренең шәкертләренә шуны укыта башлаганнар. Башта ул кул белән язылып, күчерелеп йөртелсә дә, Казан китапчылары аны бастырып таратырга керешкәннәр. Шулай итеп, «Шәрхе Габдулла» исемендәге сарыф китабы безнең татар, башкыртлар арасында таралып киткән. Ул үзе бик авыр. Гарәпчә бер фигыльне (глагол), аның тармакларын укыр өчен фарсы теле белән язылган 25—30 битләр чамасында нәрсә ятлап алырга кирәк. Моның өчен күпме көч сарыф итәргә, ни чаклы зиһен кирәк икәнен әйтеп торасы юк. Шуның өчен мәдрәсәдә йөзләгән шәкерт арасыннан сарыф-нәху укучылар, аны укырга кабилияте булучылар аз чыга. «Гыйлмә сарыф» белән «Нәху гыйлмен» бик истигдатлы[1] шәкертләргә генә укыталар икән...

Хәзрәт миңа бүген «Төхфә» дән үзе сабак биреп «мулла», «гыйлем» кеше булып чыгуымны теләп фатиха бирде. Шушы көннәрдә «Як хикаят» укыта башлаячагын белдерде.

Мин чиксез зур авырлыкны уткәргән, икенче яктан, бик зур бәхеткә ирешкән бер малай кебек булып урнымнан торып киттем. Хәзерге сагаттән башлап үземне бу мәдрәсәнең шәкертләре җөмләсеннән булган кебек хис итә башладым.

Мәдрәсәдәге тормышның рәвеше түбәндәгечә иде: таң алдыннан, иртә намазыннан элек, шәкертләрнең һичберсе калмыйча урыннарыннан торырга мәҗбүрләр. Салкын су белән тышта, боз өстендә, юынып, таһарәт алып керәсең дә, сабак яки кычкырып «Коръән» укырга керешәсең. Таң яктырып намаз вакты җитү белән, иртәнге намазга китәргә кушалар. Казандашларның берсе—гадәттә юашрагы, мәдрәсәгә яңарак килгәне, самовар кайнатырга кала. Намаздан чыгып иртәнге чәйне эчү белән, тагын шул сабакны укырга, белгән булсаң тыңлатып, яңа дәрес алырга керешәсең. Хәзрәт кергәч, аңламасаң да аның сабак биргәнен тыңлыйсың. Үз нәүбәтең булса, ашханәгә чыгып бидрә яки казаннарны өрлеккә тагылган җепьләргә асып, аш яки ботка пешерергә керешәсең. Өйлә намазын-

[1] Истигдадлы—булдыклы.

нан чыгуга, аш ашап, аштан соң теләгән эшеңне эшләргә ихтиярлы буласың. Ләкин тәрбиясез рәвештә уйнарга, шаярырга ярамый...

Икенде җитү белән тагын да таһарәт алып, икенде белән ахшам намазына барырга мәҗбүрсең. Ахшамнан чыккач, гозерсез намаздан калганнарны тикшерү, әгәр дә сәбәп күрсәтә алмасаң, йөз түбән яткырып, чыбык белән чаж-чож сугу башлана. Әрнеп, әрнеп кычкыру, җылау тавышлары чыга. Бу эшләр бетеп, тикшерүләр тәмам булганнан соң, чәй эчәсең дә, тагын ясыйг намазына барырга мәҗбүр буласың. Кизү булсаң, намазга куып, намазга бармаучыларны «гөнаһ» лылар дәфтәренә язып казый әфәндегә бирәсең. Ясыйгдән соң укуның иң кызу вакты башлана. Шаулап уку өч-дүрт сагәтләргәчә дәвам иткәннән соң, күзләр йомыла башлый. Хаталык белән йокымсырап китсәң, яшел чыбыкның арка буйлап килеп төшкәнен яки чигәңә утлар күренгәнче чапканнарын сизми дә каласың да, йокың ачылып китеп, үзең аңламаган нәрсәне тагын да мыгыр-мыгыр укырга керешкән буласың. Хәлдән тайган вакытта гына: «Нәвем базарына — ятарга!» — дип кычкырып фарман чыга. Бу тавыш ишетелү белән, йөздән артык шәкерт бердән кузгалып китә. Мәдрәсә эчендә шау-шу куба. Әйберләрен эзләүчеләрнең тавышы белән һичбер нәрсә ишетергә мөмкинлек булмый. Ярты сагәт чамасыннан соң, тавышлар басылып, тик кием-фәлән тапмаган яки ятарга урын таба алмаган шәкертләрнең зарлану яки җылау тавышлары гына кала. Казый чыгып тәфтиш[1] ясап, боларның тавышларын да басканнан соң, утлар сүндерелә. Ут сүндерелгәч, кычкырып бер генә сүз әйтү дә ярамый. Аннан соң эш харап!..

Мәдрәсәдәге хәят һәр көн шулай дәвам итә. Ул һичбер үзгәрми торган бер низам[2] булып әверелгән.

Монда уку-укыту эшләре дә шул тормышка муафыйк куелган. Бер үк яшьтәге балалар төрлесе төрле китап укыйлар. Ике-өч ел укып та язу танымаганнары бик күп. Бер китапны берничә еллар буенча күтәреп йөрүчеләр дә бик күп. Уку «Иман шартлары» ннан башлана. «Һәфтияк», «Коръән», «Ахыр заман»... Шулай китә. Сарыф-нәхү укыганнар сирәк. «Шәрхе мулла» һәм «Мохтасар» укыганнар хәлфә санала башлый. Хисап, җәграфия кебек фәннәрнең исемнәрен белгән кеше дә юк.

---

[1] Тәфтиш ясап — тикшереп.
[2] Низам — эчке тәртип.

Монда көн саен бер генә китаптан сабак аласың, артык юк. Шул алган сабакны үзең белеп, икенче сабак алганда хәлфә тыңлата. Белмәсәң, әлбәттә ачулана. Сабак белмәгән шәкертләрне укыткан хәлфәләр, күздән утлар күренгәнче, яңаклап та куялар. Аларга каршы, әлбәттә, бер генә сүз дә әйтергә ярамый. Синең җылавың аларның ачуларын гына китерергә сәбәп була. Шуның өчен, ни чаклы авыр булса да, чыдарга мәҗбүр буласың.

Минем хәзер сабакка төшүем дә, мондагы шәкертләр һәм тәртипләр белән танышып алуым да, минем авылга булган мәхәббәтемне сүндерә алмадылар. Мин үзебезнең авылга таба карауны (Үтәш авылыннан безнең авыл күренеп тора), ул якка чыгып китүче кешеләргә кызыгуымны ташлый алмадым.

Бер атнадан соң мине килеп алдылар. Беренче мәртәбә авылга кайту мине читлектән чыккан кош кебек шатландырды. Бу кайтуда мин әнигә һәм башкаларга балалык иркәләнүе белән иркәләндем. Ләкин бер кич кунганнан соң кире мәдрәсәгә киту, минем бу шатлыкларымны тагын да бетерде.

Авылга кайтып килгәннең икенче көнендә, хәзрәт тагын мине чакырып, үзенең каршысына утыртты һәм әз генә сүздән соң, кулыма бер китап биреп, «Менә, бүген фарсы теленә төшәсең» дип, шул китаптан сабак бирде. Бу инде югарыда әйткән «Як хикаят» китабы иде. Бу үзе бер генә табак чамасы булып, көйләп язылган иде. Хәзрәт шул китаптан ярты бит чамасы сабак бирде. Аның һәрбер сүзгә бер магнә биреп чыгуыннан мин рәтләп бер нәрсә дә төшенә алмадым. Мондагы сүзләрнең уннан берсенең дә магнәсе истә калмады. Шуның өстенә бирелгән чаклы сабакны ятларга кушты. «Белмәгән сүзләреңне хәлфәдән сорап алырсың, ул өйрәтер!..» диде.

Мин, хәзрәт алдыннан киткәч тә, хәзер генә алган сабагымны укырга һәм ятларга керештем. Ләкин 20—30 юл шигырьдән минем хәтремдә бары 30—40 кына сүзнең магнәсе истә калган. Сүзләрнең ничек әйтелүләрен белмим. Бик озак азапланганнан соң, кайбер шигырьләрне ятлап алдым. Хәлфәнең буш вактын күзәтеп, аның өйрәтүен сорадым. Ул ихлассыз рәвештә бер мәртәбә өйрәтеп чыкты. Бу көнге көнем шуны укып үтте. Төшенүдән, аңлаудан гаҗиз калып берничә рәт яшерен генә җылап алдым. Магнәләрен рәтләп белмәсәм дә, шигырьләрне ятлап беттем. Ике көннән соң хәзрәт тагын чакырып, сабакны

тыңлатырга кереште. Калтырана-калтырана ятка укып чыксам да, магнәләренә килгәндә кәмә комга терәлде. Ләкин хәзрәт ачуланмады. «Яхшылап укырга кирәк, хәлфәң өйрәтсен», дип тагын да сабак бирде. Мин «Як хикаят» не бик зур авырлыклар белән бер ай эчендә укып чыктым. Шуннан соң хәзрәт мине сарыфка—«Шәрхе Габдулла» га төшерде.

Минем сарыфка төшүем, әтинең башын күккә күтәрде. Минем хәлфә булуым өметен тагын да якынайта төште. Ләкин әтинең бу шатлыгы озакка бармады: ул, мескен, мин мәдрәсәгә барган көзне аурый башлап, декабрь числоларында түшәккә егылды. Мин аның үләрен уйлый алмый идем. Тик болай гына аурыйдыр кебек булып күренә иде.

Бер көн иртәнге намаз вактында абзам килеп керде. Абзамның вакытсыз килүен күреп сискәндем, аның хәрәкәтен күреп шикләндем. Ул мине күргәч тә, әтинең бик авырайганын, үзенең мине алырга килгәнен сөйләде. Мин бер дә көтмәгән вакытта өйгә кайтуымны ишетеп шатлансам да, әтинең бик авыр хәлдә икәнен, «Ясин» чыгып калуларын ишетеп кайгырдым.

Без кайтып кергәндә, өйнең эчен кайгы, хәсрәт каплап өлгергән иде. Мин өйгә керү белән, әни кочаклап алды да, җылап та җибәрде.

Әти түр сәкедә хәрәкәтсез ята, өстенә ак нәрсә ябылган иде. Нишләргә белми аптырап киттем. Әтинең үлгәнен белеп, күземнән яшьләр тамчылап төшә башлаганын сизми дә калдым.

Әни:

— Әтиең, мәрхум, сине бик көткән иде, кайтып җитә алмадың!—диде дә тагын да җыларга кереште. Миңа әтинең йөзен ачып күрсәттеләр дә, күп үтми, күршегә алып киттеләр. Күршеләр мине иркәләп, төрле сүзләр белән юатып чәй эчерделәр.

Әтинең җиназасын укырга Хатыйп хәзрәт үзе килде. Төштән соң безнең өйгә бик күп халык җыелды. Өйгә сыймаганнары тышка чыктылар. Әтинең гәүдәсен сәкенең читенәрәк куеп, түргә муллалар менеп утырдылар.

Бу вакытта безнең бер колынлы бия белән бер атыбыз бар иде. Агай-эне һәм картлар атны фидиягә (үлекнең гөнаһларын ярлыкату өчен бирелә торган садака) бирергә киңәш иткәннәр икән. Шуның өчен мескен туры атны өйнең ишеге алдына китереп, йөгәненең тезгененә дилбегә бәйләп, ул дилбегәнең очын түрдә утырган мулланың

кулына китереп тоттырдылар. Әтинең бер ягына икенче мулла чыгып утырды да:

— Нургани Габделгаффар угылының бер еллык гонаһлары бәрабәренә, шушы фидияне кабул итеп алдыңмы?— дип, дилбегәнең очын әтинең гәүдәсе аша каршыда утырган муллага бирде. Ул мулла, дилбегәне алып:

— Қабул итеп алдым, һибә кылдым,—дип, кире бу муллага бирде. Бу мулла тагын югарыдагы сүзне кабатләды. Шулай итеп әтинең унбиш яшеннән алып, илле яшенә чаклы булган утыз сигез еллык гөнаһысы өчен, утыз сигез мәртәбә югарыда әйтелгән сүзләрне тәкрарладылар. Өйдәге кешеләр һәммәсе дә туксан тугызар мәртәбә тәсбих әйткәннән соң, Хатыйп хәзрәт:

— Әйткән тәсбихларыгызның савапларын Нургани Габделгаффар угылының рухына багышладыгызмы?—дип сорады. Һәммә халык бер авыздан: «Багышладык, хәзрәт, багышладык...» диделәр. Бу вакытта теге бүлмәдә утырган әни һәм башка хатыннарның җылау тавышы ишетелде. Тагын бер мәртәбә дога кылганнан соң, әтинең гәүдәсен күтәреп өйдән алып чыгып, мәчет янында җиназа намазы укыдылар. Шуннан зиярәткә алып барып, казылып куелган кабер янына куйдылар.

Бу чакта мин үзем җыламый, тик шунда абзыйларның калтыраган иреннәренә, кайбер картларның мыш-мыш җылауларына, иске каберләрне каплап киткән, сырланып, сырланып торган кар өемнәренә, кар өстеннән башларын чыгарып торган кырлы курайларның, җил белән селкенеп, ниндидер, моңлы тавыш чыгаруларына карап утыра идем. Қаберлек өсте чынлап та моңсу иде. Андагы һәрбер нәрсәдә фанилык галәмәте сизелгән, һәрбер әйбер үлем белән сугарылган кебек булып күренә иде.

Әтинең гәүдәсен күтәреп, тирән кабергә салдылар. Шул вакытта ул миңа, хуш буллашкан, саулашкан кебек, башын югары күтәргәнсымак булып күренде. Озак та үтмәде, төрле яктан ашыгычлык белән туң балчыкларны тупырдатып төшерә башладылар. Унбиш-егерме минут эчендә кабер өстенә кызыл балчык түбә кебек булып өелде. Бу балчыклар миңа якын, елы, мәхәббәтле булып күренделәр. Боларның һәрбер кисәге кирәкле, һәрбер бөртеге тиешле урынына салынган нәрсә булып, күз алдына килделәр.

Қүмү эше тәмам булды. Хәзрәт бик моңлы иттереп тәбарәк сүрәсен укыды. Қабернең дүрт почмагына дүрт

бара торгач, әнине зиарәт капкасыннан эчкә алып керег киттеләр.

Март уртасы җитүгә карамастан, зиярәтлек өстендә кар күп иде әле. Кояшка каршы яклары эрегән каберләрнең кызыл балчыклары, кабер казыган вакытта чыгарылган зур-зур кар кисәкләре әле дә булса күз алдымда торалар. Чөнки боларның һәрберсе үлем җырларын җырлаган кебек булып исемдә калган. Моннан өч ай ярым элек әтине ничек дәфен[1] итсәләр, әни дә шулай дәфен ителде. Ләкин бу югалту минем өчен бигрәк тә зур югалту булды. Мин үземнең соңгы таянычымнан да аерылган кебек хис иттем. Шул минутта әнинең мәхәббәтле карашыннан, аның елы күкрәгендә сакланган теләкләреннән бөтенләйгә аерылуымны искә төшердем. Без өйгә кайтуга әти дә, әни дә юк иде инде. Мин дә, энем дә бөтенләй ятим идек. Анда безне, аларның хәят сөреп киткән елы урыннары салкынайган кебек каршы алдылар. Мин өйдә бер генә дә ямь таба алмыйча, кире борылып чыктым да, азбар башындагы печән янына утырып, җылап җибәрдем... Күршеләр безне чакырып тагын да кунак итсәләр дә, болай кунак булуыбыз, хәсрәтнең башлангычы кебек, күңелсез бер нәрсә булып күренде...

Әни вафат булып дүрт-биш көн үтү белән безнең тормышта үзгәреш сизелә дә башлады. Безнең өйдә хатынкыз затыннан бер кеше дә булмаганга күрә, әйберләр тырым-тырагай ята башладылар. Идән карайды. Пич тирәсе чүп-чар белән тулды. Шушы хәлдән чыгар өчендер инде, кешеләр Нурислам абзыйга теге безгә килеп эшләп йөри торган Гыйлмекәй дигән хатынны алырга димләделәр һәм шул дүрт көн эчендә туй булып, ул безнең өйгә килен булып та төште. Ул безгә килү белән, бездә борынгы тормыш икенче төрлегә әйләнде. Энем белән мин чәйгә чакырылмый башладык. Чакырылсак та ашъяулыктан читтәрәк утырырга, чәйнең калдыгын эчәргә, әпәйне чамалап кына ашарга мәҗбүр ителдек. Чәй янында озаграк утырып, күбрәк ашый башласак, җиңгәй безгә ачу белән карый башлый иде. Шуның өчен өйдә ямь беткән кебек сизелде. Кайтып керәсе килми башлады. Берәр атна чамасыннан соң, бик күптән озатылган Фатыйма исемле апам килеп, бер көн кунак булу белән, аз-маз гына мирас малын бүлү хакында сүз чыгарды. Ул ике-өч көн торып, кайбер нәрсәләрне әти төсе, кайбер әйберне әни төсе дип, алып кайтып китте. Ике абзый арасында да сүзгә килү-

[1] Дәфен итү—мәет күмү.

ләр була башлады. «Бу өй синең, бу өй минем, келәт фәләннең, ат минә...» дигән сүзләр чыкты. Ниһаят авылның мулласы белән бер-ике карт килеп, вак-төяк нәрсәләрне бүлеп, һәрберебезгә исемләп киттеләр.

Абзыйлар, кыш буенча ауру карап, ике хәсрәтне бердән күреп вакыт үткәрү сәбәпле, рәтле кәсеп итә алмаганга, ике атның берсе әтинең фидиясенә бирелгәнгә, шуның өстенә электән саклык ашлык-фәлән дә булмаганга күрә, безнең тормышның мадди ягы да күзгә күренерлек рәвештә түбән китте.

Кар эреп, җир ачылып бозлар китү белән бәләкәй абзый, кайдадыр, эшкә чыгып китте. Мин, энем белән икәү, зур абзый белән җиңгәй кулында калдык.

Без борынгы җәйләрне шатланып каршы ала идек. Мин язның матур көннәрен, үзебезнең күрше малайлары белән бергә, авыл янындагы чирәмнәр уртасында җыелып калган кар сулары тирәсендә уйнап, аннан ары китеп, «Әче асты» дигән әрәмәлек буенда язның беренче чәчкәләреннән булган кәҗә сакалы, кәккүк башы кебек чәчкәләрне җыеп, кузгалак, юа кебек үләннәрне эзләп, кош оялары карап, аларның берсен беребезгә, берсен беребезгә билгеләп үткәрә торган идек. Авылның, үзебезнең яктагы кырлары, андагы агачларның һәрберсе безгә таныш иде. Без чирәм өсләрендә көн саен уйный, ул агачларның күләгәләрендә һәр көн утыра идек. Ул агачларда кычкыра торган кәккүкләр, ул таллар арасында сайрый торган сандугачлар безне шатландыралар иде. Алар безгә үзләшеп беткән кебек якын һәм дус тоелалар иде.

Җәй якынлаша төшкәч, кыр һәм болыннар яшел хәтфә кебек үләннәр белән түшәлеп беткәч, без тагын да еракка—Җилем буйларына, андагы «Иштуган тамагы» дигән җиргә балык тотарга, кармак салырга бара идек. Анда шомырт чәчкәләренең астында уйнап йөри, шундагы балыкчы куышында хәл җыеп ята, балыкчының улы белән балыкларны пешерә, шулай итеп көн узганын белми дә кала идек. Көн буе югалып йөргән өчен әти дә, әни дә орыша торган булсалар да, аларның бу орышлары зәһәрле, йөрәк әрнетә торган әсәр калдырмый торган иде.

Сабан вактында ат башында йөреп тырма тырматулар башта күңелсез кебек тоелса да, бара торгач, аның үзендә аерым бер ләззәт, рәхәтлек сизелә башлый иде.

Мин, печән вактында, чүмәлә тарттырып кибән куйганда, атның камыт бавына тагылган озын арканны сөйрәтеп чабарга бик ярата идем. Малайлар белән чабышып, сөй-

рәлгән арканнарга атларны бастырып арканны өздерүләр булса да, моның өчен зурлар тарафыннан сүзләр ишетсәк тә, бу кызыкны ташлый алмый торган идек.

Әз генә форсат чыгу белән җиләк җыярга китүләр, агач арасына кереп карлыган, шомырт җыюлар бигрәк күңелле иде.

Урак вакты, урак уруларда безнең өчен матурлык юк иде. Ул инде, яз һәм җәй башы уеннарына чик биргәнгә күрә, безгә күңелсезрәк күренә иде. Шулай да санап, тарап куйган кебек йомшак ашлыкларны «жит-жит» иттереп, мул-мул тавышлар чыгарып уруда күңеллелек сизелә торган иде.

Умарта кортлары бала аера башлагач, авылдан бер-ике чакрым җирдә булган умарта бакчасына барып көн үткәрү, күчләрне җыюда, агач башларына сарыган күчләрне тубалга тутырышуда әтигә ярдәм итүләр тагын да күңелле иде. Андагы кабыктан ясалган куыш, аның тирәсендәге коры умарталар, читлек, күзлек, тубал кебек нәрсәләргә без иләшеп беткән идек. Без анда көннең ни чаклы тиз үткәнен сизми дә кала идек.

Көзнең үзенә башка матурлыгы бар иде. Бакча җимешләре өлгереп безне үзенә тарта, без булган акчаны базар көненә саклап, ул нәрсәләрне алып кайтуны зур бәхеттән саный идек. Көз көннәренең иң кызыклы уеннарыннан булган чәкән-шар сугу бик күңелле була иде. Очып килгән шарның башка килеп тиүе, тәгәрәп килгән шарның аякка тиеп яңгыратуы да безне куркытмый иде.

Су өсте боз белән капланган көннәрдә, битләрне кытыклап торган җиңелчә салкыннарда көзге кебек ялтырап торган боз өстендә уйнаулар бигрәк тә күңелле була торган иде.

Бу яз мине шатлык белән каршы алмады. Мин дә, энем дә каты куллы җиңги кулында идек. Абзый күп вакытта өйдә тормаганга күрә, өйдә торса да, һәрбер эштә җиңги сүзен дөресләгәнгә, без җиңгинең зәһәрле күз карашы астында изелергә, аның ишарәсеннән башка һичбер нәрсә эшләмәскә мәҗбүр идек. Без элекке кебек теләгән чакта уйный алмый, борынгы иптәшләрнең уйнауларын читтән генә карап тора башладык. Форсат тапканда уенга катышып китсәк тә, шунда ук: «Кайтыгыз, башбаштакланып йөрмәгез!» дигән тавышны ишетә һәм шунда ук кайта идек.

Бара торгач, мин карышу юлын тота башладым. Мо-

ның җәзасы буларак кай вакытта икмәксез, ашсыз калсам да, абзыйдан каты сүзләр, җиңгидән:

— «Ятим бозау асрасаң—авызың-борның май булыр, ятим бала асрасаң—авызың-борның... булыр»,—дигән сүзне ишетсәм дә, мин инде алай бала гына түгел, мин үсеп килгән, яхшы укып йөргән бер шәкерт... аның сүзләренә әһәмият бирмәскә тели башладым.

Энемнең хәле миннән дә начаррак булса да, мин аны бик кызгансам да бер нәрсә дә эшләп булмый иде.

Язгы сабан кергәч, абзый, «Барыбер тик йөрисең» дип, мине үзебезнең авылның Кәлимулла дигән бер крестиянгә сабанга бирде. Ул заманда хәзерге кебек җыйнак тимер сабаннарның исме дә юк, һәркем зур һәм авыр булган агач сабанга дүрт ат җигеп, җирне шуның белән сөрәләр иде. Мин ат башында йөрергә һәм шул атларны карарга тиеш идем.

Сабанны арбага салып, бер атны җигеп, калганнарын җитәкләп Кәлимулла агай белән кырга киттек. Анда баргач, дүрт атны җигеп, мин төпкә җигелгән бер атка менеп, алдагы атларның дилбегәләрен тотып сабан сөрергә керештек. Бердән, сабанның көйсез булуы, икенчедән, дүрт атның икәвесенең яшь булып сабанга өйрәнмәгән булулары безнең эшне чиксез авырлатты. Атлар төрлесе төрле якка тарталар. Сабан җиргә керми, читкә тайпылып чыга. Шуның ачуыннан Кәлимулла агай карлау белән атларның кирәкләрен бирә, миңа карлау белән җибәрә. Авызга алмаслык сүзләр белән сүгенә. Тик икенче көнне генә эшләр рәтләнеп китте. Мин бер чирек дисәтинә тары өчен унбиш көн эшләп, сабан беткәч, тагын үзебезгә кайттым.

Бердән, өйдә икмәк ягы бик (такыр) булганга, икенчедән, әз генә тик торсаң да, «эшләп ашагыз» дигән сүзне ишетергә туры килгәнгә, энемне ияртеп, тал кабыгы суярга йөри башладым. Иртә үк китеп көн буе тал суеп, кояш түбәнәйгәч кенә, суйган кабыкларыбызны алып кайта, тал җыючы рус баена потын сигезәр тиенгә бирә идек. 15—20 тиен акча алып, шуның 5—6 тиененә күмәч алып, калган акчаны абзыйга, ул булмаса җиңгәйгә тапшыра идек. Бу эш бер ай чамасы дәвам итте. Чытыр арасында йөри торгач, безнең ыштан-күлмәкләр дә тузып бетте.

Чит җиргә эшкә киткән абзый кайткач кына бераз иркен тын алдык. Ул миңа да, энемә дә яңа түбәтәй һәм күлмәклек алып кайткан иде. Шушы ике яңа кием шатлыгыннан безнең бәйрәм дә күңелле үтте. Ул өйдә бул-

гач, безнең өстәге гадәттән тыш авыр булган нәзарәт[1] тә бераз йомшый төште. Ул өйдә булганда уйнарга да вакыт табылды. Ләкин бу шатлык тагын да озакка сузылмады, бу абзый быел көзгә солдатка каралачак булганга күрә, солдатка китеп калсам-нитсәм акча кирәк булыр дип, шуның өчен акча җыюны лазым[2] күреп, ун-унбиш көннән соң тагын да эшкә китте. Без тагын борынгыча ага-җиңгәй кулында калдык.

Мин хәзер тизрәк көз җитүен тели, көз җиткәч тә уку сылтавы белән мәдрәсәгә таюны өмет итә идем. Анда миңа ирек, якты тормыш ялтырап күренгән кебек була, анда миңа әллә нинди бәхет кочагын җәеп каршы алырга торган кебек күренә иде. Ирексез тормышлы җәйдән салкын кыш артык сизелә иде.

Ләкин әле көз түгел, печән өсте яңа керде. Эш кызды. Энемне ат башында йөрергә, мине печән җыярга чакыручылар күбәйде. Шулай итеп без кадерләнеп киттек. Ул һәр көн ике-өч тиен акча белән бер-ике йомырка алып кайта. Мин һәр көн унбиш тиен акчаны сугып кына торам. Агай һәм җиңгәй белән үзебезгә печән эшләүдән тыш, печән беткәнче биш сум акча эшләдем. Әлбәттә аның яртысын абзый алды. Калганын җыеп куйдым. Акча өстенә печән өстендә энемнең дә, үземнең дә тамак бик тук булды. Ашау турысында җиңгәйгә ялыныч калмады. Әлбәттә, эш бик җиңел түгел. «Ашаганда колагың селкенеп торсын, эшләгәндә кулың кулга тимәсен, алкыйсалкый йөрергә ярамый!..»—бик ныклап эшләтәләр. Эш авыр булса да, матур тугайда эшләү күңелле...

Урак вакты җитте. Абзый Җилем русы дигән авылның бер баеннан кыш көне: «Җәйгә урак урырмын» дип, берничә пот он алдан алып куйган икән. Урак җитү белән теге юан рус килеп җитте. Минем абзыйда алдашу юк иде. Шуның өчен, бер дә сүзсез өйне бикләдек тә, арбага әйберләрне төяп, уракка киттек. Анда безгә кунып-ятып урырга, караңгыдан башлап, караңгы төшкәнче эшләргә туры килде. Тик атнасына бер көн—базар көнне генә авылга кайта идек. Шулай рус ашлыгын урып, урак өстен үткәреп җибәрдек. Үзебезнең ярты дисәтинә тарыны иң соңыннан урып-сугып алдык. Хәзер кырда эш бетте. Авылда—ындырда ашлык сугу гына калды...

---

[1] Нәзарәт—күзәтү.
[2] Лазым—тиешле.

Көз җитте. Кошлар җәнүп ягына—җылы якка китә башладылар. Кыр казларының кыйгак-кыйгак кычкырып үтүләре, торналарның ике чатлы булып кычкыра-кычкыра китүләре миңа ни чаклы тәэсир иткәнен әле дә оныта алмыйм. Әле дә мин аларның шулай очуларын күргән вакытта, шул заманнан калган тәэссөр аркасында, күземә яшь килгәнен сизми дә калам.

Мин аларның ирекле рәвештә, үзләре теләгән якка очуларын күреп кызыга идем. Аларның бәхетләрен көнли, шулар кебек булуны, шулай чит илләргә китүне тели идем.

Көзнең соңгы көннәре дә җитә башлады. Күк йөзендә салкын болытлар йөзәргә кереште. Ләкин мин һаман китә алмый идем. Былтыргы бишмәт тузган, былтыргы пима тишелгән, оекларның табаны кырылган иде. Алай-болай йөри торгач, бу искеләр ямалды. Абзый ике тәнкәгә төшереп җилән тектереп бирде. «Урак урган хакымны бирмәделәр дип рәнҗемә» дип, ул җиләнне эш хакына куйды. Үземнең ике тәнкә акчаның беразына күлмәк алдым. Калганына аяк киеме рәтләдем. Мине үткән елгы кебек хәзерләп озатучы булмаса да, алай-болай әзерләнеп авылдан ычкындым.

Бердән, үткән ел бу мәдрәсәдә торып өйрәнгәнгә, икенчедән, өйдә энемнән башка мине сагынып яки мин аларны сагынып торырлык кеше булмаганга, быел мәдрәсә ямьсез күренмәде. Ул мине кочаклап алган кебек җылы тоелды. Аның һәр нәрсәсе миңа якын күренде. Мин барганда кар яумаган, мәдрәсәдә шәкертләр әз иде.

Мин өйдә калган уеннарның казасын монда үти башладым. Шәкертләр рәтләп җыелып бетмәгәнгә, хәзрәт көзге кунакка йөрүдән бушанып өлгермәгәнгә күрә, сабакка төшү дә ике-өч атнага кичекте. Баштарак азыкның әзлеге, акчаның юклыгы күзгә күренмәде.

Алып килгән азык бер атнадан соң бетте. Азык алырга кайтуның мәгнәсе булмаганга, аның артыннан йөрү бушка гомер уздыру булганга күрә, анда да кайтмадым. Шулай да бу атнада бер арыш икмәге белән дүрт-биш кадак тары ярмасы килде. Икенче атнада үзем кайтып, шул микдарда азык алып килдем. Өченче-дүртенче атналарда, «инде үлдем» дигәндә, берәр икмәк килеп, эчкә җылы кертте.

Барган саен көннәр салкынайды. Карлар яуды. Коры бишмәт белән генә авылга кайтып килүгә мөмкинлек бетте. Аннан да мине искә төшерүче, азык җибәрүче булмады. Тик онтылганда бер, берәр икмәк белән бераз тары ярмасы килә башлады.

Бүген ач кунылды. Икенче көнне шәкертләрнең—танышларның калган ашларын ашап, шуның белән көн үтте.

Мәдрәсәдә торырга бер дә рәт калмагач, азык алып (килү) теләге белән өйгә кайттым. Һәм азык алырга кайтуымны сөйләдем. Абзый: «Бер дә рәт юк бит әле. Әллә быел укуыңны ташлап торасыңмы?» дип, ипле җавап бирсә дә, җиңгәй:

— Укып мулла булмассың, чукып карга булмассың. Шул уку җитәр инде. Синең кебек малайлар байга кереп, эш эшләп акча табалар!—дип, мәсьәләне ачык куйды. Ләкин абзый:

— Хәзергә барсын, укысын әле,—дип әйткәннән соң, миңа ике арыш икмәге, бераз ярма, әз генә чәй белән шикәр биреп озаттылар.

Моннан соң мин дә, өйдән тәмам туенып торырлык азык көтеп торуның файдасызлыгын белдем.

Быел без сарыфны Әхмәтгәрәй исемле шәкерт белән (Таеш исемле авылның бер байның баласы иде) бергә шәрик[1] булып укый башласак та, ул миңа иярә алмаганга күрә, хәзрәт аны сарыф укудан туктатты. Мин тагы үзем генә укый башладым. Сарыфны миңа Фазлыттин хәлфә укытса да, атнасына бер-ике рәт хәзрәт үзе дә чакырып алып, тыңлата, бигрәк тә бай шәкертләрнең аталары килгәндә:

— Мәҗит килеп сабагын тыңлатсын әле,—дип, миннән фарсыча иглалны[2] ятка укыта иде. Мин хәзрәт каршысына утырып күзләремне йомып «зарәбә—язрибө» ның иглалын укырга керешеп китәм. Ятка иглал уку иң азында ярты сагатьләргә сузылып, мин укыганда хәзрәт рәхәтләнеп, елмаеп утыра, кунаклар хәйран калып торалар. Укып беткәч, хәзрәт:

— Тырышасың икән, рәхмәт!—дип, рәхмәт укый. Кунаклар.

— Ходай бу балага тел ачкычы биргән икән... Бу кем баласы?—диләр.

— Җилем-Каранның Нурый мулла угылы, бик тырыш

---

[1] Шәрик—сабакташ.

[2] Иглал — русча әйткәндә склонение була. *(М. Гафури искәрмәсе).*

бала. Хәзер ятим...—ди. Мин зур сабан туенда алдан килгән йөгрек кебек, шатланып урныма китәм. Теге кунаклрның кайберәүләре миңа биш-ун тиен садака биреп куялар.

Шулай минем уку ягы яхшы, азык мәсьәләсе барган саен авырлашты.

Әкренләп эш эзләргә, үзләре буй булып та тик йөрергә ярата торган шәкертләрнең самоварларын куярга, ашларын пешерергә туры килә башлады. Шулай итеп, аларның калган чәйләрен, калдык ашларын ашап көн күрергә керешелде. Башта бу эшләрне уңае килгәндә генә эшләп килсәм дә, бара-тора рәттән эшләргә, шул хезмәтләрне, көнлек хезмәтләр җөмләсеннән, лазым бер эш итеп алырга туры килде.

Моның өстенә, төрле бәхәсләр дәфтәре «Әмали[1]», «Кафия[2]» кебек нәрсәләр язып бирергә дә заказ кабул итә башладым. 16 битлек берәр нәрсәне 10 тиенгә яки ярты икмәккә, булмаса өч чынаяк өсте ярма яки берәр чирек чамасындагы май бәрабәренә язып бирә идем. Бу кәсеп шәп булса да бердән вакыт табуы кыен булганга, икенчедән, мин хәзер мөстәкыйл[3] урын ишгал итүдән мәхрүм ителеп (чөнки төрле кешегә хезмәт иткән ярлы шәкертләргә урын бирелми иде) җәмагәт сәкесендә торганлыктан, утырып язарга урын таба алмаганга күрә, бик күп уңайсызлыклар күрергә туры килә иде. Күп вакытта берәрсенең лампа яктысыннан файдалану уе белән, аларның өстәлләренең янынарак барып утырсаң, куып җибәрәләр иде. Бу эшкә намусланырга, кемгәдер ачуланырга теләсәм дә, кулдан килер чара булмагач, тәкрар пичь буена—үзебезнең самовар куеп йөрүче ярлы малайлар янына килеп, шулар белән бергә, түшәмдәге җәмагәт лампасыннан төшкән яктылыктан файдаланырга туры килә иде.

Быел 30 тиен җәмагәт акчасын түләү мәсьәләсе бик авыр булды. Аны түләү өчен әллә ни чаклы нәрсә язарга туры килде.

Тырышып укуның, күп язу өстенә, башкаларда эшләп көн күрүнең авырлыгы бара торгач файдалы булып чыкты. Бер кемнән дә яшерен булмаган минем авыр хәлне

---

[1] Әмали—китап исме.

[2] Кафия—китап исме.

[3] Мөстәкыйл урын ишгаль итү—аерым, бер үзенә бер урын биләү.

һәм тырышып диккат итеп барган Сафа хәлфә мине үз янына алды. Аның урны иркен булганлыктан, минем өчен бик яхшы булды. Аның өстенә монда эш тә әз иде. Ул шушы Үтәш авылыныӊ булганга, ашны өйгә кайтып ашый. Мин аңа көненә ике-өч рәт самовар гына куя идем. Ул мине чәй эчәргә дә үзе белән бергә утырта иде. Бу кешенеӊ миңа булган яхшылыгын мин әле дә такдир итәм, һич оныта алмыйм.

Быел көз минем бәләкәй абзый солдат хезмәтенә алынды. Аны озатып калу өчен, мине махсус килеп алдылар. Быел безнеӊ авылдан бер дистәдән артык егет соладтка алынган иде. Алар бер ай буенча авылда йөреп, китәр көннәрне бигрәк тә кызыклы вакыт үткәрделәр. Берсеннән-берсе таза булган бу егетләр, билләренә кызыл билбаулар буып, бүрекләрен кырын салып, урам буйлап җырлап һәм гармон уйнап йөргәндә картлардан башка кешеләрнеӊ исләре китә, аларның йөрүләренә хәйран кала торганнар иде. Китә торган көнне, пар-пар атлар җигеп, һәрбер чанага өчәр-дүртәр кеше утырып, туган һәм танышларына (барып) күрешеп йөрүләре, бер җирдән икенче җиргә барганда җырлап гармон уйнаулары бигрәк тә күңелле, шуның белән бергә бик моңлы булып күренде. Алар авылдан чыгып киткән сәгатьләрдә, бөтен авылда җанлылык кайнап торды. Аларның якыннары, аларның сөйгән кызлары—һәммәсе, һәммәсе башка вакытларда булмаган рәвештә озату хәзерлеге күрделәр. Бүген әллә ни чаклы аналарның күз яше түгелде. Әллә нинди сүзләр, вәгъдәләр бирелде. Аларның шул рәвешле тантана белән китүләрен күрү, алар кебек булырга кызыктыра, күңел шулар белән китүне тели иде. Болар авылдан киткәндә берничә пар белән бер юлы чыгып киттеләр. Аларның җыр һәм гармон тавышлары беразга чаклы ишетелеп торды. Алар авылдан чыгып киткәч, авылда ям һәм матурлык бөтенләй беткән кебек булып күренде. Һәр кемнеӊ бигрәк тә аларның якын туган һәм сөйгәннәренеӊ, йөзләрендә кайгы әсәре чыкты. Авылда тынлык һәм борынгы моңлы хәят башланды. Шушы хәлне күргәч, мин дә тизрәк Үтәшкә барып, борынгыча торуны уйлап мәдрәсәгә киттем.

Ул абзый да киткәч, миңа өйдән азык-фәлән килү тагы да сирәкләнде. Онтылганда бер әз-мәз нәрсә килсә дә, алар да рәтле булмыйлар иде.

Укуым борынгыча, шул заманга караганда шәп барды. Быел язга чаклы сарыфны укып чыктым. Яз якынла-

шып, кар эри башлау белән, мәдрәсәдәге шәкертләр таралып беттеләр. Мин өйгә кайтуны уйламый һаман шул Сафа хәлфәгә самовар куеп тордым. Мәдрәсәдә шәкертләр таралып беткәннән соң, берәр ай торгач, Сафа хәлфә дә үз эше белән өенә кайтты. Мәдрәсәдә ялгыз яту мөмкин булмаганга күрә, мин авылыма кайтып киттем.

1895 нче елның җәй көннәре авылда эшләү белән үтте. Тик кайбер көннәрдә генә Идел яки Җилем суы буена кармак салырга барып, андагы матурлык эчендә үткәрә идек.

Көз булгач, тагын да шул Үтәш мәдрәсәсенә барырга, тагын да шул ук бер төрле тормыш белән торырга, шул ук рәвештә тамак туйдыру ягын карарга туры килде. Быел нәхүдән «Кавагыйдел-играб»[1] ны укып чыктым, 96 нчы елның башындарак «Тәркип» кә төшеп, май башларында авылга кайттым.

Хәзер мин бераз үсә дә төшкәнгә, икенче яктан караганда, шул караңгы вакытның үзенә күрә ару гына укып йөри торган шәкертләре җөмләсенә кергәнгә күрә, борынгы артык кысынкылыктан бераз ычкынып, үзем мөстәкыйл йөри башлау дәверенә кердем. Шуның белән бергә, безнең өй эчендә миңа урын, елы почмак юк кебек тоела иде. Үзебезнең көн-күреш эшләре бик түбән булып, аны эшләү бик тиз беткәнгә күрә, быел да башка кешеләргә ялланып урак урырга керештек. Шундый эшләр белән йөри торгач, җәйнең үткәне сизелми дә калды.

Мин, буш вакытта булсын, эш белән булсын, кырда, урманнарда йөрүне ярата торган идем. Форсат булганда Җилем буена, Кызыл Яр асты дигән урыннарга кармак салырга китә идем. Андагы матур яр башларында йөрүләр, агач асларында утырып хәл җыюлар, андагы төрле кошларның сайрауларын тыңлаулар җанга шатлык, тәнгә рәхәтлек бирә торган иде.

Безнең тирәдә урман шәп булганга күрә, урманда йөрергә өйрәнгән идем. Быел җәй авыл хуҗалыгы эшләрен эшләү өстенә, абзый һәм башка берничә кеше белән Инҗәр буена, ниндидер бер рус баеның җиренә сала баш төшерергә бардык.

Озыннар исемдәге авылдан 15—20 чакрым җирдә булган, чиге күренмәгән, шәм кебек булып үскән матур юкә урманы сокланып карап торырлык иде. Абзыйлар шул озын һәм юан юкә агачларын бер дә кызганмый

[1] Кавагыйдел-играб—китап исме.

кисеп аударалар һәм тагын да уртага кисеп кабыкларын төшерәләр иде.

Мин алар төшергән зур юкә кабыкларын ике тәртәдән гыйбарәт агач өстенә салып, су буена китерә идем.

Абзыйның агач кисә торган иптәше кыска гына гәүдәле Мьһран исемендәге кеше булып, бу минем өчен бик начар булып чыкты. Һәр вакыт мине «булдыксызлык» һәм эштә йомшаклык белән гаепләп абзыйны котырта, алар икәүләп миңа ачуланалар иде. Һәрбер юлсыз, куе агачлык арасыннан, шундый авыр кабыкларны китерү бик авыр була, төрле борылмада агачларга эләгеп, кабыклар тәртәдән ычкыналар, мин боларны күтәреп сала алмаганга күрә, аларны чакырырга мәҗбүр булам. Бер яктан кигәвен һәм черкиләр чиксез күп булганга атны тыеп булмый. Йөзәрләгән кигәвеннең берьюлы талауларына чыдый алмый ат тыпырчына, качарга уйлый. Менә шул авырлыклар мине тиргәтергә сәбәп булалар.

Без бу газаплы эшне өч атна чамасы эшләп авылга кайттык. Күпме акча алганнардыр, ул як миңа караңгы калды.

96 нчы елның көзе җитте. Мәдрәсәгә барыр вакытлар якынлашты. Миндә бу җәйнең башыннан ук читкә китеп уку, Үтәштә ятып гомер әрәм итәргә ярамау фикре башта йөри иде. Мин инде Кыешкы дигән авылда бик мәшһүр мәдрәсә барлыгын, Уфада икенче төрле-яңа укытулар белән укыта башлаганлыкларын ишетеп белгән идем. Шул фикерләр буенча ничек кенә булса да шул мәдрәсәләрнең берсенә барырга карар бирдем. Ләкин минем алдымда ике эш бик зур маниг булып күренәләр иде: берсе, кулда бер тиен дә акча һәм өстемдә рәтле кием булмау; икенчесе, хәзергә чаклы үзеңне укыткан хәзрәтнең рөхсәтен алу. Ул вакытта үзеңне укыткан остазның рөхсәтеннән, аның фатихасыннан башка икенче мәдрәсәгә китү хәрам иде, ярамый иде. Бигрәк тә мин әтинең укырга җибәргән вакытта әйткән сүзләреннән аның,—«Хатыйп хәзрәттә укып кеше булып чык, аның рәхсәтеннән башка бер карыш та читкә чыкма!» дигән васиятыннан чыгарга курка идем. Хәзрәттән рөхсәт сорап мәшәкатләнүнең бушка китүен мин бик яхшы белә идем. Ул гаят кызу кеше булып, безнең тирәдә үз сүзен закон итеп йөрткәнгә күрә, аның алдында рөхсәт сорарга җәсарәт[1] итү дә мохальнең[2] берсе иде. Ләкин минем күңлемдә урынлашкан

---

[1] Җәсарәт—батырчылык.
[2] Мохаль—мөмкин булмаган эш.

читкә китү уе бу маниглырның һәммәсен дә җиңәргә тиеш булып күренә, шуңа карап, мин мотлак китәргә тиеш дип, уйлый идем.

Бу хакта күп уйладым. Бүрегем белән күп киңәш иттем. Ниһаят, ни булса да булыр дип, хәзрәтнең рөхсәтеннән башка китәргә, кием һәм акча юклыкка карап тормаска карар бирдем. Читкә китүемне абзыйга да әйтмәскә уйладым. Чөнки аның да бу эшкә каршы төшүе, минем чит җиргә китүемә маниг булуы мәглүм иде. Мин хәзер мөстәкыйл рәвештә хәрәкәт итәргә, үз иркем белән йөрергә тиеш идем. Шул карарны биргәннән соң, китәргә күңел беркетеп, форсат көтә башладым.

1896 нчы елның сентябрь башлары иде. Мин югарыдагы карарым буенча, аяз һәм матур бер көнне, кулъязма «Тәркип» белән дәфтәрләремне, тагын бер-ике китабымны яшереп кенә капчыкка тутырдым. Кулда булган 15 тиен акчаның биш тиененә бик шәп, өр яңа чабата алып кидем. Иске җиләнемне киеп, кызыл башлы тастымал белән билне бәйләдем. Чабатадан калган «ун тиен көмеш» акчаны капчык төбенә җибәрдем. Юлда эчеп барырга чәй-шикәр, ашарга икмәк әләктереп булмады. Ул нәрсәләрнең минем өчен артык кирәге дә юк иде. Чөнки мин бүген унике чакрым җирдә булган авылдагы апа тиешле кешегә барып кунарга, аннан соң, икенче көннее, 25 чакрым җирдәге Олы Күл авылындагы бер туган апама барып кунарга туры килгәнлектән, миңа икмәк һәм чәйнең тиз генә кирәге юк иде. Аннан ары тагын юнен күрермен дидем.

Хәзерлек тәмам булганнан сон, капчыкны култык астына кыстырып, бер кемгә дә белдерми, ындыр артына чыктым. Аннан урап, авылның икенче башында тора торган әти белән бер туган Кәримә исемле апама кердем. Мин аны никтер якын күрә идем. Ул миңа һәр вакытта җылы йөз күрсәтә, күңелендә булган апалык мәхәббәтен изһар итә, минем янган күңлемне үзенә җәлеп кыла[1] торган иде.

Ул мине капчык тоткан, билләр буып юлга хәзерләнгән бер хәлдә икәнемне күрү белән аптырап китте булса кирәк:

— Балам, кая китәргә хәзерләндең?—диде.

---

[1] Җәлеп кыла—тарта.

Мин үземнең, качып, читкә, Уфага яки Кыешкыга мәдрәсәгә баруымны сөйләдем. Ул, әлбәттә, каршы төшмәде. Тиз генә урыннан торып, ярты икмәк белән бераз гына чәй-шикәр китереп, минем капчыкка салды.

Мин анда озак утырмый, апам белән исәнләшеп чыгып китү юлын карадым. Ул мине кочаклап үпте, дә күзләрендә яшь булганы хәлдә,

— Хәерле булсын, балам,—дип, күрешеп, озатып калды.

Апалар янындагы тыкрыктан тагын да ындырлар артына чыгып, Уфа ягына китә торган олы юлга барып төштем. Үзебезнең авылның кырларын, әрәмәлекләрен үтеп китү, алардан аерылу бик кыен төсле булды. Мин бит бу кыр, бу басуда сабан сөргән, тырма тырмалаган, утаулар утап, ураклар урган идем. Мондагы җир өсләре, алар арасыннан үткән вак-вак юллар, тар сукмакларның һәрберсе миңа таныш иде. Бу әрәмәлекләрнең һәрбер өемендә дип әйтерлек йөргән, аларның җимешләрен җыйган, алар арасында хәл җыеп утырган идем. Ат белән куна барган вакытларымда бу тирәләрдә кунып, малайлар белән җырлашкан яки үзем генә калып, ялгыз җырлаган чакларым күп булды. Бу агачлыкларның һәммәсе дә миңа якыннар, кечкенә вактымда ук миңа танышлар иде. Әнә теге зур ялбыр каенның астында бер вакытта җырлап утырган идем, әнә теге әрәмәнең уртасында утырган зур юкә агачына без үткән ел умарта күтәргән идек. Әнә теге имәннең астында мин күңелсезләнеп утыра-утыра җылаган идем. Анда әти белән әни үлгән елның җәй көнендә күп вакытлар була торган идем. Әнә теге бик ерактан күренеп утыра торган зур тирәкне без, бөтен тирә якның иң зур агачы дип, мактый идек. Мин аның шул чаклы юан, шул чаклы озын, мәһабәт булуына кызыга идем. Менә бу кечкенә күлне без төпсез дип атый, аның янына барудан саклана идек. Әнә теге Акчарлак буе дигән озын сазлыкларның озын камышлары арасында аждаһа җыланнары бар дип йөргәнгә, ялгыз-ярым түгел, бер өер булсак та аның янына барудан саклана идек. Шуларның яннарыннан үткәндә күңлем нечкәрә бара, мин аларга моңланып караган саен, алар миңа каршы әллә ниләр сөйләгән кебек була иде. Мин боларга бер генә түгел, кат-кат карый, караган саен, башка төрле бер нәрсә укый, мин аларны кызгансам, алар мине кызганган кебек булып күренәләр иде.

Үз авылыбыз җиренең чиге булган «Күк ял» дигән җиргә җиттем. Монда безнең үзем белгәннән бирле чабып килгән чабынлыгыбыз бар иде. Монда быел гына бик зур итеп кибән куйган идек. Монда җиткәч, шушы кибән янына хәл җыярга утырдым. Бу җирдән безнең авылның мәчет манаралары гына күренә иде. Без бу җирдә әти бар вакытта да печән җыеп, кибәннәр куя торган идек. Шуларның барсы да күз алдына килде. Үткән вакытлар, андагы хәрәкәтләр, эшләгән эшләр—һәммәсе гәүдәләнде. Күңел нечкәрде. Япа-ялгыз китеп баруымны уйладым. Мине озатып калучыларның юклыгы, алга алган юлымда ялгыз баруым күз алдыма килде. Бу юл авыр да, җиңел дә кебек булып тоелды. Мин бу җирдән торып китә алмый, соңгы мәртәбә исәнләшү сүзләрен әйтергә батырчылык итә алмый байтак утырдым. Кояш та яхшы ук түбән төшкәнен, алда бик зур кара урманны чыгарга кирәк икәнен, бүген барып куна торган авылга сигез чакрымнар чамасы җир барлыгын, Идел аркылы чыгып китәргә тиешлеген уйлап, урнымнан тордым да, артыма бик сокланып бер карап алганнан соң, алга таба атлап киттем.

Алдымда, «Мәндем урманы» дигән урман тора иде. Бу урманда караклар тора имеш, алар ялгыз-ярым йөргән кешеләрне үзләре янына алып, караклыкка өйрәтәләр имеш, дигән сүзләр бик күптән башка сеңдерелгәнгә күрә, мин бу урманны исән-сау үтүдән өмет өзеп киттем. Өч-дүрт чакрымга сузылган бу урманны чыккан вакытта бөтен көч белән алга киттем. Һәр минут саен артка, уң һәм сулга карый идем. Куе агачлар арасында кемнәрдер күренеп калган кебек була, алда кеше көтеп торган кебек булып тоела иде. Күпер тирәләре бигрәк тә хәвефле булып, аннан үтү бигрәк тә куркыныч иде.

Төрле уйлар белән яныл-пешеп йөгерә-атлый торгач, Идел буенa якын зур, бик зур болынга барып чыктым. Үлемнән котылган кеше кебек иркен тын алып, хәл җыярга утырдым.

Их, матур соң бу болыннар, киң тугайлар!.. Монда нинди тынлык, нинди матурлык!..

Мин бу киң тугайда тирә яклардагы төрле агачларга, алар өстенә төшкән көзге кояшның яктысына карап утыра торгач, үземнең иркенлеккә чыгуымны, теге үзем кызыгып кала торган кыр казлары, торналар кебек читкә китүемне уйлап шатланып киттем.

Шул уйлар белән гайрәткә килеп урнымнан тордым да, тагын алга атладым. Әз генә баргач та, артымнан арба

тавышы ишетелде. Гади арбага пар ат җиккән бер кеше бик шәп итеп артымнан килеп тә җитте. Аңа юл биреп калыр өчен юлдан читкә чыктым. Ул минем турыга килеп җитү белән атларын туктатып:

— Әй, егет кеше, кая барасың?—дигән сөальне бирде.

Мин үземнең укыр өчен Уфага баруымны сөйләп бирдем. Ул бер дә икеләнеп тормый:

— Әйдә, утыр менә монда, мин дә Уфага барам. Булмаса, үзеңне пар ат белән алып барып ташлыйм, — диде.

Мин бер сүз дә әйтми, шунда ук сикереп арбага менеп утырдым. Калага баргач, атларга ашатырга дип алган печән өстенә утыргач, селкенеп куйдым. Ул мине сораша башлады. Минем этине белә икән, бер яктан безгә кода булып чыкты. Бу безгә унике чакрым җирдәге Бурлы авылының байларга йөк ташый торган бер кеше икән. Үзе бик егетсымак күренә. Мине утырткач, атларына чыбыркысын селтәү белән, атлар шәбәеп киттеләр. Ике туры ат җилдерәләр генә!..

Шунда ук Иделгә җиттек. Иделне паром белән чыктык та, тагын киттек. Юлда үземнең бер туган апам торган Олы Күл авылына да туктамый үтеп киттек. Кайсыдыр бер авылда куныл, иртәнгесен төш уртасында Уфага да барып кердек...

«Уфа каласы» дип, авыз сулары корып сөйләгән Уфалары шушы икән!.. Чынлап та, ис китәрлек зур. Мин монда кереп, урам буйлап бара башлагач, өйләрнең зурлыкларына, матурлыкларына, урамнарда йөргән кешеләрнең күп һәм һәммәсе дә яхшы киемнәр киенгән булуларына аптырап киттем. Юлда килгән чакта бу агайның атлары да лачын кебек киләләр иде. Монда килгәч безнең атлар кеп-кечкенә төсле күренделәр. Хәлсезләнгәнсымак булып калдылар. Шәп атлар безне уңнан да, сулдан да узалар да китәләр. Без әкренләп кенә бер урам белән һаман югары менүдә дәвам итәбез. Ни чаклы барсак та урамның башына чыгып булмый. Мин матур йортларга, урамның ике ягыннан сузылган исәпсез күп тимер чыбыкларга карап барам. Йортларның тәрәзәләрен, чыбыкларның ничә рәт икәнлекләрен саныйм.

Бик күп барганнан соң, сул якка борылып, бер катлы йортның ишек алдына барып кердек, теге кеше атларны тугарып бәйләде дә, мине чәй эчәргә алып кереп, «ак калач» белән бик шәпләп сыйлады. Чәй эчеп бетү белән, бу кеше, үзенең эшләре артыннан, базарга чыгып китте.

Мин аның белән күрешеп, рәхмәт әйткәннән соң, Госмания мәдрәсәсен эзләп чыгып киттем.

Әй барам, әй барам, кая барганымны, кайсы урам белән барырга тиеш икәнен үзем дә белмим. Урамдагы кешеләр руслар да, рус хатыннары кебек булганга күрә, сорар кеше дә тапмыйм. Бара торгач, шәһәрнең бер ачык мәйданына (хәзерге көнне 2 нче кызлар гимназиясе булып, соңгы вакытларда рабфак булган урын: ул вакытта бу бина бөтенләй юк иде әле) барып чыктым. Шушы җирдә бер «мөселман» агайны очратып, мәдрәсәи Госманияне сораштым. Мин бөтенләй кире якка киткәнмен икән. Госмания артта калган икән. Бу кеше миңа юл өйрәтте. Аның күрсәткән урамы белән тагын да түбән таба карап төшеп киттем.

Әй барам, әй барам!.. Бара торгач, бик зур бер бакчага барып чыктым. Бу бакчага рәттән тезелеп эре каеннар һәм юкә агачлары утыртылган иде. Бакчага керергә курыктым да, бакча буйлап тагын түбән төшеп киттем. Бераз баргач, уртасына агачлар тезелеп, бакча утыртылган урамга барып кердем. Бакчаның уң ягына төшеп, таш җәйгән канау буеннан бара идем.

— Эш хәрап!..

Нак миңа каршы яктан Хатыйп хәзрәт килә!.. Ул мине күрә калса, ай-ваема куймый алып кайтуында һичбер шик вә шөбһә юк. Калтырап төштем, артка йөгерергә уйладым, күреп калуыннан курыктым. Каршы барып булмый. Инде нишләргә кирәк?.. Ара бик якынлашып килә. Алайболай карандым да, алдымда торган канау аркылы салынган күпернең астына кердем дә киттем. Минем бәхеткә каршы бу канау тирән, күпер асты киң һәм коры иде. Күргән кешеләр нәрсә уйлаганнардыр, ансы миңа мәгълүм түгел; әмма үземнең башка мондый зур гакыл килеп төшүенә һәм теге хәзрәтнең каты кулыннан котылуыма бик шатландым.

Хәзрәтнең үтеп китүенә канәгать хасыйл итәрлек вакыт күпер астында ятканнан соң гына канаудан баш калкытып карадым. Ул инде, мине узып, байтак җир киткән иде. (Бу күпер духовный собрание, дин Мөхәммәдия тәдбирендә булган казаханәнең капка күпере була). Мин шатлыгымнан нишләргә белми, тиз генә торып, мәчет капкасы турысына килеп җиттем. Анда ахшам намазыннан чыгучылардан мәдрәсәне сорап, шул ук минутта мәдрәсәгә барып кердем.

Сентябрь числосы булып, гадәттә татар шәкертләре җыелырга иртә булуга карамастан, мәдрәсәдә шәкертләр байтак күренә иде. Мин әллә ничә мәдрәсәнең кайсысына керергә белми бераз аптырап тордым да, аруырак күренгән биналарга керергә кыймый, бер читтәрәк торган һәм бинасы искерәк булган бер мәдрәсәгә кердем[1]. Монда ахшам намазыннан кайткан шәкертләр тәбәнәк өстәлләр тирәсенә җыелып, төркем, төркем чәй эчеп утыралар иде. Мин ярты көн буенча күтәреп йөргән капчыгымны ишек төбенә куеп, шул җиргә хәл җыярга утырдым. Башта миңа илтифат итүче булмады. Тик бераз торганнан соң гына, шунда чәй эчеп утыручы шәкертләр минем кем һәм кайдан килгәнемне сораша башлап, мине үзләре янына чәй эчәргә утырттылар. Алай-болай сорашканнан соң, сүз нәрсә укыганыма күчте. Сарыф бәхәсләре белән сүз көрәштерә башладык. Болар бик тирән бара алмадылар. Боларның чамаларын сизеп алгач та, иркенләп киттем. Эчемнән генә, боларның уку дәрәҗәләрен, Уфада торсалар да, «нечкә» бәхәсләргә көчләре җитмәүләрен уйлап алдым. Шуңа карамастан, кайберәүләре бик эре кыланалар иде. Боларның киемнәре яхшы булып та, уку эшенә килгәндә «әҗвәф»[2] булуларын күреп, боларга каршы күңлемдә, «Эш кием белән генә булмый шул...» дигән уй туды.

Әйберләремне шушы чәй эчкән якташлар янына калдырып башка мәдрәсәләрне карап йөрдем. Минем кебек авылдан яңа килгән бер малай өчен, әлбәттә, шәһәрнең мәдрәсәләре, хәлфәләре һәм шәкертләре дә бик мәһабәт, бик югары булып күренә иде.

Ястү җиткәч, мәчеткә намазга бардым. Мәчетләре чынлап та бик шәп икән! Кешеләр дә бик мәһабәт булып күренделәр.

Ястүдән соң дәресханәләренә кереп, хәзрәтнең дәрес биргәнен карап утырдым. Хәйрулла хәзрәт Госманов гакаид[3] дәресен бирә иде. Дәрес бик мәһабәт һәм шәп күренде.

Аның дәрес бетергәнен көтеп утырып, дәресен тәмам иткәннән соң, күрешергә теләсәм дә ул артык илтифат күрсәтмәде. Тик кулын биреп, күзе белән карамый,

---

[1] Ул вакытта хәзерге көндәге таш мәдрәсә юк иде. Бәлки аның турында һәм ишек алдында аерым-аерым биш-алты кечкенә агач мәдрәсәләр иде. (*М. Гафури искәрмәсе*).

[2] Ә җ в ә ф—куыш эчле (ягни надан).

[3] Г а к а и д—иман дәреслеге.

әллә кем белән сөйләшкәне хәлдә үтеп китте. Аның бу эрелеге, үзенең мәдрәсәсенә укырга килеп тә сүз дә кушмый үтеп китүе, күңлемдә рәнҗү катыш ачу тудырды. Ләкин андый зур һәм галим кешегә каршы ачулану һичбер яраган эш булмаганга күрә, мин аңа каршы туган үземдәге ачуга үзем дә аптырап киттем. Шулай да ул кеше минем күңлемдә каты багерле, тәкәббер бер кеше булып гәүдәләнеп калды.

Ул чыгып киткәннән соң, кемдер шунда диварга эленгән зәңгәрле, яшелле, төрле буяуларга буялган, аркылыторкылы сызыклар сызылган ашъяулык зурлыгындагы кагәзгә карап, бик матур киенгән дүрт-биш балага, әллә нәрсәләр өйрәтергә кереште. Мин бу шәкертләрдән бигрәк тә, үз гомеремдә күрмәгән һәм ишетмәгән бер нәрсәгә карап «сабак» укуларына һәм диварга эленгән кагәзгә кызыктым, бик сокланып читтән карап тордым. Ләкин бераз торганнан соң, укытучы кеше мине күрде дә:

— Монда нишләп торасың? Бар, чыгып кит!—дип, чыгарып җибәрде.

«Бу нәрсәне, күрәсең, күп акча бирә ала торган бай балалары гына укый торганнардыр», дип уйладым да ишек алдына чыктым. Ләкин чабатамның үзем куйган урында булмавы мине аптырашта калдырды. Әллә берәрсе минем чабатамны алып киткән, әллә мондагы ару урында чабатаның ятуына ачуланып, чыгарып ыргытканнар. Маглүм түгел. Ишек алларын, кәштәләрне, болдырларны карап беткәннән соң йорт алдына чыктым. Берәрсе алып ыргыткандыр уе белән шул тирәне карарга керештем. Ишек алды уртасында янып торган фонарның аз-маз гына төшкән яктысы чабатаны эзләргә ярдәм итә иде. Минем бәхеткә каршы, чабаталар табылды. Берсеберсеннән берәр сажен чамасында, аерылып, киндерәләрен сузып, берсе йөз түбән, берсе чалкан ята иде.

Күрәсең, ямьсезләп торган чабатаны берәрсе чыгарып ташлагандыр, дип уйладым да, тиз генә утырып киенеп алдым.

Теге үземнең капчыгым калган мәдрәсәгә кереп, ишек төбенә утырып чабаталарны чишендем дә, аларны бик нык урынга, кеше күрмәслек җиргә яшереп куйдым. Үзем ишек төбенәрәк утырып, мәдрәсә гражданнарының йөрешторышларын карый башладым. Шәкертләрнең кайберсе чәй эчә, кайберәүләре сөйләшеп утыралар, кайберәүләре үзләренең сабакларын укыйлар иде. Монда минем күң-

лемне җәлеп итәрлек бер нәрсә дә күренмәде (Бу вакытта Хәйрулла хәзрәт Госмановның ысулы җәдиднең ибтидаи дәрәҗәсен гамәлгә куеп маташуы, бу ысулны ибтидаи шәкертләрдә тәдбыйк[1] итеп, зур шәкертләрне һаман иске юл белән гакаит, мантыйк[2], хикмәт[3], «Фиккыһе[4]» укыткан вакытлары булган икән).

Мин бу шәкертләр белән бераз сөйләштем. Һәр сүздә, һәрбер эштә акчасыз яки азыксыз торуның мөмкин түгеллеге күренә иде.

Шулай ишек төбендәрәк утырганда, бик мәһабәт бер хәлфә кереп шәкертләр белән бераз сөйләшкәннән соң, миңа күзен салды. Ул үземнән түгел, бәлки башкалардан:

— Бу нинди малай, нишләп йөри?—дип сорады.

Аларның җавапларын көтеп тормый, үзем сүз башлап, кайдан һәм ни өчен килгәнемне сөйләдем.

Җәкре зур борынлы, үткер күзле, зур тупас гәүдәле бу кеше бераз тыңлап торганнан соң, минем акчам юклыкны һәм азык җибәрә торган кешеләрем булмауны белгәч,

— Алай булгач, сиңа монда тору авыр булыр,—диде.

Килгәннән бирле җилнең һаман каршы яктан исүе минем күңлемдә бу мәдрәсәдә торуның мөмкин түгеллеген тудыра башлады.

Иң яхшысы Кыешкы авылына барып, авыл мәдрәсәсендә эшләп тамак туйдыру, шул рәвешле укуны дәвам иттерү икән, дигән бер фикергә килә башладым.

Шәкертләр ята башладылар. Мин дә утырган урнымда чишенеп, баш астына бүрегемне салып, өстемә җиләнемне ябынып, как идәнгә ятып тирән уйга баттым... Бик озак ятканнан соң гына йокыга киткәнмен...

Иртә белән башка шәкертләрдән иртәрәк уяндым да, тиз генә киенеп, чабаталарны карарга чыктым. Алар үзем куйган урында тыныч кына торалар иде әле. Күп уйлап тормый, капчыкны чишеп, туйганчы икмәк ашадым да, үзем утырып килгән теге күрше авыл кешесен эзләп чыгып киттем. Уфага килүем муафәккыятле чыкмады, бу җир—мин үсә торган җир булып күренмәде.

Минем бәхеткә каршы, теге кеше китмәгән икән әле. Мин аңа үземнең кире Кыешкыга (Уфадан 20 чакрымда)

---

1 Тәдбыйк итү—яраклаштыру.
2 Мантыйк—логика.
3 Хикмәт—философия.
4 Фиккыһе—китап исме.

кайтырга теләвемне, монда акчасыз торуның мөмкин түгеллеген сөйләп, үземне Кыешкыга чаклы бергә алып кайтуын үтендем. Яхшы кеше икән, бер сүзсез утыртып алып кайтырга вагдә бирде. Һәм, атларны карап торырга кушып, үзе базарга чыгып китте.

Кесәмдәге ун тиен акча төгәл көенчә тора иде әле. Шәһәргә килгәч, берәр тәмле нәрсә алып ашамый китүне күңел күтәрә алмады. Урам кибетенә барып кердем. Төрле ашамлыклар күзне кызыктырып, тамак төбен кытыклап торалар иде. Күп уйлап тормый, ике тиенлек чия, өч тиенлек калач алып кердем дә, арба өстенә кырын ятып, ашап алдым. Күңел ачылып китте.

Озак тормый теге кеше дә кайтты. Ул тагын чәй һәм ак калач белән сыйлап җибәрде.

Чәйдән соң атларны җигеп, Уфадан чыгып киттек. Өч-дүрт сәгәт эчендә Кыешкы авылына барып та кердек.

Кыешкы авылы Уфа һәм безнең тирәдә үзенең данлыклы мәдрәсәләре, Кышкар мәдрәсәсенең Уфа вилаятендәге бер шагбәсе[1] кебек, мантыйк һәм гыйлмекәлам[2] фәннәрен шәп укытуы белән мәшһүр. Монда укып чыгып мулла булган кешеләрне йөзәрләп санайлар. Шулар җөмләсеннән минем борынгы укытучым Хатыйп хәзрәт тә шушы Кыешкы мәдрәсәсендә укып, зур «галим» булып чыккан. Әлхасыйл, минем монда килүем бик үк урынсыз эш түгел.

Зур гына мәйдан тирәсенә дүрт-биш агач мәдрәсә салынган. Кыш көннәрендә боларның һәр берсендә шәкертләр шыгрым тулы булалар. Мәчет турысына җиткәч, мин теге кешенең арбасыннан төшеп калдым. Мәдрәсәнең мөдәррисе булган Мирсәяф хәзрәт ахшам намазында икәнен белеп, аның намаздан чыкканын көтәр өчен, мәчет алдындагы бүрәнәләр өстенә утырдым.

Иң элек шәкертләр, аннан соң хәлфәләр чыгып мәдрәсәгә юнәлделәр. Алар чыгып берәр ун минут торгач, Мирсәяф хәзрәт чыкты. Мин аны үзебезнең авылга кунакка барган вактында күргән идем. Шуның белән бергә, аның әтиемне белгәнен дә белә идем. Мин дә бик тиктәс кешенең баласы түгел. Үзем дә бераз укыган шәкерт дигән уй белән, хәзрәткә каршы барып, тагзим[3] кылып сәлам бирдем.

---

[1] Шагбә—бүлек.
[2] Гилмекәлам—дин фәлсәфәсе.
[3] Тагзим кылып—олылап.

Ул туктальп кайдан килгәнемне, кем улы икәнемне сорашканнан соң, мәдрәсәгә барырга кушты. Шуннан үтеп баручы бер шәкертне чакрып, үзебезнең авылдашларым янына алып барырга әмер итте. Мәдрәсә һәм андагы шәкертләрнең бик күбесе миңа бик мәһабәт булып күренделәр.

Авылдашлар якты чырай белән каршы алып, шунда ук чәй янына чәйгә утырттылар. Бу авылдашлар элек үзебезнең авыл мәктәбендә, минем белән бергә укыганнар иде. Шуның өстенә, без яшькә дә бер чама булып, байлык ягыннан аерма булмаса, башка яктан аерма юк. Бәлки минем укуым боларга караганда алдарак икәнен белә идем. Шуның өчен мин боларны күреп бергә чәй эчәргә утыргач, үземне, үзебезнен авылдагы мәктәптә кебек хис иттем. Соңра монда, безнең Үтәш мәдрәсәсендәге кебек, простойлык бар иде. Минем өчен бу ягы бигрәк шәп булып төште.

Монда тормыш бик кызык күренде. Зур сакаллы, картаеп беткән (шәкертләр) белән яшь кенә шәкертләр бер үк урында торалар, шунда мыж киләләр иде.

Мондагы укуның тәртибе дә миңа бик маглүм булганга күрә, ул якларын уйлап баш ватасы юк иде.

Ястүдән соң, Мирсәяф хәзрәт шушы мин кергән мәдрәсәгә дәрескә керде. Ул кергән вакыттагы тынлык, аңа булган хөрмәт, аны тәгзим белән каршы алу, ул утыра торган урынга өелгән мендәрләр—искиткеч иде. Ул бик мәһабәт кереп, үзенә хәзерләнгән урынга аякларын бөкләп утырды. Соңра, һич кемгә карамастан, кесәсеннән күзлеген алып аппак яулык белән сөртеп, ике кулы белән күзлекнең ике канатыннан тотып, киеп алды. Ул шул эшләр белән мәшгул булганда, төрле мәдрәсәләрдән зур-зур сакаллы шәкертләр, кулларына зур-зур китаплар тотып, хәзрәткә каршы ярты хыйлка—түгәрәк булып тубыкланып утырдылар да, китапларын ачып куйганнан соң, хәзрәтнең әйтәчәк сүзләренә монтазир[1] булган кебек, аңа таба карадылар.

Хәзрәт күзлеген киеп, тагы да бер рәт кузгалып, рәтләп утырганнан соң: «Мулла кем, гыйбарә[2] укы!» дип, берәүгә карап ияк какты да, башын түбән салды.

«Мулла кем» әгүзе, бисмилла укыганнан соң, ниндидер бер кечкенәрәк китаптан өч-дүрт кенә җөмлә укыды

---

[1] Монтазир булу—көтеп тору.

[2] Гыйбарә—дәреслектәге җөмләләр.

да, туктап, башын күтәреп, хәзрәткә карады. Хәзрәт тагын да бераз тын торганнан соң, ниндидер, мин белмәгән, сүзләрне сөйләп китте. Аның гаҗәп оста сөйләвенә сокланып:

— «Искиткеч галим икән!»—дип, шак катып утырам. Шул өч-дүрт җөмлә хакында, әллә шәт, ике сәгать сөйләгәндер.

Сирәк-сирәк кенә зур хәлфәләр дә сүзгә катышып куялар... Аңа каршы яктан бер зур мыеклы мәһабәт хәлфә: «Ланөсәллим![1]..» дип кычкырып, моңа каршы төшеп китә. Бу вакытта хәзрәт елмаеп карап утыра да, аларның сүзләре беткән кебек булгач, үзе сүз башлап, такрир[2] һәм изахәт[3] биреп алып китә. Мин аның «Галламәи-Тәфтазани», «Мирсәет Шәриф», «Ибене-Сина»[4] дигән сүзләрен ишетеп, аңлаган кебек булып калам. Хәзрәтнең бу чаклы шәп сүзләренә һич туктап тормый сөйләвенә аптырыйм.

Ике-өч сәгаттән соң дәрес бетте. Зур шәкертләрнең кайберәүләре, китапларын култык асларына кыстырып, чыгып китә башладылар.

Мин монда бигрәк тә бер арыграк, озынча буйлы, ачрак яңаклы үзе яшьрәк кенә хәлфәгә исем китте. Ул бик күп катышуы өстенә, хәзрәт тә бик күп сүзләрне аңа карап сөйли иде.

— «Их, шуның кебек шәп булсаң иде...»—дим эчтән генә.

Хәзрәт шул ук, мин сокланган хәлфәгә карап:

— Мулла Мотаһһар, син бу шәкертне дә укыт инде, ул безнең мулла Хатыйпта сарыф укып, нәхүгә төшкән икән,—дип, мине күрсәтте. Һәм сүзендә дәвам итеп, миңа таба карап:

— Синең исмең ничек, «Тәркипне» күп укыдыңмы?— дип сорашты.

Мин башта калтырап киттем. Бөтен шәкертләр миңа таба карадылар.

— Исмем Мәҗит. Әлхәмденең тәркибен укып беттем,—дидем.

— Алай булса, менә шушы хәлфәдән укырсың. Бик нык тырыш. Без дәресенә тырышкан иҗтиһадлы[5] шәкерт-

---

[1] Л а н ө с ә л л и м—бирелмим, үз сүземдә торам.
[2] Т а к р и р—сөйләп аңлату
[3] И з а х ә т—аңлату
[4] Г а л л ә м ә и—Тәфтазани, Мирсәет Шәриф, Ибене-Сина—борынгы атаклы галимнәр.
[5] И җ т и һ а д л ы—тырыш.

ләрне яратабыз,—диде. Мин аның сүзләрен, башымны кагып, тәсдыйк итеп кенә утырам. Эчемнән шатланам. «Эш пеште, юлым уңды», дип уйлыйм.

Тик аның:

— Сине тәрбия итүче, азык җибәреп торучы бармы соң?—дип соравы, миңа җавап бирүе авыр булган бер сөаль булып төште. Мин, әлбәттә, дөресен әйттем:

— Тәрбия итүчем юк. Шулай да өйдәге агам әз-мәз булса да азык җибәреп торса кирәк,—дидем.

— Алай икән... Тәрбия итүчең булмагач, кыенрак булыр бит.

— . . . .

— Ярый, торып кара. Сабагыңны яхшы укы! Алла ризык бирер...

Мин, кайда барсаң да эшнең азыкка килеп терәлгәнен уйлап, уңайсызланып калдым.

Шуннан соң хәзрәт сүзне башка мәсьәләгә борды. Көлке сүзләр сөйләп куйды. Ниһаят, бер хәлфә кереп:

— Хәзрәт, безнең бүлмәгә чәйгә рәхим итсәгез иде,—дип үтенгәч, күзлеген салып, урыныннан торды. Аның торуына бөтен шәкерт урыннарыннан торып, тезелешеп юл биреп тордылар.

Ул чыгып киткәч, мәдрәсәдә тавыш купты. Анда чәй урны хәзерләп җибәрделәр. Монда икмәк ашарга, тегендә укырга керештеләр.

Бер-икесе безнең янга килеп, минем укуымны сораша башладылар. Шулай итеп ятар вакыт җитте. Мин авылдашлар янында ятып, бик тирән, тыныч йокыга киттем...

Иртән чак,

— Хәзрәт килә, торыгыз!—дигән тавышка уянып киттем... Бу тавыш бөтен мәдрәсә шәкертләренә яшен кебек тәэсир итте; бер-ике минут эчендә һәммә шәкертләр урыннарыннан торып, лампаларын яндырып, киенеп өлгерделәр. Хәзрәткә урын хәзерләп, биш-алты минут эчендә, кайдадыр барып, юынып та керделәр.

Хәзрәт иртә намазыннан элек килеп, җиңел генә дәрес биреп китә икән. Бүген дә, кичәге кебек тезелеп утырып, дәрес алдылар.

Башкалар рәтеннән мин дә намазга бардым. Мин дә шулар кебек, кайткач чәй эчеп, капчыкны чишеп китапларны алып, былтыр укыган сабакларны күздән үткәрә, күңел байлыгын барлый башладым. Күп тә тормый берәү килеп:

— Сине Мотаһһар хәлфә чакыра,—диде. Шул шәкерткә ияреп, икенче мәдрәсәгә, хәлфә торган җиргә бардым. Утырырга кушты, утырдым. Укуларымны сорашты, сөйләп бирдем. Бер-ике сөаль бирде, аңа җавап кайтардым.

«Әлхәмде» нең тәркибен, өр яңадан башлап тагын да өйрәтте. Шул сүзгә кушып, «Лиллаһи раббелгаләмин»нең тәркибен бирде һәм шуларны белеп, ятлап килергә кушты.

Хәлфә күңелгә ошады. Биргән сабагы һәм өйрәткән нәрсәләре бик мөһим булып күренде. Күңлемнән тырышырга, тизрәк «шәп» кеше булырга тиеш икәнен уйлап куйдым. Теге биш тиен көмешне хәлфәнең алдына куеп, кире урныма утырдым. Хәлфә дога кылды, тәкрар тәүфик һәм гыйлменафиг теләде. Шуннан мин дә чыгып, үземнең теге урынга кайттым.

Өч-дүрт көндә мәдрәсәнең «тәртип» һәм «низамнарына» төшенеп алдым. Бирелгән сабакларны ятлап өлгертә бардым. Ул яклар яхшы барды.

Әмма, дүрт-биш көннән соң, азык мәсьәләсендә көймә тагын комга терәлде. Теге икмәк күптән бетте. Авылдашлар ике-өч көн «кунак» итсәләр дә, хәзер алар да чәй янына чакырмый, аш ашаган вакытта эндәшми башладылар. Кешеләр шаулашып, тәмләп ашаган вакытта карап утыру бик авыр күренгәнгә күрә, мин мәдрәсәдән чыгып, алар ашап-эчеп беткәнче ишек алдында йөреп гомер үткәрә башладым.

Азык ягының начар, эшнең һәр ягы күңелсез булуының каруын сабактан ала идем. Бик тырыша, хәлфә биргән дәресләрне су кебек эчкәнче ятлый, шулай итеп күңелне юата идем.

Бара торгач, шундагы иркен тормышлы шәкертләргә самовар куярга, аш пешереп торырга кердем. Мин аларның эшләрен эшләү өстенә, сабакларымны да укып өлгертә, алар укыган «Төхфә» кебек нәрсәләрне дә өйрәтә идем. Шулай итеп, азык мәсьәләсе тагын бераз юлга куелды, эш эшләп ашауга юл ачылды һәм бу эшләргә күнегелде.

Монда укучыларның саны күп булса да, күбесенең укулары түбән иде. Аларның күбесе «Таглимоссала», «Төхфәтелмөлек» кебек, мин әллә кайчан укып үткән китапларны укыйлар һәм шулар белән баш ваталар иде. Берничә ел укып та, рәтләп татарча укый һәм бер сүз дә яза белмәгәннәре бик күп иде.

Мәдрәсәнең эчке «тәртибе» һәм андагы тормыш бик түбән булып, моның да иң авыр ягы, безнең кебек самовар куеп, башкаларга аш пешереп йөрүче ярлы шәкертләр өстенә төшә иде.

Менә сиңа бик зур ашханә. Аның түшәме астына бик юан ике өрлек куелып, рәттән епькә тагылган ыргаклар тезелгән. Шунда казаныңны асып, һәркем үз казаны астына ут ягып җибәрә. Кай вакытта бу ыргаклар, утын һәм күмер өчен сугыш та чыгып китә. Эш бик зурга китсә, казыйга хөкемгә барырга туры килә. Гаеп сиңа ауса, җазаңны күрәсең: син ул көнне һәммә кеше ашын пешереп беткәнне көтәргә, шуңарчы аш пешерми торырга мәҗбүрсең. Әдәм күренмәслек төтен эчендә тончыгып, мең бәлә белән пешергән ашның, епь өзелеп, җиргә авып киткән вакытлары да була... Бу эш бигрәк авыр, бу вакытта аш көтеп утырган хуҗаларга җавап бирергә кирәк.

Чәй эчкәндә самовар кайнату мәсьәләсе дә бик җиңел түгел. Монда боз өстендәге самовар авып китә. Анда самоварның борнын кемдер борып киткән дә, суы агып беткән, бөтен тирә-як су белән күл булган, самовар эри башлаган. Аңа шунда ук салырга су юк. Шул ук вакытта күмер өчен сугыш, низаг чыгып китә. Кыямәт, мәхшәр!..

Мәдрәсә эчендә бер үк вакытта теләсә кем, теләсә нәрсә эшли, теләгән нәрсәсен укый. Яки бер дә укымыйча тик йөри.

Монда тырышып укыганда да әллә кая бара алмыйсың. Атнасына ике-өч рәт сабак алырга, атна буенча шуны ятлап, тик йөрергә туры килә.

Бу мәдрәсәдә 96 нчы елның декабренә чаклы тордым. Шул вакыт эчендә барлыгы җиде-сигез бит тәркиб укыдым.

Ашау-эчү мәсьәләсен тәэмин итәр өчен һаман самовар куеп, аш пешереп йөрсәм дә, бер вакытта теге шәкертләр, үзләре эшли башлап, мине урыннан «мәхрүм» иттеләр. Мин тагын да һичбер нәрсәсез калдым.

Шушы мөнасәбәт белән, үзебезнең Җилем-Каранга кайтып, эшләрне рәтләп килергә уйладым да, Уфадан кайтучы авылдашларны очратып, Хаҗигали исемле авылдашның йөз җирдән ямаган, ямала торгач бик калын һәм авырга әйләнгән бишмәтен киеп, авылдашларның утын чаналарына утырып, авылга кайтып киттем. Кыешкы артта, буран эчендә, торып калды...

Өч-дүрт ай читтә тору белән авыл сагындырган иде.

Читтән йөреп, шәкерт булып укып кайтканга күрә, өйдә дә ачык йөз белән каршы алдылар, бер-ике көнгә чаклы кунак кебек итеп тоттылар.

Кыешкыга китү чараларын эзләп карасам да мөмкин булмады, бер яктан, өскә киеп барырга кием, икенче яктан, алып китәргә акча һәм азык юк иде.

Мин Үтәшкә укырга киткән елны, авылның берничә байлары, элекке муллага үч итеп, Уфадан Җамалетдин исемле берәүне яшь мулла итеп китергәннәр иде. Шушы яшь мулла, үзенә аерым мәктәп салып, Хәйрулла Усманов кебек яңачарак укыта башлаган иде. Шушы мулла, мин Кыешкыдан кайткач, өенә чакырып, мине үзенең мәдрәсәсендә укырга, үзе мине укыту белән бергә, мине үзенең яшь шәкертләрен укытуда ярдәм итәргә чакырды.

Мин аның димләве буенча шуның мәктәбенә кереп, бер яктан, үзем укырга, икенче яктан, вак балаларны укытуда бу муллага ярдәм итәргә, ягни мөгаллимлек кылырга керештем.

Монда тору минем тормыш ягын бик күп җиңеләйтте. Ашау-эчүнең артыннан йөрү, кайгыру бетте. Авыл халкы да, «Мәҗит хәлфә» дип минем исемгә койрык тагып йөртә башладылар. Балаларның ата-аналары кунакка чакырырга, хөрмәт итәргә керештеләр. Мәдрәсәдә миннән дә шәп, миннән дә күп укыган кеше булмаганга күрә, хәзрәт булмаганда бөтен балаларның өстеннән карау, кайбер эшләрдә юл күрсәтү, аларны мәктәп тәртипләрен ригая итәргә мәҗбүр итү минем кулда иде. Бу эш мине үсендереп җибәрде булса кирәк, мин үземне эрерәк тота башладым. Бала-чагалар белән «ваксынмаска» тырыштым. Минем атналык доход бер сум тирәсенә җитә башлады. Чабатаны ташлап, матур гына галуш алдым. Өскә кия торган җилән дә тектереп алдым. Эшләр шәбәйде. Шулай итеп, язның җиткәнен, шәкертләрнең тарала торган заманы килгәнен белми дә калдым.

Апрельдә укучылар таралып беттеләр. Мәдрәсәдә бер сукыр суфи белән икәү генә торып калырга туры килде. Ашау-эчү мәсьәләсе тагын да такырлана төште...

Җәй көнен кайда һәм ничек, нинди эш белән уткәрү мәсьәләсе алга килеп басты. Авыл тар төсле, монда тору авыр булыр кебек күренде. Матур язның матур көннәре, чит илләрдән килеп, төрле тавышлары белән тирә якны яңгыратып торган кошлар күңелне җилкендереп, әллә кайда, читкә китәргә кызыктыра башладылар.

Май ае кереп, авыл тирәсендәге чирәмлекләр яшәреп матурлану белән, кызлар-егетләр уйнарга чыга башладылар. Боларның уеннарында, биюләрендә, кызларның түгәрәк булып кулга-кул тотынышып уйнауларында шигырият, матурлык бар иде. Менә монда үзләренең яңа бишмәтләрен киеп, җәй көне булуга карамастан, билләрен кызыл, ал билбаулар белән буган егетләр бергә җыелып гармон уйныйлар, бииләр. Үзләренең йөрәкләрендәге дәртләрен кайда куярга белми шаяралар. Әнә шулардан утызкырык сажен чамасы җирдә—хатын-кызлар төркеме. Төрле төстәге күлмәкләр кигән, башларына ал, кызыл, зәңгәр, яшел, ак төсләр белән бизәкләнгән төрле төстәге шәлләр ябынган бу төркем, читтән караганда төрле төстәге чәчәкләрдән ясаган бик зур букет кебек булып күренә. Боларның берсе бик моңлы иттереп курай уйный, бер-икесе бии, кулга-кул тотышып култык асларыннан чыгып уйныйлар. Кызлар белән егетләр төркеме арасында һәр вакыт малайлар аркылы мөнәсәбәт ясалып тора. Бара торгач, гармончы егет, кызлар арасына килеп, гармон уйнап, аларны биетә башлый. Уен кызганнан кыза. Барабара кызлар, егетләр аралашып китәләр. Менә шул җиргә җиткәч, авылның динче картлары белән куштаннары уенны килеп туздыралар. Кызлар төркеме тарала. Егетләр качалар... Шуның белән уен бетә. Мин боларның уеннарына кызыксам да, алар белән бергә йөрүне яратсам да, хәзер мин үземнең урным, тоткан юлым белән алардан аерылган идем. Мин болардан бөтенләй аерылып, боларның күзләрен кыздырып чит җиргә китүне арзу итә идем.

Бу вакытта читтән килеп, безнең ил аркылы үтеп киткән кошлар мине кызыктыралар, күңел шулар кебек һавада очарга, чит илләргә китәргә тели иде. Ләкин кайда барырга, кайсы җиргә китәргә, нәрсә эшләргә?—дигән уйларга җавап табып булмый иде.

Көннәр тагын да матурлана төште. Күңел тагын да талпына башлады. Тормыш авырлыгы да килеп кушылды. Шулай торганда Урал таулары эчендә, кайдадыр бер җирдә, яңа бер урынга чуен заводы салына башлап, безнең авылның Габдулла, Фазулла дигән кешеләр, шул заводка кирпеч сугарга подряд алып, авылдан үзләренә муафик кешеләр алырга кайттылар. Болар белән мин дә сөйләшеп, ат белән балчык ташырга айга дүрт сумга ялландым. Ашау-эчүнең һәммәсе дә алардан иде.

Урал таулары арасына эшкә китү—минем өчен бер дә

көтелмәгән зур шатлык булды. Бу эш, бердән, минем моннан соң үз көнемне үзем күрә ала торган ирекле булуымны күрсәтә, икенчедән, матур таулар арасына, әллә кайда, ерак җирләргә барырга, күрергә юл ача. Эшнең авыр булачагын бераз күз алдыма китерсәм дә, башкалар чыдаган эшкә мин ник чыдамаска дигән уйга киләм.

Китәргә килешкән көннең иртәгесен Урал таулары эченә карап чыгып киттем. Менә безнең авылдан күренеп торган Урал тавының тармаклары! Менә мин күптән бирле башларына чыгуны уйлап йөргән биек-биек таулар!..

«Биек үр», «Таш тавы», «Бужан», «Такаты» дигән тауларны абзыйлар сөйләп, мине кызыктыра торганнар иде. Мин бит бүген шуларның башына менәм. Аюлар улап, боланнар торган урыннарның уртасыннан үтәм! Күккә чыгып торган тауларның башына менеп, тирә-ягыма карап торам! Бу уйлар мине барган саен исертә, рәхәтләндерә, яшьлек шатлыгы белән шатландыра иде.

Авылдан егерме биш чакрым киткәч тә таулар арасына кереп киттек: мин беренче күрдүк тауларның матурлыгына, мәһабәтлегенә, урманнарның тирән тынлыкта утыруларына карап исердем. Менә уң якта биек тау: аның башындагы агачлар, үзләренең югарыда утырулары белән мактанган кебек утыралар. Сул якта ниһаят тирән чокырлар. Алардан аккан сулар таштан-ташка бәрелеп, төрле тавышлар чыгарып, шаулап аксалар да, куе агачлар арасыннан яшеренеп акканга күрә, үзләре күренмиләр. Бара торгач, атлар пошкырып куялар. Ахры якын тирәдә аю бардыр да, болар шуның исен сизә торганнардыр дип уйлап куясың. Куе агачлар арасында кошлар сайрап тора. Их, шул кошлар кебек һәр вакытта шушы җирләрдә торсаң иде. Юл, барган саен, куркыныч җирләрдән үтә. Аста тирән чокырлар, икенче якта—өскә аварга торган кыялар, ташлар... Каршыда күккә чыгып торган тау. Бу тау һәмме таулардан да биек булып, горурланып торган кебек утыра. Ул ни исемле тау икән соң? «Бужан» тавы диделәр. Чынлап та биек икән. Их, шуның башына менсәң иде.

— Юк шул, безнең юл аның бер як кабыргасыннан урап китә,—диләр.

Һаман алга барабыз. Менә инде биек тауга карап менә башладык. Атлар үзләре ихтиярлары белән баралар, без һәммәбез дә җәяү барабыз. Юл, борылып-борылып, югары менә бара. Бераз баргач, атларның хәлләре бетеп, тук-

талалар, шунда ук, арба артка китмәсен өчен, арткы тәгәрмәчнең астына зур таш кыстыралар, атлар бераз хәл җыйгач, тагын да алга китәбез. Тауның башы ерак диләр әле. Ләкин барган саен кызык, барган саен югары менәсе килә. Шушы тауларның тирәсендәге чиксез урманнарны тауның башына менеп карап торасы килә.

— Уф, чак менеп җиттек!..

Тауның башы ялангач икән. Гадәттә бик биек тауларның башларында агач үсми. Моннан тирә яклар әллә кайларга чаклы күренеп аяк астында торган кебек торалар. Утыз-кырык чакырымдагы безнең авыллар, аның тирәсендәге кырлар күренеп торалар.

«Таш тавы» дигән бу тауның башына менеп җиткәч, атларны туктатып хәл җыярга, тирә-якны тамаша кылырга туктадык. Түбәндә, агач арасында, бер дә җил юк иде, бөркү иде. Монда тәнгә рәхәтлек бирә торган хуш җил исә. Тауның башында эре ташлар аунап яталар. Шул ташлардан бу тирәдәге башкыртлар төрле зурлыктагы тегермән ташлары ясап, башкыртлар үзләрендә генә булган осталык, батырлык белән ул тегермән ташларын, кыш көнендә, аерым ясалган ныклы чаналарга салып сигезәр ат җигеп, шул коточкыч юллардан, бирегә—идел буена ташлыйлар. Яз көнендә бу ташларны, Иделдәге баржаларга төяп, читкә озаталар. Агыйделгә тимер юл күпере салганда аның баганалары өчен кирәк булган ташларны да шушы «Таш тавы»ннан ташытканнар.

Мин теге үзем кызыгып кала торган кыр казлары кебек чит илләргә, матур урыннарга баруымны уйлап шатландым. Күзем туйганчы тирә-якны карап тордым.

Тауны төшү хәзерлеге башланды. Атлар чабып, арбаларны ватып, җәһәннәм кебек чокырларга төшеп китмәсеннәр өчен, арба тәгәрмәчләрен үрәчәләргә нығытып бәйләделәр. Атларны авызлыклап, аркалык белән бавыргалыкларны яңадан нығыттылар. Арбага утырырга курыккан хатын-кызлар (хуҗаларның гаиләләре) җәяү төшмәкче булдылар. Без арбаларга утырып, әкренләп таудан төшә башладык. Тәгәрмәчләр беркетелүгә, атларның авызларын тартып торуга карамастан, арбалар алга китәргә омтылып торган кебек булалар. Таудан төшү артык кыен булмады. Озакка сузылмады. Без төшеп бераз торганнан соң, җәяү килгән кешеләр дә килеп җиттеләр. Көн яхшы ук иртә булуга карамастан, кояш таулар артына төшеп, күздән югалды. Тау, урман арасына җиңелчә салкынлык төште.

Тагын бераз баргач, шаулап ага торган елга буена килеп җиттек.

— Шунда кунарга кирәк, югыйсә «Биек үр» не үтеп, Куйлыга җиткәнче төн уртасы булыр, аю-фәләннән дә куркыныч,—дип, елга буена туктадылар. Атларны тугарып бәйләдек. Мин һәм минем белән бергә эшкә яллангaн бер малай, хәзер инде үзебезне «бай кешесе» дигән уйга кереп өлгергән идек. Безнең хуҗалар да, аларның хатыннары да хәзер безгә шулай карыйлар һәм төрле йомыш кушалар иде. Атларны тугарып, суытырга бәйләп кую белән, мин, утын китереп, ут ягарга керештем. Хатыннар су китерделәр. Зурлар чәйнек элеп чәй кайната торган казыклар кактылар. Без күптән бирле күләгәдә. Кояш безнең артта калган тауга яшеренгән. Безгә каршы яктагы биек тау башы кояш нуры белән балкып тора. Безнең яныбыздан ага торган елга шаулап ята. Ямь-яшел яфракларга төрелгән төрле агачлар арасында урман кошлары сайрыйлар, кычкыралар. Шул матурлыкларга карап торатора чәйнең кайнавы сизелми дә калды. Чәй урнын әзерләп иң элек хуҗа һәм аларның хатыннары һәм зур кешеләр чәйгә утырдылар. Без теге малай белән, алар чәй эчеп бетергәнче, читтәрәк тордык. Тик аларның кайберәүләре чәйгә туеп, урыннарыннан киткәннән соң, безне чәйгә чакырдылар. Хуҗа хатыны безгә дә әзрәк ит бирде. Алдыбызга икмәк куйды.

— Их, нинди тәмле бу чәй белән икмәк...

Чәйләр эчелде. Ул арада кич тә булды. Төн буенча ягып чыгар өчен эре-эре утыннар хәзерли башладылар.

— Атларны арба тирәсендә генә ашатырга кирәк, юк исә аю һөҗүм итәр,—дип, атларны арканлап, аның өстенә тышаулап куйдылар. Бик шәп, гүләтеп ут (костер) ягылды. Тирә-якта тагын тынлана төште. Көндезге кошлар кычкыруларыннан, сайрауларыннан туктадылар. Алар урынына безнең янда гына сандугачлар сайрап җибәрде. Безнең каршыдагы биек тау янында «Сак-сок»[1] кычкыра башлады. Төн караңгысы тирә-якны тәмам баскач, куркыныч каплаган кебек булып китте.

---

[1] Үзенең тавышы белән исемләнгән, ягни: «Сак-сок...» (ның), төннәрдә генә кычкыра торган бу кошның тавышын мин Урал таулары арасыннан башка һичбер ишеткәнем юк. Бу кош шулай ике генә сүзле тавыш белән кычкырса да, аның тавышы моңлы була: шуның моңына карап булса кирәк, татарлар арасында «Сак-сок» бәете чыгарылган. (*М. Гафури искәрмәсе*).

Кайдадыр урман арасында шытырдаган тавышлар ишетелә башлады. Атлар колакларын шомартып, утка якынлашып, пошкырып ашауларыннан туктадылар.

— Бу инде, якын тирәдә аю булуның билгесе!—(Шундагы зурлар шулай диделәр). Шушы вакытта костерның өстенә тагы да зур-зур утыннар салынды. Агайларның кайберәүләре сөрәннәр кычкырып аю качырырга тотындылар, кайберәүләре утлы агачларны алып, чаткыларын чәчеп селкә башладылар.

Шушы рәвешчә аюдан саклану таң атканчы дәвам итте бугай. Мин төрле тавышларны тыңлап ята торгач, йокыга киткәнмен...

Без уянганда кояш чыгып, безнең артта калган тауның башын алтынлаган иде инде. Бүген көн бигрәк матур иде. Иртәнге матурлык белән бизәлгән таулар, агачлар, текә ташларны күреп туймаслык иде. Чәй эчеп беткәч, атларны җигеп, юлыбызда дәвам иттек. Таулар берсеннән-берсе биекләнгән кебек булса, барган саен табигат үзгәрә, каршыда шәм кебек тезелгән нарат урманнары була башлый.

Шул көнне кичкә каршы «Зигәзе» заводына җиттек. Кара урман, биек тау, шалтырап аккан суның янына салынган бу заводның корымланган озын морҗалары, аның тирәсенә скертләп өелгән чуеннар, болар арасында йөргән эшчеләр мине хәйранга калдырды.

Үзем кебек бер малай һәм бер зур кеше белән чуен эреткән урынны карарга бардык. Чуен су кебек эреп, калыпларга тула, анда туңган чуеннарны тирләп-пешеп беткән эшчеләр икенче яктан алып, сындырып чыгара баралар иде.

— Их, шулар кебек шунда үзләшеп эшләп йөрсәң иде!—дигән уйга килдем. Алар минем күземә көчле, гайрәтле булып күренделәр.

Без бераз карап йөргәч, кайтып киттек.

Иртә белән тагын да юлыбызда дәвам иттек. Беренче мәртәбә күргән, шаулап торган бу заводны калдырып китү күңелсезсымак булды.

Шул көнне кичкә каршы юлыбызның чиге булган «Лапашты»га килеп җиттек.

Яңа салынырга уйланган бу завод «Лапашты» дигән кечкенәрәк бер елганың буена эшләнә башлаган икән. Әле монда эш башындагы кешеләр торыр өчен генә берничә матур өйләр салынган. Эшчеләрнең күбесе казармаларда

яки бик ашыгыч ясалган кечкенә-кечкенә куышларда торалар. Бу йортлар шундагы агачлардан гына ясалып, тирә-яктагы урманнарга балта кермәгән.

Безнең хуҗалар үзләренең кирпеч сарайлары янына салынган кечкенә йортларына барып туктадылар.

Без, эшкә ялланып килгән берничә кеше, кыш көнендә кирпеч киптереп, җәй көнендә казармалык хезмәтен үтәгән зур һәм озын амбар кебек йортның бер башына урнаштык.

Электән эшләп килгән берничә буйдак эшче дә шунда торалар иде. Шуларның берничәсе үзебезнең авылдаш яки якташ булганга күрә, шунда ук сөйләшеп киттек. Алар авыл хәлләрен, андагы тормышны сораштылар. Без мондагы тормышны сораштык.

Без торачак бу урын бик күңелсез һәм тузан оясы булса да, без анда кичен генә кереп ятачак булганга күрә, аның ямьсезлеге безнең өчен нык тәэсир итмәде.

Иртәнгесен кояш чыгар-чыкмастан уяттылар. Электән эшләп килүчеләр эшләренә киттеләр. Безгә дә хуҗалар шунда ук эш билгеләделәр. Миңа балчык ташый торган бер арба, бөтен сбруйлары белән бер ат биреп, бөтен мәсьүлиятен үземә тапшырдылар. Мин шул ат белән бер чакырымлык җирдән кирпеч суга торган сарайлар янына балчык һәм ком ташырга тиешле идем.

Шул тапшырылган вазифаны үтәү өчен, башкалар белән эшкә киттем. Шул минуттан башлап кечкенә бер хезмәтче яки эшчеләр дөньясының кечкенә бер агзалары булдым.

Ике-өч көнгә чаклы эшнең тәртибенә, гомумән иртәдән алып кичкә чаклы эшләүгә төшенеп китү авыр булса да, соңыннан бу эшләргә күнегеп кителде.

Башка кешеләр кебек куллар ярылды. Өс-баш сапсары тузанга манчылды. Ыштанның тезләре, бишмәтнең терсәкләре тишелеп, ямалдылар. Иртәдән кичкә чаклы эшләргә, сәгать тугыздагы иртәнге чәй белән көндезге аш вакытында атларны ашатырга тукталган вакытлардан башка сәгатьләрне, һичбер нәрсәгә карамый, балчык ташырга тәмам өйрәнелде. Көн буе эшләү җитмәгән кебек, кич белән атларны куна алып барып, төнне урман арасындагы аланнарда ашатып, иртән кояш чыкканда кире кайту эшләре дә безнең өскә йөкләнгән иде. Безнең һәм без йөрткән атларның өстеннән хуҗаның энесе карый. Ул бик мыжык кеше. Ул һәммә нәрсәне җентекләп кенә тора. Ат-

ларны җигеп, эшкә китәргә әзерләнеп беткәч, килә дә тикшерә башлый. Иң элек дуганы селкетеп карый. Аркалык белән бавыргалыкны, аннан соң тяжләрне тикшерә. Әгәр дә камыт бавы йомшак тартылып селкенә торган булса яки аркалык түбән яки югарырак бәйләнсә, тяжләр бушрак тартылган булсалар, арба рәтләп майланмаса пыр туза:— «Болай булса атны хәрап итәсез!» дип, шунда ук тугартып кире җиктерә. Тәгәрмәчләргә баткак ябышып калмасын. Аларны кырып торырга кирәк. Эштән кайткач та, атларның ял асларын, муеннарын тотып карый. Әгәр дә гадәттән тыш тирләгән яки камыт тию билгесе була калса, ул атны йөртүчегә яхшы сүз юк.

Кунарга китә башласаң, атларның тышауларына чаклы карый һәм:

— Үләннең яхшы җирендә куныгыз. Атларыгызның тышавы агач төбенә эләгеп, егылып ятмасыннар. Кояш чыгуга кайтып җитегез!..»—дип, әллә ничаклы сүз сөйләп җибәрә.

Атны кыйнаган, бигрәк тә аның башына суккан кеше—аның дошманы. Ул атның башына суккан кешене күреп калса, әрләү белән генә тукталып калмый. Ул кешене шунда ук эштән туктата да, атны икенче кешегә бирә. Аның шушы сыйфатын мин бик ярата идем. Чынлап та, ат кыйнаган кешедән начар кеше буламы?

Якшәмбе көн бәйрәм була. Эшчеләр ял итәләр. Ләкин күп вакытта якшәмбе көн, минем кебек берничә малай өчен, иң авыр көннәрнең берсе була. Ул көнне хуҗа безне кирпеч яндыра торган мичләрне тазартырга куша. Һәр кайсыбыз икешәр мич тазартырга мәҗбүрбез. Биеклекләре бер аршин гына булып, сигезәр аршин озынлыгы булган көл, кирпеч вагы, өстән төшкән тузаннарны көрәп чыгарырга кирәк. Шуның өчен мичьнең авызыннан башлап тазарта, тазарта эчкә керә барасың. Чиксез тузан тончыктыра, тын алу авырлаша, хәл бетә. Кирпеч яндырган вакыттагы кызулыктан эреп чөй кебек торган һәм пыяла кебек каткан нәрсәләргә баш бәрелеп, башны җәрәхәтли. Төптәге көлләрне алга этеп үзең эчкә калгач, рәтләп һава да керми башлый. Шундый авырлык белән мичләрне тазартып чыгабыз. Аннан чыккан вакытта күзебез белән тешләребез генә ялтырап күренәләр. Баш, бит, муен, җилкәләр тирләп, аларга тузан каткан була. Шул чакта ютәлләтә башлый. Авызларыбыздан төкерек урнына тузан гына какырабыз. Танауларыбызны сеңгер-

сән, кызыл тузан белән көл катыш нәрсә чыга. Бераз утырып, елга буена барып юынганнан соң гына бераз хәл керә башлый. Төш вактына чаклы сузылган шушы авыр эштән соң гына безгә бераз ял итәргә мөмкинлек туа.

Ике ай чамасы эшләгәннән соң мин ат куып, балчык ташуның эш түгеллеген, эшләгәч-эшләгәч башкалар кебек кирпеч сарайлары тирәсендә эшләргә кирәк икәнен уйлый башладым. Һәм бу фикеремне Габдулла абзыйга сөйләдем. Башта ул минем теләгемә каршы торды. «Син яшь, синнән ул эш булмас», диде... Шулай да бара торгач, мин үз теләгемә ирештем: ат белән балчык ташып йөрүдән туктап, кирпеч сарайларында эшләргә эшкә калдырылдым. Мондагы эшләр бик төрлечә иде—сугылган кирпечләрне әйләндерү, кипкәннәрен бер җиргә җыеп өю, аларны кирпеч яндыра торган базга ташып тору, янып кирпеч хәленә килгән кирпечләрне чыгарып өю кебек эшләр һәммәсе дә безнең җилкәдә иде. Монда, әлбәттә, эш байтак авырлашты. Шуның белән бергә, жалованиe да дүрт сумнан җиде сумга күтәрелде. Югарыда саналган эшләр булмаганда мин кирпеч сугарга да өйрәнеп киттем. Баштарак бу эш кыен кебек булса да, бара торгач, җиңелләшеп китте.

Эшнең күңелсез яклары булган кебек, күңелле яклары да була иде: мондагы урман арасында, таулар уртасында, табигатьнең матур җирләрендә йөрү күңелгә рәхәтлек бирә иде. Моның өстенә эшчеләрнең эштән бушаган вакытларында тау буена җыелып уйнаулары, гармон тартып биюләре дә күңелләндерә торган иде. Төрле урыннардан җыелган, гомерләре буенча завод һәм приискаларда йөргән бу халыкларның арасында төрле тип, төрле сыйфатлылары булулары, үзләренең башларыннан үткән вакыйгаларен сөйләүләре—һәммәсе дә төрле уйларга төшерә, тормышның төрле тармакларын күз алдына китерә иде.

Бу эшчеләр арасында, гомерләре буена эшләп йөреп тә ялгыз торганнары булган кебек, берничә балалылары, тормышның бөтен авырлыкларын күрүчеләре дә күп иде.

Мин боларның кайберәүләре белән үзләшеп киттем. Болар үзләре дә мине якын күрәләр, «уңган шәкерт» дип, ригая күрсәткән булалар иде.

Шулай итеп, матур җәй үтте. Тау арасында көннәр салкыная башлады. Борынгы гадәт буенча уку мәсьәләсе тагын да алга килеп басты. Елы мәктәп, китап, уку күз алдыннан китми башлады. Ниһаять, мин үземә тиешле ак-

чаларны алай-болай алып авылга кайтып киттем. (Мин башта ук көзгә каршы авылга кайтуны шарт иткән идем).

Быел мин читкә китәргә уйлый идем. Ләкин бу эш булмады. Үткән елгы кебек, үзебезнең авыл мәктәбендә бер яктан балалар укыткан, бер яктан үзем укыган булып, шунда калырга булдым. Тормышта артык үзгәреш булмый озын кыш үтеп китте. (1897 нче елның көзе һәм 98 нче елның язы).

Тагын да матур яз көннәре килеп җитте. Мәктәптәге шәкертләр таралдылар. Мин тагын да шунда ялгызлык газабын күрә башладым, эш юк. «Рөбгузи» тарихын, «Алты бармак», «Сәет Баттал» кебек китапларны укып чыктым. Шуларны укудан башка җан азыгы бирерлек нәрсәләр дә юк иде.

Мин Үтәш мәдрәсәсеннән киткәнгә ике ел булса да, Хатыйп хәзрәткә бер генә мәртәбә дә күренгәнем юк. Ул безнең авылга бик еш килә. Авылның байлары, зур кунак мәҗлесе ясаганда, аны һичбер калдырмыйлар. Ул мәҗлеснең түрендә була. Шуның өстенә ул безнең авылда һәр атна саен була торган базарга да килә. Шуның өчен мин аны бик еш күрәм. Ләкин ул күренү белән әллә кайдан ук качам. Аңа очрашу минем өчен арыслан яки аюга очрау белән бер. Әгәр аңа очрый калсам, аның мине кыйнау ихтималы бар. Кыйнамаса да бик нык тиргәвеннән шөбһә юк.

Бер базар көнне мин базарга чыгып бара идем... Урам почмагыннан базарга карап борылган чакта гына Хатыйп мулла алдыма килеп чыкмасынмы?.. Мин куркуымнан шак каттым да калдым. Ул ачулы тавыш белән:

— Син, качак, нишләп йөрисең? Миннән рөхсәт сорамый, фатыйха алмый киттең.

— Укып...

— Җилем-Каранның надан мулласыннан укып кеше булырмын дип уйлыйсыңмы? Ахмак...

— . . . .

— Сине миңа атаң мәрхүм тапшырып киткән иде. Син аның васиятен тотмадың...

— . . . .

Ул никтер йомшады:

— Син бу авылда ятып әрәм буласың. Син монда да торма, миңа да барма, Троицкийга, Зәйнулла ишан мәдрәсәсенә кит. Миннән сиңа фатыйха,—дип, дога кыла башлады. Мин аның бу сүзләреннән соң шатланып киттем.

Аның белән бергә кул күтәреп, дога кылуымны сизми дә калдым. Ул бик якын кеше кебек, баягы сүзләрне кабатлап, минем белән күрешә:

— Ишет, бүгеннән Троицкийга кит!—дип үз юлына китте...

Читкә китү минем күптән бирле теләгән теләгем иде. Шуның өстенә аның бу сүзләре миңа бик нык тәэсир итте. Авылда караңгылык эчендә яту үзе дә туйдырган иде.

Хәзрәт белән шушы очрашудан соң озак тормый сәфәр хәзерлеген күрә башладым. Волостьтан паспорт алып кайтып куйдым. Китап-фәләннәрне капчыкка тутырдым. Шулар белән хәзерлек эше бетте дә.

Троицкийга Уфа һәм Чиләбе аша поезд белән баруның җиңел икәнен белсәм дә, минем юллык акчам юклыктан, бу эш мөмкин түгел иде. Шуның өчен дүрт йөз илле чакрымлык мәсафәне[1] Урал таулары аркылы үтеп җәяү барырга тиешле идем.

Минем бәхеткә каршы, үзебезнең авылдан маглүм «Лапашты» заводына чаклы ат белән баручы кеше чыкты. Бу кеше мине шунда чаклы буш алып барырга вагдә итте.

Шушы вагдәнең өченче көнендә без Урал тауларына карап чыгып киттек. Янымда, китап һәм вак-төяк нәрсәләрдән башка, җитмеш биш тиен көмеш акчам да бар иде.

Йөз егерме чакрымда булган «Лапашты» заводына бару башта җиңел булса да, бара торгач, бик шәп яңгыр булып киткәнлектән, юллар авырлашты. Арбаны тарттырып бару мөмкин булмый башлады. «Зигазе» белән «Лапашты» заводлары арасындагы урманнар уртасыннан барган тар гына юл арба белән йөрерлек хәлдән чыккан иде. Үзебез җәяү барсак та, ат коры арбаны да тартып бара алмый башлады. Бара торгач, бөтенләй арыды һәм алга барудан бөтенләй баш тартып тукталды. Без көч-хәл белән Әхмәр авылына җитеп хәл җыйганнан соң, шул авылга ниһаят арбаны калдырып, икәү бер атка атланып китәргә мәҗбүр булдык. Шулай итеп мең бәлә белән «Лапашты» заводына барып җиттек.

Мин монда бер кич кундым. Троицкий ягына китә торган берәр иптәш эзләдем, ләкин иптәш туры китерә алмадым. Иптәш таба алмый аптырагач, юлны өйрәнеп, капчыкны аркама асып Биләрәт заводына таба карап ялгызым чыгып киттем.

[1] Мәсафә—ара, ераклык.

Юл тар, борылмалы, ике як—кара урман. Ялгыз бару бик куркыныч. Аюның нак өстенә барып чыкмасын өчен һәр вакыт кычкырып, сөрәннәп барырга кушканнар иде. Мин аларның сүзләре буенча минут саен кычкырып барам. Юлда бер кеше дә очрамый. Урман эченнән лап-лоп басып аю килеп чыгар төсле тоела. Шулай уйлап та бетмисең, урман эчендә әллә нәрсә шытырдаган, агач ботакларын сындырып алга таба килгән кебек булып китә. Аю гына түгел, шүрәлеләр, урман качкыннары чыгып, арттан килеп тотарлар кебек тоела. Утырып хәл җыюы да куркыныч. Шуңа күрә йөгерә-йөгерә алга барырга ашыгасың. Барган саен урман тыгызлана, караңгылана. Бу гына җитмәсә, әллә кайсы якта күк күкрәгән тавышлар ишетелә. Ашыгып бара-бара хәлем беткән, тыным кысылган кебек була башлады. Ниһаять, нәрсә булса да булыр дип, бер таш өстенә утырып хәл җыярга керештем. Моң-зар эчкә сыймый җырлап җибәрәм. Бу җыр минем эчемдә кайнашкан ялгызлык кайгыларын юып төшерде. Мин хәзерге минутта бөтен куркыныч һәм эч пошулардан азат булдым. Мина алга барырлык көч керде. Шул көч белән мин тагын да алга киттем. Кара урман хәвефсезгә әйләнде. Аю-фәлән чыкса да бер нәрсә дә булмас, дигән уй башка килеп утырды. Шулай бара торгач, урманны чыгып бик биек булмаган таудан төшеп бер авылга барып җиткәнемне сизми дә калдым.

Бу авыл Кәртәле исемендә кечкенә генә бер катай авылы иде. Авылдан кергәч тә су буендагы бер йортка барып, хәл җыеп, кунып китәргә рөхсәт сорадым. «Рәхим ит», диделәр.

Кәртәле авлы урман арасында, Инҗәр суына төшкән кечкенә, ләкин ташлар арасыннан шылтырап аккан кечкенә бер елга буенда утыра. Авылның читеннән үк эре карагайлар тезелешеп киткәннәр. Мин үзенең өенә кереп кунарга рөхсәт иткән кеше бик ачык йөзле. Минем шәкерт икәнемне белгәч, хөрмәтләп чәй эчерде. Бу авылның бөтен кәсебе урман кисү икән. Җәйгә чыгу белән агач кисеп, күмер яндырырга (әлбәттә, завод өчен) китәләр имеш. Мине чәй эчергәч, өй хуҗасы урманга китте. Алар анда кунып эшлиләр булса кирәк. Үзе белән байтак кына азык та алды. (Хәзерге көндәге яшь шагыйрьләрдән М. Таҗи шушы Кәртәле авылыныкы).

Шушы авылда кунганнан соң, моннан егерме биш чакрым җирдә олы юл өстендә булган Ак Көчек-Сәрмән авылына таба карап, тагын да ялгыз чыгып киттем. Бу

ике арада бер генә дә авыл булмау өстенә, юл һаман шул кара урман һәм тау арасыннан бара иде.

Башта яхшы гына шәп барсам да, бара торгач, аяклар тала башлады. Ташлы юлдан бару аякларны кабартты. Унбиш чакрымнар чамасы баргач, су буена утырып хәл җыеп, тамак туйдырып алдым да тагын алга киттем. Кичкә каршы Ак Көчек авылына җитеп, шунда ил мулласы булып, балалар укытып торган бер татар муллясына кердем. Ак Көчек-Сәрмән Агыйдел буена утырган бик зур авыл. Бу авылда торган көннәремнең һәрберсендә мин Идел буена барып бик озак йөреп, су кереп кайта торган идем. Агыйдел бу тирәдә бәләкәй генә. Ләкин чиксез матур. Ул миңа бик якын күренә. «Безнең авыл янынннан үтә торган Агыйдел бит бу!» дип, мин аңа бик озак карап утырам. Мин аны бала вактымнан бирле белгәч, ул да мине белгән кебек булып китә. Мин төшкән кеше үзе дә, хатыны да бик ачык йөз белән каршы алдылар. Һәм өч көннән соң Мши авылының Минһаҗ дигән бер мулланың Троицкийга барачагын, аның мине алып баруында шөбһә юклыгын сөйләделәр. Икенче көнне Минһаҗ мулла үзе шушы авылга килде.

Бу кеше аппак сакаллы, киң күңелле, ачык йөзле бер кеше булып чыкты. Мин аңа, күрешеп, үземнең Троицкийга, Зәйнулла хәзрәт мәдрәсәсенә укырга баруымны әйтү белән, бер сүзсез алып китәргә вагдә бирде һәм иртәгә шушы авыл аркылы үтәчәген белдерде. Бу мулла шуннан ерак түгел Күнтәк яки Күнтәй авылының бер суфи белән Зәйнулла хәзрәткә кул биреп кайтырга баралар икән.

Троицкийга хәтле ат белән бару бәхетенә ирешү мине чиксез шатландырды. Вагдәнең икенче көнендә, пар ат җиккән тарантаска утырып, мин бу ике суфига күчер булып Троицкийга чыгып киттек.

Безнең тирәдә Биләрәт заводының исме Иделбашы заводы дип мәшһүр. Җәйгә чыккач, безнең яктан монда эшкә китүчеләр күп. Бу заводны гаҗәп иттереп сөйлиләр. «Идел чаклы иделне буганнар!..» дип хәйран калалар иде. Хәзер мин шуны күреп үтү шатлыгы белән барам.

Атлар көр. Олы юл белән җилдереп алга баралар. Менә заводның һавага төтен чыгарып утырган морҗалары, әнә йортлар...

Барып җиттек. Чынлап, Агыйдел буылган. Тик мәгълүм бер җирдән генә шаулап су ага. Буаның югары ягы

чиксез күл булып ята. Заводдан төрле тавышлар чыга. Заводга керел-чыгып йөрүче эшчеләр күренә.

Завод тышыннан караганда да искиткеч. Аның эче гаҗәптер инде, диган уй башка төшә. Әлбәттә, аның эченә керү, күрү минем ихтиярда түгел.

Без бер фатирга кереп атларны ашатып, чәй эчтек тә юлыбызда дәвам иттек. Бераз барганнан соң, Урал тавының үзәге булган:

Уралларданг биек ай тау булмас,
Уралларданг үткән су булмас,
Ир башкайларына эшләр төшсә
Ни авыру булмас, ни сау булмас...

дип җырланган Уралга менә башладык. Урал чынлап та биек икән. Аның башыннан күп җирләр күренә. Аны үткәндә күңелгә әллә нәрсәләр төшә. Менә аның нак башы. Бу инде Европа белән Азиянең аерылган җире. Хәзер без Азиягә чыгып китәбез...

Минһаҗ мулла күңелле кеше: ул күпне күргән карт, кай вакытта күңелле вакыйгаләр сөйләп ташлый, кай вакытта «Мөхәммәдия» көйләре белән мөнаҗәтләр әйтеп җибәрә. Үзе артык вакчыл түгел, егетсымак кеше. Уку ягы бик сай булса да, төрле сүзләр кушып сөйләгәнгә күрә, белемле генә булып күренә. Ләкин бу ике зат күп вакыт күзләрен йомып тәсбих тартып баралар. Берсе көненә утыз биш мең, икенчесе егерме биш мең зекер әйтә Ишан биргән сабакларын шулай итеп һәр көн җиренә җиткереп баралар. Арба өстендә зекер әйтеп барган чакларында бөтен дөньядан ваз кичкән кебек күренәләр. Һичбер сүз әйтмиләр, башларын югары күтәреп карамыйлар. Намаз вакты җитү белән, кайда туры килде шунда, намаз укып китәләр.

Мулланың иптәше бер нәрсә дә белми торган бер башкырт. Ул яшьрәк вактында тәүфиксызрак булган да, соңра, тәүбә итеп, Зәйнулла ишанга мөрит булып сабак алган. Хәзер сабагын яңартырга бара. Минһаҗ муллага бу тирәдәге авылларның муллалары бик таныш булсалар кирәк, без ат ашатканда да, кунган вакытта да берәр муллага яки мәзингә төшәбез. Алар, муллалар рәтеннән, мине дә ашка, чәйгә бергә утырталар. Күп җирдә атларны да үзләренең кешеләреннән каратып, мине кунак кебек итеп сыйлыйлар.

Безнең юл күңелле булды. Пар ат, шуның белән бергә

атлар таза булганга күрә, дүрт көн тулып бишенче көндә Троицкийга барып та кердек. Авылдан чыгып китүемнең унөченче көнендә Троицкий шәһәрендә булдым. Дүрт йөз илле чакрым бер араны бу чаклы аз вакыт эчендә бару бик зур бәхет...

Бөтен тирә-якка шөһрәте таралган Зәйнулла ишанның мәдрәсәсе, Троицкий шәһәренең бер як читендә «Магмурия» дигән өлешендә икән. Без шәһәрне чыгып, хәзрәтнең мосафирларга хаслап салдырган «Мосафирханә»гә барып төштек.

Мосафирханә зур-зур бүлмәләрдән гыйбарәт булган бер йорт булып, һәрбер бүлмәсендә лык тулган мосафирлар. Монда татар, башкырт, кыргыз, казак һәм башкалардан һәр төрле халыклар бар. Кайбер бүлмәләрдә хатыннар белән ирләр аралаш. Бу мосафирларның бик күбесе мөрит булып сабак алырга килгән. Арада аурулар да бик күп. Болары ишан хәзрәттән өшкертеп, дару алырга килгәннәр.

Мондагы тормышны беренче мәртәбә күргәндә хәйран каласың. Шул ук бүлмәнең бер почмагында берәү косык даруы эчеп косып ята. Икенче берәүләр шуның янында ук рәхәтләнеп чәй эчеп, ашап утыралар. Кайбер кеше кыйблага каршы утырып зекер әйтә, ягни тәсбих тарта, капыл гына: «Һу, шәйхем, мәдәт...», «Һү, һу, һу алла!» дип кычкырып җибәрә. Икенче бер бүлмәдә көйләп мөнаҗәт укыйлар, кайберәүләре ишан хәзрәтнең яхшы сыйфатларын сөйлиләр. Кайберәүләр «Коръан» укыйлар. Мулла кебек күренгәннәре нәрсә турындадыр бәхәсләшәләр.

Без барып чәй-мәй эчкәнче икенде намазы җитте. Монда мәчеткә бармый калу һичбер ярамый. Без дә намазга киттек. Монда эшләр тагын да кызык. Һәркем алдына гына карап, кулындагы тәсбихен тартып утыра. Шым гына торганда, тегендә дә, монда да «Алла...», «Шәйхем...» дип кычкырып җибәрәләр. Арадан берәү, «Һу, һу, һу, алла!..» (дип) туктаусыз «һулый» башлый. Урнында гына торып чыдый алмый, дуларга, тыпырчынырга керешә. Авызыннан күбек ага башлый. Ниһаят, хәлдән таеп егыла. Үзе җан тиргә бата... Ләкин мондагы кешеләрнең бу эшкә карап исләре китми. Бер нәрсә дә булмаган кебек утыралар. Минем кебек беренче күрүчегә бу эшләр куркыныч...

Менә ишан хәзрәт килде. Аның тирә ягын төрле яшьтәге, һәммәсе дә чалмалы булган мөритләр чолгап алган-

нар. Ул бик әкрен һәм бик вакарлы рәвештә, һич кемгә карамый, ике якка тезелгән кешеләр уртасыннан үтеп михрапка каршы барып утырды. Ул үзе гәүдәгә мәһабәт булмаса да, карап торуга тәэсир итә. Ул килеп утыргач, кычкырып җибәрүчеләрнең саннары тагын да күбәйде. Хәтта намаз укый башлагач та, капыл гына «алла» дип кычкырып җибәрүчеләр булды.

Бүген миңа мондагы ахирәт тормышы кебек тормыш бик кызык тәэсир итте. Мондагы эшләргә, «серләр» гә төшенү авыр кебек булып тоелды. Мин шундый уйлар белән баш ватып йокыга киткәнмен.

Иртәнчәк төрле шау-шуга уянып киттем. Иртән торып намазга барып кайтканнан соң, чәй эчеп, тәһарәт алып бик нык әзерләнгәннән соң, ишанның өенә, аның мәҗелесенә баралар икән. Минһаҗ мулла белән иптәше дә, тәһарәт алып, тәмам хәзерләнеп, мине үзләренә ияртеп ишан йортына алып киттеләр.

Ишанның капка төбеннән башлап кеше тулган. Ярлы һәм хәерчеләр тышта нәрсәдер көтеп торалар. Хәзрәткә килгән мосафирлардан садака сорап калалар. Эчкә кергән саен тыгызлык арта. Муллалар, яхшы киемле кешеләрне каршы алып залның түренә таба озатып торучы махсус кешеләр бар. Болар үзләре дә чапан-чалма киеп, күзләренә сөрмә тартып, кулларына тәсбих тотып алганнар.

Минһаҗ мулла белән суфи алга үтеп киттеләр. Мин ишек төбендә карап калдым. Ләкин тартыша-тырыша торгач, ишанның кабул бүлмәсенең ишегенә төбенә җитәргә мөвәффәк булдым. Менә сиңа зур зал, идәнгә әйбәт паласлар түшәлгән. Бик яхшылап чәй мәҗелесе хәзерләнгән. Тирә-ягына чалма-чапан һәм яхшы киемнәр кигән кешеләр аяк бөкләп утырганнар. Ишек төбендәрәк гади һәм ишан өчен файдасызрак сыйныф—аурулар тезелгәннәр. Боларның кайберсе утырган, кайберсе аяк өстендә тора. Ишан үзе бик шәп тышлы, кыска җиңле, мех эчле камзолсымак нәрсә, аягына яшел читек, башына чалма кигән хәлдә иң түрдә китап тотып, борынгы әвлиаларның һәм сәләфәсалихинларның[1] кәрамәтләрен сөйләп утыра. Сәхабәләргә дә барып җитә. Сүзен аңлауы бик читен. Бер мәүзугдан икенче мәүзугга бик тиз күчә. Күзләре соң дәрәҗәдә үткер, туры караган вакытта загыйфрәк кешеләрнең башлары иелми калмый. Тирә ягында ярдәмче хәлфәләре, суфилары бик күп. Боларның кай-

[1] Сәләфәсалихин—элекке изгеләр.

берсе кунакларга чәй ясый, кайберәүләре шундагы халыкны утыртып, тәртип саклап йөри.

Беренче күргәндә мәҗелес артык мәһабәт. Соң дәрәҗәдә изгеләр мәҗелесе булып күренә. Мондагы күренешкә хәйран калмаслык түгел. Миңа мондагы хәлфәләр бик галимнәр, гыйлем диңгезендә йөзә торган кешеләр төсле булып күренделәр.

Чәй янына кайнар пирожки килеп тора. Самоварлар берсе артыннан берсе китерелә. Өстәл өстендә, токмачка дип басып куйган камыр кебек, кызыл бер нәрсә тора. Моны «магҗүн» диләр. (Әфиюн һәм башка дарулар катнаштырып ясалган, борчак кадәрсен генә капсаң да, җанга рух биреп, кәефләндереп җибәрә торган бер нәрсә. Моның артыннан сөтсез чәй эчәләр. Чәй эчкән саен кеше кәефләнә бара.) Шушы «магҗүн»нән һәркемгә бирәр борчак кадәре генә биреп торалар. Чәй һәм хәзрәтнең шунда килгән муллалар белән сөйләве озакка сузылды. Мин, басып тора-тора арып беткәч, ишек төбендә кысылып утырдым. Ишан белән күрешүне көтәм. Тәртип буенча шулай кирәк дигәннәр иде.

Бер вакыт ишан хәзрәт, урыннан торып, ишек төбенә килә башлады. Һәр яктан шалтыр-шолтыр алтын, көмеш яварга керәште. Һәркем аның кулын үбеп күрешә дә, соңра алып килгән сәдакасен бирә. Бик илтифатсыз гына бер кулын биреп икенче кулы белән акчаны ала. Әллә ничә кеше биргән сәдакага бер генә мәртәбә битен сыйпап куя. Ул әкренләп ишек төбенә—безнең тирәгә дә килеп җитте. Өшкертергә килгән аурулар—казак хатын-кызлары алдагы бүлмәдә утыралар иде, алар янына да килеп, өс-башларына карап бер-ике өреп, ниндидер сүзләр әйтеп үтте. Тик бер бик матур җиткән казак кызы янында озаграк тукталып, аның маңлаен һәм күкрәген тотып карады. Теге ауру чынлап та бик матур иде!..

Шулай итеп бөтен зал һәм алдагы бүлмәне урап чыкканнан соң, өстәл янына утырды. Төрле яктан, вак капчыклар белән, тозлар суза башладылар. Өстәл өсте тоз белән тулды. Ишан боларның өстенә бер генә мәртәбә өрде дә, шуның белән эшләре бетте. Һәркем үзенең тозын яңадан алды. Аннан соң ауруларга төрле дарулар өләшергә керәште. Мин әле аларның нинди дарулар икәнен бер дә белмим. Тик ишан хәзрәт биргән дару булгач, ул даруларның шифалы булуларына да шөбһә итмим.

Кешеләр күрешкән рәттән мин дә күрештем. Башта бер сүз дә әйтми, «Нигә килдең?» дип сорамый үтеп китте. Сон-

ра Минһаҗ мулла сүз башлап, минем укырга килгәнемне сөйләде. Шуннан соң ишан миңа карап: «Кайда укыдың, нәрсә укыдың, паспортың бармы? дигән сөальләрне бирде.

Мин югарыдагы ике сөальгә тиешле җавап биргәннән соң, паспортның юклыгын, тәәссефкә[1] каршы өйдә онытылып калганын сөйләдем.

— Юк, балам, юк. Паспортсыз мәдрәсәгә керергә рөхсәт юк. Ярамый!—дип сүзне бик кыска бетерде.

Мин нәрсәдер әйтергә теләгән идем, ишан тыңлап та тормый икенче кешеләр белән мәшгул булып китте. Димәк, минем монда эш бетте. Я кайтып паспортны алып килергә кирәк яки башка бер чара эзләргә тиеш була.

Мәҗлестәге кешеләрнең элек килгәннәре чыга башладылар. Минһаҗ мулла белән суфи да чыкты. Мин алар белән бергә мосафирханәгә кайттым. Минһәҗ мулла: «Паспорт булмагач ярамас шул, ишан белми әйтмәс. Әллә нинди бәләгә очрарсың. Иң яхшысы син безнең белән кире кайт. Көзгә каршы кабат килерсең», диде. Ишанның сүзе алар өчен катгый икән... Ул, ярамый дигән эшләрнең һичберсен эшләргә ярамый. Эшләргә кушкан эшләрен нинди генә булса да эшләргә кирәк. Әгәр дә каршы килсәң, берәр уңайсызлыкка очравыңда һичбер шөбһә юк (?). Мин боларның киңәшләренә риза булдым. Болар белән кире кайтып, паспорт алып килергә карар бирдем. Болар өч көннән соң кире кайтачаклар иде. Шуларны көтеп өч көн буенча мәдрәсә тирәсендә йөрдем.

Мәдрәсә шәкертләре кыргыз арасына таралып беткәннәр, монда тик бер-ике дистә чамасы гына кеше калган иде. Боларның һәммәсе дип әйтерлек тәсбихлы шәкертләр булып, үзләренчә бүгеннән җәннәт ачкычы кулларына тоткан, ишан фатыйхасы аркасында гыйлем дәрьясына кергән кебек йөриләр иде. Минем кебек чабаталы кешегә илтифат итүче булмады. Шулай да боларның бик күбесе «Шәрхе мулла» тирәсендә генә йөзгәнгә күрә, боларның коры кабык икәнлекләрен төшенеп була иде.

Шуның өстенә, монда кая карасаң анда мөрит, суфилар тулган булып, бөтен эшләре намазга барып, тәсбих тартып кайтудан гыйбарәт иде. Монда тагын бик мәһабәт йөргән пишкадәм хәлфәләр дә күп. Боларга якын барып сүз кушу, мөнасәбәт ясау вак шәкертләргә мөмкин түгел кебек күренә. Шуның өчен, мин боларга хөснозан[2] белән

[1] Тәәссефкә каршы—кызганычка каршы.
[2] Хөснозан—яхшы дип уйлап.

карап, «Болар бик галим кешеләрдер инде...» дигән фикерне башка утыртып куйдым. Һәм моңарчы үзем укып йөргән мәктәп, мәдрәсәләргә караганда ишан хәзрәт мәдрәсәсенең артык һәм күп нәрсәләр укыла торган булуына бер дә шигем калмады. Шуның өчен көз көнендә тәкрар килү уе белән кире кайтып китәргә уйладым.

Өч көннән соң Минһаҗ мулла белән теге суфи эшләрен бетерделәр. Мин дә ничек килдем, шулай аларның күчерләренә утырып кире юлга чыктым.

Эшнең болай булып чыгуы, укырга дип китеп тә кире кайту, күңелгә начар тәэсир итсә дә, җәй көнендә берәр урында эшләп, бераз акча хәзерләп килүне уйлап күңелемне юата идем.

Биш көн эчендә Ак Көчек аулына кайтып та җиттек. Мин тагын да маглүм ил мулласының өенә төштем. Ләкин болар минем Троицкийда тора алмавымны белгәч, күңелсезрәк каршы алдылар. Ничек тә шунда бер кич кунганнан соң, тагын юлга ялгызым чыгып киттем. Борынгы өйрәнгән юл буенча сәфәрне дәвам иттердем.

Берничә чакрымнар барганнан соң, хәл җыярга утырган идем, артымнан җәяүле ике кеше килеп җиттеләр. Боларның өс-башларына караганда эш эзләп йөрүчеләр яки берәр заводда эшләп тә инде шуннан кайтып баручылар икәнлекләре күренеп тора иде. Шуның белән бергә, боларның бик үткер күзле һәм сүзләрне киная беләнрәк сөйләүләрендә күңелгә курку төшмәслек тә түгел иде. Болар бер дә әйтми-нитми минем янга утырып тәмәке ясап тартырга, шуннан соң гына минем белән сөйләшергә керештеләр.

Сүзне әлбәттә: «Я, егет, кайдан киләсең?»нән башладылар. Мин кайда барып, кайдан кайтып килгәнемне сөйләдем. Сүз байтакка тартылды. Боларның, берничә заводда эш таба алмый, хәзер «Лапашты» заводына барулары маглүм булды. Һәм юл бер якка карап киткәнгә күрә, бергә бармакчы булдык. Болар бик таза булып, шәп йөргәнгә күрә, боларга ияреп бару бик кыен булса да, ялгыз курка-курка баруга караганда бердән, күңелле, икенчедән, куркынычсыз булганга күрә, болардан калышмаска тырыштым. Болар да минем аруымны сизгән булсалар кирәк, бераз барган саен хәлемне сорыйлар һәм туктап тәмәке тарталар иде. Бара, бара болар белән килешеп киттек. Кичкә таба Кәртәле авылына барып җиттек. Ләкин авылда фатир табу бик мөшкел булды. Чөнки бу ике егетнең тышкы күренешләре һәркемне шикләндерә

дерерлек булганга күрәме, нәрсәгәдер фатир бирергә шөбһәләнәләр иде. Ниһаят, боларның берсе бик шәп һәм урынлы итеп сүгенде: «Безгә кайда да бер кояш, әйдә шунда агач арасында кунабыз, безнең бәхет үзебез белән» дип, безне ияртеп авылның читендәге агачлар янына китерде. «Монда чынлап та бик матур бит, иптәш!» дип, шунда ук чәйнекләрен кайнатырга керештеләр. Матур суның яр башында үскән ямьле агачның төбендә шәпләп, тәмләп чәй эчеп алдык. Бик шәпләп хәл җыйдык.

— Ну, нишлибез, иптәшләр, әле кояш баярга ике сәгать вакыт бар, «Лапашты» моннан унике чакрым. Без анда караңгы төшүгә иркен җитәбез, кузгалабызмы?—диде берсе. Икенчесе дә аңа кушылып: «Давай китәбез, безгә бу башкырт авылын каравыллап ятудан файда булмас» дип, иптәшенең фикренә кушылды. Бу эш минем өчен яхшы ук авыр булса да, мин болардан калуны мәслихәт күрмәдем. Шунда ук капчыкларны аркага асып, тау буйлап, урман арасына кереп тә киттек.

Башта бару бик артык күңелсез булмады. Ләкин бик күп баргач кына юлны адашып, урман юлы белән китүебезне сизә башладык. Барган саен юл начарлана, бетәргә якынлаша иде. Ул арада кояш баеганлыгы мәгълүм булып, эре агачлар арасы караңгыланды. Безнең бара торган юлыбыз да төрле якка таралып, эш бөтенләй чуалды. Мин генә түгел егетләр дә шөбһәләнделәр. Аю-фәләнгә очрау ихтималын сөйли башладылар. Әле һаман сукмак кебек тар гына бер эздән барсак та бу эзгә аркылы-торкылы агачлар авып, йөрергә соң дәрәҗәдә уңайсыз итәләр иде. Тик болар, бу сукмакның берәр күмер яндыра торган җиргә барып чыгуын ихтимал тотып, күңелне юаталар һәм еш-еш кына кычкыралар иде.

Караңгы төште. Без бөтенләй үлән каплаган эздә, урман уртасында торып калдык.

— Чу, тукта!.. Кыңгырау шалтырый түгелме?—диде берсе. Аның сүзе буенча өчәвебез дә туктап, диккать белән кыңгырау тавышын тыңлый башладык. Чынлап та колакка кыңгырау тавышы ишетелә иде.

Бу инде якын тирәдә күмер яндыра торган урын барлыгын, бу тавыш шуларның атлары муйнына тагылган кыңгырау тавышы икәнен белдерә иде. Тагын да бераз тыңлагач, тавыш ишетелгән якка киттек. Барган саен кыңгырау тавышы якынлаша бара иде. Менә бер вакыт урман арасыннан эт тавышы да ишетелә башлады. Хәзер монда

торган кешеләрнең барлыгы ачык маглүм булды. Без зур өмет белән эт тавышы ишетелгән якка киттек. Ут күренде. Менә ут тирәсендә йөргән кешеләрнең шәүләләре, бара торгач, аларның безгә таба караган ялтыравыклы күзләре күренде.

Без алар янына барып җиттек. Табигый, башта алар безне бик нык шикләнеп, саклык белән каршы алдылар. Хәтта берсе үзенең җиргә ташлаган тимер көрәген кулына тотты. Ләкин без адашуыбызны сөйләгәч, басылдылар һәм «Лапашты» ның өч чакрым сулда калганын, болар яныннан «Лапашты»га туп-туры юл киткәнен сөйләделәр. Болар һәр хәлдә монда кунуыбызга авырсыналар кебек күренәләр иде. Ләкин без китмәскә карар бирдек, шунда кунып калдык. Иртән тору белән китеп «Лапаштыга» барып кердек.

Мин мондагы авылдашлар янына төштем. Теге иптәшләр казармага төшеп, шул көндә үк эшкә яллавдылар.

Монда бераз эш эзләп карасам да, үземә муафик булган эш табылыр төсле күренмәде һәм нигәдер минем монда торасым килми, икенче җиргә китәсем килә иде. Мин монда бер-ике көн тордым. Үзем кебек эш эзләүче бик таза бер егеткә очрадым. Бу егет миңа моннан кырык чакрымнарда, «Калма-елга-Инҗәр» дигән заводда эш барлыгын сөйләп, мине үзе белән шунда алып китәргә кызыктырды. Кайсы юл белән кайтсам да, мәсафә бер микдарда булганга күрә, мин сүзсез риза булып чыгып киттек. «Калма-елга» заводы моннан кырык чакрым ераклыкта булганга күрә, бер көн эчендә барып җитә алуыбыз мөмкин түгел иде. Шуның өчен юлда күмер яндыручылар янында кунып, икенче көнне төштән соң барып кердек. Ләкин безнең эштән бәхет булмады. Бер-ике көн эш эзләп казармада ятсак та эш таба алмадык.

Безгә монда тагын, шушы җирдән кырык биш чакрым чамасында яңа завод салына башлаганын, анда эшчеләргә ихтияҗ зур икәнен сөйләделәр. Без икәү анда китәргә риза булып, юлын өйрәндек тә, төштән соң чыгып та киттек.

Көннәр матур, таулар арасында нур уйнап тора иде. Шуңа күрә, сәфәрнең мөваффәкыятсезлеге, юл йөрүнең кыенлыгы бөтенләй онытылды.

Без шулай икәүләп бик күңелле барган вакытта, таштан ташка бәрелеп, шаулап агып яткан елгага очрадык. Бу суның Бәләкәй Инҗәр дигән су икәнен башта ук белгән идек. Ун саженнар чамасы киңлектә булган бу суның

тирәнлеге артык маглүм булмаса да, аны аркылы үтеп киткән ат аягы эзләре һәм арба тәгәрмәче юллары беленеп ятканлыктан, моннан аркылы кичеп чыгуның мөмкин икәнлеге күренә иде. Без алай-болай уйлап тормый аякларыбызны чишенеп бил тиңенте төрендек тә суга кереп киттек. Су ниһаят каты акканга күрә, аякны үзе белән алып китәргә көчләп тора иде. Иптәш егет таза һәм миннәм зур да булганга күрә, алдан китте. Ниһаят, ул аръякка барып чыгарга якынлашты, ләкин мин, инде суның уртасына җиттем дигән чакта, су уңгаена ага һәм авып китә башладым. Тотынырга һәм ярдәм өмет итәргә һичбер юл калмаганга күрә, кычкыра башладым. Суның агымы мине бер минуттан соң үзе белән алып китте, зур ташларга бәрәчәк вакыт җитте. Ләкин шул минутта иптәшем килеп миңа таяк тоттырды һәм шул ук минутта арттан бер атлы башкырт килеп җитте, миңа үзе менгән атның койрыгына ябышырга кушты. Шулай итеп алар икәүләп мине үлемнән коткарып, икенче якка алып чыктылар.

Без сәфәрне тагын дәвам иттердек. Икенде җитәр алдында баягы судан да зур булган Олы Инҗәр дигән су безнең юлга аркылы төште. Без моны үтәргә тиеш икәнбез. Мин яр башында тып туктап уйга калдым һәм, суга агып китүемнән куркып, бер адым да алга бармаска, бәлки шуннан бер чакрым җирдә генә күренеп торган тау буендагы авылга борылып барырга карар бирүемне иптәшемә сөйләдем. Ул мине димләп караса да булдыра алмады, ниһаят, миннән аерылып, су аркылы үзе генә чыгып китте. Мин аның чыгып киткәнен карап тордым да, теге күренеп торган авылга таба киткән юлга төшеп, алга киттем.

Авылга барып кердем. Ләкин авылда һичбер җан әсәре юк. Урамнар алабуга, кечеткән һәм башка үләннәр белән тулы. Тәрәзәләр ябык, капкалар бикле, әлхасил, авыл тәмам ташландык бер хәрабә хәлендә иде.

Бер яктан, авылда кеше булмавы, икенче яктан, кояш батарга якынлашу, мине бик зур күңелсезлеккә, төрле шөбһәләргә төшерде. «Калма-елга» моннан җиде-сигез чакрымнар чамасы булганга, аның өстенә моннан ике-өч сәгәт кенә элек, мине агызып үзе белән бергә китә язган судан чыгарга тиешле булганга күрә, бүген үзем генә булган хәлдә ул якка аяк атлавым һичбер вәҗһедән[1] ярамый иде. Ничек тә шушы ташландык авылда берәр

[1] һичбер вәҗһедән—һич тә, бер дә.

җан иясе табу өмете белән, урам буйлап югары очка таба карап алга киттем. Шулай җан иясе эзләп бара торгач, авылның иң яхшы йортларыннан берсенең капка төбендә нярләгән ат торганын күреп, шунда карап юнәлдем. Капка төбенә бару белән этләр миңа каршы өреп чыктылар. Боларның һөҗүменнән кычкыра башлаган идем, капкадан бәрәү килеп чыкты һәм миннән нәрсә кирәклеген сорады. Мин кунарга урын эзләгәнемне әйткәч, бу кеше: «Мин хуҗа түгел, хезмәтче, әйдә үзләреннән кереп сора», дигәч, шуңа ияреп ишек алдына кердем. Монда хуҗа булып йөргән кеше Үтәш авылында укып йөргәндә күргән Гомәр исемле егет булып чыкты. Бу кеше мин Үтәштә укып ятканда зур шәкертләрдән санала иде. Мин аны күреп шатландым, монда куна алуыма һичбер шөбһә итми, аның: «Әйдә...» дип әйткәнен көттем.

Ләкин эш мин уйлаганның киресенчә булып чыкты: бу егет башта мине танымаска салышты, соңра таныса да, ул вакыттагы танышлыкның һичбер әһәмияте юк икәнен күрсәткән рәвештә, рәтле сүз дә кушмый, хезмәтчеләренә төрле эш хакында әмерләр бирә башлады. Шулай итеп үз йомышы белән икенче якка китте.

Мондагы халыкның бик нык хәзерләнеп йөрүеннән, хатын-кызларның бик кызу эшләп йөрүләреннән кунак көтү галәмәтләре күренә иде.

Мин шунда якынрак келәт алдына хәл җыярга утырдым. Һәм боларның рөхсәтләрен көтә башладым. Кояш бая башлады. Ярты сәгать кадәр утырсам да һичбер сүз кушучы булмады. Шулай торганда бик шәп атка атланган өч кеше килеп төштеләр. Бу кешеләрне йорт хуҗаларының соң дәрәҗәдә хөрмәт белән каршы алуларыннан үзләренә бик кадерле кешеләр икәнлеге күренеп тора иде.

Минутлар тагын үтте. Кунаклар өйгә кереп киттеләр. Байтак торгач, бер хатын минем янга килеп: «Безгә бүген старшиналар килде, кунак бар, сезгә монда кунарга урын юк. Өй хуҗасы чыгып китәргә куша», диде.

Бу хатынның сүзләре һәм шушы чаклы киң ишек алдында миңа кунарга урын булмавы бик кызык тоелды. Боларның бу мөгамәләләренә нәрсә дип мәгънә бирергә дә белмәдем.

— Миңа өй кирәкми, шушы келәт алдында иртәгә чаклы ятарга рөхсәт бирсеннәр әле,—дидем.

— Юк, ярамый. Әнә теге урамда тагын бер йортта кешеләр тора, шунда бар. Безнең нәрсәләр җәйләүгә ки-

теп беткән, сезгә салып йокларга бер әйбер дә юк,— диде. Бу хатынның сүзләрен ишеткәч, Хуҗанасретдинның арканга он тутырып куйган дигән сүзе искә төшеп көләргә дә, җыларга да белмәдем.

Ул арада хезмәтче егет килеп җитте. Ул да теге хатынның сүзләрен тәкрар итеп, мәсьәләне бик тиз кисте. Хәзер үк чыгып китәргә кушты.

Мин, капчыкны аркама асып, чыгып киттем. Теге хатын әйткән йортны эзләп, икенче урамга төштем. Чынлап та монда бик шәп кенә кара-каршы салынган, такта түбә белән ябылган, гадәттә башкырт авылларында бик сирәк очрый торган бер йортта кешеләр бар икән. Урам як башындагы өйнең тәрәзәләрен ачып чәй эчеп утыралар. Мин тәрәзә төбенә барып, кунарга рөхсәт сорадым. Озын таза башкырт, миңа бераз шөбһә белән караганнан соң, өй эчендәге икенче берәүгә әйләнеп, «Керсенме?» дип сорады. Аның «Керсен!» дигән тавышын ишеттем. Капкага килеп аның ачылганын көттем. Хуҗа чыгып ачты да тагын бикләп куйды. Өй эчендә бер ир, бер хатын һәм уникe, унөч яшьлек кыздан башка берәү дә юк иде. Чәй эчәргә утырырга куштылар, утырдым. Сораша башладылар. Кыскача гына әхвалне сөйләдем. Паспорт юк дигән хәл боларны шөбһәгә төшергән кебек булды, шулай да белдермәделәр.

Теге байларның ни өчен кундырмауларын сорадылар. Мин анарга кунак килгәнен, мине ни өчендер кундырмавын сөйләдем.

Караңгы төште. Чәй урны җыелды. Үзләре бу өйдән кунак өйләренә ятарга чыкмакчы булдылар һәм аска киез, баш астына мендәр биреп, сәке өстендә ятарга кушып чыгып киттеләр.

Яттым. Өй эче тәмам караңгыланды. Тыштан күк йөзен каплаган болытлардан вак яңгыр сибәләп ява башлады. Миңа өй эче бөркү булу өстенә, таракан, кандалалар төрле яктан һөҗүм итә башладылар. Өй эчендә ниндидер шомлы ямьсезлек бар. Мин бик нык арыган булсам да, ач кандалаларның йокларга ирек бирү ихтималлары юк. Шуның өчен төнне яисә бөтенләй йокламый үткәрергә яки моннан чыгып ике өй арасындагы чоланга ятырга кирәк. Мин артык күп уйланып тормый теге биргән киез белән катып беткән мендәрне күтәрдем дә шунда чыктым. Монда һава бөркү түгел. Кандалалар да юк. Мин бик әйбәтләп йокыга киттем дип торганда гына, өй түбәсендә

нәрсәдер дөбердәп йөри башлады. Песи-мазардыр дисәң аның йомшак тәпиләре ничек такта түбәне болай дөбердәтә алсыннар? Өй кыекларына оялаган күгәрченнәрдер дисәң, аңа бик ошамый. Мин шикләнә төшеп бу тавыш чыгаручының чолан түбәсендәме, әллә бөтенләй өй башында— тышкы яктамы икәнен аера алмый аптырап, һаман тыңлап ята идем. Менә бер вакыт хуҗалар яткан өйнең ишеге ачылды. Бер кулына лампы, бер кулына балта тоткан өй хуҗасы чыкты да, соң дәрәҗәдә ачу белән миңа карап:

— Син, карак малай, төн белән нишләп дөбер-дөбер йөрисең?!. Синең ни дә булса усал уең бар икән, мин күптән бирле тыңлап ятам. Син һаман йөрисең, синең иптәшләрең дә булырга кирәк! Ник монда чыгып яттың?!—дип кычкыра башлады.

Мин өйдән чыгуымның сәбәбен һәм әй түбәсендә миннән башка нәрсәнең йөрүен сөйләсәм дә, аны ышандыра алмадым. Ул һичбер минут та тормый өйдән бөтенләй чыгып китәргә кушты. Мин бераз ялынып карасам да, ул аның саен шикләнде, аның саен кыза башлады. Балтасын югары күтәрә төште. Ниһаят, мин торып китәргә, капчыкны алып чыгып китәргә мәҗбүр булдым. Башкырт агай мине ишектән чыгару белән бикләп алды.

Тышта төн караңгы булып, вак кына яңгыр сибәләп тора иде. Миңа эт абалап өрә башлады. Келәт алдына ятырга уйласам да, бу этнең ирек бирү ихтималы юк иде. Аптырагач, капка астыннан урамга чыгып китәргә мәҗбүр булдым. Эт минем итәгемә ябыша язып, чын ихлас белән өреп калды.

Урам тын иде. «Кайда барырга?» дигән уйга төштем. Авылда буш өйләр булса да, бердән, аларның ишек һәм капкалары ябык, икенчедән, аларга керү куркыныч иде. Теге эт минем капка төбендә торганымны сизеп өрүендә дәвам итә иде. Болай эт өрдереп торсам, өй хуҗасы чыгып башка берне кундырудан куркып, кузгалып киттем. Шунда ерак түгел бер өйнең артына барып, яңгыр төшми торган урнына барып утырдым. Монда берничә кәҗә яңгырдан шыкланып, күшәп яталар иде. Мин баргач төрлесе төрле якка китсәләр дә, мин әз генә утыргач та, читләтеп кире минем янга килделәр.

Монда яту башта куркыныч кебек тоелды. Ләкин бара торгач, күңел курыкмый башлады, күз караңгылыкка өйрәнеп китте. Шуннан соң капчыкны баш астына салып, коры һәм елы туфрак өстенә яттым. Кәҗәләр дә миңа

бик тиз ияләшеп киттеләр. Минем белән бер рәттән яттылар. Болар миңа бик якын иптәш кебек күренделәр.

Мин башта эш бик күңелсез һәм урамда калу бик куркыныч булыр дип уйлаган идем. Ләкин эш моның киресенчә булып чыкты. Монда яту белән мин үземнең күңлемдә әйтеп бетерә алмаслык рәхәт бер йомшаклык хис иттем. Куркуның әсәре дә калмады. Мин гомер буена кешеләргә яхшылык итәргә, бу кешеләрнең могамәләсенә карап һич рәнҗемәскә, рухны төшермәскә кирәк, дигән уйга төштем. Күздәге яшь бөртекләре куылып чыгуның хәсрәтеннән түгел, бәлки изге бер уй, шул караңгылык эчендә килгән матур йомшак бер хис аркасында чыгалар иде. Чынлап та монда бик матур тынлык дәвам итә, теге кеше белән эт булмагач, бер нәрсә тарафыннан да куркыныч юк иде.

Әллә кайда, бик еракта, мин тавышын ярата торган Сак-Сок сирәк кычкыра, шуның белән бергә һәмме бөртекләре энҗе зурлыгында гына булган вак яңгыр сибәләп өй түбәсендә бер тигез генә тавыш чыгара иде. Мин шул ике матур тавыш астында, кәҗәләр янында рәхәтләнеп йоклап киткәнемне сизми калганмын. Бер вакыт иртәнге кояшның кызуына уянып киттем. Хәзер болытлар китеп, күк йөзе ачылган, кояш минем өстемә нурларын чәчеп, көлеп караган иде. Ул аның тауларга һәм урманнарга биргән матурлыгы һичбер сөйләп бетерерлек түгел иде. Мин шушы матурлыкның нак уртасында уянып, торып утырдым. Бераз утыргач та китүне уйлап урыннан торган вакытта, теге башкырт агай капкасыннан чыгып, мине чакырды. Һәм өенә алып керде.

Ул бүген бик йомшак иде. Хатыны бигрәк йомшак могамәлә белән югары утырырга кушты. Чәй кайнап тора, аның янына сары майга гына пешергән коймак таба белән алда утыра.

Мин боларның кичә төн уртасында куып чыгарып та, бүген болай хөрмәт итүләренең магнәсенә һич тә төшенмәдем. Ләкин алар бу мәсьәләне үзләре чишеп бирделәр.

Теге мине кундырмаган байлар белән болар авылның иң бай кешеләреннән булып, бер-берсенә соң дәрәҗәдә дошманлыклары бар икән. Мин, гуяки, шул байларның кушуы буенча боларга килеп, боларга берәр төрле зарар уйлап, явыз ният белән кунмакчы булганмын икән дә, төннә үземнең иптәшләремне кертергә, шул иптәшләрем белән боларны үтерергә яки боларның әйберләрен алып

китәргә йөргәнмен икән. Болар шуңа күрә миннән бик зур шөбһәгә төшеп, куып чыгарырга мәҗбүр булганнар икән...

Чәй эчеп утырганда алар, минем турыдагы шөбһәләрен тәмам бетерергә теләгән рәвештә, Троицкий һәм Зәйнулла хәзрәт хакында байтак сораулар бирделәр. Мин әлбәттә күргән-белгән кадәре нәрсәләр сөйләдем. Үземнең Минһаҗ муллага кучер булып кайтуымны әйттем. Шуннан соң гына боларның күңелләрендә минем хакта һичбер начар уй калмаганлыгы беленде. Минем укып йөрүче шәкерт, гарип бер мосафир икәнемә тәмам ышандылар. Чәйдән соң миңа теге агай ун тиен көмеш сәдакә бирде. Гафу үтенгән рәвештә: «Рәнҗеп китмә. Кичә без синең шәкерт икәнеңә төшенеп җитмәдек...» дигән сүзләрне кушты. Минем өчен бик күңелсез булган кичәнең иртәсе бик күңелле булды. Мин әйберләремне күтәреп, болар белән күрешеп, Калма-елга заводына карап юлга чыгып киттем. Алар мине озатып калдылар.

Кичә үзем агып китә язган Бәләкәй Инҗәргә җиткәч, үзем генә суга төшәргә куркып, берәр яктан атлы кешеләрнең килгәнен көтә башладым. Берәр сәгать көткәннән соң, өч сыбай кеше килеп мин аларга хәлне аңлаткач, аларның берсе мине үзенең атына меңгәштереп теге якка алып чыкты. Мин бик зур авырлыктан котылган кебек, шатлык белән Инҗәр заводына барып казармага кердем. Казарма иркен, берничә мин кемнәр икәнен белмәгән кешедән башка кеше юк. Монда миңа муафик эш юклыгын белгәнгә күрә, авылга кайтуны уйлап, берәр юлдаш эзләргә, сорашырга керештем. Монда иптәш эзләп өч-дүрт көн торырга туры килде. Ниһаят, бер эшче рус егете очратып, шуның белән икәү юлга чыгып киттек. Тау һәм урманлы җирләрне ике (көн) йөргәннән соң, өченче көндә яланлы җирләргә килеп чыктык. Юлда борынгы кебек кычкырып килергә, аю очраудан сакланырга туры килде.

Мин, авылдан чыгып китүгә бер ай булды дигәндә, авылга кайтып кердем. Бик күп кеше минем Троицкийга барып кайттым дигән сүземә ышанмадылар. Ул чаклы ерак җирдән бер ай эчендә җәяү йөреп, урап кайтуыма мөхаль бер эш иттереп карадылар. Никтер хәзер миңа авылда торуы авыр һәм күңелсез иде. Шуның өчен бу кайтуда мин авылда дүрт-биш көннән артык тора алмадым. Инҗәр суы буенда быел гына салына башлаган

«Француз-Лямязинский» дигән заводга барып үзебезнең авылның Гани исемле бер итчегә язу-сызу һәм вак-төяк эшләрне эшләргә ялландым.

Монда минем күңелгә иң якын булган нәрсә—бу җирнең матурлыгы булды. Зур таулар арасыннан килеп чыккан зур гына Иңҗәр суы, аның тирәсенең матурлыгы әйтеп бетерерлек түгел иде. Шуның өстенә монда эшче халыкның күплеге, аларның күңелле эшләүләре—һәммәсе дә минем рухка якын булып, барган саен бу тормышка үзләшә бара идем.

Монда минем эшем, Ганинең атасы Кәрим исемле карт белән ит сату, көтәргә биргәннәрен язып кую, үзебезгә аш пешерү, чәй кайнату кебек эшләрдән гыйбарәт иде. Әлхасил, мин сатучы да, конторщик та, аш пешерүче дә бер кеше идем. Кәрим бабай үзе бик күп вакытта исрек булганга күрә, ит сату эшләре дә минем өскә йөкләнгән иде.

Без икәү көн саен дип әйтерлек бер сыер суеп, шуның итләрен сатабыз. Безнең тирәдә хатын-кызлар булмаганга күрә, сыерның эч-карыннары ташланып әрәм була иде. Хәлбуки шул ук җирдә эшкә килеп эш тапмый яки башка берәр сәбәп белән ач йөргән, ит йөзе күрмәгән әллә ничаклы эшчеләр булып, мин шуны игтибарга алып, ташланып әрәм була торган эч-карыннарны су буенда тазартып алып кайтып, зур казан белән аш пешерергә һәм зур-зур тустак ашны ике-өч тиен көмешкә сатарга керештем. Минем бу эшем ач һәм эш таба алмый йөргән иптәшләр өчен бик яхшы булды. Алар миңа иялләшеп киттеләр. Акчалары булмаганнарына көтәргә биреп ашата идем. Бөтенләй акча бирми китсәләр дә монда миңа бер кыенлык та юк иде. Чөнки аш сатудан килгән акчалардан мин хуҗаларга вагы-төягенә чаклы хисап бирергә мәҗбүр түгел идем. Шулай да, элек әрәмгә югала торган һәр көн саен аларга берәр сум чамасы акча җыеп бирүем аларны шатландыра торган булса кирәк, алар минем бу эшемне һәр кемгә мактап сөйлиләр иде. Бу эш, бердән, шулай мондагы эшчеләргә файдалы булса, аның өстенә, төштән соңгы вактымны эш белән үткәреп җибәрергә сәбәп була иде.

Шушы эшләр белән җәйнең үтеп киткәнен сизми дә калдым. Тагын көз җитте. Мин үземә тигән әз-мәз акчаны алып авылга кайтып киттем.

Бу акчаның беразын абзыйга биреп, калганына өс-

баш киеме алдым. Хәзер мин Троицкийга китәргә уйласам да, бердән көзге пычрак булып юл өзелеп барганга, икенчедән, мондый вакытта җәяү йөрү соң дәрәҗәдә авыр булыр кебек булып күренгәнгә, анда китүне чана юлы төшүгә кичектереп, әлегә үзебезнең авыл мәдрәсәсенә кереп торырга карар биреп, шунда кердем.

Җамалетдин мулла мине ничек тә шунда тотарга тырыша иде. Ләкин ул кешедә минем җанга бер тиенлек тә азык бирерлек куәт булмаганын мин бик яхшы төшенә башлаганга күрә, ничек кенә булса да моннан китү җаен карый идем.

Бу кешенең нәхүнең бик гади урыннарында да хата мәгнә бирүләре, куәи гыйлмиясенең[1] соң дәрәҗәдә түбәнлеге, шушы мөнасәбәт белән минем аңа бәйләнүләрем—ике араны боза башлады. Барган саен ара салкынайды. Ара салкынаю минем өчен матлуп булганга күрә, моңа карап шатлана гына идем.

Кар яуды, чана юлы төште. Ниндидер бер эш сәбәпле мулла абзый белән бик каты ачуланышырга туры килде. Мин шушы форсатны ганимәт белеп, мәдрәсәне ташлап чыгып үзебезнең өйгә кайттым.

Шушы вакыйгадән өч-дүрт көн үтү белән «Лапашты» заводына йөк төяп баручыларга утырып, кулыма паспорт алып, юлга чыгып киттем. Өстә бик юка булу сәбәпле, юлда бик нык өшергә, күп вакытта җәяүләп йөгереп барырга туры килде. Йөк төягән олаучылар бик ашыкмыйлар. Бигрәк тә кар тирән төшкән, әле юл такырланып җитмәгән урыннарда алар туктар-туктамас бер хәлдә баралар. Шуның өчен юл авыр булды. Тик өч-дүрт көннән соң гына «Лапашты»га барып кердек. Инде «Лапашты» заводыннан Троицкийга карап ничек һәм кем белән китү мәсьәләсе килеп басты. Табигый, кыш көнендә ялгыз баш китү һичбер мөмкин түгел. Чөнки бердән, бу тирәләрдә авыл араларының бик ерак булуы, икенчедән, көннәрнең салкынлыгы ялгыз китүгә юл куймый иде. Минем бәхеткә каршы Верхний Урал өязе, Ачулы волосты, Исламгул авылының иген сатарга килгән кешеләре очрадылар. Ун-унбиш чанадан гыйбарәт булган бу юлаучылар игеннәрен сатып буш кайтачак булганга, алар өчен мине утыртып алып кайту бер нәрсә дә түгел иде. Шуның өчен бу кешеләр бер әйтү белән мине үзләренә

[1] Куәи гыйлмия—белемнең көче.

(150 чакрым чамасында) чаклы алып кайтмакчы булдылар. Килгән көнне алып килгән оннарын сатып, иртәгесен иртүк юлга чыктылар. Мине бодай салып килгән торыпшаларга урап, өстемнән тагын да торыпша ябып бәйләделәр. Мин хәзер алар эчендә рәхәтләнеп ятам. Үзем теләгәндә торыпшаның бер як читен ачып карыйм. Мин утырган атны да уртадан буш җибәрделәр. Үзләре бераз төшереп алып атларын куа башладылар.

Мин елы урында юлның күбесен йоклап үткәрдем. Тик атларны ашатырга туктап, чәй эчәргә кергәндә генә алар мине чишеп алып керәләр, соңыннан тагын әввәлге кебек иттереп бәйлиләр иде. Уртада бер куныл, икенче көнне кич белән үзләренең авылларына кайтып керделәр. 150 чакрым җирне ике көндә барып җиту, минем өчен бик зур шатлык булды. Хәзер мин Троицкийга якынлаша төштем.

Бу авылда бер көн торганнан соң, Ахун авылына баручылар белән киттем. Ахун авылында фәкыйр генә бер кешегә кереп торырга туры килде. Болар фәкыйр булсалар да күңелләре бик бай булганга күрә, үзләрендә озак торуыма уңайсызланганымны сизү белән, мине юата һәм уңайсызланмый, үз йортымда торган кебек торырга кушалар иде. Мин һәр көнне Троицкийга баручы юлдаш эзләсәм дә, монда әле рәтләп чана юлы төшеп бетмәгәнлектән, һичбер баручы очрата алмый идем. Мин Ахун авылында берәр атна ятканнан соң гына кар яуды.

Троицкийга укырга баручы Мөхәммәтҗан дигән бер шәкертнең агасы, мине үзләре янына утыртып, Троицкийга алып китте. (1898 нче ел, ноябрь.)

Без Троицкийда Зәйнулла ишан мәдрәсәсе янындагы маглүм мөсафирханәгә төштек. Иптәшем электән монда берничә еллар укып йөргәнгә күрә, үзенең махсус урнына, борынгы иптәшләре янына күчте. Мин мөсафирханәдә калдым. Хәзер мәдрәсәләр шәкертләр белән шыгырым тулганнар иде. Беренче күрүдә мондагы шәкертләр һәм аларның тормышлары, байлыклары мине гаҗәпкә калдырды.

Боларның бик күбесе бай балалары, калганнары казак арасына муллалыкка чыгып акча җыеп кайткан акчалы шәкертләр булып, һәрберсе бик эре киенеп, төзәнеп йөриләр иде. 5—6 йөз шәкерт эчендә минем кебек чабаталы шәкертләр 5—6 гына булганга күрә, безнең чабаталар ямьсез дә, мескен дә, кызганыч та күренәләр иде.

Мин бераз вакыт мәдрәсәгә керми мөсафирханәдә ятып, шунда куныл йөрдем. Башта берничә көнгә чаклы көндезләрен төрле мәдрәсәләргә кереп, ишекнең төбеннән генә карап йөри идем. Югары үтәргә мөмкинлек булмаганга күрә, мич буена, шәкертләрнең киез һәм паласлары җәелмәгән җиргә утырып, аларның укулары, дәрес алулары вә башка хәрәкәтләре белән танышып утыра идем.

Троицкийда ишан мәдрәсәсеннән башка тагын берничә мәхәлләдә мәдрәсәләр бар. Боларның кайберәүләрен барып карадым. Ләкин боларның һәммәсе дә бер төсле, бер тәртиптә күренәләр иде. Шулай йөри торгач, «Яушевлар Җәмгыяте Хәйрия мәктәбе ачканнар имеш... анда бөтенләй яңача укыталар икән...» дигән хәбәр ишеттем һәм икенче көнне шул мәктәпне эзләп таптым .

Мәктәпкә барып керү белән мине бер төрле гаҗәпсенү алды. Мин бу мәктәпкә керү белән, аның моңарчы үзем күргән мәктәп, мәдрәсәләргә караганда башка икәнен күрдем.

Ишектән керү белән, берәү мине туктатып ни өчен килгәнемне сорады. Мин мәктәпне күрер өчен килүемне әйткәч, чабатамны чишенергә кушты. Мин ул кушканча эшләдем. Ул миңа «Шәкертләр теге бүлмәдә сабак алалар» дигәч, коридор буйлап шунда киттем. Уңга карасам, андагы бүлмә кровать белән тулган. Һәммәсенең өсте дә аппак нәрсә белән ябылган. Бүлмә бик таза һәм матур. Сул яктагы бүлмәдә озын өстәл, аның тирәсенә урындыклар тезелгән. Өстенә тәрилкә, кашыклар куелган. Хәлфә дәрес биргән бүлмәне акрын гына ачып кердем дә арттагы буш партаның бер як читенә утырдым. Укытучы хәлфә башына бик шәп фәс, өстенә өр яңа җөббә кигән. Үзе бик мәһабәт, 30—35 яшь чамасындагы бер кеше. Шәкертләр һәммәсе дә бер төсле киенгәннәр. Хәлфә дә, шәкертләр дә миңа күз төшереп алдылар. Кайберәүләре елмаеп куйдылар. Стенага ашъяулык зурлыгындагы теге мин Уфада күргән төсле буяулы кагәз эленгән. Мин парталарны рус мәктәпләренең тәрәзәләре аркылы гына күргәнем бар иде. Хәлфәнең артында елтырап торган кара буяуга буялган зур кара такта басып тора. Кыскасы, бу мәктәптә моңарчы мин күрмәгән яңалык һәм башка төрле тәртип күренеп тора. Мин монда укучы шәкертләрнең бәхетләренә кызыктым. Боларның һәммәсе дә шәп, һәммәсе дә мин белмәгән белемнәрне беләләр кебек булып күренделәр.

Минем үземнең өстемә кигән җиләнемне башымдагы мескен бүрекне, билемә бәйләгән кызыл башлы тастымалны боларның киемнәренә чагыштырып, уңайсызланып калдым.

Дәрес гарәпчә нәхудан бара иде. Ниндидер бер җөмләдә мин хәлфәгә бәхәс итәргә уйладым һәм, аны-моны карап тормый, бәхәс итеп ташладым. Хәлфә минем сүзне илтифатсыз калдырмады, җавап биреп китте. Минем сүземнән кайбер шәкертләр елмаеп көлделәр. Дәрес ахрында, нинди мөнасәбәт беләндер, елның кайсы числолары утыздан, кайсылары утыз бердән килү турында сүз чыкты. Хәлфә ике кулының бармакларын йомып, шулар аркылы числоларының ничәдән килүләрен күрсәтергә кереште. Аның өйрәтүе бик-бик авыр һәм чуалчык күренде. Мин чыдый алмадым:

— Хәлфә әфәнде, числоларның ничә көннән килүләрен белер өчен, моннан да җиңел юл бар бит,—дидем. Бөтен шәкертләр миңа карадылар. Хәлфә мине бер төрле мыскыл иткәнсымаграк елмая төшеп:

— Я, әйтеп кара әле. Ул нинди юл икән?—диде.

Мин каядыр (Каюм Насыйриның календарында булса кирәк) числоларның көн саннарын белер өчен Петр Великийның «ап, юнь, се, но» дигән сүзләрен укыган идем. Хәлфәнең соравына бер дә аптырап тормый:

— Числоларның көн саннарын белер өчен «ап, юнь, се, но» сүзләрен генә ятка алырга кирәк. Ап—апрель, юнь—июнь, се—сентябрь, но—ноябрь...—дигән сүз була. Шулардан башка айлар утыз бердән киләләр. Тик февраль генә өч ел егерме сигездән, дүртенче ел егерме тугыздан килә,—дидем.

Хәлфә минем сүзне тәкрарлатты һәм шунда ук:

— Бу юл бик җиңел икән,—дип «апъюньсено» сүзләрен тәкрарлады. Шунда ук башка шәкертләр дә авыз эчләреннән шул сүзләрне тәкрарлыйлар иде...

Дәрес беткәч, мин хәлфә белән күрештем. Ул минем кайдан килүемне, кайда торуымны сорашты да:

— Әгәр телисең икән безнең Җәмгыяте Хәйрия мәктәбенә кер. Гәрчә монда алынырга тиеш булган шәкертләрнең саннары тулган булса да, мин сине бүгеннән алам,—диде. Аның бу сүзләреннән соң, мин бик шатландым. Үземнең теге бәхетле шәкертләр рәтенә керүемне уйлап, шунда ук:

— Рәхмәт, хәлфә әфәнде. Мин ишан хәзрәттән рөхсәт

алыйм да, монда килермен,—дидем. Хәлфә шунда ук мине ияртеп, икенче берәү янына алып барды һәм үзара нәрсәдер сөйләшеп, алар икәүләп бүген үк монда килергә мөмкин икәнен әйттеләр.

Мин бу мәктәптән шатлык белән чыгып, «Иртәгә иртүк ишан хәзрәткә кереп рөхсәт алырмын да, монда килермен» дип, мөсафирханәгә кайттым. Иртәгесен ишан хәзрәткә барып, бик озак көткәннән соң, вактын табып Җәмгыяте Хәйрия мәктәбенә китәргә рөхсәт сорадым. Хәзрәтнең рөхсәт һәм фатыйха бирүенә ышана идем. Ләкин эш алай булып чыкмады.

— Юк, юк. Рөхсәт юк. Ул мәктәп—фатыйхасыз мәктәп ул. Анда укып кеше була алмассың да!—дип кырт кисте, һәм:

— Бар, кайт, укый башла. Мөхәммәт хәлфәдән укырсың, миннән фатыйха,—дип кул күтәреп дога кыйлды. Мин инде шундый зур ишан хәзрәт булгач, белми әйтмәс дип, үзем дә аның белән дога кылдым. Җәмгыяте Хәйрия мәктәбенә бармаска карар биреп, кайту белән мөсафирханәдәге капчыгымны алып, мәдрәсәгә күчтем. Анда кереп мич янына урнаштым. Монда миңа илтифат итүче, сүз кушучылар юк иде. Тик шул тормышның авырлыклары эчендә ватылган, башкаларга самовар куеп йөргән сынык күңелле, ертык киемле, эшкә түземле шәкертләр генә минем янга килеп, кайдан килүемне сорашып утыра торганнар иде. Шулай итеп мәдрәсәдә үземә муафик берничә иптәш ясап алдым һәм дәреснең тәртип, низамнарына өйрәндем...

Бу мәдрәсәләрдә тәрәзә яныннан, стена буеннан урын ишгал итәр өчен үзеңне мадди җәһәттән тәэмин итәрлек азык һәм акча булу белән бергә, әйберләрең булу шарт ителгән кебек булганга күрә, мин тәрәзә янында торудан, урын алудан мәхрүм идем. Мәдрәсәгә кергән вакытта ук, минем акча ягы такырайган иде. Кереп берничә көн торгач, бөтенләй акчам бетте. Бер-ике көн ачлы-туклы тордым да, ниһаять шундагы дүрт-биш шәкерттән гыйбарәт булган бер казандашлар груһына самовар куеп, аш пешереп торырга кердем. Монда шундый шәкертләрне «малай» дип йөртәләр. Алар тагбиренчә әйткәндә мин шуларга «малай» булдым. «Малай» булган шәкертләргә кичен башка шәкертләр ятып беткәч кенә, җәмагәт сәкеләрендә, мич буйларында ятып йокларга рөхсәт булса да, көндез, әлбәттә, бу урыннарда утыру, уку бик уңайсыз. Шуның

өчен, көндезләрен күп вакытта кайда урын булса, шунда утырырга, урын булмаса аяк өстендә йөрергә туры килгәнгә күрә, мин шулай йөри башладым.

Мин килгән көннәремдә мондагы шәкертләрнең бик күбесен уку мәсьәләсендә бик шәпләрдер дип уйлый идем, ләкин бик аз вакыт эчендә боларның бик күбесенең кием калыбы икәнлекләре маглум була башлады. Мәсәлән, кай берәүләре коры «Шәрхе мулла» китабын гына өч-дүрт елдан бирле укып йөрсәләр дә, әле бер нәрсә дә аңламыйлар иде. Соңра мондагы шәкертләрнең бөтенесе ишанга мөрид булып, тасаввеф[1] юлына кереп тәсбих тартып йөриләр, укудан бигрәк, тизрәк ишан булуны күз алдында тоталар, боларның башларыннан чалма, өсләреннән чапан төшми иде. Мин бер-ике айга кадәр боларның бу эшләренә магнә биргән кебек йөрсәм дә, аннан соң боларда фәкать аңсызлык сизә башладым. Монда унбиш яшьле малайларга чаклы мөрид булып кергәннәр иде. Болар каршында мөрид булмаган, ишаннан күңел сабагы алмаган кешеләр—болар инде бөтен фәзыйләттән мәхрүм кешеләр булып тәләккый[2] ителәләр һәм шуны бүтән шәкертләргә тукып кына торалар иде.

Мин ике ай чамасы шәкертләргә самовар куеп йөргәннән соң, урыннан чыгарылдым. Шәкертләрнең кайберәүләре кыш уртасыннан башлап кыргыз арасына тарала башлаганга күрә, самовар куйдыручылар да азая башлады. Шуңа күрә, мин урынсыз калдым. Акча бетте. Бүген ашамый торуга чыдадым. Икенче көнне дә ач торырга туры килде. Башка шәкертләр симез куй итләре ашап утырганда яки аларның ак күмәчләр белән тәмләп чәй эчкән чакларында карап утыру уңайсыз булганга күрә, ашау-эчү вакытларында мәчеткә барып, шунда аулакта вакыт үткәрергә туры килә иде. Ак күмәчнең кадагы өч кенә тиен булса да, ул өч тиен акча миндә булмаганлыктан, күмәч алып булмый иде. Өченче көн ашамый, коры су белән тору яхшы ук кыен була башлады. Болай күнегеп кителсә дә, хәл бетә, күз аллары караңгылангансымак булып китә башлады. Минем кешедән икмәк сорау ихтималым булмаганга, шуның белән бергә минем хәлне беркем дә сизмәгәнгә, мин һаман шулай йөри, бөтен көн буе сабак укып утыра идем.

---

[1] Тасаввеф — суфилык, суфиларча булу.
[2] Тәләккый ителү—табылу, танылу.

Икенче бер авыр як—кич яту мәсьәләсе булып, (бу) эш тагын да хәлне бетерергә сәбәп була иде. Махсус урын юклыктан, җәмагәт сәкесендә ятарга туры килгәнлектән һәм кешеләр ятып беткәнне көтәргә, ятканда баш астына бүрекне салып, өскә җиләнне ябынып как идәнгә ятарга туры килә иде.

Мәдрәсәдә һичбер укымый һәр вакыт скандал чыгарып йөрүче, үзенең көче белән бөтен шәкертләрне куркытып бер каравы белән кешеләргә тәэсир итә торган Михиан дигән бик таза шәкерт бар иде. Бу кеше болай карагаңда һичкемгә изгелек итү, кешенең әхвал рухиясенә төшенү, башкаларның положениесенә керү ихтималы юк кебек күренә торган иде. Ләкин бу алай булып чыкмады. Ул минем авыр хәлдә булуымны сизде булса кирәк, һичбер сорамый-нитми мине чәй эчәргә чакырып, туйганчы ашатты. Миңа хәл кертте. Мине сорашты. Шуннан соң һәр көн үзләреннән артып калган аш белән ярты кадак чамасы күмәч бирә башлады. Шулай итеп мине авыр хәлдән коткарды.

Бераздан соң тагын да самовар куярга кереп, укуымны дәвам иттердем. Хәзер мин мәдрәсәнең бөтен тәртипләренә, андагы хәлләргә төшенеп беткән идем инде. Шуның өчен, килгән вакыттагы кебек, һәр кемнән кагылудан, аларга ис китеп караудан чыктым.

Апрель башларында укучылар таралып бетәргә якынлаштылар. Аларның бик күбесе казак арасына укытучы мулла булып тaралдылар. Мулла булып китәргә ихтыяҗлары төшмәгән бай малайлары үзләренең илләренә—авылларына кайтып киттеләр.

Мәдрәсәдә укулар тукталды. Без казак арасына да чыкмаган, илебезгә кайтуга да имкан[1] булмагам берничә шәкерт белән, берничә сукыр суфи торып калдык. Хәзер безнең уку юк, ашарга да бик такыр. Иртән торгач, төрлебез төрле җиргә эш эзләп чыгабыз. Ләкин һичбер эш табып булмый. Тик берничә көн эзләнгәч кенә өч иптәш бер тире җыючы байга көннекләп эшләргә ялланып, меновныйга эшкә йөри башладык. Монда без чи тиреләрне киртәгә элеп киптергәндә киереп куяр өчен чөй очлый идек. Берәр чирек, ярты аршин чамасындагы чөйләрнең ике як башын очлар өчен мең данәсенә егерме биш тиен түлиләр. Көндезге аш байлар өстендә. Без беренче көндә

[1] Имкан—мөмкинлек.

бик тырышып эшләгәндә дә дүртәр-бишәр йөз чамасында чөй очлый идек. Бара торгач, бу эшкә бик өйрәнеп киттек. Иртәдән кичкә чаклы сигезәр йөз, хәтта меңәр данә чөй ясый башладык. Бу кәсеп безнең өчен бик шәп булып төште. Һәр көн алган егерме, егерме бишәр тиен акчабыз ак күмәч ашаудан да артып кала башлады. Без тәмле тамакланып киттек. Ак калачка гына канәгать итми хәлвә кебек әйберләр дә ала торган булып киттек. Ләкин безнең өчен бик файдалы булган бу кәсеп унбиш көннән соң тукталды. Тагын эш эзләргә кирәк. Кайберәүләр мойкага йон юарга, кайберәүләр Яушевларның торф суктыра торган җирләренә киттеләр.

Мин, кулыма шеш чыгу сәбәпле, бу иптәшләр белән эшкә китә алмый мәдрәсәдә калдым. Көн озын, ашарга аз, иптәшләр юк. Шуның өчен бу көннәрне үткәрү авыр һәм күңелсез иде. Монда, миннән башка, Якуп карый дигән бер сукыр белән, гомренә шушы мәдрәсәдә яткан Нурый карт дигән карт бар иде. Өченче кыш мәдрәсә ишек алдын тазартып, җәй көннәре хәзрәтнең вак-төяк эшләрен эшләүче бик тупас берәү мәдрәсәдә кунып йөри. Дүртенче— мин. Кыш көнендә һичбер мөнасәбәте булмаган без шушы дүрт кеше дуслашып киттек. Безнең дуслашуны чыгыта торган нәрсә минем аларга хикәяләр укудан башланып китте. Мин боларга иң элек «Мең дә бер кичә» хикәяләрен укыдым. Бик күңелле булган, тыңлаган саен тыңласыны китерә торган бу хикәяләрне укыйм. Алар мине иртән чәй эчерәләр. Аш пешергән көнне көндезге ашны үзләре белән бергә ашаталар. Беренче, икенче томнарны өч төн эчендә укып чыктым. Инде «Мең дә бер кичә»нең ике генә томы калды. «Әгәр дә мин бу ике томны да укып чыксам, бу кешеләрнең миңа ихтыяҗлары калмый, шуннан соң алар мине ашатудан тукталачаклар...» дигән уйга төшеп, мин укуымны әкренләтә төштем. Хикәянең иң кызыклы җиренә җиткәч кенә юк-бар сылтау белән укудан туктала торган була башладым. Шулай мин назлана төшкәндә, алар миңа: «Укы әле... иң кызык җиргә җиткәч туктыйсың», дип ялыналар. Ләкин мин аларны ялындыруны еш эшләмим. Ике ара бозылып, аларның мине чәй эчерүдән мәхрүм итүләреннән куркам.

Чәй эчкәндә, әле генә укыган хикәядәге каһарманнар, матур кызлар, андагы чиксез матур булган тормышлар хакында сүз китә. Минем тыңлаучыларымның өчәвесе дә матур кызлар һәм аларның сөйгән егетләре белән очра-

шып «пуся алышу»ларын сөйләгән чакта, авызларыннан сулар ага. Үзара бәхәсләшеп китәләр. Бигрәк тә сукыр Якуп карый сөйләшә башласа, аның ак салган ике күзе хәрәкәткә килеп, зураеп тәгәрәп йөргән кебек булып күренәләр. Сүз сөйләргә комачаулык итәр төсле булып күренгән калын һәм салынып торган ирене чәпелди башлый, авызыннан төкерекләре чәчелә. Тумыштан сукыр булган, анасыннан башка хатын-кыз кочагы күрмәгән, гомренә өйләнү бәхетенә ирешмәгән бу кеше хикәянең хатын-кызларын сөйләгән җирләрендә кулларын уарга керешә. «Шундый матур кызлар белән бер генә атна торсаң иде!» дигән сүзне ычкындыруын сизми дә кала. Без аңа:

— Якуп агай, синең бит күзләрең күрми. Аларның матурлыкларын кайдан беләсең?—дибез.

Ул мескен уфлап башын күтәрә. Күгәрчен йомыркасы чаклы булган күз алмалары да түшәмгә күтәрелгән кебек булалар. Шуннан соң ул:

— Их, белмисез. Аларның матурлыклары тавышларыннан ук билгеле бит... Алар яныннан үтеп киткәндә дә хуш исләре бәрелеп китә... Шулай булгач, патша кызларының тагын да башкачарак булулары маглүм инде,—ди. Ул үзе дә Нурый картка сөаль биреп, өйләнгән вакытларын сораша. Нурый карт җиңелчә бер көлү белән көлеп үзенең үткән бәхетләрен сөйләп китә. Кияү булып кергән көннәрендәге рәхәтлекләрен сөйли. Якуп карый һич туктаусыз:

— Я, шуннан соң? Я, сөйлә инде, тагы нәрсә булды?— дип сорый. Нурый карттан бөтен эшнең вагы-төягенә чаклы сөйләтмәкче була. Нурый бабай:

— Аръягын әйтмә инде...—дип сүзен кисә, шул сүзенә, үзенең хатыны үлгәнен, шуннан соң өйләнергә теләми, монда килеп, ишан хәзрәткә мөрид булуын әйтеп сүзен бетерә.

Мәдрәсәнең ишек алдын себерүче—эле утыз-утыз биш яшьләрендә. Ул моңарчы өйләнмәгән. Ул озын сөйләп тормый. Боларның сүзләрен тыңлап тора, тора да:

— Биллаһи, бераз акча җыям да, авылга кайтып өйләнәм. Болай йөреп гомер җилгә генә үтә...—дип куя. Тегеләр моның өйләнергә мөмкинлеге барлыгын уйлап, аның бәхтенә кызыгалар.

Шундый тәмле сүзләр, матур хыяллар белән безнең чәй сәгатьләргә сузыла. Самовар сүнә. Теге дворник самоварны яңартып җибәрә.

Якуп карый иркен торучы кеше. Ул куй мае салдырып, йозырык зурлыгында гына вак күмәчләр пешертеп ала да, чәй эчкәндә шуларны бәләкәй капчык белән алып килеп, үзенең тезе янына куеп берәмләп алып ашый. Миңа тик берне генә бирә. Бер чирек кадак та булыр булмас бу күмәчне мин шунда ук ашап бетерәм дә, карыйның авызына карап утырам. Күңел кызыга. Алар шулай бик кызулап патша кызлары турында сөйләшкәндә капчыкның башын әкрен генә үземә таба тартып алып, берәр күмәч алганнан соң кире урнына куям. Нурый карт белән дворник бер-берсенә күз кысалар, һәм:

— Ул патша кызлары Якуп карый кебек куй маена пешерелгән бодай күмәче генә ашап торганнардыр инде...—дип көләләр. Якуп карый аларның сүзләрен чынга алып:

— Әй наданнар! Әллә сез аларны үзегез кебек кара корсак дип беләсезме! Алар оҗмах җимешләре кебек җимешләр, оҗмах нигмәтләре кебек нигмәтләр генә ашап үсәләр...—дип шелтәләп куя.

Минем хәйлә күпкә бармады. Берничә рәт аның күмәчен эләктергәннән соң, тегеләрнең күмәч сүзен күп тәкрарлаулары һәм:

— Мәҗит, синең майга пешкән бодай күмәчен туйганчы ашаганың бармы?—дип сораулары сәбәпле, Якуп карый минем хәйләне сизеп, капчыкның авызын тезе астына кыстырып утыра башлады. Ләкин ул минем шаянлыкны белгәнгә, күмәчен алганга һич рәнҗеш күрсәтмәү өстенә, кай чакта миңа бирә торган өлешне арттырып бирә башлады.

Мин аларга ай ярым чамасы эчендә, «Мең дә бер кичә» дән башка «Сәет Баттал Газый», «Тарихи табри» (6—7 том) «Каһәрман Катыйл», «Салсал», «Хәзрәти Гали батыр» вә башка бик күп китаплар укып чыктым. Безнең бу ай ярым гомер чынлап та бик күңелле үтте. Гәрчә, безнең беребезнең дә ул китапларда язылган бәхетләргә ирешү ихтималларыбыз булмаса да, без бу ай ярым гомерне шул бәхетләргә ирешкән кебек рәхәт үткәрдек.

Ишан хәзрәткә казаклар саба-саба кымыз китерәләр. Ул кымыз ишан өендә генә бетми, артып кала. Шул артык кымызны ул мәдрәсәгә җибәртә. Шунда без кымыз мәҗлесе ясап җибәрәбез. Җәй көне тору өчен генә килгән икенче мәдрәсәдә ятучылар да кымыз мәҗлесенә киләләр. Монда көйләп монаҗәт уку да, Ашказар, Тәфтиләү көй-

ләрен җырлау да ярый. Бу көн безнең тормыш бәйрәмгә әйләнә...

Тамак хакына хикәя укып эш чыкмый. Болай торганда кышка бер тиен акчасыз, киемсез керергә кирәк. Кайдан эш табарга?

Шулай аптырашта торганда кемдер миңа, «Бер байның заемкасындагы эшчеләргә аш пешереп тору өчен кашевар кирәк, барасыңмы?» ди. Мин, куктән көткәнен җирдән тапкан кеше кебек, шунда ук теге байның исмен, кайда торганын сорашып, эзләп киттем. «Шакирҗан Учаров...» Бу исемне бик нык хәтергә алдым. Болар шәһәрнең уртасындарак бер катлы гына йортта торалар икән. Бай базарга киткән икән. Капка төбендә утырып бик озак көтәргә туры килде. Бик озак көткәннән соң гына, кап-кара мыеклы, кызыл йөзле, уртача буйлы, башына каракүл бүрек кигән һәм яхшы гына арбага уртача гына ат җиккән берәү кайтып, капкадан кереп китте. Мин аның артыннан кердем. Ул миннән эшли алып-алмавым һәм башкалар турында бик җентекләп сорашканнан соң, печән чабучыларга аш-су пешереп торыр өчен, мине айга 5 сумга яллады. Мин байның эшкә алмый кире кайтарып җибәрүеннән шикләнеп, аның биргән хакына риза булып, иртәгә иртүк килергә вагдә биреп кайттым.

Минем китүем Якуп карый өчен бераз күңелсезлек бирсә дә, үзем өчен күңелле иде. Шәһәрдә тору мине ялкыткан, киң яланнар, яшел сәхраләр бик сагындырган иде.

Иртәнгесен байның йортына барып, аның заемкасында башлык булып торучысы белән заемкага киттек.

Заемка Троицкийдан кырык-илле чакрымнар чамасында икән. Анда торучы күп түгел. Тик шул мин утырып барган кешенең гаиләсе, аннан башка дүрт буйдак егет һәм бер каравылчы гына. Без барганда теге егетләр печән чабарга китәр өчен хәзерлек күрәләр иде. Менә мин шул егетләргә аш пешереп, чәй кайнатып торырга тиеш идем.

БАШТАН ҮТКӘННӘР

1898 нче елның көзендә Троицкийга яңадан барып, шундагы тәртип буенча эшләргә керештем.

Монда, әлбәттә, уку дигән нәрсә күбрәк Бохара ысулында иске хорафатләрне һәм дини әсәрләр укудан, бо-

ларны да иң тәртипсез рәвештә таглим[1] итүдән гыйбарәт иде.

Монда бөтен укучы шәкертләр, укудан бигрәк, ишан тирәсенә җыелып, шуңа мөрид булуны төп максат итеп алганнар, бөтенесе тәсбих тартудан, суфилар мөнаҗәте, «Көрьән» укудан бушамыйлар иде.

Монда яңалык, иң аз булганда, дини үзгәреш яки шул вакытта Россия мөселманнары арасында тарала башлаган ысул җәдиде хакында уйлап караган шәкертне очратыр хәл юк иде.

Мин беренче елны башка шәкертләргә хезмәт итеп, шулардан калган ашны ашап, укып чыктым.

Монда кыш уртасы үтү белән бөтен шәкертләр кыргыз, казак арасына таралалар, елның 8—9 аен шунда үткәрәләр иде.

Болар 8—9 ай кымыз эчеп, казылык ашап симереп кайтканнан соң, мәдрәсәгә килеп, шул ук ашау-эчү белән гомерләрен үткәрәләр иде.

Мине, шундагы кайбер танышып өлгергән һәм кыргыз арасына чыгып өйрәнгән шәкертләр, кыргыз арасына чыгарга димләделәр.

Шуларның димләүләре аркасында мин дә, март аенда, Троицкийдан 35 километр җирдәге бер кыргыз авылына, мулла (шул вакытның тагбире буенча) булып чыктым.

Бу, минем кыргызның кышкы тормышларын беренче күрү иде.

Ләкин боларның тормышлары, андагы каралык, аңсызлык, тагын әллә нәрсәләр миңа шул чаклы начар (тәэсир) итте ки, мин монда бер атнадан артык тора алмадым.

Ауруга сабышып, үземне Троицкийга алып барып ташларга мәҗбүр иттем.

Троицкийга кайтып, тагын да шунда хезмәт итеп укырга керештем.

Апрель эчендә шәкертләр таралып беттеләр. Мәдрәсәдә бер-ике генә дистә шәкертләр калды.

Арба юлы төшү белән боларның да бик күбесе таралдылар.

Уку да бөтенләй тукталды. Миңа эш тә, аш та калмады.

Ләкин шунда бер-ике суфи һәм карый бар иде. Гомер буенча шушы мәдрәсәдә ятып картайган бу сукырларның

---

[1] Таглим итү—укыту, өйрәтү.

һичбер эшләре булмаганга күрә, көн уздыра алмый аптырыйлар иде. Мин шуларга төрле китаплар укырга керештем. Мин аларга «Сәет Баттал»лар, «Табәри тарихы» (6—7 жилд[1], «Әлфе ләйлә», «Кәһарман Катыйл», «Салсал» вә башкаларны бөтенләй укып чыктым.

Шушы хезмәт бәрабәренә алар миңа көненә бер-ике мәртәбә чәй эчерәләр, ашаталар иде.

Июнь ахырларында болар да үзләренең авылларына кайтып китте.

Хәзер мин ничек тә берәр эш табарга мәҗбүр идем.

Берәр атна ачлы-туклы торганнан соң, Троицкийның Шакирҗан Учаров дигән байларның заемкаларына, эшчеләргә аш пешереп торырга ялланып, хезмәткә киттем.

Монда мин машина белән печән һәм иген чабучы 6—7 егеткә аш пешерергә, чәй кайнатырга тиеш идем.

Мин баргач, арба өстенә ясалган такта куыш белән сыер һәм башка нәрсәләрне печән чаба торган җиргә күчердек.

Мин аларга ашау-эчү хәзерләп, сыерны савып, бөтен кирәкләрен җитештереп тора идем.

Боларга буш вакытларында тагын да иске хикәя китаплары укырга керештем. Шуның өчен булса кирәк, бу эшчеләр белән бик яхшы тордык. Болар мине бик яраталар, мин өлгермәгән вакытта, миңа тиешле эшләрне дә эшлиләр иде.

Печән беткәч, заемкага кайтып, иген җыю эшләренә керештеләр.

Бу байның чәчкән игеннәре дүрт-биш йөз дисәтинә булганга күрә, эшчеләрнең саннары артты. Күрше рус авылларыннан килеп эшләүчеләр дә кушылды.

Мин боларның һәммәсенә төшлек әзерләргә һәм икмәкне үзем салырга мәҗбүр идем.

Шуның бәрабәренә жалование 5 сумнан 7 сумга күтәрелде.

Сентябрь аена чаклы шунда эшләгәннән соң, тагын да мәдрәсәгә кайтып укырга керештем.

Быел инде нәхүдән[2] чыгып мантыйкка[3] төштек. Бер ел эчендә болай күтәрелү, бу мәдрәсәдә бик зур муәффәкыяттән[4] санала икән. Үткән ел, мин зур һәм галимдер дип

[1] Җилд—том.
[2] Нәху—синтаксис.
[3] Мантыйк—логика фәне.
[4] Муәффәкыят—уңыш.

йөргән шәкертләрнең күбесе хәзер артта калдылар. Кайбер миңа сабак өйрәткәннәре дә быел миннән артта калдылар.

Мин хәзер ярлылык ягыннан беренче булсам да, уку ягыннан байтагын узган идем. Бу эш рухны күтәрде. Бу, әрәм тамаклар белән каршы сөйләшә башлауга юл ачты.

Мин быел көз ике-өч ай үз акчам белән тора алдым.

Аннан соң тагын да бай шәкертләргә самовар куярга керергә мәҗбүр булдым.

Шәкертләр һаман борынгы юллары белән мөрид булуны беренче максат итеп тоталар иде. Ишан тирәсе бөтенләй шулар белән тулып, монда бөтен эш шул тасаввеф тирәсенә корылган, бөтен тормышлары шул тирәдә чуалудан гыйбарәт иде.

Мин үзем ару күргән шәкертләр арасында ишаннан көлә башладым. Бу эш, әлбәттә, боларга гаҗәп тоелды. Болар каршында ишанга тел озату—үзеңне ходаның каһәренә дучар итү белән бер булганга күрә, болар хәйранга калалар, иманыбыз бозылыр, дип миннән ерак шылып утыралар иде.

Шушы көз көненнән (1900) башлап, мондагы укыту һәм укулардан җанга азык табу авыр кебек була башлады.

Нак шул вакытта, кайдандыр «Тәрҗеман» газетасы кулга төште. Мин бу нәрсәгә гаҗәпкә калдым.

Электән иске төрек теленчә һәм госманлыча язылган әсәрләр укып килгәнгә күрә, моны аңлау артык авыр булмады.

Мин бу газетаны йотлыгып укыдым. Үземнән башка иптәшләргә дә укырга теләсәм дә тыңлаучы булмады.

Инде бу газета(ны) кайдан алып торырга?—дигән уй керде.

Троицкийда бу газетаны өч-дүрт кенә кеше алдыра икәнен сорашып белдем. Ләкин мин аларның капкасыннан керә алырлык түгел идем.

Соңра шушы мәдрәсәдә хәлфә булып торучы Сабир мулла (хәзер Уфа мулласы) «Тәрҗеман» алдыра башлады. Ләкин ул кеше, газетаны турыдан-туры миңа бирү ихтималы юк иде.

Мин вакытларында Фазылҗан карый дигән кешегә самовар куя идем. Бу сукыр карый бик дәртле булганга,

соңра ишан һәм хәлфәләр каршында игтибары зур булганга күрә, газетаны алып килә башлады.

Шуның белән бергә һәрбер номер газетаны икәү укып бара башладык. Шуның аркасында дуслашып киттек.

Ләкин шәкертләр бездән көлеп йончыталар иде.

Шушы арада «Сәлимә»ләр чыкты. Каюм Насыйриның әсәрләре күренә башлады. «Шәкерт һәм студент» басылды. Мин бу әсәрләрне үзем генә укып калмый, шәкертләрне җыеп, шуларга укый башладым.

Бу эшкә күп шәкертләр ачулансалар да, кайберәүләре миңа дуслык күзе белән карый башладылар.

Мин бу әсәрләрне 15—20 мәртәбә укып чыктым.

Ишаннардан көлүгә чыдый алмый торган шәкертләр үзләренчә донос ясап карадылар.

Мин килгәннән бирле ишанның йортына бармаганга күрә, болар шуның өчен дә ачуланалар иде.

Шушы тормыш белән 1900 нче елның язына барып чыктым.

Шәкертләр тагын да таралдылар. Без тагын бер-ике дистә торып калдык.

Апрель аенда тормыш тагын да авырлашты. Троицкий меновныенда эш барлыгын ишетеп, бер шәкерт белән шунда эшкә киттек.

Вакыйган, монда тире киптерү өчен нәзек чөйләр очлап тору эше бар икән. Чөйләрнең мең данәсен эшләп бирү 25 тиен булып, без эшкә керешеп киттек. Бер чирек, ярты аршин чамасындагы тире киерә торган чөйләрне һәр көн 7—8 йөздән (көненә 12—13 сагәт) эшләп, 15—20 тиен чамасы акча төшерә башладык.

Бу безнең өчен зур кәсеп булды. Ләкин бу эш бер айдан артыкка сузылмады; тагын эш бетте.

Сораша торгач, Яушевларның торф чыгартуларын ишетеп, шунда бардык. Бу урын шәһәрдән 12 чакрым читтә булып, шунда ятып эшли идек. Монда да эш вакты кояш чыгудан кояш батуга чаклы булып, көненә 30 тиен генә эшли идек.

Май урталарында моннан да кайтып киттек.

Бердән, мәдрәсәдә тору өчен ашау-эчүгә акча кирәк булганга, икенчедән, күз күне укыр өчен хәзерлек күрергә тиешле булганга күрә, Зиннәтулла дигән бер шәкерт белән алтын приискасына эшкә чыгып киттек.

Без барырга уйлаган «Восьмой» дигән алтын приискасы (Рәмиевләрнең) Троицкийдан 150 чакрым ераклыкта иде.

Ике көн эчендә җитмеш чакрым барганнан соң ашарга да бетә башлады. Иптәш кәефсезләнеп китте.

Аптырагачтан бер кыргызга ике күлмәк биреп, ат белән киттек.

Кайбер урында буш утыртып алып баручылар очрады.

Шулай итеп, майның 20 ләре чамасында приискага барып җиттек.

Монда бездән элек килгән, Троицкийда икенче мәхәлләдә укучы берничә шәкерт бар икән, шулар белән очрашып, дүрт кеше бергә казармада тора башладык.

Без төрлебез төрле җирдә, төрле эш эшли идек.

Мин башта алтын комын юган җирдә су тартып тордым. Озын калай торбага тыгылган юан гына агачны тартып, комны юарлык су чыгарып тору бик авыр булды. Ярты сәгать эчендә беләк тала, хәл бетә иде. Өстән карап торучылар булганга күрә, хәл җыю да бик сирәк туры килә иде. Ләкин бара торгач өйрәнелде.

Бу эшне атна-ун көн эшләгәч шахтага төшеп, казылган туфракларны ишек алдына ташу эшенә кердем.

Шахта мүкәйләп, тезләнеп йөрерлек рәвештә казылган тар-тар коридорлардан гыйбарәт, шәм яктысында эшләргә туры килде.

Монда ике атна чамасы эшләгәннән соң эш бетте.

Тик ятарга туры килде.

Шул вакытта, приискада күптән бирле эшләп килгән бер картка очрап, анда яңа китаплар бар икәнен ишеттем.

Вакыйган, монда «Тәрҗеман» газетасына гыйлавә[1] итеп чыгарылган кечкенә җаграфия харитасы һәм җаграфия, Каюм Насыйриның кайбер әсәрләре белән «Җаграфияи кабир» нең Азия кыйсымнары[2] бар икән.

Мин, тик яткан вакытларда, иртәдән кичкә чаклы шуларны укып ибтидаи[3] дәрәҗәдә булса да, җир йөзе белән танышып алдым. Бу исә минем өчен бик яңа нәрсәләр иде.

Мин боларны шул чаклы дәрт һәм ләззәт белән укый идем, бөтенесе күз алдында тәҗәссем итә, күп нәрсәләр хәтердә кала иде.

Шушы эшсезлек вакты миңа бик күп файда итте.

Июнь ахырларында, безнең теге иптәшләр белән Лот-

---

[1] Гыйлавә—кушымта.

[2] Кыйсем—өлеш, кисәк.

[3] Ибтидаи—башлангыч.

фулла исемле иптәшләр контора белән алтын эзләп разведкага чыгарга сөйләштеләр.

Без Шакир дигән шәкерт белән, «ялчыга ялчы» кабиленнән, боларга көненә 50 тиен белән эшкә барырга килештек.

Безнең белән эш башкарып йөрүче бер рус барачак иде. Аның үзенә махсус хезмәтче малае да бар иде.

Рус үзенең малае белән, тарантаска утырып, алдан китте.

Без дүртәү ике атка кирәкле коралларны төяп, Бирский өязенә, Ябык Карагай дигән җиргә карап чыгып киттек.

Монда бик матур урман арасы булып, без шул урман арасындагы ялан җирләрдә алтын почвасы эзләргә керештек.

Эзләү эше, җирне төп-түгәрәк казып төшеп (аның үзенә махсус туфрагы була), шундагы балчыкны алып юып караудан, алтын бөртекләрен эзләүдән гыйбарәт иде.

Башта алтын була торган туфрак өч-дүрт аршин (тирәнлектәге) җирдән чыкканга күрә, эшләр бик шәп китте. Безнең теге иптәшләр аршин башына 20 тиеннән алып 30 тиенгә чаклы алалар иде.

Казый торган җир бай булганга күрә, без дүртәү дүрт җирдә казып, көненә 30 аршин чамасы җир эшли идек.

Бу исә һәр көн 6—8 сумнар акча табу дигән сүз.

Тегеләр безгә мәгәр 60 тиеннән хисап бирәләр. Ашауэчүгә бөтенебезгә 2 сум чамасы чыгар. Димәк, болар бездән һәр көн 2 шәр сум акча артык алалар.

Мин үземнең иптәшне эш ташларга котырттым.

Үзе бик көчле булып та, аңсыз булган бу егет башта күнмәсә дә соңыннан күнде.

Без бер көнне боларга ялланып эшләргә теләмәгәнебезне, мәгәр бөтен файда тигез булса гына эшләвебезне, булмаса кайтып китүебезне иглан иттек.

Башта болар ачуландылар:

— Без бөтен корал һәм атларны үзебезнең мәсьүлият астына алдык, сезгә корал да, бер нәрсә дә бирмибез, теләсәгез нишләгез,—диделәр.

Ләкин без кайтып киткәч, эшнең уңайсыз бер хәлдә калуын уйлап, ике арага теге рус катышып, мәсьәләне безнең теләкчә хәл кылырга мәҗбүр булдылар.

Беренче эш ташлау шәп булып чыкты. Без көн саен кеше башына бер сум утыз, бер сум илле тиен акча калдыра башладык.

Лэкин бу эш озакка сузылмады. Икенче җиргэ күчеп барып эшли башлаган җиребез(дә) алтын туфрагы 15—20 аршиннар чамасы тирән җирдә генә була башлады. Мондагы тирән җирдә, ике кеше бер урында эшләргә туры килгәнлектән, эш шәп бармый иде.

Беребез астан казып балчыкны бадиага тутырып тора, икенчебез өстән әйләндереп тартып чыгара иде. Тирәндә озак тору тынны кысканга күрә, алмашлап төшеп эшли идек.

Казу эше тирән киткән саен, ташлык урыннар чыгу эшне тагын да авырлата иде.

Бара торгач, безнең чокыр 30 аршинга җитте. Түбәннән караганда күк йөзе кечкенә йолдыз кебек күренә башлады.

Без һаман да казуда, максат булып... җиргә җитәргә тырышуда дәвам итә идек.

Шулай эш барганда, түбәнгә төшү нәүбәте миңа җитеп, мин түбәндә казый идем.

Бер вакыт югарыдан вожлап бер нәрсә төшә башлады. «Ә» дигәнче бер нәрсә минем аркамны сыдырып җиргә төшеп, яңгыратып җибәрде.

Югарыдан:

— Һәләк булды, үлде!—дигән тавышлар чыкты.

Миңа кычкыра башладылар. Бу төшкән нәрсә тимер көрәк икән. Мин исән калдым. Алар минем исән калуга бик шатландылар.

Икенче көнне тагын шул ук рәвештә, ярты пот чамасындагы таш килеп төште. Анысы да миңа зарар китермәде.

Шушы вакыйгадән соң, мин бу эшне ташлап китәргә карар бирдем дә, үземә тиешле булган 35 сум акчаны алып, юлчылар белән «Восьмой»га кайтып киттем. Акчаның 30 сумын бишмәтнең яшрен бер җиренә тегеп, 5 сумын расходка калдырдым.

Берьюлы бу чаклы акча керү мине соң дәрәҗәдә шатландырган иде. Теккән урнымнан акчам төшеп калмадымы икән дип, минут саен сәрмәп, карап тора идем.

Хәзер июль ахырлары булганга күрә, урак вакты булып, мин уракка чыгарга уйладым да, Троицкий ягына гаиләләре белән уракка баручы башкортларны очратып, шуларга бер сум акча биреп утырып киттем.

Болар җиде, сигез гаиләдән гыйбарәт булып, һәрберсе үзләренең кирәк нәрсәләрен арбаларга төяп, кечкенә карван булып баралар иде.

Йөкләре яхшы ук күп, үзләре күмәк булганга күрә, күбрәк вакытта ирләре юлның читеннән җәяү баралар. түбән таба булганда гына утыралар иде. Мин үзем яллаган кешенең кучеренә утырып барам, хатыны түргә утырган, үзе җәяү бара иде. Кичкә таба бер рус авылына җиткәч, болар миннән азык алырга бурычка акча сорый башладылар.

Мин теге 5 сумның 3 сум кадәресен тараттым. Шалтырап торган көмеш акчаларны чыгарып биргәнемне һәм үземдә тагын да калганын күргәч, боларның күзләре елтырый башлаган кебек булды.

Болар миннән кайда эшләвемне сораштылар.

Болар бүген кайда туры килсә, шунда—кырда кунарга баралар иде.

Караңгы төшә башлады. Ирләре һаман читтән нәрсәдер сөйләшеп баралар иде.

Караңгы төшкән вакытта бер җиргә туктадылар да, атларын тугардылар.

Мин арбаларына утырып килгән кешенең хатыны, ирләре янына барып килде дә, минем колагыма гына:

— Егет кеше, мин сине кызганам, болар сине үтерергә әйтәләр, акчасы күп, дип уйлыйлар, син ничек тә кач, мин әйткәнне белдермә,—диде.

Бу хатынның мине кызгануы, һәм шул вакыттагы хәрәкәте, мөлаем табигате миңа бик нык тәэсир итте.

Мин аңа карап:

— Мин булган акчаны аларга биреп беттем. Миндә акча юк. Киемнәр дә иске, мине үтерүдән аларга бер файда да килмәс,—дидем.

Мин, качудан файда юклыгын, ул вакытта бигрәк тә куркыныч икәнен уйлап, качмаска карар бирдем.

Бу хатын тагын да ире янына барып, нәрсәләрдер сөйләде. Тагын минем янга килде.

Мин куркып, кайчан һөҗүм итәрләр икән дип, үлем көтә башладым.

Шулай да, караңгыдан файдаланып, алар атларын ашатырга йөргәндә, шундагы якындагы агач арасына барып яттым.

Бик күп көтеп ятсам да, килүче булмый, йоклап киттем.

Мин иртән торуга, болар чәй эчәргә утырганнар иде.

Бүген бик ачык йөз белән каршы алдылар.

Без тагын кузгалып киттек.

Теге хатын, юлда ирләрен бу начар уйларыннан кайтарырга тырышуын, хәзер курыкмаска тиеш икәнен сөйләде.

Мин Троицкийга 50 чакрым җирдә 10—15 көн урак урганнан (соң) Троицкийга кайтып кердем. (1900 нче елның көзе).

Җәй буе эшләп 40 сумга якын акча табу аркасында, мин бу ел кышны, кешегә хезмәт итми, тыныч күңел белән үткәрдем.

Мәдрәсәдә укылган сабаклар өстенә, яңа чыккан әсәрләрне дә укып бардым.

1901 нче елның мартында, Троицкийдан 130 чакрым җирдәге Ташлы Күл дигән җирдә Ишмөхәммәт дигән картның авылына балалар укытырга бардым.

Бу кыргыз авылы 7—8 өйдән гыйбарәт булып, башка кыргызлар кебек мал-туарга бай түгелләр иде.

Шуның өстенә Ишмөхәммәт карт, соң дәрәҗәдә тупас табигатле, кара йөрәкле кеше булып, моның янында тору бик начар тәэсир итәр кебек булды.

Шунда да мин чыдап тордым. Яз җиткәч, Урынтай дигән мәшһүр хаҗи килеп, шуның белән таныштым. Ул мине бик яратып, теге кыргызларга, күз алдымда, яхшы тәрбия итәргә, обижать итмәскә кушып, бик дуслашып, үзенә кунакка чакырып китте.

Урынтай хаҗи казакларның игтибарлы кешеләреннән булганга күрә, аның сүзе боларга нык тәэсир итте. Кыргызлар миңа яхшы карап, бик нык хөрмәт итәргә керештеләр.

Кыргызларның кышкы—кышлау тормышы миңа бик начар тәэсир калдырса да, җәйләүгә чыгып тора башлаулары белән, мин аларның иркен җәйләү тормышларын бик яраттым.

Җәйләүнең иң яхшы тәэсир иткән ягы, анда күп илләрнең бер жиргә җыелып утырулары, үзара бик нык мөнасәбәт ясап, кымыз мәҗлесләрендә төрле сүзләр сөйләүләре һәм үлән—җыр җырлаулары булды!

Боларның хатын-кызлары да бик ачык булып, кызлары, аларның йөреш-торышлары, сөйләшүләре бик матур тәэсир калдырды.

Мин җәйләүдә чакта кыргызларның сүз (гә) оста, иске җыр һәм мәкальләрне яхшы белүчеләре белән таныштым.

Аларның маллары өчен түгел, шундый магнәле сүзләре, җырлары өчен аларга якынлашуым аларның миңа игтибар итүләренә, хөрмәт кылуларына сәбәп булды.

Бу җәй шулай итеп ничево гына күңелле үтте.

Монда 1901 нче елның сентябренә чаклы торып, Троицкийга кайттым да, Троицкийдан солдатка каралу өчен үзебезнең Уфа губернасына кайтып киттем.

Солдатка каралып (алынмый) калгач, кире Троицкийга бардым.

Ләкин мәдрәсәдә урын бирмәүләре сәбәпле, фатирга чыгып, шуннан йөреп укый башладым.

Бер яктан, ишан тирәсендәге төрле риалар[1], алдашулар, икенче яктан, шәкертләрнең соң дәрәҗәдә юк-бар белән чубалулары, гомерләрен әрәм итүләре күңелгә сәлби[2] яктан тәэсир бирә баралар иде.

Мин хәзер ишан тирәсендәге риалар хакында, шәкертләрнең ялкаулыклары турысында бик нык сөйли башладым.

Бу эш аларга төрлечә тәэсир итте.

Ләкин коры сүз белән эш чыкмавын күреп, 1902 нче елның язына таба, «Ишан шәкертләренә» дигән назым[3]ны язып тараттым.

Язма көенчә таралган бу назым шәкерт һәм хәлфәләргә бик нык тәэсир итте. Бик күп шәкертләр соң дәрәҗәдә хурландылар.

Ишан кебек ишанга һәм аның шәкертләренә тел тидерүгә кафыр диүдән башка сүз таба алмадылар.

Минем шигыремне аңларлык шәкертләр күчереп алып укый башладылар. Бер-ике көн эчендә таралып өлгерде.

Мин, мәдрәсәгә дәрес вактында гына барып, Габдуллаҗан хәлфәдән укый идем, бу кеше шигырьне ератты. Һәм саклык белән эш күрергә тавсия итте[4].

Бер көн мәдрәсәгә хосусый йомыш белән барган вактымда, Мөхәммәтҗан белән Шаһишәриф исемле сакаллы шәкертләр миңа һөҗүм итеп, кыйный башладылар.

— Син ишан һәм аның шәкертләрен хурламакчы буласың икән әле,—дип, аяк астында тапарга керештеләр.

Бөтен шәкертләр көлеп торалар иде.

---

[1] Риа — ясалма яхшылык.

[2] Сәлби яктан—кире яктан.

[3] Назым—көйле әсәр.

[4] Тавсия итү—киңәш бирү.

Минем хәл бетә башлагач, бер-ике тарафдар килеп өлгереп, мине яклап, тегеләрнең кулларыннан алып фатирга чаклы озатып куйдылар.

Икенче көн кич кайтып барганымда, юлда саклап торып, тагын да кемдер суга һәм кыйный башлады. Монда руслар килеп коткардылар.

Мин хәзер, кайбер иптәшләрнең тавсиясе белән, бу ел март башында казак эченә китәргә мәҗбүр булдым.

Анда баргач, «Фәкыйрлек белән үткән тереклек»не яздым. Монда язган назымнарым булса да, алар матбугат дөньясына чыкмадылар.

(Төрлесе төрле җирдә югалып беттеләр, шәкертләр хакындагы назымнар яндылар.)

Мин солдат хезмәтенә каралырга кайткан вактымда, Чиләбе аркылы, Себер тимер юлы белән кайткан идем. Тимер юлны беренче мәртәбә күрүем булганга күрә, бу миңа бик нык тәэсир калдырган иде. Быел (1902 нче елның көзенә таба) шуннан алган тәэсир буенча, «Себер тимер юлы» дигән нәрсәне яза башладым. Бу юлның миңа тәэсир иткән ягы аның искиткеч озын һәм соң дәрәҗәдә (үз каравымча) яхшы, машиналарның дөнья җимереп йөрүе, Урал тауларын ярып, кычкырып үтеп китүе, андагы эшчеләр һәм башкалар иде. Шуның тирәсенә утырган татар-башкорт халкының соң дәрәҗәдә надан, бер нәрсә аңламый, ишан тирәсенә барып мөдир булудан бушамый, хорафәт эчендә яшәүләрен күреп, шушы эшне күз алдына китерә идем.

Бу ел мине, казак эчендә аңлы һәм казакның иске әдәбияты (белән) байтак таныш, думбрага оста булган Муса һәм Җома исемендәге ага-энеле ике казак яратып үзләренә мулла итеп чакырганнар иде.

Боларда тору бик-бик яхшы тәэсир калдырды.

Болар бик хөр, шуның белән бергә ишанлыкны яратмый торган, саф күңелле, йөрәкләре хорафәтләр белән пычранып өлгермәгән кешеләр иде.

Болар белән даимә әдәби нәрсәләр сөйләп, мин алардан үләң белән думбра чирттереп көн үткәрә идек.

Мин аларга татар җырлары җырлый идем.

Бу елның көзенә (1902 нче елның көзе) чаклы боларда торып, тагын да мәдрәсәгә кайттым.

1902 нче елның соңгы яртысы белән 1903 нче елның башында фатирда торып, мәдрәсәгә йөреп укыдым.

Мин монда, укудан бигрәк, шул вакытта яңа ачылган «Хезмәт» көтепханәсеннән төрле китаплар алып уку белән шөгелләнә идем.

Мәдрәсә һәм шәкертләр белән барган саен ара еракլаша иде.

Бу елда шәкертләр арасына аң, фикер керә башлады.

Мин аларның сүз аңлый торганнарын фатирыма чакырып, дөньядагы яңа тормыш һәм төрле нәрсәләр хакында үземчә генә маглүмат бирә идем. Шулай итеп безнең тарафдарлар барган саен арта башлады.

Троицкийның башка мәдрәсәләрендә дә кайбер шәкертләр хәзерге мәдрәсә тормышыннан һәм андагы укытулардан зарлана башладылар. Ләкин боларның теләгән ислахатлары[1] шул заманга нисбәтән генә булып, болар мантыйк укуга каршы торалар, тәфсир, хәдис кебек диннең әсасларын өйрәтә торган фәннәрне күбрәк укытуны таләп итәләр иде.

1903 нче елның башы керде. Мин хәзер «Тәрҗеман» газетасын рәттән укып бара идем. Ул бу дөньядан хәбәрдар булып тору өчен бердәнбер юл иде.

Бу газетаның 3 нче майда (иске стиль белән) 20 еллык юбилейе булды.

Мин бу юбилейгә махсус тәбрик шигыре язып җибәрдем.

Бу ел җәйне тагын да казак эченә барып, җәйне шунда үткәрдем һәм «Яшь гомрем» исме белән язылган шигырьләрнең башындагы кыйсмен шунда язып куйдым.

1903 нче елның көзендә тәкрар мәдрәсәгә кайтып, үземә фатир алдым да шунда тора башладым.

Мондагы укулар һаман да бер нәрсәгә яраксыз рәвештә дәвам итә иде.

Бу ел русча укырга теләп, бер учительдән 3 ай кадәр русча укыдым.

1904 нче елның язында да казак арасына чыктым. Көзендә тәкрар мәдрәсәгә килеп, фатирда тордым.

Хәзер, татар мәдрәсәләре дөньясында — шәкертләр арасында, хәрәкәт башланган иде.

Бигрәк тә зуррак мәдрәсәләрдә шәкертләр укуның тәртипкә салынуын таләп итәләр, надан хәлфәләрне яратмыйлар иде.

[1] **Ислахат**—тәртип кертү, яхшыландыру, яңалыклар кертү.

Бу елның кышында шәкертләр арасында яшрен җыелышлар ясап, котыртулар башланды.

Мин бу елның кышында, бөтен шәкертләрне җыеп, бер-ике җыелыш ясадым.

Хәзер хәлфәләр каршы тора алмый башладылар.

Мин, боларның дәресенә йөрүдән бөтенләй туктадым. Һәм, бу елдан соң икенче бер җиргә бару уе белән, кыргыз арасына чыгып киттем.

1905 нче елның язында, тагын да мөгаллим булып, маглүм Урынтай хаҗига бардым. Бу кеше, заманына күрә аңлы булып, яңалык тарафдары, ишанлык һәм суфилыкка каршы иде.

Бу кешенең казакча язган шигырьләре булып, язма көенчә тота иде. Аларны бергәләп җыеп бастырырга җибәрдек.

Минем мондагы тормыш бик күңелле һәм шагыйранә үтте.

Казакларның моңлы көйләре, магнәле шигырьләре, матур гына тавыш чыгара торган думбралар, пәрдәсез йөргән кызлары— һәммәсе дә җанга азык бирәләр иде. Шулай итеп, август башына чаклы укытып тордым да, август башында, Троицкийга кайтып берәр атна торганнан соң, Буби мәдрәсәсенә бару уе белән, Чиләбегә ат яллап киттем.

Ул вакытта Буби үзендә яңа фәннәр укылу, тәртип һәм яхшылыгы белән мәшһүр иде.

Чиләбедән Уфага килеп, аннан пароход белән Пьяный-Борга бардым.

Пьяный-Борга, аннан, Янагуш авылының бер кешене яллап, Бубига киттем.

Юлда Янагуш авылына төштем дә андагы Бубида укыган шәкертләр һәм бер-ике мулла бар икәнен ишетеп, шулар белән күрештем.

Ләкин болар, Бубида укысалар да, бөтенләй мин уйлаганның хилафынча[1], аңсыз булып чыктылар.

Шулай да мин Бубига бардым. Әле монда шәкертләр аз булып, рәтле дәресләр башланмаган иде.

Мин боларның әхвал рухияләре[2] белән танышып, Гөбәйдулла Буби белән күрештем. Бу кешене беренче күрүдә үк, үзем уйлаганның хилафынча таптым.

[1] Хилафынча—киресенчә.
[2] Әхвал рухия—уйлары, фикерләре.

Бу бик тупас, шуның белән бергә, укытуга дәртсез кеше булып күренде.

Аның калдырган начар тәэсире белән, мин, монда торуны мәслихәт күрми, шундагы бер шәкертне котыртып, Казанга алып киттем. Казанга барып аның мәдрәсәләрен карап йөрдем. Боларның мәслихәт булганы мәдрәсәи Мөхәмәдия күренде һәм Галимҗан мулла имтихан кылып, гали сыйныфка керергә мәслихәт күрде.

Монда укылган нәрсәләрнең минем өчен иң мөһиме—гарәп әдәбиятыннан «Мәкамати Хәрири»[1] белән Юсоф Акчура тарафыннан укытылган җаграфия белән тарих иде.

Бу нәрсәләрне бик яратып укырга керештем.

Октябрь җитте. Россиянең төрле урыннарында, шәһәрләрендә эшчеләр хәрәкәте башланды.

Бу революция тулкыны Казанга килеп бәрелде. Атышлар башланды.

17 нче октябрь манифесты чыкты. Моның бөтен кешегә тәэсире булган кебек, миңа да бик нык тәэсир итте.

Шунда ук һәр җирдә, шулар җөмләсеннән мәдрәсәдә, митинглар булды. Мин шул көннең тәэсире (белән) бер шигырь язып («Милләтемә шатлык шигыре») ташладым. Бу шигырьне Юсоф Акчура һәм башкалар укып яраттылар һәм тиздән чыга башлаячак «Казан мохбире» газетасына басарга вагдә бирделәр. Тагын да язып торырга тавсия иттеләр.

Минем бу шигырем октябрь ахрында чыккан беренче номер «Казан мохбире»ндә басылып чыкты.

Шушы көннән башлап «Казан мохбире» нең даими язучыларыннан исәпләнеп, анда төрле шигырьләр һәм мәкаләләр язып тордым.

Язган әйберләрем өчен миңа гонорар да бирәләр иде. Бу елда (1905 һәм 1906 нчы елның башы) язган нәрсәләрем, элек язган шигырьләрем белән бергә, «Яшь гомрем» исемендә (бу—Шәрәфләр бастырган шигырь мәҗмугаләренең 1 нче мәҗмугә (се) иде) булып басылдылар.

Быел яз җиткәч, күңел тагын да киң сәхрага талпына башлады, шәһәр тормышы күңелгә тарлык биргән кебек була иде. Яз җитеп апрель кергәч, бу теләк бигрәк тә көчәйде.

---

[1] «Мәкамати Хәрири»—гарәпчә әдәби әсәрнең исме.

Шуңа бинаән, 12 нче апрельдә, кыргыз арасына киттем һәм, маглүм Урынтай хаҗиның чакыруы буенча, шул авылга мөгаллим булып бардым.

Моннан торып Казан газеталарына шигырь һәм мәкалә яза идем.

Җәй көнендә, Уфада Мәдрәсәи Галия ачылганын ишеткән идем. Һәм бу хакта мәглүмат алып, бу ел көз көнендә шунда барырга карар бирдем.

Моннан максат, анда фәннәр күп укылуын ихтимал тоту иде.

Шушы уй белән, сентябрь башында, Уфага бардым. Һәм Мәдрәсәи Галиягә кереп укырга керештем.

Бу мәдрәсәнең диккатне җәлеп итәрлек җире һәм башка мәдрәсәләргә караганда артыклыгы: дин хакындагы яңа фикерләр, башка мөдәррисләр тарафыннан тәлкыйн[1] ителгән дини хорафәтләрне бушка чыгарып ташлау һәм «Коръан» аятләренә яңа рәвештә магнә биреп, аларны хәзерге көндәге фән һәм фән исбат иткән соңгы әсасләргә[2] тәтбыйк[3] итү иде.

Шуның өстенә бу көнгә чаклы башка мәдрәсәләрдә укылмаган фәннәр өстәлү булып, бу нәрсәләр шәкертләр өчен һәммәсе дә яңа нәрсәләр иде.

Шуның өчен дә монда, 5 нче ел революциясе тулкыны белән, төрле иске мәдрәсәдә остазларына каршы баш күтәргән һәм мәдрәсә ислахәтен теләгән күзгә күренерлек шәкертләр җыелганнар иде.

Бу мәдрәсә алар өчен яңалыкка, алмашынуга таба беренче баскычлык хезмәтен итте. Мин монда 1906 нчы елның көзендә килеп, фатирдан йөреп укыдым. 1907 нче елда җәйге тагтил[4] вактында, соңгы мәртәбә казак арасына барып, Дусмаил хаҗи дигәннәренең балаларын укыттым.

Бу ара эчендә язылган төрле шигырьләр (күбесе газеталарда басылганнан соң) «Милләт мәхәббәте» исме астында басылып чыктылар.

Мәктәпләрдә шәкертләр укырлык төрле шигырьләргә бик зур ихтиаҗ күренә һәм күргән бер мөгаллим мәктәп балалары өчен махсус шигырьләр язылуын миннән сорый-

---

[1] Тәлкыйн итү—укытып күңелгә сеңдерү.
[2] Әсас—нигез.
[3] Тәтбыйк итү—чагыштыру, туры китерү.
[4] Тагтил—укудан туктап торган вакыт, каникул.

лар, шуның өстенә мәктәпкә җыр-көй кертү мәсьәләсе матбугатта да бик еш очрый иде.

Шул тәэсирләр арасында «Милли шигырьләр» исемендәге шигырьләрне яздым.

Вакыйган, бу әйберләр бик тиз вакыт эчендә берничә рәт басылып, таралып өлгерде.

Шул ел эчендә «Ярлылар» дигән әсәремне язып бетердем.

Күз булгач, тәкрар Уфага кайттым.

Мәдрәсәи Галия ни чаклы яңа (белемнәр) биргән кебек булса да, анда укуның да артык зур хикмәте булмас төсле күренгәч, соңгы ике елында самиг[1] сыйфаты белән генә йөреп укыдым.

1908 нче елның җәен төрле авылларга йөреп үткәрдем.

Бу дәверләрдә, 5 нче ел революциясенең тулкыннары сүнеп Россиядә соң дәрәҗәдә истибдад[2] башланды. Бөтен Россияне төпсез бер караңгылык каплап, тавыш-тынсыз булган хәят башланды.

Государственная Дума һәм аларга сайлаулар вактындагы мөнасәбәтләр белән бераз талаш-тартышлар чыкса да бу—эш юктан эш булсын, дигән кебек кенә эшләнә, эшче һәм крестьян халкының сайлау хокуклары бөтенләй кысылып, сайлауларга мал-милек ияләре генә катнашалар. Шулай итеп, катлы-катлы сайлау аркасында Думага зур җир хуҗалары гына, байлар гына сайланалар иде.

Бу дәверләрдә мин «Вакыт» газетасына язгалап тордым. Шуның белән бергә, Муса Бигиев, Зиа Камали һәм Риза казый кебек кешеләр исламиятне иске хәленә кайтару, аны төрле хорафәтләрдән әрчеп, икенче төс бирү өчен бөтен көчләрен сарыф итәләр. Шул мөнасәбәт белән төрле вак мәсьәләләрне зур итеп күрсәтергә тырышалар иде.

Бу эш бигрәк тә ваклыкка барып җитте.

Муса Бигиев төрле вак мәсьәләләрне матбугат дөньясына чыгара иде.

Шул мөнасәбәт белән «Юк белән баш ватучылар» дигән мәкалә язып, «Вакыт» газетасында бастырдым.

---

[1] Самиг—мәдрәсәгә укучы булып кермичә, ирекле рәвештә лекцияләргә генә йөреп уку.

[2] Истибдад—түрәләрнең башбаштаклыгы.

1908 нче, 1909 нчы елның кышында Уфада торып, Мәдрәсәи Галиягә йөрсәм дә, күбрәк вакыт төрле әдәби әсәрләр уку, газеталарга язу белән үтте.

1909 нчы елның җәендә Уфада торып, бер айга Җантуриннарның Килем авылындагы имениеләренә бардым. Аларның тормышлары һәм крестьяннәр белән мөгамәләләре соң дәрәҗәдә начар тәэсир калдырды.

Крестьяннәрнең бояр алдына килеп, кул баглап, бүрек алып торулары, баяр хатынының аларны тәхкыйрле сүзләр белән сүгеп, кол итеп тотулары ачуны кабартты.

Мин крестьяннәргә:

— Нигә бүрек алып торасыз, нигә кул кушырып, шул чаклы хурлыкны күтәрәсез?—дип сорауга каршы, алар:

— Без борыннан шулай өйрәнгәнбез: сөрергә җир, чабарга печән кирәк булгач, шулай итми хәл юк, югыйсә ул бит безгә җир бирми,—дип әйтә торганнар иде.

Июль эчендә Уфага кайтып тора башладым. Мохит[1] начар, ялгызлык эч пошыра, иркен эшләргә юл юк иде.

Бигрәк тә татар дөньясында хәят юк, тормышның магнәсе юк иде.

Шушы вакытларда Зөһрә исемендә бер кыз белән таныштым.

Ятим үсеп, үзенең кул көче белән тегү тегеп, үзен тәрбия иткән эшчән бу кыз шул заманның үзенә күрә ачык фикерле (кешесе) һәм ару гына укыган да иде.

Аның эшчән һәм шулай аңлы булуы минем диккатемне җәлеп итте.

Мин аңа үземне такдим иттем. Һәм бөтен тормышны сөйләп, әгәр дә шулай бергә-бергә эшләп көн күрергә риза булса, үземнең бик шат булачагымны сөйләдем.

Зөһрә үзенең риза икәнен сөйләгәч, шул вакытның гадәте буенча, 1909 нчы елның 16 нчы августында туй булды.

Туй үтү белән без, икәвебез бер фатирга чыгып, тормыш корып җибәрдек. Аның кул көче белән эшләп әзерләгән нәрсәләре белән йорт эчен бизәгән булып, ямьле, тыныч һәм мәхәббәтле бер оя ясадык.

Ул кул эше эшли, мин яза идем. Безнең тормыш күңелле бер төс алып китте. Мал әсасенә корылмый, бәлки эш һәм чын гаилә әсасенә корылган бу тормыш миңа

---

[1] Мохит—тирә-юнь.

утырып эшләргә һәм күп укырга, тәртипле рәвештә бер хәяттә яшәргә ирек бирде.

Безнең кайгы да, шатлык та уртак иде. Аның күңле белән минем күңлемдә һич пәрдә булмый, һәммә эшләр киңәш белән эшләнә, һәрбер нәрсә һәр икәвебезнең теләгенә муафик бара иде.

Бу елларда «Заятуләк белән Сусылу», «Кыз балалар өчен мәктәп шигырьләре» яздым.

10 нчы елның 11 нче октябрендә бер ир балабыз дөньяга килеп, Әнвәр исмендә куштык.

Бу бала безнең тормышка тагын да бер матурлык бирде, өйгә тагын да тулылык, җанлылык кертте. Безнең өйдә эш артты. Өйнең тулмаган бер җирен тутырган кебек булды.

Ләкин без, мадди якны икәү тырышу аркасында ару гына алып барсак та, 11 нче елларда тормышның мадди ягы яхшы ук авырланып китте. Бердән, язган әсәрләр өчен наширлар гонорарны бик сатулашып биргәнгә, икенче, шул аз акчаны да бик интегеп алырга туры килгәнгә күрә, язу-сызу, әдәбият эшләре (белән) тормышны тәэмин итү авыр иде.

Бу вакытларда, Зөһрәнең кул көче белән тегү тегеп алган акчаларын тотып, бераз гына булса да тормышның җитешсез якларын ялгап җибәрә идек.

Бу дәвердә татар мәктәбендә укучыларның бердәнбер эшләре—берәр мәктәптә мөгаллимлек итү генә иде. Мин мөгаллим булуны үземнең табигатем белән сөйми торган булганга, соңра бу эш бөтенләй мораи миннәтче байлар кулында гына дәвам иткәнгә, алар янына барып, алар кулы аркылы акча алып торуны күңлем сыйдырмый иде.

Мин үзем генә берәр завод кебек җиргә эшкә керергә дә уйлап йөрдем. Ләкин бердән, физический яктан бу эш мөмкин түгел, икенче, сәламәтлек урта иде...

11 нче елның ахрында Зөһрә II классллы Башкирский приютка ана теле мөгаллимәсе булып керде һәм аннан айга 10 сум жалование ала башлады.

Аның бу эше безнең тормышның мадди ягын тагын да җиңеләйтә төште.

Ай саен мөрәттәп[1] рәвештә 10 сум акча килеп тору безнең өчен бик шәп эш иде.

---

[1] Мөрәттәп—тәртипле.

12 нче елның язында Уфадагы Кәримевләрнең «Шәрык» матбагасына мөсаххих[1] булып кердем. Монда эш вакты иртәнге 8 дән кичке 7 гә чаклы булып, айлык вазыйфасы 25 сум иде.

Монда минем өчен эш вакты озак булса да, буш вакытларда укып-язып утырырга мөмкинлек булу, шуның өстенә эш белән үземнең тормышны тәмин итү кебек яхшы яклары булганга күрә, яхшы булып чыкты.

Эш һәм эшчеләр арасында вакыт үткәнен сизми калу гадәтем бар. Монда да шулай булды: төрле эш белән вакыт үткәне сизелми кала торган булды.

Бу елларда (11—12) «Исәпсез байлык», «Хәмитнең хәяты», «Тәэссоратым» дигән әсәрләрем басылды.

13 нче елда мин һаман типографиядә мөсәххихлык эшен алып бардым. Җәйләрдә ел саен бер айга авылга чыгып, хәл алып, тагын бер еллык көч алып керә идем.

13 нче елда төрле вакытларда (11 — 12 елларда) язылган «Әмсаль» дигән мәсәлләр мәҗмугасе басылды.

14 нче елда да һаман матбагада эшләдем. Бу ел эчендә милли шигырьләрнең 3 нче җөзье[2], «Моң-зар», «Әдәбият кисәкләре» нәшер ителделәр.

Шушы елның җәендә маглүм бөтен дөнья сугышы чыкты.

Бу сугышны күңел теләп алды. Чөнки бу сугышның нәтиҗәсендә инкыйлап[3] булуы, дөньяда зур үзгәрешләр тууы якын ихтимал булганга күрә, бу сугышның булуы матлуп иде.

Сугыш дәвам итте. Эшче-крестьян каны дәрья булып акты. Аларның балалары, хатыннары ятим калдылар.

Фаҗигаларның барган саен көчәя һәм арта баруы күңелгә начар тәэсир калдыра башлады. Моның бер чиген, кан дәрьясы агуының тукталуын күрәсе килә башлады.

Казарма яннарында мәхшәр булып, балаларын озаткан ата-аналар, аталарын озаткан яшь балалар тулды.

Мин монда сагәтләрчә карап утырдым. Шул вакытта «Юктырсың ла алла» ны яздым.

---

[1] Мөсаххих—корректор.
[2] Җөзье—кисәге.
[3] Инкыйлап—революция.

БИШЕНЧЕ ЕЛ РЕВОЛЮЦИЯСЕ ХАКЫНДА ИСТӘ КАЛГАННАР

I

1905 нче елның көзендә мин Казанда идем. Октябрь (искечә) башларында ук Россиянең фабрик-завод төбәкләрендә тынычсызлыклар башланганлыгы, забастовкалар ясалганлыгы хакында хәбәрләр килә башлады. Казанда әле, болай өстән караганда, тынычлык кебек күренсә дә, югары мәктәпләрдә укучы студентлар арасында укуларны бер якка ташлап, нәрсәгә булса да хәзерлек күренә, ни дә булса алда зур эшләр булачагын аңлаткан эшләр сизелә иде. Казанда Алафузов фабрикасында һәм башка фабрик-заводдагы эшчеләр арасында да тынычсызланулар барлыгы телләрдә сөйләнә башлады. Ничек тә октябрьнең башыннан башлап укучылар арасында да, общий Казан халкы арасында да Питер һәм Мәскәүдә хөкүмәткә каршы аякланулар барлыгы, нәрсәнең дә булуы, бер зур эшкә хәзерлек күрелүе хакында колактан-колакка сөйләнгән хәбәрләр күбәйде.

Мәдрәсә шәкертләре арасында бу хәбәрләр таралды һәм Казан гали мәктәпләрендә укучы студентларның хәрәкәтләре боларга да тәэсирсез калмады. Мәдрәсә шәкертләре белән ике арада катнашулар, алдагы зур эшкә хәзерлек күрергә димләп ике арада йөрүчеләр күренә башлады. Мәдрәсәгә, һәр көн дип әйтерлек, кул белән язылып, җилем басмада басылган кочак-кочак прокламацияләр, революциягә өндәүләр таратыла иде. Кайбер татарча прокламацияләр мәдрәсәнең үзендә дә басыла, боларда да шул ук хөкүмәткә каршы өндәү белән бергә, мәдрәсәләрне ислах[1] итү, аларга фән кертү, мантыйк кебек хорафәтләрне бөтенләй чыгарып ташлау, мәдрәсә идарәләренә шәкертләрдән дә вәкилләр кертү кебек төрле таләпләр кертелә, шулар мәдрәсә идарәсе һәм мөдәррисләр тарафыннан кабул ителмәгән суратттә уку ташлау, мәдрәсәдән чыгып китү белән тәһдид[2] ителә иде.

Шәкертләр арасындагы хәрәкәтләрнең иң кызуы мәгълүм Мәдрәсәи Мөхәммәдиядә булды.

Бу вакытта һәрбер груһ халык алдагы көндә булачак үзгәрешләр турында үз мәнфәгате ягыннан карап сөйли,

---

[1] Ислах итү—тәртип кертү.
[2] Тәһдид—куркыту, янау.

һәр кем ирекне бер төрле, үзенчә, аңлый иде. Общий мөселманнар, бигрәк тә аларның шул заманнарда эш башында йөргән сатучылары, муллалары, хәлфәләре әлбәттә дингә ирек булуны күз алдына китерәләр, ирекнең бар хикмәте—дини, милли иркенчелектә дип уйлыйлар иде. Эшчеләрнең, аңлы рус укучыларының, революционерларның таләпләре маглүм, боларга караганда бөтенләй һәм башка һәм бик киң рәвештә иде. Татар укучыларының иң зур өметләре—шул мәдрәсәләрне ислах итү, анда фән кертү иде.

Октябрьнең 15—16 ларында эш тагын да куерды. Кешеләрнең куллары көндәлек эшләреннән бушанды. «Университетта митинг имеш... Студентлар баш күтәрәләр имеш!.. Казаклар аларны чолгап алганнар, кыралар, аталар имеш!..» дигән хәбәрләр бөтен Казанга яңгырый башлады. Бу хәбәрләр электән кузгалырга торган шәкертләргә тагын да ныграк тәэсир итте. Мәдрәсәләрдә укулар бетте. Һәр кем бер нәрсә көтә, һәрбер кеше бүген-таңда зур эшләр булуын көтеп кенә тора башлады. Урамнар шундый эшләрнең булуын көтүчеләр белән тулды. Алар полиция, казаклар тарафыннан куылып кайтарыла башладылар...

II

УНҖИДЕНЧЕ ОКТЯБРЬ

Күңелләр бер урында гына тора алмый. Көнлек эшләргә бер шатлык сизеп, кул чабалар, урыннарында басып тора алмыйлар.

— Сөйләргә ирек!..

— Матбугатка ирек...

— Вөҗданга ирек...

Тагын әллә нәрсәләргә ирек!.. дигән матур сүзләр бөтен шәкертләргә яшен кебек тәэсир итә.

Җыелыш беткәннән соң, бөтен сүзләр шул хакта гына бара... Һәр кем бер нәрсә сөйли, һәрбер кеше бер хәбәр китерә, һәр шәкерт яңа бер нәрсә өсти.

Яңа гына рус ягында җыелышта булып кайткан берәү, тагын да арттырып, анда бу эшләргә генә канәгат итәргә ярамаганын, көрәш кирәк икәнен ишетеп килгәнен сөйли.

Бу сүзләр тагын да шәкертләрне кайнаштыра. Бүген төн шулай гаҗәп вакыйгаләр, гомрендә күрелмәгән хөрриятне сөйләп үтә...

III

18 нче октябрьнең иртәнен җиткерү авыр... Кичтән «хөррият» нең бирелгәнлеген ишеткән кешеләрнең иртән торып, аның дөньяга китергән алмашынуларын тизрәк күрәселәре килә.

Иртән, Галимҗан мулла, дәрес китапларын күтәреп, дәрескә, шәкертләрне вагәз итәргә керә. Ләкин аның алдында бер-ике суфидан башка бәндә калмый. Бөтен шәкертләр бергә җыелып «Марсельеза» җырларга керешәләр. Бөтен Казан ирекле рәвештә җырланган «Марсельеза» тавышлары белән яңгырый. Бөтен шәкертләр груһ-груһ булып урамнарга чыгып китәләр, университет тирәсенә, Воскресенский (хәзер Чернышевский) урамга йөгерәләр. Бу тирәләр халык белән тулган, һәр җирдә кызыл флаглар җилберди, һәр кем тагын да әллә ниләр буласын көтә, полициянең коралларын алу турысында каты тавышлар ишетелә. Урамда да, университетта да, шәһәр Думасында да митинглар, җыелышлар, киңәшләр бара. «17 нче Октябрь манифесты» гына халыкны канәгатьләндерми. Почмакларда, участкыларда тешләрен ыржайтып торган полициянең коралсызландырылуын, милиция төзелүне таләп итәләр.

Бүген Казан «ду» килә, урамнан керәсе килми. Җыелган эшчеләр, укучылар үләргә әзер булган кебек кайнашалар... Озак та үтми, полицияне коралсызландыру башлана. Төркем-төркем халык (ул чагында кемне кемнән аеруы читен иде әле) участкыларга таралалар. Печән базарында бик зур җыелыш булып, анда төрле кешеләр тарафыннан речьләр сөйләнә (Хөсәен Ямашев һәм башкалар). Падишаһның «17 нче Октябрь манифестының» магнәсе югала. Аңа гына ышанып тормаска өндиләр. Халык зык кубып кул чаба. Сатучылар, әллә кемнәр читтән карап хәйран булып торалар.

— Бу чаклы хөрриятттән артык тагын да нәрсә кирәк икән?—диләр.

IV

КАЗАН РЕВОЛЮЦИОНЕРЛАР КУЛЫНДА

19 нчы октябрьдә партийныйларга һәм укучыларга корал таратылып, шәһәр алар кулына күчә, «шәһәрнең тынычлыгын саклау комитеты» кулында була.

Мәдрәсәләрдәге шәкертләргә чаклы корал алалар, шулар рәтеннән Мәдрәсәи Мөхәммәдиядәге шәкертләр кулына берничә дистә мылтык, шул ук микдарда кылыч, берничә ат төшә, таза шәкертләр билләрен буып, коралланып, шәһәрнең тынычлыгын сакларга йөриләр. Мәдрәсәләрдә укулар ташлана. Һич кем урнында гына тыныч утырып тора алмый. Монда үзенә күрә аерым хәрәкәт башлана. Бүгеннән башлап мәдрәсә идарәсенә үзләренең таләпләре кабул ителүе хакында катгый[1] таләп бирәләр. Мәдрәсә мөтәвәллиләре, мөдәррисләр, бик зур эшкә очраган кебек, төн-көн җыелыш ясап, нәрсә эшләргә белми аптырыйлар, алар да үзләренчә, вагдә белән генә алдамакчы булалар.

Шәкертләрнең каннары кайнашкан, вагдәләрне көтәрлек сабырлары беткән. Зык куптарып революция җырлары җырлыйлар. Мәдрәсәләрнең тәрәзәләрен вата башлыйлар. Мәдрәсәнең ишек алды пыяла ватыклары белән тула. Бик күп шәкертләр шундук мәдрәсәне ташлап, фатирләргә чыгып китәләр.

Галимҗан мулла, мәдрәсәгә килеп, шәкертләрне җыеп җылый-җылый вагәз әйтә. Аның сүзләренә әйләнеп тә карамыйлар. Аның үзенә каршы төрле сүзләр әйтәләр. Аның үзен куып чыгаралар. Ул, нәрсә эшләргә белми, чыгып китә. Байлар белән Казан муллаларының көн-төн яшерен җыелыш ясаулары хакында шәкертләргә хәбәр алынып тора.

Шул ук көннәрдә тагын әллә ничаклы прокламацияләр таратыла. Ашыгыч листовкалар чыга. Бу әйберләр шунда ук таратылып, кулдан кулга йөреп укылып чыгалар. Һәр җирдә җыелышлар дәвам итә. Урамнарда хәзер борынгы рәсми киемдә торган полицияләр урнында, төрле киемдә, төрле төстә, төрле корал белән коралланган милиционерлар торалар. Хәзер Казан бөтенләй икенче төскә керә. Ләкин әле бер урында да чын тынычлык күренми. Һаман да имеш-мимеш хәбәрләр тарала тора. Кара груһларның революциягә каршы аякланырга хәзерләнүләре хакында төрле сүзләр чыга. Болай караганда бер якка да катнашмаган кебек күренгән халыклар, бу хәбәрләрне тагын да куертып, әллә нәрсәләр өстәп тараталар. Башта халыкның күпчелеге бер агымнан, бер юл белән барган кебек күренә, ләкин читтән карап, эшне җентекләп бар-

---

[1] Катгый—кискен.

ган кешеләргә дә алдагы көндә каннар түгеләчәге, әле эшнең чынлап хәл кылынып бетмәгәнлеге, алдагы көндә эчке йэзләрнең ачылуы, төрле агымнарга бүленәчәкләре, революция дошманнары кулында көч барлыгы күренеп тора. Йөрәкләр куркына, алда тагын да каты көрәшләр булачагы күренә. Читтән карап торучыларның күзләре шуны белдерәләр.

V

ӨЧ КӨННӘН СОҢ

21 нче октябрьдә (искечә) университет, Воскресенский урам ягында күп халыкның кычкырган тавышлары ишетелә, сирәк-сирәк, кай чагында, залп биргән тавышлар бөтен шәһәрне яңгыратып җибәрә, шәһәр тагын да моннан дүрт көн элек булган шау-шуга әйләнә. Бөтен шәһәрдә, һич көтмәгәндә, икенче төрле хәрәкәт, икенче төрле күренешләр башлана.

Рус ягыннан булак аша качып кайтучылар, кайдадыр качарга урын эзләгән кебек йөгерүчеләр күбәйгәннән күбәя. Төш ауганнан соң шәһәрне авыр бер тынлык баскан кебек була. Төрле уку йортларында, шулар җөмләсеннән шәкертләр арасында да, шау-шу куба. Мәдрәсәгә бирелгән кораллар ашыгычлык белән бер җиргә җыелалар, кайберәүләрен кеше күрмәс урынга яшерәләр. Бөтен шәкертләр мәдрәсәгә кайтып тулалар.

Шундук кара груһларның тәре күтәреп йөрүләре, студент һәм башкаларны кыйнаулары, яһүдләргә погром ясарга керешкәнлекләре хакындагы хәбәрләр бөтен шәһәргә тарала. «Өч көнлек иреклe тормыш» корырга катнашкан кешеләрнең күбесе яшеренә башлыйлар, кайберләре коралларын илтеп бирәләр. Кайберләре яшерәләр.

Теге ямьсез тынлык тагын да арта...

Бер вакыт безнең мәдрәсә урамыннан (хәзер Тукай урамы) болыт кебек халык килеп чыга. Боларның иң алдыннан тәре күтәргән әллә ничаклы поплар, алар артыннан аппак чалма, яшелле, сарылы тун яки чапан кигән Казан муллалары, алар артыннан түрәләр, балыкчылар, итчеләр, кибетчеләр бағалар, болар һәммәсе дә тәрегә, патша сурәтенә баш игәннәр.

Болар рус ягында үзләренең ямьсезлекләрен эшләп, күрсәтеп беткәннән соң, «шәүкәтләрен»[1] татарларга, мөсел-

---

[1] **Шәүкәт**—олылык.

маннарга да күрсәтер өчен, бу якларга чыкканнар. Патша сурәте белән тәреләр, кызыллы, каралы, аклы флаглар күтәреп «боже царя храни»ны җырлап баралар. Аз гына шикле кеше булса, шундук чәйнәп, өзгәләп ташлар кебек баралар.

Хәзер боларны тәрәзә аркылы карап, иске тормышның яңадан аякланып чыгуына лагнәт әйтеп калудан башка чара юк.

Болар шулай тәреләре белән үтеп киттеләр...

Халык кулына таратылган коралларны кире җыеп алу башланды[1].

Шәһәрне тирән тынлык басты. Патшаның биргән вәгъдәләренә ышанмый каршы күтәрелүчеләр тагын да мәйданнан югалдылар. Алар киләчәктәге булачак олуг октябрьгә хәзерләнү өчен, тагын да идән астына эшләргә керделәр. «Җиңелми торган октябрь» ясар өчен тагын да көч җыярга керештеләр.

Вакытча сафтан чигенеп торсалар да, тагын да гайрәт, тагын да зур көч белән үзләренең дошманнарына һөҗүм итү уе белән артка чигенделәр.

Шулай итеп 1905 нче елгы октябрь революциясе күмелде. Күңелләр алдагы зур, җиңелмәс «Октябрь»гә юнәлеп, шуны көтеп калдылар.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ УФАДА

I

Г. Тукайның Уфага килгәнен ишетү белән «Сабах» көтепханәсенә бардым. Бу вакыт 1912 нче елның язы иде.

Мин барганда Тукай «Сабах» ның артындагы бер дәрәткә салынмаган бүлмәдә, әрҗәләрдән җыелып укмаштырылган сәке сыман бер нәрсә өстендә ята иде.

Тукайның өс-башы карайган, сәфәр мәшәкатене күреп бигрәк тә йончыган иде. Сөйләгән сүзләребез: аның сә-

---

[1] Кара груһлар шәһәрне кире үз кулларына алу белән, коралларны җыярга әмер тараттылар булса кирәк, мәдрәсәләргә таратылган коралларны тизлектә кире Бәдри Апанаевка (шул вакытның зур сәүдәгәре) итеп тапшыру хакында әмер килде. Кайбер шәкертләр генә коралларны кире алып барып бирделәр. Кайберләре бөтенләй бирмәделәр (*Мәҗит Гафури*).

фәре, кымыз эчәр өчен Троицкийга баруы, Казан вә яшьләре хакында булды.

Тукай юлда бик йончыганлыгын, Казаннан ничек булса да иртәрәк китәргә теләгәнен, кымыз вакты җиткәнче Уфада, юлда үткәрүен сөйләп, «Юлда бик күңелсез иде, Уфага килеп саф һавасын иснәп хәл җыйгач, үземне күтәренке сизә башладым»,—диде. Тукайның яткан җире, гадәттән тыш эссе, бик тәэсир итә торган сурәттә бөркү иде.

Бүлмәдә байтак утырдык. Кергән-киткән булмады. Бары Х. Зәбири бәгъзе эштән бушаган вакытта кереп, төрле сүзләр әйтеп, көлдереп чыга иде.

Тукай бәгъзе берәр генә мисраглы шигырь яки «Коръан» нан берәр аят укып куя иде.

Бераз торганнан соң, чыгып йөрергә карар бирдек. Чыгар алдыннан ниндидер бер дару эчеп, «Бер файдасы да булмаса да, моны эчәргә туры килә»—диде.

— Кайда барырга телисез? Теләсәгез, ат белән берәр җиргә барыйк,—дидем.

— Уфа урамында бу извозчиклар белән йөрсәң, эчәгеләрең калмас. Вокзалдан менгәнче дә үлә яздым. Җәяү генә бераз йөрик,—диде.

Безнең төбәп бара торган җиребез булмаганга күрә һәм минем Тукайны шатландырасым, үзе теләгән эшләрен эшләттерәсем килгәнгә, «Кайда барабыз?..»—дидем.

— Кайда барырга, берәр җиргә кереп утырырга кирәк, ләкин бик шәп урын булмасын, безнең Казанда шундый муафик урыннар була торган,—диде.

Ниһаять, бик гади генә бер җиргә кереп утырдык. Ләкин безнең монда эш пешмәде. Бездән ерак түгел бер өстәлдә утырган ике татардан Тукай никтер шомланды. «Болар тикмәс кешеләр булмаска кирәк, караулары шуны белдерә, моннан китик»—диде.

Мин, Уфада, Казандагы кебек, татарларның кешене тикшермәүләрен сөйләсәм дә, канәгать хасыйл[1] иттерә алмадым.

Ниһаять, «Сабах» ка кайтып киттек. Безнең беренче көн шулай үтте. Кичке салкыннан куркып Тукай чыгып йөрмәс булгач, мин кайтып киттем.

Икенче көн, ничек тә вакытны күңелле уздырыр өчен,

---

[1] Канәгать хасыйл иттерү—канәгатьләндерү.

Тукайны резиновый ходлы арбага утыртып, бик иркенләп йөрисе килә иде. Мин ат табарга вагдә иткән идем. Ләкин бу эш тә булмады. Бер-ике кешегә мөраҗәгат итеп карасам да, эш чыгара алмадым.

Тукай бүген кичәгедән кәефле иде.

Уфаның һавасы килешкәнен, кәефе төзәлгән сыман булуын сөйләде. Тагы да йөрергә чыктык. Фәкат безне шул барыр җир булмау гына бераз изә иде.

Тукай гаилә тормышын артык ук сөймәгәнгә, аны гаилә эченә алып барырга теләү бушка китәчәк булганга, ул якны әйтеп тормадым.

Без, язгы кояш астында бераз йөреп, берәр җиргә кереп утырырга карар бирдек. Без бүген матуррак бер җиргә керергә муаффәк[1] булдык. Кояшка каршы булган бу залны Тукай үзе дә яратты.

Без инде монда бик иркенләп утырмакчы булдык. Эшләр, Тукай теләгән рәвештә, бик шәп китте.

Бик кәефле утырган вакытта, Тукай бизгәк тоткан кебек калтырана башлады. Аның шундый вакытта йота торган порошогы «Сабах» та калганга күрә, даруны җибәртеп алдырырга туры килде. Шул даруны эчкәннән соң, Тукайның калтыравы басылып бераз кәефе төзәлде.

Баштарак Тукай да, мин дә, сүз таба алмаган кебек, бер-беребезнең күзебезгә карашып, тик утыра идек. Бара торгач, безнең мәҗелес бик күңелле булып китте. Күбрәк сүзләребез шигырь вә шагыйрьләр, Казан һәм дә мохитымыз хакында иде. Тукай, Казандагы тормышыннан ялыкканлыгын, шул сәбәпле кымызга иртәрәк булса да, Казаннан китәргә ашыкканын сөйләде.

Тукайның хәссас[2] күңленнән чыккан бик гади генә сүзләре аның бу дөньядан һәм дә үзенең мохитыннан разый булмавы—миңа яхшы ук зур тәэсир бирде. Бу вакытта безнең икебезнең дә күзләребездә ихтыярсыз атылып чыккан күз яшьләре ялтырый иде.

Тукайның рухы күтәрелде. Үзенең Петербургга чакырылганлыгын, анда барып кайтырга теләгәнен сөйләде. Тукайга Казаннан туры Петербургга бару уңаерак булганын, Уфага килеп кире Петербургга китү бераз рәтсез икәнен белсәм дә, аның теләгенә каршы бер сүз әйтүне теләмәдем. Аның бу ялгыш планында аерым бер шигы-

---

[1] Муаффәк булдык—ирештек.

[2] Хәссас—сизгер.

рият булганга күрә, Тукайның Петербургга китүе кызыксыман тоела иде.

Безнең иртә башланган мәҗелес тәмам булган вакытта, кояш баеган иде.

Тукай «Сабах» ка кайту белән Петербургга баруыннан хәбәр биреп телеграмма сукты. Шул карары буенча Тукай Уфадан Петербургга сәфәр итте.

II

Тукай Петербургдагы сәфәрендә унбиш көн чамасы йөреп, апрель 18 ләрендә тәкрар Уфага кайтты.

Тукай бу сәфәреннән гаят йончып килгән иде.

Ул, бичара, Петербургда бер дә үзе өмет иткән күңел рәхәтләренә очрый алмаган. Үзенең тагбире белән әйткәндә, «Бу сәфәр—хәерсез сәфәр» булган. Юл йөреп ниһаят дәрәҗәдә ватылган. Үзендә хәлсезлекнең бик күп артканын сизгән. «Ник бардым?» дигән көнгә төшкән.

— Юл йөрү бик кыен булды, күп вакытта чәй эчми килергә туры килде,—ди.

— Ник чәй эчеп, рәхәтләнеп килмәдегез?—дигәч,

— Чәй алып керер кеше булмады, мин үзем вагонда вакытта төшеп йөрергә куркам, я поезд китеп калыр,—диде.

Тукайның Уфага икенче мәртәбә килүенә бакчаларда агачлар яфрак ярган, җир өсте яшел мамык кебек яшь үләннәр белән капланган, кымызлар хәзерләнгән иде. Бик матур кояшлы көндә шәһәр бакчасына чыктык. Анда кымыз эчкәннән соң, агачлар арасындагы ачык җиргә яшел үлән өстенә барып яттык.

Тукай:

— Кайда ул Петербургда бу һава белән бу яшеллекләр! Анда яшел нәрсәләрне суганчы марҗалар кулында гына күреп калырга була,—диде.

Кымыз эчеп, һавада яту Тукайның сәламәтлеген кайтарган кебек булды. Һаваны мактый, иркен сулу ала, ике сүзнең берсендә «Сәламәтлек һавасы эчәм», дип сөйли иде.

Тукай Уфаның саф һавасын, матур бакчаларын бик яратты. Шуның өчен, Уфада торганда аз гына кояшлы вакыт булса бакчага чыга, кымыз эчеп яшел үлән өстендә ята иде. Бакчада яшел үлән өстендә йоклап киткән вакытлары да булды.

Тукай Уфага соңгы мәртәбә килгәндә, бер һәфтәгә[1] якын торып, әвәлдәге карары буенча, кымыз эчәр өчен, Троицкийга китте.

III

Уфа, Тукайның дәрәҗәсенә мөнасип[2] һичбер хәрәкәт күрсәтә алмады. Тукайның Уфага килү хөрмәтенә һичбер мәҗелес-фәлән тәртип кылынмады. Аның Уфага килгәнен күп кеше белми дә калгандыр.

Тукайның Уфада үткәргән ун-унбиш көн гомре «Сабах» көтепханәсенең артындагы бүлмәдә үтте. Аның күңлен ачып, рухын күтәрерлек һичбер эш эшләнмәде. Бер гаиләдән башка, хосусый дагвәт итеп[3] күңлен ачучы да булмады.

Тукайга катышырга, аны хөрмәт итәргә ярамаган кебек хәрәкәт иттеләр.

Аның ауру рухын күтәрер өчен Уфа халкына һәр төрле тәдбирләрне[4] кылу тиешле булса да, Уфа моны булдыра алмады. «Сабах» бүлмәсенә төшеп, шунда ятып, шуннан сәфәр итте.

Вактында Уфада тиешле хөрмәт күрсәтә алмаган Уфа яшьләре, Тукайның вафатына бер ел тулу мөнасәбәте белән «Тукай кичәләре» ясыйлар. Уфаның кызлары, егетләре Тукайны хөрмәт белән искә төшерәләр. Фәкать бу хөрмәтне Тукай үзе күрә алмый.

ХӘЗЕРЛЕК

I

Кырымга китәргә карар бирелгәч тә, безнең өйдә юл хәзерлеге башланды. Мин үзем юл хәзерлегенең нәрсәдән гыйбарәт һәм нәрсәләр кирәк икәнен тикшереп торуны тиешсез санасам да, Зөһрә һәм кайбер иптәшләр, мине рәтләп җибәрүне бик мөһим эштән санап йөриләр иде.

Зөһрә, юл өчен әйберләр пешерү, өс-баш киемнәрен юып, ямап, рәткә салу белән зык куба иде. Ул базарга чыгып күлмәклек алып кереп, бер генә данә булса да, матур күлмәк текте. Калган күлмәкләрне рәткә салды. Юл

---

[1] Һ ә ф т ә—атна.
[2] М ө н а с и п—яраклы.
[3] Д а г в ә т и т е п—чакырып.
[4] Т ә д б и р к ы л у—чарасына керешү.

әсбапларын[1] бер жиргә җыеп хәзерләп куйды. Шулай итеп, өч-дүрт (көн) эчендә курыкмый утырып китәрлек бер хәлгә килгәнде.

Иртәгә, 10 нчы майда, мине озатачаклар иде. Шуның өчен кичтән үк, алып китәргә хәзерләнгән нәрсәләрне кәрзинкәгә тутыру, вак-төяк нәрсәләрне төреп, бәйләп кую эше башланды. Өйдә булган нәрсәләрнең һәммәсе дә миңа маглүм иде, шуның өчен үзем белән нинди нәрсәләр алып китүем күңелдә язылган иде. Әвәлдән хәзерләнгән әйберләрне рәтләп салдык.

— Соң, син, Зөһрә, тастымал салырга онытмадыңмы?—дим.

— Менә, сиңа ике матур тастымалны салдым,—ди.

— Ә үзегезгә нәрсә калды соң?—дим.

— Безгә, монда тора торган кешегә, начар булса да ярар дип, теге кызыл башлы сөлгене генә калдырдым, ди. Сиңа, ди, юлга, чит кешеләр арасында йөргәндә, матуррак булсын дип, теге челтәр башлы сөлгене дә куйдым,—ди. Шуннан соң, эчке киемнәрне санап алып китте:

— Юлга өч күлмәгең булды, ике сөлге, өч ыштан, өч кул явлыгы, аннан бер чынаяк салфеткасы.

Аның бу сүзләрне ихлас белән әйтүен һәм үзләренә бер генә тастымал алып калуын белгәч, минем күңлем йомшап китте. Әйберләр күп булмаса да, ярарлык булды дидек тә бик яхшылап чәй эчәргә утырдык. Чит илләрне күрергә ашкыну—күздән йокыны качырган иде. Мине озатырга булгач, Зөһрә дә йокы уйлау онытты. Без хәзер юлны һәм өйдәге мәсьәләләрне сөйләшә идек. Балалар бик матур тын гына йоклыйлар иде. Бу вакытта безнең өйдә матур бер мәхәббәт балкый, шуның белән бергә, бераз вакытка булса да, аерылышу моңы чыңлый иде.

Әзрәк булса да, истирахәт[1] итәргә кирәк дип сөйләшкәндә, таң әтәчләре кычкыралар иде инде.

II

Иртән көн матур иде. Май кояшы, без торуга тәрәзәдән карап, безнең өй эченә матур нурларын сибә иде. Бүген Әнвәр белән Халит тә көндәгедән иртәрәк уяндылар. Мин, аларның аркасыннан сөеп, битләреннән үбеп, Кырымнан матур тәтиләр алып кайтырга вагдә бирә идем.

---

[1] Әсбаб—нәрсәләр, кирәк-ярак әйберләр.
[1] Истирахәт—ял итү.

Әнвәр минем байтак вакытлар йөриячәгемне белсә дә, Халит белми иде. Ул иртән эшкә китеп төш аугач кайтуымны гына белгәнгә күрә, бу юлы да шулай тиз кайта дип уйлый иде. Шуның әчен, мин вагдә иткән нәрсәләрне төш ауу белән көтә һәм артыгы белән шатланып, алдымнан төшми иде. Шушы сүзләр, балаларның шатлыклары астында чәй янында күпме утырганыбызны белми дә калдык... Иптәш ат белән килеп тә җитте. Ул килү белән өйдә ашыгыч хәрәкәтләр башланды, Зөһрә әйберләрне алып чыга башлады. Мин Әнвәр белән Халитнең аркаларыннан сөеп, маңлайларыннан үбеп, аерылышу минутларында була торган бер моң белән, кулларын кулыма алып кыса башладым.

— Әйдә, тизрәк, соңга калабыз!—дигән тавышлар булмаса, мин һаман аларны сөюдә дәвам итәчәк идем. Тагы бер мәртәбә үптем, тагы бер рәт сөйдем дә, арбага менеп утырдым. Бу минутларда шатлык белән моң бергә катышкан иде. Бу минутларда магсум күңелләрнең эчләрендәге саф мәхәббәт кайнашып күз аркылы тышка чыгарга тели иде. Бу минутларда берсе берсен сөйгән калепләрнең эчләрендәге моңнар нәрсәдер җырлыйлар иде.

Без киттек.

Чаттан борылганча артка карап бардым. Бу вакытта магсум балалар безгә карап нидер селкәләр иде. Иң соңгы мәртәбә башымны селектем. Бу вакытта күземдә яшь иде.

III

Без вокзалга төшкәндә, кайбер иптәшләр алдан төшеп билет алу чараларына керешкәннәр иде. Без төшеп бераз гына торгач, тагын бераз иптәшләр озатырга төштеләр. Вокзалда артык галәбәлек[1] булмаса да, китәргә хәзерләнгән яки кайда барырга белми юлда туктап калган ачлар, гариплар байтак күп күренәләр иде. Минем күңлем китү, чит җирләрне күрү арзусы белән тулы булу өстенә, шушы ачларның аяныч хәлләрен күреп, шуларны кызгану белән дә мәшгул булганга күрә, озатырга төшүче иптәшләрнең күңелләрен күтәрерлек төрле сүзләр табудан гаҗиз идем. Шулай да иптәшләр озату чәен күңелсез үткәрмәделәр: төрле сүзләр табып, мәҗелесне матурлап, аерылышу сәгатләрен шатлык белән тутырдылар.

[1] Галәбәлек—тыгынлык.

— Поезд килә!..—диләр.

Бу сүз китүче һәм озатучыларны бердән кузгатты. Һәр кем эчә торган чынаягын куеп, нәрсәсенә барып тотынды. Һәр кешедә бер үзгәреш һәм җиддият туды. Һәр кем сүзен аерылышуга таба борып, сүзләренең иң мөһимнәрен генә сайлап сөйли башлады. Әнә бер хатын, иренең каршысында күзен яшьләндереп, моңлана һәм еларга керешә. Ире аңар каршы, бик чын рәвештә, тынычлык белән җавап бирә башлады. Кайберәүләр, нәрсәләрендер югалткан кебек, артык ашыгычлык күрсәтерегә керештеләр. Кайдадыр бер бала еларга кереште. Анда «әкрен-әкрен!..»—дигән тавышлар чыкты. Монда берәү,—«Әй ходаем! Билет алып утырып китеп булса гына ярар иде»,—дип сызлана башлады.

— Ул кая китте соң?

— Урын таптыгызмы?

— Нәрсәләр кайда?

— Ничә урын?..—дигән сөальләр белән дөнья тулды.

ЧИРЛЕ ВАКЫТТА

(Көндәлек дәфтәреннән)

Бүген өченче көн инде, мин, эшкә бара алмый, бик каты чирләп ятам. Кышның моңарчы булган салкыннарына бирешми түзеп килгән кара бишмәтем, гыйнвар суыклары башлану белән бераз сер биреп ташлады булса кирәк, салкын тидердем... Башта бизгәк сыман бер нәрсә хафалаган иде, хәзер бөтен чир тамакка күчте: ашап та, эчеп тә, вакыт-вакыт, хәтта, төкерек йотып та булмый, авырта...

Бөтен дөньяң энергия белән, эшкә, хезмәткә дәрт белән, мәхәббәт белән тулып торган бер вакытта чирләп яту... харап икән ул: әйтерсең аның көннәре көннәр генә түгел, берничә көн һәм айлар бергә кушылып, бер ел тәшкил итәләр. Ятып та карыйсың, торып та, утырып та карыйсың—берсе дә файда бирми, көн туса, кич булмый, төнгә керсәң, таң аттыра алмый җаның чыга...

Шундый вакытларда иң файдалы эш уку булыр иде. Чирле вакытта ул ләкин укып та булмый икән: күзләрнең хәле бетә; берничә юл уку белән алдагы хәрефләрнең һәммәсе бергә катнаша, бутка хасил була, бер хәреф биш

булып, ун булып күренә башлый... Кроватьта ятып торуны аны сөйләргә дә ярамый инде, мин үзем, покранимер, тәнем иң актык мәртәбә суына башлап, аякларым мәңгегә хәрәкәттән туктамый торып, ул эшкә риза булып калу ихтималым юк... Шулай булгач, ни эшләргә?!

Менә шушындый вакытларда минем, яхшымы, яманмы, электән үк калган бер гадәтем бар: янымда бала-чага булса, чир кулына кереп бетми калган барлык хәлемне җыеп кулга алам да, шулар белән шаярырга керешәм. Вакыйгдә мин бу «уен»ны сәламәт вакытта да яратам: әмма соң чирле вакытта инде... Чирле вакытта аның биргән ләззәтен, рәхәтен, мин сөйләп тә, язып та, аңлата алмыйм. (Чирле вакытта дигәч тә, һәрбер чир вактында дигән сүз түгел, әлбәттә, балаларга йогу ихтималы булмаган чирләр вактында гына шулай).

Бу юлы да, чирле тән эчендә калып ярсыган йөрәкне басар өчен бердәнбер чара итеп, мин шул эшемне ходка җибәрдем. Бәхеткә каршы, өй тулы бала. Үзебез без, барыбыз да яшьләр булып, кайсыбыз бөтенләй хатынсыз, баласыз, кайсыбыз хатынлы-балалы булсак та, балалар безнең әле бик яшь булуына да карамастан, нәслебездә булган барлык ятим-җилби безнең тирәгә җыелганга, өйдәге «уен» га катнашырлык балаларның барсын бергә кушканда, бер уннан артыграк сан тәшкил итәләр. Ул яктан, ягни бала юклыктан, эш ярты юлда туктап калырлык түгел иде.

Кичәгенәк шулар белән җенләнеп чыктык. «Уен» ярты сәгатьләргә сузылгандыр; соңга таба шул чаклы кызып китте, алар, минем чирле икәнемне бөтенләй оныттылар булса кирәк, берничә тапкыр идәнгә җыгып чәчләремне тарткаладылар. Алар түгел, хәтта үзем дә үземнең чирле икәнемне онытканмын; артык аякка басып тора алмаслык дәрәҗәгә җитеп, кроватька килеп егылгач кына чирлелегем исемә төште... Тәннәрем тагы кыза, кайнар тәнемнән ниндидер салкын тирләр бәркелеп чыга башлады...

Балалар да тынды, минем кроватымны әйләнеп, тавышсыз-тынсыз гына миңа карап тора башладылар.

Берничә минуттан соң, миңа тагы азрак хәл кергән төсле булды; башымны калкыта төшеп балаларга карадым:

— Нихәл, егетләр, туташлар... әле сез һаман мондамыни?..

Балалар, бер-берсенә карап, җылмаешып куйдылар...

Балалар арасында, яңа гына авылдан килгән, Әхкәметдин исемле бер ятим бар иде. Өйдә балалар гына калганда, аның һәр вакыт җырлап йөргәнен сөйлиләр иде. Хәзер дә, әллә нишләп, минем башка шуны җырлату уе килеп төште:

— Хәзер, мин әйтәм, Әхкәметдин туган, син бер җырлап җибәр инде,—дидем.

Бала тартына; иптәшләренә карап, оят катыш җылмая. Кемдер, аның җиңеннән тартып, колагына нәрсәдер әйтә, аз гына тынлыктан соң, бала кычкырып җырлап та җибәрә:

Абзыкаем, син үзең, кашыңнан кара күзең,
Энҗе кебек тешләреңнән сайланып чыга сүзең.

. . . .

Буржуй кар көрәргә чыккан кулында юк көрәге,
Җитмеш буржуйны куркыта бер коммунист йөрәге.

Биек тауның башында, автомобиль машина,
Коммунистны шуннан таныйм, чәче төшкән кашына.
. . . .

ЭЧТӘЛЕК

Бит

М. Гафури әсәрләре (Х. Хәйри) 3

ШИГЫРЬЛӘР

I

1909.
... гә багышлап 10
Бакчада . . . . —
Вафасыз гашыйк 11
1913.
Көзнең соңы 12
Авырлык, ярлылык кай җирдә булса . . . . —
Уфа сахралары . . . . —
1917.
Юл 13
Кешеләр берсе-берсен яманлаша 14
Гомернең чәчкәсе сулды . . . . —
Саз . . . . —
1919.
Көтмәгәндә 15
Имла (... гә) . . . . —
Күлдә 16
Барчасыннан син матур . . . . —
Яңа танышым . . . . —
Гаҗәп эш 17
Мин . . . . —
Шәүләсе 18
„Ул“ . . . . —
Бер гашыйкның сүзләре . . . . —
Чәче 19
Сулган чәчкә . . . . —
1921.
Картайдыра дөнья 21
Шатлык белән хәсрәт . . . . —
1922.
Гомрем бинасына менеп барам . . . . —
1923.
Кырым, Кырым диләр иде 22
1926.
Адашкан . . . . —
Нигә кирәк иде 23

Китапханә

бит

1927.

Сукырлар 23

Үзбәкстан сәнагь нафисәсенең беренче карлыгачларына. 25

1929.

Ленин иптәш... дисәм . . . . —

Тарихи ун ел . . . . —

Бак урамга 26

II

Кешеләр 27

Мәжелес . . . . —

„Ул“ . . . . —

Алга омтылдым 28

Кырдагы чәчәкләр . . . . —

Энә белән епь . . . . —

Чын бәхетләр эзләп йөрүчегә 29

Өметләр булдылар да беттеләр дә . . . . —

Һәр минутта 30

Юк, кирәкми . . . . —

Этнең кешеләрне саклау өчен . . . . —

Сөт җебек ак . . . . —

Ялкынланып яндым 31

Тын алып булмый . . . . —

Шайтан алгыры . . . . —

Бер ягым тау . . . . —

Юеш, болытлы көн 32

Беләбез без! 33

Ах, кыен . . . . —

Юлдан (Туган җиргә) . . . . —

Алтын затын 34

Яратамын . . . . —

Рәнжемә 35

Чәйнәп ташлар идем патшаларын . . . . —

Чәчү беткәч 36

Дусларга... һәммәсенә . . . . —

Яз! 37

Мин Мәскәүгә бардым 38

„Өзлексез эш атнасына күчү“ . . . . —

Сынау көне . . . . —

Һәр кайда да 39

Дингез янында . . . . —

Бүген 40

Бал корты һәм кигәвен . . . . —

Урак урганда 41

Ленинизм минем маягым 42

Парчалар 43

Ялгыз тора-тора . . . . —

Утыз ел . . . . —

Укыйм җай чагында . . . . —

Бер адым алга басам да 44

„Үткән бишьеллыкның уңышлары“ . . . . —

Без электән дә урак урган 44

Шатланам мин . . . . —

бит

Эшләр яхшы 44
Дөньяның бар жиреннән монда матур 45
Көтмичә . . . . —
Шатлык кадерледер . . . . —
Үзем бармын . . . . —
Егет тә генә кеше . . . . —
Әгәр дә мин . . . . —
Елы кояш . . . . —
Һәр кеше 46
Эш эшләп . . . . —
Түбәнчелек итсәң . . . . —
Юлаучылар . . . . —
Мөмкин булса . . . . —
Ни магнәсе бар соң 47
Ник кылычтан курыксын . . . . —
Күнел йөзә . . . . —
Күзләреңнән . . . . —
Кай вакытта . . . . —
Яз житәр . . . . —
Эч пошып китә 48
Сөеклем . . . . —
Күк йөзендә . . . . —
Уйлап-уйлап торып хәйрән калам . . . . —
Чәчәкләр бәйләмен тоткан . . . . —
Чәчәк ул . . . . —
Син миңа рәсменне бирмә 49
Елмаеп . . . . —
Уңайсызлык килә дә ул, китә дә ул . . . . —
Төнгә каршы туган айдай . . . . —

III

Җәннәт көткәндә (поэма) 50

ХИКӘЯЛӘР, ОЧЕРКЛАР

Серле бер мәхәббәтнең тарихы 71
Хокуксызлар 104
Үз башына үзе житте 122
Ул бу эшләрнең буласын алдан белгән иде 128
Гармон тавышы 129
Дәртле егетләр 133
Дингез артында (көйле фельетон) 136
Октябрь революциясенең таңында 139
Йөзгә-йөз каршы килгәндә 143
Денщик Мәхмүт 148
Без аларның йөзләреннән беләбез 152
Урал таулары арасында 156

ИСТӘЛЕКЛӘР

Тәржемәи хәлем 158
Баштан үткәннәр 254
Бишенче ел революциясе хакында. Истә калганнар . 274
Габдулла Тукай Уфада 279
Хәзерлек 283
Чирле вакытта (көндәлек дәфтәреннән) 286

Мазит Гафури
ПРОИЗВЕДЕНИЯ
(на тат. языке)

Җаваплы редакторы Г. РАЗИН

Басарга кул куелды 29/X-1940 ел. Тиражы 6075. Басма табак 18¼. Табакта 54400 хәреф. Авт. табак 14,88. Заказ № 099. ПФ 1716. Бәясе 5 сум 65 тиен. Төпләү 50 тиен. Коленкорлы төпләү 1 сум 50 тиен.

Басылды Татарстан АССР ҖПХК каршындагы Татполиграф типографиясендә. Казан, Миславский урамы 9. 1941 ел.

07 СЕН 2016

Бәясе 6 сум 15 тиен